# ФӘНГӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

Нурмөхәммәт һәм Фәһимә
Хисамовларның 80 яшьлегенә

Казан
2017

**УДК 929(082)**
**ББК 81.2 Тат:83.3(2Рос=Тат)гя43**
**Ф 94**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

Филология фәннәре докторы, профессор,
Халыкара төрки академиянең хакыйкый әгъзасы,
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы
***Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Хисамовның***
һәм филология фәннәре докторы, профессор
***Фәһимә Миргали кызы Хисамованың***
80 яшьлек юбилейлары уңаеннан

**Төзүче һәм җаваплы мөхәррир –** Эльвира Сафина

**Ф 94 Фәнгә багышланган гомер:** Нурмөхәммәт һәм Фәһимә Хисамовларның 80 яшьлегенә / төзүче һәм җаваплы мөхәррир – Э.И. Сафина. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – 304 б.
ISBN 978-5-93091-215-9

Әлеге китап филология фәннәре докторлары Нурмөхәммәт Шаһвәли улы һәм Фәһимә Миргали кызы Хисамовларның гыйльми эшчәнлеген, фән өлкәсендә ирешкән уңышларын һәм милләткә хезмәт белән гаилә тормышыннан оста итеп үрелгән гомер юлларын күз алдына китерергә ярдәм итәр.

**ISBN 978-5-93091-215-9**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2017

# ХӘТЕР САГЫНДА

Борынгылар: «Гыйлем – дәрәҗәләрнең иң олысы», – дип юкка гына әйтмәгәндер, мөгаен. Бүген дә бит без кемнең дә булса укымышлылыгына сокланып: «Һай, нинди галим кеше!» – дип тел шартлатабыз. Кем дә булса, әрсезләнеп, нигезсез рәвештә әлеге исемне дәгъвалый башласа: «И-и, аның галимлеге инде», – дип, ерак гасырлардан килгән бәяне биреп, мөһер сугып куябыз. Әйе, кешегә галимлек дәрәҗәсен халык үзе бирә, аның олылыгы халык тарафыннан бәяләнә. Әнә шундый бәхеткә ирешкән гыйлем ияләребез арасында, һичшиксез, инде ярты гасырдан артык иңнәрен-иңгә куеп, ихлас ниятләр белән татар фәненә хезмәт иткән Нурмөхәммәт ага белән Фәһимә апа Хисамовлар да бар.

Ни хикмәт, әлеге ике могтәбәр затның эшчәнлеген күз алдына китерим дисәң, уйлар-фикерләр үзеннән-үзе ерак гасырларга – фәннең чишмә башына алып китә. Бу табигый дә: аларның икесенең дә гыйльми эшчәнлеге әдәбият һәм тел тарихыбызны тулаем иңләп ала, татар фәнендәге үткән белән киләчәкне тоташтыра торган мөһим күперләребезнең берсе булып тора.

Мәгълүм ки, халкыбызда тупланган белемнәрне системага салырга омтылу Идел буе Болгарында ук башланган. Әйтик, шул чордан тарих, дин, әхлак, география, математика, астрономия, химия, медицинадан хезмәтләрнең барлыгы билгеле. Алга таба да, милләт язмышында нинди генә катлаулы чорлар булмасын, фән белән кызыксыну кимеми, һәр дәвердә зыялылыгы, укымышлылыгы белән данлыклы ата-бабаларыбыз чылбыры саклана килә.

XIX гасырның икенче яртысыннан башлап татар галимнәре фән дөньясының ишекләрен киңрәк ачып керә, берсен-берсе алмаштырып килгән төрле буын вәкилләре фәннең һәр тармагында җиң сызганып эшкә керешә. Иң әүвәл үз мәктәпләрен булдырырдай абруйлы затларга әверелгән Ибраһимовларны, Хәлфиннәрне, Ш. Мәрҗанине, К. Насыйрины искә алырга кирәк! Алар салып калдырган сукмаклардан яшь буын татар галимнәре олы юлга чыга. XX гасырның 20–30 нчы елларында көчле буын хасил иткән Г. Әхмәров, Җ. Вәлиди, Г. Гобәйдуллин, Г. Ибраһимов, Г. Рәхим, Г. Шәрәф, Г. Нигъмәти, Г. Алпаров, Х. Мөштәри, Г. Камай һ.б.лар фәнни алгарышка үзләреннән сизелерлек өлеш кертә. Шушы буын тәрбиясендә үскән Х. Ярми, М. Гайнуллин, Л. Җәләй, Х. Госман, И. Нуруллин, Г. Халит кебек галимнәребез, үзләренең фәнни эшчәнлекләрен алып бару белән беррәттән, югары уку йортларында мөгаллимлек тә итәләр. Шуның нәтиҗәсе буларак татар галимнәренннән ныклы бер буын үсеп чыкты. Бүген инде ул исемнәр дөнья күләмендә билгеле: Д. Тумашева, Н. Юзиев, М. Зәкиев, В. Хаков, Р. Сәгъдиев, К. Вәлиев, Р. Сюнәев… Нурмөхәммәт ага белән Фәһимә апа да, һичшиксез, шушы буынның лаеклы вәкилләре.

Шунысы үзенчәлекле: инсани фәннәр өлкәсендә хезмәт куйган галимнәребез башка тармаклардагы укымышлыларыбызга караганда киң җәмәгатьчелеккә күбрәк билгеле, алар халыкка, халык рухына якынрак, күрәсең. Аларның исемнәре халык хәтереннән җуелмый, яңа буын аларның хезмәтләренә кайта-кайта мөрәҗәгать итә. Әлеге күренешнең бер сәбәбе – әлбәттә, әдәбиятыбызның меңеллык тарихка ия булуы, дөньякүләм мөһим җәүһәрләребезнең байлыгы. Икенче сәбәбе, тагын да әһәмиятлерәге, әлеге төркем галимнәребезнең гыйльми эшчәнлекләрен, гомерләрен милләтебезнең хәтер сагында торуга багышлавына барып тоташа. Шанлы да, фаҗигале дә язмыш кичергән бай тарихлы халкыбыз шушы юнәлештәге галимнәрне милләт уллары, милләт кызлары буларак кабул итә һәм хөрмәтли.

Әнә шул милли идея, милләтпәрвәрлек хисе алтмышынчы еллардан башлап татар фәненең үзәген тәшкил иткән галимнәребез өчен яшәү мәгънәсенә әверелде. Алар арасында фәнгә гаиләләре белән хезмәт итәргә алынучыларның артуы аеруча үзенчәлекле

күренеш булып тора. Хәтерлим әле, Казан университетында укыган олы абый белән апам әнә шулай парлашып фәнни эш алып барган гаиләләр турында хөрмәт белән сөйли иде. Казан университеты доценты Алмазия Хаҗи кызы Нуриеваның ул заманда сөйләм телендә «филиал» дип йөртелгән Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәре Фазыл Салих улы Фасиев белән гыйльми эшчәнлекне дә, гаилә тормышын да бергә көйле итеп үреп барулары миңа үзем университетка укырга кергәнче үк мәгълүм иде. Инде студент булгач, мөлаемлылыгы, чибәрлеге һәм шул ук вакытта таләпчәнлеге белән аерылып торган укытучыбыз Фәһимә Миргали кызының җәмәгатен – шулай ук галим, Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәре Нурмөхәммәт Хисамовны күрептаный башладым. Баксаң, диплом эшемнең җитәкчесе Резеда Кадыйр кызының ире дә галим, шул ук «филиал»да эшли торган әдәбиятчы-текстолог Зөфәр Рәмиев икән! Атап үтелгән гаиләләр татар фәне үсешенә үзләреннән зур өлеш кертте. Мөгаен, төрле юнәлештә тикшеренүләр алып барган, шул ук вакытта берсен-берсе тулыландырган гаилә әгъзаларының фикерләшеп, җылы атмосфера тудырып яшәве моңа төп сәбәпче булып торадыр. Яңа буын галимнәрдән дә парлашып фәнгә хезмәт итә торган гаиләләр байтак. Алар арасында тарихчы Илдус Котдус Заһидуллин һәм әдәбият галимәсе Дания Фатих кызы Заһидуллина, филология фәннәре докторлары Рәүф Салих улы Нуриев һәм Фәнүзә Шәкүр кызы Нуриева гаиләләре бар.

Инде ярты гасырдан артык татар фәнен үстерүгә парлашып көч куйган Нурмөхәммәт ага белән Фәһимә апаны мин бер-берсен тулыландырып, бер-берсен һәрдаим баетып, рухландырып яши торган бербөтен итеп кабул итәм. Галим-голәма арасында легендага әверелгән бу гаилә, чыннан да, барыбыз өчен дә үрнәк булырлык.

Нурмөхәммәт аганы без барыбыз да әдәбиятчы, алай гына да түгел, мең еллык тарихы булган әдәбиятыбыз тарихының һәр чорын иңләп алган киң колачлы бик сирәк уникаль галимнәребезнең берсе дип беләбез. «Колач һәм тирәнлек» дип аталган мәкаләсендә галим һәм язучы Мөдәррис Вәлиев бу хакта: «Нурмөхәммәт Хисамов нинди үзенчәлек белән аерылып тора соң? Татар әдәбияты тарихының мөһим өч дәвере хакында да бердәй тирәнлектә фикер

йөртүе белән, минемчә», – дип яза. Әйе, ничәмә-ничә гасырлар халкыбызны тәрбияләп килгән Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрен тикшерү, Дәрдемәнд, Тукай, Сәгыйть Рәмиев кебек иң югары биеклектәге шагыйрьләребез иҗатын бәяләү өчен үзең дә шәхес һәм шагыйрь булу кирәк.

Нурмөхәммәт ага исә фән белән иҗат дөньясын бергә тоташтырып, гармониядә яши. Ул бүген татар матбугатын даими күзәтеп бара, игътибарга лаеклы һәр әсәрне укый, фикерен белдерә, күңеленә хуш килсә – матур сүзләрен жәлләми, иҗат кешесенә канатлар куя белә. Еш кына Нурмөхәммәт аганың нарат агачыдай төз, мәһабәт гәүдәсен беркадәр ия төшеп, башын чайкап кәефсезрәк йөренүенә тап буласың да, берәр борчуы бармы икән эллә дип, пошаманга төшәсең. Чыннан да, бар икән шул хәлләр: кайсыдыр газетадагы бер авторның мәкаләсендә тел-стиль ягыннан хилафлык киткән, агабызның шуңа борчылып, үзен-үзе кая куярга белми йөренүе икән! Әдәбиятчы галимнең әнә шулай тел үзенчәлекләрен дә биш бармагыдай белүенә сокланасың да, тел өлкәсендәге абруйлы галимә Фәһимә апа белән бер-берсен тулылындырып, мәгънәле тормыш кичерүенә кабаттан инанасың. Мәкаләндәге хатаны тапкан, җитешсезлекне күргән Нурмөхәммәт ага белән бәхәсләшүнең урынсыз бер эш икәнлеген барыбыз да беләбез, чөнки аның имән бармагын өскә каратып, ышанычлы, ныклы тавыш белән: «Фәһимә апагыз әйтте!» – диюе мәсьәләне яба да куя.

Нурмөхәммәт аганың әлеге дәлиле, чыннан да, бәхәскә урын калдырмый. Фәһимә апа – тел белеме өлкәсендәге үзенчәлекле, универсаль шәхесләрнең берсе. Тел тарихын, аның барлык юнәлешләрен, бүгенге хасиятен өйрәнүгә багышлап, ул чын мәгънәсендә үз мәктәбен булдырды, аның «Татар теленең тарихи грамматикасы. Фонетика. Морфология» фундаменталь хезмәте, һичшиксез, киләчәк буын тел галимнәренең өстәл китабы булып хезмәт итәчәк.

Хисамовлар гаиләсен ягымлылык, мәһабәтлелек кебек сыйфатлар да берләштерә. Хәтерлим әле, сиксәненче елларда Казан университетында белем алганда, укытучыбыз Фәһимә апаның табигый, эчке матурлыгын чагылдырган мөлаемлылыгы безне – авылдан килгән егет-кызларны аеруча сокландыра иде. Гомере буе

энә шул табигый матурлыгын җуймыйча, елмаюын кызганмыйча, шәкертләрен рухландырып яши ул.

Нурмөхәммәт ага институт директоры булганда да, бүген дә дәрәҗәле утырышларда, киңәшмәләрдә һәрвакыт теләп катнаша. Ул анда төпле, акыллы фикерләре белән, сөйләү осталыгы һәм эрудициясе белән генә түгел, ә үзенең мәгърур, чибәр, олпат кыяфәте белән дә кунакларда татарга карата хөрмәт һәм соклану хисләре уята. Бу хакта Роберт Миңнуллинның аңа багышланган шаян шигырь юлларыннан да арттырып әйтеп булмас:

...Нурмөхәммәт Хисамовка
Барсын да биргән Ходай.
Ул бүген безнең арада
Иң чибәр татар бугай.
Татар менә шундый диеп,
Шаккаттырып дөньяны,
Экспонат итеп кенә
Йөртер идем мин аны...

Әйе, әлеге икәүнең гыйльми эшчәнлеге, яшәү рәвеше инсани фәннәребезгә нигез салган мөхтәрәм шәхесләребезнекенә аваздаш. Гомерен татар телен өйрәнүгә, тикшерүгә багышлаган Фәһимә апа ана телебез сагында торучы булса, Нурмөхәммәт ага, һичшиксез, тарихыбызны, яшәешебезне, милли үзенчәлекләребезне чагылдырган әдәбиятыбызны яклаучыларның, саклаучыларның берсе. Әлеге максатын ул әдәби-фәнни мәкаләләрне, иҗат портретларын һәм публицистик әсәрләрне туплаган «Хәтер сагында» исемле китабында ачык белдерә. «Хәтер сагы дигәндә, без мирасыбызны тулырак барлап, аны халыкка кайтарып тапшыруны, җәмгыять, ил тарихының мөһим вакыйга һәм күренешләрен төгәл яктыртуны, халкыбызның иҗтимагый һәм мәдәни тарихын тулы, объектив һәм гадел бәяләүне күздә тоткан кебек, әдәбият һәм сәнгать, сәясәт һәм фән өлкәсендә якты эз калдырган бөек шәхесләребезне тәкъдир итү хакында да фикер йөртәбез», – дип яза Нурмөхәммәт ага.

Бер-берсен тулыландырып, нәтиҗәле фәнни гомер кичергән мөхтәрәм галимнәребез безнең өчен хөрмәтле дә, кадерле дә шәхесләр. «Татар зыялылары нинди була?» – дигән сорау бирсәләр, мин һич тә икеләнмичә: «Татар зыялылары Фәһимә апа

белән Нурмөхәммәт абый кебек булырга тиеш!» – дип жавап бирер идем. Чыннан да, алар фәндә дә, тормышта да, бер-беребезгә булган мөнәсәбәтләрдә дә, барыбыз өчен дә үрнәк! Алар татар фәнендәге иң күренекле затларыбызның дәвамчылары гына түгел, үзләреннән соң шәкертләр – хәтер сагында торучыларның яңа буынын әзерләгән шәхесләр дә. Әнә шундый ихлас галимнәребез булганда, хәтеребез уяу торыр, милләтебез яшәр әле!

Минем сүзләремне әлеге басмада урын алган язмалар да куәтләп тора. Г. Ахунов, К. Вәлиев, Х. Якупов, И. Таһиров, Р. Харис, Ф. Галимуллин кебек олуг шәхесләребезнең, хезмәттәшләренең, фикердәшләренең саллы-саллы фикерләре хөрмәтле юбилярларыбызның олылыгын, аларның ил алдындагы, милләт алдындагы хезмәтләренең кыйммәтен, үзләренең халкыбызга кирәклекләрен кат-кат раслыйлар.

*К.М. Миңнуллин,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты директоры,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең*
*мөхбир әгъзасы*



*«Сез болгар-татар әдәбиятының чишмә башында торган, урта гасыр шигъриятенең данлыклы ядкәре – Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф”ка киң колачлы, җентекле тарихи-әдәби анализ ясап, төрки әдәбиятлардагы төрдәшләре белән чагыштырып, комплекслы өйрәнеп, фән дөньясында үзегезне олпат галим итеп таныттыгыз».*

Минтимер Шәймиев

*«Шагыйрь Нурмөхәммәт Хисамов әсәрләрендә галимлек чалымнары булу, шагыйрәнә хис белән олы тәҗрибәле акылның гел янәшә торуы – шулай ук аның иҗатының үзенчәлеген тәшкил итәдер. Аның яшәешенең, аның шәхесенең, аның иҗатының бер канаты – шигърият булса, икенчесе – фән, гыйльмияттер. Ә күккә – биеккә менү өчен кошларга ике канат кирәк».*

Разил Вәлиев

*«Татарның беренче бөек әсәре саналган “Кыйссаи Йосыф” поэмасын өйрәнүгә аеруча күп көч куйды Нурмөхәммәт ага. Бу әсәр аның җанында, язмышында. Нинди генә хезмәткә тотынса да, ул шушы бөек әсәрдән башлап китә һәм шушы әсәрне телгә алып тәмамлый торган булды».*

Галимҗан Гыйльманов

# НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВ ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ

## БӨЕК ЭЛГӘРЛӘР ИЛЧЕСЕ

Мондый олы исем белән аталуга лаеклы галимнәребез, шөкер, байтак булды. Мөхәммәт Гайнуллин, Нәкый Исәнбәт, Хатип Госман, Гали Халит, Әбрар Кәримуллин, Ибраһим Нуруллин, Нил Юзиев, Хәмит Ярми, Шакир Абилов кебекләрнең шәхесләре һәм хезмәтләре бары тик шулай гына бәяләнә ала. Бүген исән-сау галимнәребез арасында да, бәхетебезгә, байтак андыйлар. Шуларның берсе, һичшиксез, Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Хисамов. Соңгы унъеллыкларда аны шундый затлылар арасында карау омтылышы ныгыганнан ныгый гына бара. Матбугатта да бу хактагы фикерләр күренә тора.

Моннан бер айлар элек кулыма «Звезда Поволжья» газетасының узган елгы 45 нче (3–9 декабрь) саны килеп керде. Анда татарның күренекле галиме Камил Әхмәт улы Вәлиев исеме күзгә чалынды. Бу шәхес Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты вәкилләре өчен аеруча якын. Ник дигәндә, ул олы фән юлына беренче, әмма ныклы адымнарны шушында ясады. 1956–1963 елларда, биредә эшләп, ул парамагнит резонансы буенча тикшеренүләр алып барды, физика кафедрасына җитәкчелек итте. Докторлык диссертациясе яклагач, аны Мәскәүгә – академик институт директоры итеп алдылар. Тора-бара К.Ә. Вәлиев СССРның Ленин исемендәге һәм Россия Федерациясенең Дәүләт премияләренә дә лаек булды. Ул – Россия Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы. Мин дә аны, бик күпләр кебек, хөрмәт итәм. Моннан бер-ике ел элек Казанда татар галимнәренең Бөтендөнья форумы булган

иде. Шунда, нигездә, ике галим – Рәшит Сюняев һәм Камил Вәлиевләр, аларның дөнья фәненә керткән өлешләре турында сөйләшү алгы планга килеп чыккан иде. Халкыбызның затлылыгын бөтен Җир шарына таныткан галимнәр!

К.Ә. Вәлиевнең җәмәгате Венера ханым да халкыбызга билгеле зат. Бөек Тукаебызның 120 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә ул, шагыйрь әсәрләреннән үз тәрҗемәсендә русча китап чыгарып, әдәби-фәнни җәмәгатьчелекне таң калдырган иде. Ник дигәндә, Г. Тукайны рус телендә яңгырату буенча байтак эшләнсә дә, әле бу җәһәттән хәл ителәсе бурычлар һаман да кала бирә. В. Думаева-Вәлиева тәрҗемәнең уңышлы үрнәкләрен бирүгә ирешкән. Аның иҗади хезмәте нәтиҗәсендә бөек шагыйребез рус телендә укучыларга тагын да якыная төште.

Хуш, сүзебез К.Ә. Вәлиев мәкаләсе хакында. Ул анда үзе өчен бик үк гадәти булмаган катлам – әдәби-рухи байлыгыбыз хакында уйлана һәм, әйтергә кирәк, бу юнәлештә дә гаҗәеп тирән фикер йөртә. Тагын да төгәлрәк әйтсәк, Татарстан Республикасының Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителгән әдәбият галиме Нурмөхәммәт Хисамовның күпьеллык фәнни хезмәтләрен күздән кичерә, алар турында гомумиләштерелгән сүз әйтә. Галимне ул энциклопедик белемле шәхес дип атый. «Аның хезмәтләрендә, – ди академик К.Ә. Вәлиев, – татар әдәбиятының меңьеллык тарихы төрки һәм гарәп ислам әдәбиятларының состав өлеше итеп карала». Бу чыннан да шулай. Әгәр каләмдәшебез Н.Ш. Хисамовның гарәп, фарсы һәм төрки әдәбиятларның күп гасырлык контексты белән эш итүен искә алсак, биредә энциклопедик белемгә ия булмаган кеше берни дә майтара алмый.

Менә шушы мәкаләдә үткәрелгән фикерләр мине дә Н. Хисамов шәхесе һәм эшчәнлеге хакында фикер әйтергә җилкендерде. Заманыбызның әлеге затлы шәхесе, дөрестән дә, әдәби байлыгыбызны, аерым алганда, Кол Гали мирасын бөртекләп барлауга, аны дөньякүләм системада карауга, шуның ярдәмендә аның моңача билгеле булмаган күп якларын ачуга һәм билгеләүгә гаҗәеп зур хезмәт куйды. Юкка гына К.Ә. Вәлиев болай дими: «Н.Ш. Хисамов иҗатының фундаменталь өлешен К. Галинең үлемсез «Кыйссаи Йосыф» поэмасына багышланган хезмәтләре тәшкил итә» (ни кызганыч, хөрмәтле Камил Әхмәт улы, быел да Дәүләт

бүләген алучылар арасында без шушы хезмәтләрнең авторын күрә алмадык).

Әйе, урта гасыр әдәбиятыбызның бөек ядкәре, татар халкының газиз китабы – Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны хакында күренекле әдәбият галиме Нурмөхәммәт Хисамов гаять киң колачлы хезмәтләр язды. Дөресен әйткәндә, аерым бер әдәби һәйкәл уңаеннан андый зур сыйдырышлы тикшеренүнең татар әдәбият белемендә дә, тюркология күләмендә дә язылганы юк иде. Барыбызга да билгеле, узган гасырның алтмышынчы елларына кадәр Советлар илендәге төрки халыкларның тарихын, әдәби җәүһәрләрен өйрәнү, алар тирәсендә сүз алып бару, гомумән, хупланмады. «Манас», «Китабы дәдә Коркыт», «Идегәй» һәм башка дастаннарга утызынчы-кырыгынчы елларда ябыштырылган социаль-сәяси эчтәлектәге ярлыклардан килеп торган җан өшеткеч салкынлык өне үз эшен башкарды. Бары «җепшеклек чоры» гына борынгы һәм урта гасыр ядкәрләре өстенә төшкән кырпакны бераз эретә алды. Шуның нәтиҗәсендә 1963 елда «Борынгы татар әдәбияты» исемле яшел тышлы (монысы да тирән мәгънәгә ия иде) китап мәйданга килде. Анда әлеге әсәр дә бар. Бу «Кыйссаи Йосыф»-ның (бу китапта ул «Йосыф вә Зөләйха» дип бирелә) 1917 елгы вакыйгалардан соң безнең илебездә беренче тапкыр басылуы иде. Әлеге әсәрне шушы басмага әзерләүче Хисам Мөхәммәтов аның әһәмиятен мәкаләсенең беренче җөмләсендә үк билгели: «Йосыф вә Зөләйха» поэмасының татар һәм гомумән төрки телдә сөйләгән күп кенә башка халыкларның әдәби телләре һәм әдәбияты тарихын өйрәнүдә зур әһәмияте бар» (67 бит). Менә шуны күрсәтеп бирергә, фәнни яктан исбатларга кирәк иде. Әмма моны кем эшләр? Галиҗәнап Вакыт бу сөальне дә җавапсыз калдырмый – әле алтмышынчы еллар башында Казан университетында укучы Н. Хисамовны шушы миссияне үтәүгә әзерли. Шуннан соңгы ярты гасыр дәвамында әлеге ир-егет үзенә тарихи барышыбыз тарафыннан йөкләнгән вазифаны армый-талмый алып бара.

Н. Хисамов үзенең бу казанышларына бөтен аңлы гомере буена килде, дисәк, һич тә хата булмас. Аның 1979 елда Мәскәүдә «Фән» нәшриятында басылган «Поэма “Кысса-и Йусуф” Кул Али» дигән хезмәте, «Бөек язмышлы әсәр» (Казан, 1984 ел) исемле китабы һәм күп санлы мәкаләләре моны раслап тора. Бу галимебезнең

«Татар әдәбияты тарихы»ның Урта гасырлар дәвере әдәбиятына багышланган беренче томын әзерләүгә керткән өлеше дә зур булды. Аның С. Иванов тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителгән һәм 1985 елда басылып чыккан «Сказание о Йусуфе» китабын дөньяга чыгарудагы хезмәтен дә тәкъдир итү тиеш. Кереш сүз һәм комментарийлар авторы буларак, әлеге басманың фәннилек дәрәҗәсен тәэмин итүче нәкъ менә ул булды.

Бу өлкәдә аның тагын бер югары бәяләнергә тиешле иҗади эше бар: бер үк вакытта талантлы шагыйрь дә булган Н. Хисамов «Кыйссаи Йосыф»ның хәзерге телгә күчерелгән шигъри текстын әзерләде. Аны 1989 елда бастырып чыгарды. Шуның белән әлеге әсәрне укырга, аннан ләззәт алырга теләгән хәзерге укучы алдыннан тел аңлашылмавы дигән киртә алып ташланды. Ләкин моны кабул ителгән текстны (ягъни У. Имәни варианты һәм Суыксу кулъязмасы нигезендә басылган 1983 елгы текстны) гади тәрҗемә итү генә дип карап булмый. Чөнки Н. Хисамов бу «текстның буш калган, яки шигъри зәгыйфьрәк урыннарын, башка кулъязмалар ярдәмендә» тулыландырып һәм төзәтеп чыга, зур гына текстологик хезмәт башкара. Иң мөһиме – безнең ил филологиясендә беренче тапкыр буларак Дрезденнән үзе алдырган кулъязмага таянуы. Ә ул язма XVII йөзгә карый һәм иң искесе хисаплана. Бу яктан Н. Хисамовны элгәре У. Имәнинең эшен дәвам иттерүче дип әйтергә дә мөмкин.

Галимнең армас кулы аша Йосыф-Зөләйха турындагы сюжетның уннан артык төрдәше узган. Фарсы телендә (Фирдәүси һәм Җами), төрек телендә (җиде әсәр), кырымтатар, үзбәк, төркмән, көрд телләрендәге төрдәшләр чагыштырып бәяләнгән. Алардагы һәр уртаклыкка яки аерымлыкларга, сүзләрнең нинди мәгънә төсмерләре бирүләренә игътибар ителгән. Шушы бихисап эшнең нәтиҗәсе буларак, Кол Гали әсәренә генә хас үзенчәлекләр һәм сыйфатлар аерып чыгарылган.

Галимнең иң мөһим ачышы – аларның үзара бәйләнешләрен дәлилле итеп ачыклау, сюжетның беренче төрдәше – «Кыйссаи Йосыф»ның фарсы телендәге төп чыганагын – XI йөз Һират галиме Габдуллаһ Әнсаринең «Әнисел мөридин» әсәрен табып, чагыштырып тикшерү; төрек шигъриятенең төрекләрнең үзләренә дә мәгълүм булмаган күренекле ядкәре – Әхмәдинең «Йосыф вә

Зөләйха» әсәрен (XIV йөз) «Кыйссаи Йосыф», Хәмди поэмасы, үзбәк шагыйре Дүрбәк дастаны белән (XV йөз) детальле чагыштырып, тыгыз багланышын ачу, бигрәк тә Әхмәди-Дүрбәк поэмаларының табигый бәйләнешләрен исбатлау һәм иң мөһиме – Кол Гали әсәренең барлык төрки төрдәшләргә фундаменталь йогынтысын нигезле билгеләү.

«Әхмәди» дигәннән, бу үзе гыйбрәтле вакыйга булды. Шушы төрек шагыйре дастанының бердәнбер кульъязмасы ТӘҺСИ Мирасханәсендә саклана. Ул профессор Габдрахман Таһирҗанов архивы белән Ленинградтан кайтарылды. Ә Ленинград галименә Апас районының Морзалар авылы имамы Таһирҗан хәзрәттән, ягъни Габдрахман аганың әтисеннән, мирас булып калган. Нурмөхәммәт, шушы әсәрне кульъязмадан җентекле өйрәнеп, бик мөһим ачышлар ясады. Беренчедән, аны төрек шигъриятенең үсеш контекстына куеп, дастанның XIII йөз шагыйре Сули Фәкыйһ белән XV йөз шагыйре Хәмди арасындагы логик төгәл урынын билгеләде. Икенче мөһим ачышы шуннан гыйбарәт булды: галимнең күзәтүенчә, XIII йөз төрек шагыйрьләре Шәйяд Хәмзә һәм Сули Фәкыйһ Кол Галигә турыдан-туры таянсалар да, йогынты эзен яшерергә, болгар шагыйренең тарту көченнән котылырга омтылалар. Әхмәди исә үзенең элгәресе – Сули Фәкыйһкә нык таяна, әмма янәдән Кол Галигә әйләнеп кайта. Аңардагы җәенке метафора һәм эпизодларны төп-төгәл үзләштерә. Структур һәм шигъри яктан сюжетны җитди рәвештә камилләштереп, төрки шигърият үсешендә яңа баскыч хасил итә. Аңардан иң камил «Йосыф вә Зөләйха» авторы Хәмдигә кул сузымы гына кала. Өченче һәм иң сенцацион ачыш үзбәк шагыйре Дүрбәкнең киң рәвештә Әхмәди поэмасына нигезләнүен исбатлау булды. Болар төрек һәм үзбәк шигъриятен яктыртуга бәһасез өлеш булса, төрки шигъриятнең өч гасырлык үсешенә Кол Галинең өзлексез йогынтысын күрсәтү белән «Кыйссаи Йосыф»ның чыннан да дөнья әдәбиятының бөек җәүһәре икәнен раслау булды. Әсәрләрнең күбесе кульъязмада икәнлеген исәпкә алсак, гарәп язуындагы гаять күләмле шул әдәбиятны дөрес укып, бәяләп чыгу үзе генә дә зур гыйльми казаныш буларак хисаплана ала. Галим бу киң колачлы багланышлар системасын төрки шигъриятнең өч гасырлык тарихи процессын «төрки Йосыфнамә» («тюркская Йусуфиана») дип атый һәм, әйтергә кирәк, бу дөрес

тә. Болай гомумиләштереп атау галимнең хезмәтләренә дә тулаем карарга ярдәм итә.

Бу циклдагы соңгы монография «Кол Гали һәм төрки “Йосыфнамә”» дип атала да (Казан, 2006 ел). Ул хәзер Төркиядә төрек телендә басылып килә. Кол Гали әсәренең инглизчәгә тәрҗемәсе якын арада Лондонда дөнья күрәчәк. Монда Н. Хисамовның хезмәте бик җитди булды. Казан дәүләт университетының татар теле, әдәбияты һәм тарихы факультетының бу хезмәтләрне тикшерүгә багашланган гыйльми советы утырышында аларга шушы җәһәттән бик югары бәя бирелде. Саллы биш китаптан торган шушы цикл дәүләт бүләгенә тәкъдим ителде. Әлеге хезмәтләр белән танышкач, Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиев, аларның авторына махсус хат язып, болай дигән иде: «Сез болгар-татар әдәбиятының чишмә башында торган, урта гасыр шигъриятенең данлыклы ядкәре – Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ка киң колачлы, җентекле тарихи-әдәби анализ ясап, төрки әдәбиятлардагы төрдәшләре белән чагыштырып, комплекслы өйрәнеп, фән дөньясында үзегезне олпат галим итеп таныттыгыз».

Мин М.Ш. Шәймиевне бераз беләм дип уйлыйм. Чөнки язучылар берлеге белән җитәкчелек иткән елларда аның катнашында байтак мәсьәләләр хәл итәргә туры килде. Ул бервакытта да уйламыйча, үзе шуңа ихлас инанмыйча мондый олы бәя бирә торган сүзләрне әйтми. Олпат галим ди икән, бу инде чыннан да шулай. Мондый бәя үзебезнең дә тел төбендә тора иде. Әмма һаман тыйнаклык саклыйбыз, әйтеп бетермибез. Бу очракта Илбашы тагын үрнәк күрсәтте, галим эшчәнлегенең дәрәҗәсен шулай бәяләде. Нурмөхәммәт Шаһвәли улының хезмәтләре чит илләрнең һәм үзебезнең күренекле галимнәребез В.М. Гацак, И.В. Боролина, И.В. Стеблева (Мәскәү), С.Н. Иванов (Санкт-Петербург), Ф. Төркмән (Төркия), И. Фазыйлов (Үзбәкстан), Х. Мәхмүтов, Х. Миңнегулов, Р. Мостафин, Ш. Абилов, Р. Ганиева (Казан) һәм башкалар тарафыннан югары дәрәҗәдә хуплау тапты. Аеруча урта гасыр әдәбиятының күренекле галиме Хатыйп Миңнегуловның университетның татар факультеты гыйльми советында хезмәтне тирән һәм масштаблы анализлап ясаган чыгышы Н. Хисамов иҗатына лаеклы бәя иде.

Нәкъ менә шушы хезмәтләре нигезендә Россия Фәннәр академиясенең М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институтында докторлык диссертациясе яклавы да (1996) Н.Ш. Хисамов тикшеренүләренең ил кысаларын ерак атлап чыкканлыгы һәм киң яңгыраш алуы турында сөйли. Аларның соңгы өч елда ТӘҺСИнең гыйльми советы тарафыннан ике тапкыр бертавыштан дәүләт бүләгенә тәкъдим ителүе тикмәгә генә түгел иде.

*Фоат Галимуллин,*
*филология фәннәре докторы, профессор.*
*2016*

## НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВ

Ул – күпкырлы уникаль шәхес. Хисамов – тирән хисләргә бирелеп рәхәтләнеп укырдай шигырьләр, моңсуланып тыңлардай җырлар авторы. Аларның һәрбер иҗегенә генә түгел, хәтта хәрефләренә дә моң сеңгән. Шуңа күрәдер аның шигърияте җырдай агыла.

Бу талантлы шәхес – шагыйрь генә түгел, зур галим дә. Аның фәнни хезмәтләре укучыны тарих төпкеленә җиткерә, халкыбызның күп гасырлар буена барлыкка килгән әдәби мирасын, аның аркылы бөек тарихыбызны милләтебезнең үзенә кайтарып бирә. Кол Галинең «Кыссаи Йосыф»ын җентекләп тикшерүе үзе генә дә ни тора. Композитор Нәҗип Җиһанов шагыйрьнең «Йосыф-Зөләйха» шигыренә көй язды. «Йосыф-Зөләйха» җыры халык тарафыннан яратып кабул ителгәннән соң, Хисамов композиторга бу әсәр өчен үзе язган көйне пианинода уйнап күрсәтә. Алар моңы аваздаш булып чыга.

Әгәр дә мин Нурмөхәммәт Хисамовның табигый сәләтен нәкъ менә Кол Гали, аның мәшһүр әсәре кузгатып җибәргән дисәм ялгышмамдыр. Бу әсәр аның туган йортында күп мәртәбәләр яңгырамаган, аның яшьлек елларында ук күңеленә сеңмәгән булса, бәлки, романтик рухлы Хисамовтай шагыйрь барлыкка да килмәс иде. Хисамовның иҗат юлы әнә шулай малай чагыннан ук башлана. Аның «Дуслык» шигъри җыентыгында басылып чыккан шигырьләре дә әнә шул олуг кыйсса рухы белән нурланган. Бу шәхестә шагыйрь һәм галим бер ук вакытта ярала башлаганлыгын

күрү әллә ни авыр түгел. Ул нәкъ шушы кыйсса аркылы шигъри рухлы галимгә әверелгән. Кыйсса, гомумән аның авторы Кол Гали, Хисамовның гомерлек юлдашына әверелгән. Мәскәү шәһәрендә яклаган кандидатлык диссертациясе – аның фәнни эшчәнлегенең чишмә башы. Докторлыгы да аның шунда, Дөнья әдәбияты институтында яклана.

Әйе, Нурмөхәммәт Хисамов – романтик рухлы һәм нечкә күңелле шигъри җанлы кеше. Юкка гына аның иҗаты әдипләребезне барлауга, аларга тирән анализ ясауга багышланмагандыр. Аның әдәби эшчәнлеге Кол Гали, Дәрдемәнд, Тукай, Сәгыйть Рәмиев кебек әдәбиятыбызның асылташларын барлыкка китергән шәхесләргә багышланган.

Ул Совет заманында буржуаз пессимист дип бәяләнгән Дәрдемәндне өр-яңадан ачты, аның тирән фикерле философ-шагыйрь икәнлеген беренчеләрдән булып күрсәтә алды дисәм, һич кенә дә ялгышмамдыр. Аның шушы даһи затка багышланган хезмәтләре Дәрдемәнд тудырган әсәрләрне бөтен тулылыгы белән нәшер итүгә юл ачты. Чыннан да, бу эш бик кирәк иде. Чөнки ул да Совет чорында шундый ук буржуаз милләтче әдипләр исемлегендә булды. Хисамов исә аны Тукай белән мөнәсәбәтләрен күрсәтү рәвешендә анализлый. Рәмиев Тукай кебек үк моң иясе булган. Аның «Милли моңнар»ын аларның уртак иҗат җимеше дип карарга да була. «Ишеттем мин кичә берәү җырлый». Ә ул берәү – аның дусты – күрше бүлмәдә яшәүче Сәгыйть Рәмиев. Тукайның йөрәген нәкъ менә аның җырлавы тетрәтә, аны тарихыбызның һич кенә дә җиңел булмаган бормалы юлларына алып керә. Чыннан да, моңыбызга шанлы тарихыбыз сеңгән. Шул тарихның Рәмиев җырында җанлануы Тукайның искиткеч шигъри юлларын тудырган. Әйтерсең лә Тукай тик әнә шул моң артыннан гына ияреп барган. Ләкин мондый тоемлау ул бөек шагыйребез кебек гениаль шәхесләргә генә хас.

Хисамовның иң яраткан шагыйре – Габдулла Тукай. Ә Дәрдемәндне ул олуг шагыйрь буларак бәяләгән. Тукайның кайбер шигырьләре юкка гына «Дәрдемәнд» исеме белән тамгаланмагандыр.

Тукай – Нурмөхәммәт өчен үзе бер могҗиза. Ул аны гениаль шәхес рәвешендә шәрехли алган, аның иҗатына тирәнтен бәя биргән.

Нурмөхәммәт Хисамов бу ике бөек иҗатчыны чагыштыра, алар арасындагы уртаклыкларны эзли һәм таба. Аның язганнарын укыганда, Рәмиев иҗатының бүгенге көнгә кадәр рәнҗетелеп килүенә инанасың. Юк, юк шул бездә бөекләребезнең кадерен белү. Исән чакларында түгел, хәтта үлгәч тә. Тукай – Н. Хисамов өчен бөекләрдән дә бөек. Ә Рәмиев аның янәшәсендә.

Нурмөхәммәт бер ук вакытта җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Аның шушы эшчәнлеге бөтен тулылыгы белән Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли башлагач ачыла. Ул мондагы галимнәр белән һәрвакыт аңлашып, аларның яшенә дә, картына да тиешле игътибар күрсәтеп яши.

Ул бигрәк тә вакытында шушы институтның директоры булган профессор Мидхәт Кәрим улы Мөхәррәмовка рәхмәтле. Нурмөхәммәт шушы олпат галимнең кешеләргә карата ихтирамлы мөнәсәбәтен үзенә өлге рәвешендә кабул иткән. Аны Мөхәррәмов институтның партоешма җитәкчесе итеп тәкьдим итә. Алар күп еллар иңгә-иң коллективның эшен җитәклиләр.

Шушы вакытларда тупланган тәҗрибә Хисамовка үзе директор итеп билгеләнгәннән соң да бик кирәк була. Әгәр дә институт ул җитәкләгән елларда тулысы белән тату һәм аңлашып яши торган фәнни коллективка әверелде дисәм, хата булмастыр. Аның фәнни хезмәткәрләрнең эш һәм яшәү шартларын яхшырту юнәлешендәге адымнары – Мөхәррәмов башлап җибәргән эшләрнең дәвамы. Институт хезмәткәрләренә биш ел эчендә биш фатир алып бирә алу аңа җиңел булмагандыр.

Хисамов – милләтпәрвәр шәхес. Ул һәрвакыт халык белән аралашып тора. Бик еш туган якларында була. Андагы төрле чараларда катнашып тора.

Бу кешегә Аллаһы Тәгалә бетмәс-төкәнмәс иҗат мөмкинлекләре биргән. Алай гына да түгел, ул мөмкинлекләрне гамәлләштерүгә дә юл ачкан. Һәм бу мөмкинлекләр һич кенә дә саекмый. Аның дистәләгән китаплары, йөзләгән мәкаләләре дөнья күрә тора.

Нурмөхәммәт Хисамов исеме әдәбият һәм аның тарихы битләренә уелган.

*Индус Таһиров,*
*академик.*
*2016*

## ГАЛИМНЕҢ АЧЫШЛАРЫ

Нурмөхәммәт Хисамовның укучылар кулына тапшырыла торган әдәби тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы, минем белүемчә, галим һәм әдипнең 50 яше тулуга багышлап чыгарыла.

Беренче карашка түгәрәк дата уңае белән чыгарылган җыентык калын бер том булырга тиеш иде кебек. Ә биредә нибарысы – 7–8 табак. Азрак түгелме? Әллә бу авторның тыйнаклыгымы? Ләкин кулъязманы кулга алган беренче минутларда гына азсыну тойгысы кичерәсең. Мәкаләләрне укый башлау белән күңелдә җыентыкның авторына карата ихтирам хисе уяна, ул хис отыры үсә, тирәнәя, ә азактан, укып чыккач, үзең өчен җитди бер нәтиҗә ясарга мәҗбүр буласың: бу ел саен чыгып килә торган гадәти мәкаләләр җыентыгы түгел, бу – безнең традицияләребезгә, әдәбиятыбызның борынгы чыганакларына, буыннар бәйләнешенә галимнең төгәл үз карашы, фәнгә нигезләнгән үз концепциясе. Шуңа күрә җыентык «Бәрәкәтле чишмәләр» дип атала да.

Безне, әдипләрне, моңарчы кайбер галимнәрнең Тукай иҗатын өйрәнгән чакта, бигрәк тә өлгесен кемнәндер алган шигырьләрне анализлаганда, шагыйрь аларны күчергән икән дигән тойгы калу, бу примитивлыкның исә галим табышы итеп бирелүе аеруча җанны рәнҗетә иде. Н. Хисамов, әдәбиятчы галим буларак, Тукайның Көнчыгыш шагыйрьләреннән алган мотив һәм өлгеләрне никадәрле үстергәнлеген, үстереп кенә калмыйча, заман поэзиясе итеп тудырганлыгын конкрет мисалларда, чагыштырып карауларда исбатлый алган.

Күптөрле мисаллардан «Көзге җилләр» шигырен алам. Көнчыгышның суфи шагыйре Шәех Гаттар иҗатындагы контраст буяулар, антитезалы тасвирнең Тукай күңеленә хуш килгәнен әйтә галим.

Аеруча хуш килгән юлларның берсе менә мондый:

Беригә алтун табакида нан бирүр,
Бери нан тип хәсрәтиндә җан бирүр.

Галим әйтә: «Суфи шагыйрь бу әсәрендә иҗтимагый гаделсезлекне фаш итү максатын күздә тотмый, билгеле. Ул тормышның мондый контраст тасвирен илаһиятнең кодрәтенә дәлил итеп кенә җитерә», – ди.

1911 елгы ачлыктан интеккән халыкның аһ-зарын ишеткән, фаҗигасен күргән Тукай әлеге өлгегә «чорның социаль портретын» сала.

Куйса монда корткалар төшкән тешен алтын белән,
Бер телем икмәк дип анда назлы нечкә бил җылый.

Күрәбез, Тукай илаһи көчләргә табыну белән бәйле шигырьнең өлгесен алып, контрастлар һәм антитеза ярдәмендә, җан тетрәткеч реалистик картина тудырган һәм шуның белән егерменче йөз башындагы чынбарлыкның трагедиясен ачып бирүгә ирешкән. Тукайның бөеклеге әнә шунда. Тукай кемнәндер күчерми, иске калыпларга ул яңа дөньяның эчтәлеген сала.

Мондый алымга без дөнья әдәбияты классикларыннан да мисал китерә алабыз. Әйтик, Шекспир яңа сюжетлар, фабулалар уйлап чыгарырга маһир булган. Ләкин ул Испаниядә, Италиядә яки гарәпләрдә йөргән сюжетларны алып, аларны, үз даһилыгы кушканча, сәнгать җәүһәренә әйләндергән. Тукай да шулай!

Н. Хисамовның әдәби традицияләргә бәйле бу ачышы безгә ифрат та файдалы һәм гыйбрәтле бер нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Димәк, Тукай самородок талант кына түгел, ә бәлки кыска гомерендә төрки телләрдәге әдәбиятны, Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәбияты хәзинәләрен, унтугызынчы гасыр рус әдәбиятын тирәнтен белгән, аны үз иҗат максатларына файдалана алган бөек талант. Менә шулар нигезендә без 27 яшендә Столыпин реакциясенең тигезсез көрәшендә һәлак булган драматик талантның дөнья культурасы хәзинәсен белү өчен никадәр көч куйганлыгын аңлый башлыйбыз. Менә шуңа күрә кайберәүләрнең, объектив сәбәпләргә сылтау ясап, Тукайны гадиләштерергә, кечерәйтергә маташуы көлке тоела.

Моннан тыш без әдәби практикабызда бик тә кирәкле тагын бер нәтиҗә чыгарабыз: Тукайны русчада тулы көченә, барлык зурлыгында яңгырата алмау аның поэтикасының шушы көнгә тикле галимнәр тарафыннан ачылмавыннан килә. Тәрҗемәче шагыйрьләр коры социологик эзләнүләрдән үзләренә азык таба алмыйлар. Димәк, шулай булгач, Тукайны рус укучысына тулысынча, барлык сәнгать көче белән, барлык даһилыгы белән җиткерү тәрҗемәчеләр кулыннан гына килә торган эш түгел. Биредә бөтен бер

коллектив – Тукай институты эшләргә тиеш. Ул институтта, минем уемча, тикшеренүче галимнәр, филологик-фәнни подстрочник ясаучылар, талантлы тәрҗемәче шагыйрьләр, әсәрләрнең язылу тарихын, Тукайның поэтикасын яхшы белгән редакторлар тупланырга тиеш.

Н. Хисамовның «Бәрәкәтле чишмәләр» җыентыгы безне әнә шундый уйларга алып килә. Аның, әдәбиятчы галим буларак, Тукай поэтикасын ача башлаудагы беренче адымнары ук бу эшне алга таба да сузып килүнең зарарлы икәненә әдәбият тарихыннан әзерлеге булмаган гап-гади укучыны да ышандыра.

Н. Хисамов Тукай поэтикасын аңлауга һәм аны тиешле дәрәҗәдә аңлатып бирүгә ничек ирешкән соң? Ул бит әле М. Гайнуллин, Х. Госман, Г. Халит, Х. Хәйри, Ш. Абиловлар кебек өлкән яшьтәге галим түгел. Яки И. Нуруллин кебек гомерен тулысынча Тукайны өйрәнүгә багышлаган галим дә түгел.

Минемчә, моның берничә төрле сәбәбе бар.

1937 елны Татарстанның Чүпрәле районы Мунчәли авылында крестьян гаиләсендә туган Нурмөхәммәт, унынчы классны тәмамлагач, Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Нигә университетны сайлавы да мәгълүм. Нурмөхәммәтнең әтисе Шаһвәли абзый – игенче, умартачы; китаплар ярата, Көнчыгыш әдәбиятын һәм тарихын, рус әдәбиятын һәм күп телләр белә, аеруча шигъри телне нечкә киземли. Борынгы татар поэзиясен, Тукай әсәрләрен ул улына күбесенчә яттан сөйли. Әбисе Сабира абыстай исә XIX йөз азагында бик күп шәкертләр үстергән мөгаллимә була. Табигый, шундый мохиттә Нурмөхәммәтнең күңеленә борынгы узганыбызның кагылмый калуы мөмкин түгел. Монысы – бер. Икенчедән, романтик табигатьле авыл малае кече яшьтән шигырь яза, университетка кергәндә, 1955 елны аның беренче шигырьләре «Үсү юлы» альманахында басылып та чыгалар. Ә 1967 елны аның «Яз миңа чәчәкләр китерә» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Димәк, шигырь техникасы, поэзия дөньясы аңа практик рәвештә таныш. «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томына кергән борынгы татар шагыйрьләреннән кайберләренең шигырьләрен бүгенге әдәби телебезгә тәрҗемә итүе, белеп, яхшы тәрҗемә итүе юкка түгел. Моннан тыш ул – әлеге алты томлык хезмәтнең беренче һәм дүртенче томнарының фәнни редакторы.

Димәк, ул борынгы әдәбиятны да, егерменче гасыр башы әдәбиятын да башыннан ахыргача узып чыккан, кайда нинди хәзинә ятканны, чишмә башыбызның кайда икәнен белә. Һәм, ниһаять, университетта Х. Госман җитәкчелегендә аспирантура узган чагында ул тикшерену объекты итеп XX йөз башы татар лирикасын ала, соңрак исә, Фәннәр академиясенә эшкә килгәч, тикшерену өчен Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын сайлый. Димәк, телиме-юкмы, ул борынгы әдәбиятыбызны өйрәнеп чыгарга тиеш була. Тукайның нинди традицияләргә таянуын аңлау, «бәрәкәтле чишмәләр»ен ачу әнә каян ук башлана.

Кандидатлык диссертациясен яклау да Н. Хисамовка ансат кына бирелми. Тормыш – тормыш инде ул: авыл малаена билгеле бер яшәү шартлары булдыру өчен, университет тәмамлагач, үзе туып-үскән Чүпрәле якларына кайтып, район газетасында хатлар бүлегендә эшләргә, ә аспирантура тәмамлагач, күптиражлы завод газетасында берничә ел редактор булырга туры килә. Ләкин әдәбиятчының ул еллары да бушка узмый, Нурмөхәммәт халык арасында була, борынгы китаплар халык аңында ничек сакланганны үз күзе белән күреп белә, күңеленә борынгы китапларны укыган әтисе һәм мөгаллимә әбисе салып калдырган культурабыз хәзинәләрен онытмау рухы аңарда сакланып килә.

«Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф поэмасы”» дигән кандидатлык диссертациясен Н. Хисамов 1980 елны СССР Фәннәр Академиясенең А.М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институтында яклады. Бу хезмәт аерым китап булып Мәскәүдә русча (1979), «Бөек язмышлы әсәр» исеме белән Казанда татарча (1985) басылып чыкты.

Еллар буе әзерләнгән зур фәнни хезмәт, шулай итеп, дөнья күрде һәм безнең галимнәребезгә Кол Галинең бөек әсәре хакында компетентлы фикер йөртү өчен мөмкинлек туды. Хезмәтнең авторы Н. Хисамов бу фәнни эшендә зур таяныч булган Казан профессоры Х. Госманга, Ленинград профессоры Г. Таһирҗановка, Мәскәү галиме Х. Күроглыга, СССР Фәннәр Академиясенең член-корреспонденты Г. Ломидзега күңелендә рәхмәт хисе саклый.

Соңгы елларда ул борынгы поэзия, бигрәк тә М. Кашгари «Диваны»ндагы шигъри үрнәкләр белән шөгыльләнә. «Урта гасыр төрки-татар поэзиясендә версиялелек проблемасы» дигән темага докторлык диссертациясе әзерли.

Нурмөхәммәт Хисамовның Тукай поэтикасына килүенең, кыскача гына әйткәндә, алшартлары әнә шундый.

Әдәбият белеме һәм җанлы әдәби тәнкыйть безнең алга барышыбызга ярдәм итәргә тиеш дип кат-кат әйтеп киләбез. Ләкин аның әдәбият үсешенә булган ярдәме конкрет нинди формада чагыла ала? – Ул хакта әле бер генә әдәбиятчы галимнең дә, нәфис әдәбият белән практик рәвештә шөгыльләнүче бер генә әдипнең дә нигезле итеп язып чыкканы юк. Н. Хисамовның «Тукай поэзиясендәге борынгы әдәбият традицияләре» исемле әтрафлы, дәлилле, тәфсилле мәкаләсен укыгач, күңелдә әнә шул ярдәмнең чаткылары чагылып уза. Тукайның зурлыгын, бөеклеген исбат иткән чакта галим гасырлар тирәнлегенә төшә, «җан кошы» образының Тукайгача меңьеллык эволюциясен күзәтүе шулай ук аның нечкә ачышларыннан булды. Тукай иҗаты татар әдәбиятының күп гасырлык үсешенә йомгак ясый, дип белдерә ул.

Узган юл бер йомгакка төйнәлеп куелгач, алда тагын бер юл бар бит әле. Н. Хисамов Тукай традицияләренең шифалы йогынтысын Н. Исәнбәт, Х. Туфан, С. Хәким, Г. Афзал һ.б. шагыйрьләр иҗатында күрә.

Әйтергә кирәк, әдәбиятчы галим татар әдәбиятының ерак үткәнен нинди олпатлык белән тикшерсә, аның бүгенгесе хакында да саллы итеп фикер йөртә белә. Бу исә аңарда әдәбиятчы һәм тәнкыйтьче сыйфатлары бердәй тигез яшәвен әйтеп тора. Филология фәннәре докторы Ф. Мусинның: «Бу нәрсә аңа әдәбиятта дәверләр һәм буыннар бәйләнешен, традиция һәм новаторлыкны нигезләп ачарга булыша. Күпчелек мәкалә һәм рецензияләрдә авторның гомуми сүз һәм фараз кылулардан качуы, аерым әсәр, язучы иҗаты һәм әдәбиятның гомуми мәсьәләсе турында конкрет, аналитик фикер йөртүе күзгә ташлана. Бу сыйфат Н. Хисамовның галимлек тәфсиллеге һәм тикшерелә торган материалны яхшы белүе белән бәйләнгән», – дигән бәясе белән тулысынча килешергә кирәк.

Яшь Совет поэзиясендә Нәкый Исәнбәтнең тоткан урынын ачкан чакта да, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Шәрәф Мөдәррис, Гамил Афзал поэзиясенең асылын ачкан чагында да автор гомуми сүз сөйләми, коры риторикага бармый, бу авторларның шигырьдәге мотивларын, идея-сәнгатьчә чараларын социаль җирлеккә,

мохиткә бәйләп алып бара. Иҗатта бик иртә һәм тиз өлгергән Н. Исәнбәткә карата язганда ул ачыктан-ачык әйтә: «Ил бер революциядән икенче революциягә юл тота. Корбаннар сораган көрәштә мәктәпләр, газета-журналлар яулап ала-ала, мәгърифәткә, милли һәм социаль азатлык дауларына йөз тоткан татар халкы да алгы сафларның берсендә атлый. Иҗат көчләре иртә җитлегүнең җирлеге шушы».

Минемчә, бу – дөрес фикер. Егерменче гасыр башындагы социаль үзгәрешләр татар культурасы эшлеклеләренең бөтен бер плеядасын тудырган. Совет властеның беренче елларында да шулай. Аннары, давыллар тынгач, әкренрәк җитлегә талантлар, авылны күмәкләштерү кебек бөек борылыш еллары, Бөек Ватан сугышы дәвере иҗатчыларны янә дә алгы сызыкка чыгарып куя.

Н. Хисамов, Тукай традицияләре белән бергә, өлкән шагыйрьләребез һәм алтмышынчы-җитмешенче елларда күтәрелгән шагыйрьләр иҗатында Сәгыйть Рәмиев, Такташ, Дәрдемәнд традицияләрен дә күрә, ул традицияләрнең яңа шартларда ничек яңаруын, башка төсмер һәм мотивларга күчүен, әдәби форманың нинди эчтәлеккә хезмәт итүен җентекләп ача.

Дәрдемәнд иҗатын тикшергән чагында аның каршылыклы булуын, буржуазиягә тугрылыгын, сыйнфый чикләнгәнлеген бер генә минутка да онытмый. Һәм шул ук вакытта кешелек, ил язмышына кагылышлы олы гуманистик мәсьәләләрдә бу үзенчәлекле шагыйрьнең сыйнфый чикләргә генә сыеп бетмәвен дә күрсәтә. Аның әдәби форма өлкәсендәге камиллеген, аһәңлелеген аерым мисалларда дәлилләп бирә, образлы үткенлекнең, кыска-тыгызлыкның мисалларын Ренат Харис поэзиясеннән таба.

Әгәр бер сынландыру яки чагыштыру берничә шагыйрьдә кабатланса, галим һәм тәнкыйтьчеләребез аларны бер-берсен кабатлауда гаепли башлыйлар. Миңа, мәсәлән, Н. Хисамовның һәр образлы сүзгә, метафорага, сынландыруга яки рефреннарга иҗатчының үз алдына куйган максатларына карап якын килүе ошый. Күп төрле мисаллар арасыннан д и ң г е з образын алыйк. Г. Ибраһимовта диңгез мәһабәт стихия рәвешендә, Ш. Камалда диңгезнең катлаулы холкын кеше холкына охшатып тасвирлау бар; Ә. Еники, мәсәлән, диңгезне тыштан акрын үзгәрә торган зур тормышка тиңли, кеше хисләренең тыштан үзгәрешсез күренгән талгын

мәңгелек белән бәхәскә керүен әйтә; Х. Туфанның «Тугызынчы дулкын»ында «төне буе борчылулар, сораулар белән актарылып чыккан шагыйрь күңеле диңгез белән ике арада рухи туганлык, тиңлек» таба; Н. Арслан диңгездә үзе туып-үскән казакъ даласын, Ш. Маннур халыклар язмышын күрә. Матур, чын күзәтү бу, безнең тәнкыйтьчеләребез өзлексез ачып торырга тиешле күзәтү. Югыйсә әдәби әсәрнең асылына төшәргә бик үк теләмәгән тәнкыйтьчеләр мондый очракта гел кабатлау гына күрергә гадәтләнеп баралар. Әдәби әсәрләрдә схематизм чире булганны белгән кебек, әдәби тәнкыйтьнең дә кайвакыт шундый чиргә дучар булуын онытырга ярамый безгә.

«Әдәбиятның кан тибешен тоеп» исемле мәкаләсендә бүгенге әдәби тәнкыйть хакында Н. Хисамов мондый фикер әйтә:

«Соңгы вакытта чыккан тәнкыйть хезмәтләренең иң характерлы үзенчәлеге итеп киң гомумиләштерүләргә омтылуны, аерым жанрларның, төрле буын язучыларының иҗат тәҗрибәсен чор һәм тарих контекстына куеп карауны күрсәтергә мөмкин».

Бу бәя Нурмөхәммәт Хисамовның үз иҗатына да тулысынча туры килә. Аның күпчелек мәкаләләре нигезле, салмак агышлы, алдынгы тәгълимат казанышларына нигезләнеп язылган, алар әдәбиятта фидакярләрчә эшләүче галимнең образын күз алдына бастыралар. Мондый олы сыйфат галимнең алдагы иҗатында тагын да үстерелебрәк дәвам итәр дип ышанып калабыз.

*Гариф Ахунов.*
*1987*

## ОЛЫ ЮЛ БАШЫНДА

*(Яшьлек истәлекләре)*

Күпгасырлык тарихы булган татар әдәбиятында поэзия гомер-гомергә авангард, байракчы ролен үтәп килә. Хәер, борынгы төрки дәвердә дә бу шулай булган. Йосыф Баласагунлы үзе генә дә моңа зур дәлил! Инде конкрет үзебезнең җирлеккә килсәк, анда күпме мәшһүр исемнәр: Кол Гали, Котб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр, Утыз Имәни, Кандалый, Тукай, Дәрдемәнд, Такташ, Муса Җәлил, Туфаннар, бүгенге күренекле шагыйрьләр... Аларның ижа-

ты нинди бай шигърият хәзинәсен тәшкил иткәнлеге бик ачык аңлашыла. Табигый ки, бу хәзинә бездә шактый ук тирән өйрәнелгән. Идел Болгарстаны, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорлары, XVII–XIX йөзләр, XX гасыр, хәзерге заман шигърияте буенча безнең әдәбият фәнендә зур-зур галимнәр эшләде һәм эшләп килә. Гадәттә, һәр конкрет чорның абруйлы үз белгечләре була. Барлык чорларны да нигезле итеп өйрәнгән универсаль галимнәребез дә юк түгел. Соңгыларыннан берсе – филология фәннәре докторы Нурмөхәммәт Хисамов. Шигырь белгече буларак, аның әле җитди бер өстенлеге дә бар: ул – үзе дә шагыйрь, хәтта ки җырлар шагыйре!

Биредә әле тагын бер өстәмә сорала: Н. Хисамов поэзия генә түгел, ә әдәбиятның башка барлык төрләре һәм жанрлары буенча да киң мәгълүматлы һәм тирәннән фикер йөртергә сәләтле галим. Моны ул, мәсәлән, алты томлык «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томына фәнни редактор булганда бик ачык күрсәтте. Вакыт ягыннан ун гасырлык дәверне колачлаган, төрле заманнарда яшәп төрле жанрларда иҗат иткән 20 гә якын зур әдипләр мирасын яктырткан, 35 тематик бүлектән торган бу фундаменталь басманың тиешле югарылыкта дөнья күрүендә аның өлеше ифрат зур булды.

Бу урында Н. Хисамовның фәнни дәрәҗәләрен, мактаулы исемнәрен янә бер мәртәбә санап чыгуга ихтыяҗ күрмибез. Бары тик аның шушы олы юлга ничек кереп китүен күрсәткән кайбер хатирәләрне генә яңартып үтәсе килә.

...1954–55 уку елы иде. Мин Казан университетының икенче курсында укыйм. Матбугатта шигырьләрем басылгалап торгангамы, миңа студентларның иҗат түгәрәген җитәкләү вазифасын йөкләделәр. Безнең утырышларда рус бүлеге шагыйрьләре Вил Ганиев, Геннадий Калинкиннар да еш булалар иде.

Гена Зеленодольскидан йөреп укый. Калын гәүдәле кешеләрнең күбесенә хас булганча, үзе бик яхшы күңелле егет. Шигырьләрне рус телендә генә түгел, немецчә дә яза, ягъни поэзия корифейләре Гөте, Шиллер, Һәйнеләр иҗат иткән телне камил белә.

Ул чакта безнең татар теле һәм әдәбияты кафедрасы, шулай ук мөдир Хатип ага Госман кабинеты «Химкорпус» дип йөртелә торган бинаның дүртенче катында урнашкан иде. Бер көнне коридорда Г. Калинкин килеп очрады. Янында озын буйлы, куе бөдрә

чәчле, йөз-кыяфәте Александр Блокның яшь чактагы фотосурәтенә охшаган бер егет тә бар иде.

– Шагыйрь Нурмөхәммәт Хисамов, – дип таныштырды Гена. – Сезнең иҗат түгәрәгенең булачак члены.

– Зеленодольскиданмы?

– Юк, мин үзем Чүпрәледән. Яшел Үзәндә беркадәр укыдым гына, – диде егет. Унынчы сыйныфны Чүпрәледә тәмамлаячак икән. Киләсе елда университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә керергә хыяллана... Мин, хуплап һәм уңыш теләп, берничә сүз әйттем.

...1955 елның сентябрендә Нурмөхәммәт инде университет студенты иде. Һәм, Г. Калинкин юраганча, иҗат түгәрәгенең барлык утырышларында актив катнаша башлады. Үз шигырьләрен, башка авторларның, хәтта алман шагыйрьләренең әсәрләрен укый (Яшел Үзән мәктәбе!). Аның тикшерүгә тәкъдим иткән беренче шигыре «Урман аша» дип атала иде. Һади Такташ истәлегенә багышланган һәм аның «Узып барышлый» шигыренә ияреп (нәзыйрә рәвешендәрәк) язылган бу әсәр барыбызга да бик ошады. Аның үлчәме инде туйдырып бетергән 10-9 лы түгел, ә 12-9 лы. Һәм ул баштан ахырга кадәр төгәл саклана. Бары тик соңгы строфаның беренче тезмәсендә генә 13 иҗек килеп чыга. Яшь автор мәгънә төгәллеге хакына моны аңлы рәвештә эшләгән булса кирәк. Лирик герой вагон тәрәзәсеннән карап бара. Аның күз алдында күренешләр, калейдоскоптагы сыман, алмашынып кына торалар. Әмма төп мотив – урманның шаулавы, геройның сагыну-юксынуы үзгәрешсез кала. Шуны сиздерү өчен текстка «ә» каршы кую теркәгече кертелгән.

Шигырьдәге рифмалар барсы да тулы яңгырашлы. Арада шактый оригинальләре дә күренә: *чын бары – җырлары, ала тын – баласын.* Ул чакта рифмалашкан сүзләрнең төрле сүз төркемнәренә каравы бик хуплана иде. Иң мөһиме – яшь авторның Такташтагы шигъри сурәт-детальләрдән оста һәм урынлы файдалануында иде:

Ак төтенен бөркеп, ярсып поезд чаба,
Күкрәк йота урман сулышын.
Нинди рәхәт тою һәр татарга якын
Такташ туган якның җылысын.

Бәхеттер бу – үз күзләрем белән күрәм,
Ул сөйләгән төсле чын бары.
Күңел юлларыннан яшел вагоннардай
Йөгреп уза Такташ җырлары.
Тезелеп кала моңга чумган ак каеннар,
Уйга талган зифа усаклар.
Тик сүнгәннәр күптән олы юл чатында
Әтәч пешереп яткан учаклар...
Менә алан.
Ике малай, зур юл эзләп,
Сукмагыннан бәлки үткәндер,
Иркә җилләр шунда урман кызының
Ефәк толымнарын сүткәндер.
Ә урман шаулый, шаулый.
Беләм, юксынудан
Шулай тирән, уйчан ала тын –
Бар ил белән бергә ул да сагына
Үзе үстергән җырчы баласын.

Баштарак миңа (башкаларга да шулай булгандыр) Н. Хисамов шигърияткә дә, фәнгә дә өйрәнчеклек чорын кичермичә генә аяк баскан шикеллерәк тоела иде. Һәрхәлдә, университетка кергәндә аның сурәтле фикер һәм сәнгатьчә нәфислек дәгъвә итәрлек тәүге шигырьләре матбугатта дөнья күреп өлгергәннәр булып чыкты. Озак та үтмәде, вуздагы беренче семинарлар, студентларның фәнни түгәрәк утырышлары егетнең әдәби тәнкыйть, тарих, сәясәт, иҗтимагый фикер өлкәсендә дә шактый эрудицияле булуын күрсәттеләр. Гадәттә «шигырь җене» кагылган студентлар «максималистлар» булалар: поэзиядән башканы, шул җөмләдән тел буенча лекцияләрне, бик үк өнәмиләр. Нурмөхәммәт Хисамов исә беренче җәйге каникулында ук доцент Диләрә Тумашева җитәкләгән фәнни экспедиция составында Себер татарларының тел үзенчәлекләрен өйрәнү өчен Төмән якларына юл тотты...

Бераз соңрак, танышлыгыбыз дуслыкка әверелгәч, мин Нурмөхәммәт Хисамовның затлы-зыялы, образлы итеп әйткәндә, Коръән-Кәримле һәм «Кыйссаи Йосыф»лы гаиләдән чыгуын, ул 10 нчы сыйныфны тәмамлаган Чүпрәле мәктәбендә укытучы

Абязов җитәкчелегендә бик җитди әдәби түгәрәк эшләгән булуын белдем. Берничә елдан соң, журналист сыйфатында бу районга командировкага баргач, Абдулла ага Абязов белән миңа шәхсән танышырга туры килде. Какчыл йөзле, әмма бик мөлаем, көләч күзләреннән җылылык бөркелеп торган бер зат иде ул. Нурмөхәммәт сөйләвенчә, шигырьләр язган, көйләр чыгарган, гармунда уйнаган, рәсемнәр ясаган, Хатип Госман белән бергә Казан педагогия институтында укыган, икесе дә Такташ иҗатына мөкиббән булганнар. Соңрак репрессиягә эләгеп, аның өчен матбугат мәйданына юл бикле булса да, поэзиягә мәхәббәте сүрелмәгән. Әдәби талантының очкыннарын балалар күңеленә күчерергә тырышкан. Нурмөхәммәт яшь Туфанның ул чакларда әле матбугатта күреп булмый торган шигырьләрен яттан укый-укый да: «Абдулла абый сөйләгәндә отып алган идем», – дип куя иде.

Гомумән, Чүпрәле төбәге ул вакытларда кечкенәрәк «Парнас»ны хәтерләткән. Монда Шәрәф Мөдәррис, Зәки Нуриларның таланты ачылган. Сембер ягы мишәре, профессор Латыйф Җәләйнең авылдашы шагыйрь Сахаб Урайский да бу төбәккә еш килгән. Ул Нурмөхәммәтнең әтисе, үткен фикерле эрудит, оста умартачы Шаһвәли ага белән якыннан таныш булган, Ә Җәләй аганы абитуриент Н. Хисамов беренче кат нәкъ менә Урайскийның Казандагы квартирасында күргән.

...Шигърият, әдәбият турындагы сөйләшүләребез фатирларда очрашкач та дәвам итә иде. Ул вакытта мин Чернышевский (хәзерге Кремль) урамында кеше почмагында яши идем. Миннән бер курс түбән укучы Фәсих Хисмәтуллин, КАИдан ике студент – дүртебезгә кечкенәрәк кенә бер бүлмә. Нурмөхәммәт Федосеевский урамында үзенә аерым бүлмә алып тора. Ул бүлмә бик якты булып хәтердә калган. Урындыкта – гармун. Үзенеке. Кәефе күтәренке (яисә киресенчә) чакта, үзе уйнап, «Урман кызы»н җырлаштыра иде. Ул студент вакытта ук өс-башын бик пөхтә йөртте. Аның соры төстәге җәйге пәлтәсе өчен Фәсих «француз» дигән кушамат та тагарга тырышып карады. Нурмөхәммәт, җавап итеп, французларны зурлый торган озын гына бер шигырь дә язды. Хәер, буй-сын, төс-бит, көязлек (һәрхәлдә, шуңа омтылу) җәһәтеннән Фәсих үзе дә Нурмөхәммәттән калышмый иде. Җәйге каникулда «Совет Татарстаны» газетасында эшләп кулына шак-

тый хезмәт хакы һәм гонорар төшергәч, шәп костюм сатып алды. Шуннан соң көзге каршында «нарциссланып» та торгалый иде. Гомумән, ул үз-үзеннән бик канәгать йөри. Талантлы шагыйрь, тәнкыйтьче, публицист икәнлегенә тамчы да шик-шөбһәсе юк. Безнең язганнарны тәнкыйтьләп кенә йөрәге басылмаса, Бауман урамындагы Тукай клубына төшеп, олырак язучыларны «өйрәтеп» менү бу гайяр егет өчен берни тормый иде. Матди кыенлык аркасында укуын бүлеп торырга туры килсә дә, ул барыбер югары белем алды, үзенең күпкырлы талантын шактый тулы ачуга ирешге: тирән фикерле һәм форма ягыннан үзенчәлекле шигырьләре, полемик рухлы, дәлилле-аргументлы, мавыктыргыч итеп язылган әдәби тәнкыйть мәкаләләре, эссе һәм очерклары аркылы күренекле әдип булып үсте. Бүгенге киң катлау укучыларга ул «Фаяз Дунай» дигән бик аһәңле һәм зәвекъле тәхәллүсе белән билгеле.

Безнең компаниядә Фәсихнең курсташы Әхмәт Рәшитов (Рәшиди) дә булгалый иде. Шигырьләрне ул күп яза, башкаларны тәнкыйтьләргә бик һәвәс. Лекцияләргә артык исе китми. Дивар газетабыз «Әдәби сүз»дә хәтта: «Тәнкыйтьче һәм шагыйрь Рәшиди Семинарда бер дә дәшми, ди», – дигән «бер гайбәт» тә күренгән иде. Нурмөхәммәт Әхмәткә һәрвакыт «шагыйрел мәшһүр» дип эндәшә. Тонында бераз ирония булса да, Әхмәт аны сизми. «Мәшһүр шагыйрь» дигән сүзләр аны сихерли. Әхмәт белән очрашканда Нурмөхәммәт хәзер дә яшьлектәге мөрәҗәгать формуласын куллана, әмма анда инде иуниягә урын юк. Үзенең ихлас лирикасы, шул җөмләдән популяр җыр текстлары, публицистик һәм тарихи поэмалары белән Әхмәт Рәшитов чыннан да бүгенге шөһрәтле шагыйрьләребез сафында лаеклы урын алып тора.

...Борынгы төркиләрдә «Болдачу бузагу өкүз ара белгелүг», ягъни «үгез буласы бозау үгезләр арасында да билгеле» дигән мәкаль булган. Мәхмүд Кашгари аны: «Зур эшләр өмет игелә торган яшь, зирәк, батыр егетләргә карата әйтелә», – дип шәрехли. Шуның шикелле, университет укытучылары: танылган әдәбият галимнәре Хатип Госман, Якуб Агишев, Ибраһим Нуруллин, тел белгечләре Латыйф Җәләй, Мирфатыйх Зәкиев, Диләрә Тумашевалар студент Хисамовтан киләчәктә зур эшләр өмет ителүен бик тиз күреп алалар. Хатип ага фатихасы белән ул берләштерелгән

тел-әдәбият фәнни түгәрәгенә җитәкчелек итә башлый. «Декадент» Дәрдемәнд мирасын өйрәнү, халыкка кайтару мөмкинлеге туа башлагач, Хатип Госман бу олы һәм бик үзенчәлекле шагыйрьнең иҗатын аңа диплом темасы итеп тәгаенли. Шуннан Нурмөхәммәт «рәсми» рәвештә дә Дәрдемәндче булып китте. Бу вакытта ул инде язучылар берлегендә дә үз кешегә әверелгән иде.

1960 елның февраленнән мин Буага кайтып, район газетасы «Яңа юл»да эшли башладым. Ә җәй көне, диплом алгач, Нурмөхәммәт Чүпрәле редакциясенә эшкә кайтты. Ике елдан артык без (төгәлрәге: ике редакция) газеталар алмашып яшәдек. Н.С. Хрущевның нәүбәттәге «реформасы» – районнарны эреләндерү башлангач, Буага Чүпрәле, Кайбыч, Апас, Тәтеш, Кама Тамагы кебек районнарны куштылар, әлбәттә, газета да берәү генә калды. Безнең «Яңа юл» Буа зона газетасы «Байрак» булып әверелде. Штатны бөтенләй диярлек арттырмадылар. Алай да Н. Хисамовка Буага эшкә килү мөмкинлеге бар иде. Һәм ул безгә килде дә (1962 елның язы иде). Ләкин бу «разведка боем» шикеллерәк кенә булып чыкты, чынлыкта Нурмөхәммәтнең алдагы җитди адымы инде хәл ителгән иде: озакламый ул Хатип Госман җитәкчелегендә аспирантурада уку өчен Казанга китеп барды.

Буада очрашу кыска булса да, шигърият өчен вакыт табылды, билгеле. Нурмөхәммәт редакциядә үзенең яңа шигырьләрен укыды. Шуларның берсе – «Күксел яллы йөгрек поездлар» исемлесе – үзенең ашкынулы пафосы белән хәтердә калды. Менә ул шигырь:

Күксел яллы йөгрек поездлар,
Мине кайчан алып китәрсез,
Казаныма кайчан илтәрсез,
Күксел яллы йөгрек поездлар?

Кичерсеннәр мине арышлар –
Юк, бу түгел сезне хурлавым,
Һич туймадым сездән, кырларым, –
Кичерсеннәр мине арышлар.

Башакларның дәртле шавында
Өлешем бар азрак минем дә.
Сөенү тулы шуңа күңелдә
Башакларның дәртле шавына.

Тик җанымның шундый гадәте:
Һаман сорый үзенә хәрәкәт,
Хәрәкәтсез аңа һәлакәт –
Җанымның шул шундый гадәте.

Дәшә үзенә яңа офыклар,
Гүя анда минем язмышым,
Ә бармаска хакым бармы соң
Чакырганда яңа офыклар?!

Күксел яллы йөгрек поездлар,
Мине моннан алып китегез,
Казаныма тизрәк илтегез,
Күксел яллы йөгрек поездлар!

*Хуҗиәхмәт Мәхмүтов.*

*1962*

## О НУРМУХАММЕТЕ ХИСАМОВЕ

Услышал я как-то песню по татарскому радио. Красивая мелодия, хорошие слова. Имя поэта я запомнил. Нурмухаммет Хисамов. Позже мне довелось познакомиться с этим человеком. Нурмухаммет оказался красивым, рослым мужчиной. Модно одетый, очень обаятельный. К тому же я узнал, что он известный татарский ученый, ныне директор ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. У нас оказалось много общего, наши родовые корни выходят из Дрожжановского района Татарстана.

Нурмухаммет – большой любитель изобразительного искусства. Он постоянный посетитель наших художественных выставок, иногда сам берет карандаш и рисует. И своих сыновей хотел видеть художниками. Нияз и Айдар после учебы в Казанском художественном училище окончили знаменитый Ленинградский институт живописи, скульптуры и архитектуры имени Репина. Вернувшись в Казань, оба совершенствовались в творческой мастерской Академии художеств под моим руководством.

Симпатичные, интеллигентные, талантливые ребята. Они тоже стали своеобразным вкладом Нурмухаммета Хисамова в татарское искусство.

У него есть замечательное стихотворение «День Победы». Меня, фронтовика, поражает то, что поэт, в годы войны бывший маленьким мальчиком, создал удивительно мудрые и величественные строки:

...Народ, осиливший врага,
Ты будешь славен на века,
Твоя дорога велика –
Живи в веках,
Живи в веках!

*Харис Якупов,*
*Народный художник СССР,*
*действительный член Академии художеств России.*
*2007*

## ТӨРКИ ЙОСЫФНАМӘНЕҢ ЧИШМӘ БАШЫ

Татар халкында «китап сүзе» дигән төшенчә бар. Сүзлекләр аны акыллы сүз, рәсми сүз, хакыйкать сүзе дип аңлаталар. Бу төшенчә белән янәшәдә шуңа бәйле тагын берсе бар – «китап сүзе сөйләү». Ул татар халкының милли гадәтенә, традициясенә әверелгән иң күркәм гамәлләренең берсен белдерә. Безнең энциклопедияләрдә, аңлатмалы сүзлекләрдә «Китап сүзе сөйләү» дигән төшенчәгә, «Сабантуй», «Нардуган», «Җыен» дигән төшенчәләр белән бер дәрәҗәдә, аерым мәкалә багышланырга тиеш дип уйлыйм.

Мин бала чакларда, ягъни үткән гасыр урталарында, китап сүзе сөйләшүләр була торган иде әле. Ашка-чәйгә җыелган әбиапалар, табынга ризык чыкканны, я булмаса кунаклар җыелып беткәнне көткәндә, «Әйдәгез, булмаса, китап сүзе сөйләп алыйк» дип, укыган-белгәннәре белән уртаклашканнарын үземнең дә берничә тапкыр ишеткәнем булды. Китап сүзе итеп, күп вакыт, пәйгамбәрләр тарихын һәм «Кыйссаи Йосыф» маҗараларын сөйләгән булганнар икән. Йосыфны күреп, аның гүзәллегенә сокланудан,

дөньяларын оныткан хатыннарның үз бармакларын тураууларын да тоймаулары хакында мин шундый табыннарның берсендә ишеткән идем.

Кол Галинең мәшһүр әсәре, шул рәвешчә, гасырлар дәвамында халкыбызның аңына, әхлагына, эстетик зәвегына, гореф-гадәтләренә йогынты ясап килгән рухи чыганакка әверелгән. Димәк, бу чыганакта халыкка кирәкле бөтен төрле витаминнар, сихәтле матдәләр һәм тозлар булган. Ул халкыбызның һәм дини, һәм дөньяви ихтыяҗларына җавап бирә алган. Алай гына да түгел, «Кыйссаи Йосыф» башка төрки халыклар әдәбиятларына да үсеш өчен таянычка һәм этәргечкә әверелгән.

Кайдан килгән соң «Йосыф китабы»на шундый универсаль көч-куәт?! Кол Гали иҗатының иң зур белгече, бөек шагыйрь турында төрле телләрдә чыккан күпсанлы китаплар авторы Нурмөхәммәт Хисамовның «Кол Гали һәм төрки “Йосыфнамә”» дигән яңа монографиясе шушы катлаулы сорауга җавап эзләшә торган үтә актуаль фәнни хезмәт булып чыккан. Алай гына да түгел, монография яңа дәлилләр белән «Кыйссаи Йосыф»ның дөнья әдәбиятындагы, бигрәк тә төрки әдәбиятлардагы, күренекле, хәтта фундаменталь урынын тагы да ныгыткан, тәхетен биеккә урнаштырган дип тә әйтергә була.

Әлеге монографияне укып чыкканнан соң, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы минем күз алдыма Байкал кебегрәк бер олы һәм тирән күл булып килеп басты: күлгә бик күп елгалар, елгачыклар уңнан, сулдан, көньяктан, төньяктан төрле-төрле галәм элементларына бай су ташыйлар; үз нәүбәтендә күлдән дә елгалар агып чыгалар һәм диңгез-океанга кушылалар. Нурмөхәммәт Хисамов яңа китабында бу әсәргә Коръәннән, Библиядән, Коръән тәфсирләреннән, XI йөз галиме Г. Әнсаринең «Мөридләрнең дусты һәм мәҗлесләр кояшы» исемле трактаты кебек чәчмә чыганаклардан килгән агымнарны да, фарсы шагыйре Фирдәүсигә тоташкан шигъри дулкынны да ачык итеп күрсәтә. Байкалдан Ангара агып чыгып Енисейгә, ә Енисей океанга барып тоташкан кебек, «Кыйссаи Йосыф»тан төрек, кырымтатар, үзбәк, төрекмән, казакъ, кумык әдәбиятларында Йосыф белән Зөләйха турындагы тылсымлы сюжет дәрьялары юл ала, һәм дөнья әдәбиятында «төрки Йосыфнамә» дигән яңа диңгез барлыкка килә.

Нурмөхәммәт Хисамов монографиясенең максаты – әнә шул «Кыйссаи Йосыф»тан юл алган агымнарны, ягъни әсәрләрне, барлау, аларны чагыштырып тикшерү, үзенчәлекләрен ачыклау җирлегендә төрдәшләр (вариацияләр, назыйрәләр) ясалу технологиясен ачыклау һәм шул технологияне фәнни нигезләү.

Галим эш барышында Йосыф турындагы кыйссаның дистәләгән төрки тиңдәшләрен җентекләп өйрәнә, алар арасындагы уртаклыкларны, аермалыкларны ачыклый, һәр әсәрне чор, халык, ил язмышы контекстында тирәнтен анализлый, аларның һәрберсендә Кол Галидән килгән традицияләрне конкретлаштыра. Автор «Кыйссаи Йосыф»тагы аерым эпизодларны, әйтик, Йосыфның изге төш күрүен һәм Йагкубның төш юравын, я булмаса ата белән угыл, Йосыф һәм хөкемдар мөнәсәбәтләрен ала да, аны Библиядә, Коръәндә, тәфсирләрдә, «Кыйссасел әнбия»дә, Фирдәүсидә, Габдуллаһ Әнсаридә тасвирланган шул ук эпизодлар белән чагыштыра һәм Кол Галинең әлеге сюжетны ничек итеп һәм нинди максат белән үзенә буйсындыруын, аңа керткән координаль яңалыкларын күрсәтә. Аннары – Кол Галидән килгән яңалыкларның Дүрбәк, Сули Фәкыйһ, Шәйяд Хәмзә, Әхмәди, Хәмди һәм башка шагыйрьләрнең төрдәш әсәрләрендәге шул ук эпизодлар белән чагыштыра. Нурмөхәммәт Хисамовның бер үк вакытта текстолог, филолог, лингвист, тарихчы, философ, психолог буларак эшләгән бу анализын мин «әдәби-молекуляр» экспертиза дип атаудан да тартынмас идем, чөнки анализ гаҗәеп җентекле итеп, авторларның стиленә, әсәрләрнең архитектоникасына, сурәтләү чаралары тукымасына, психологиясенә үтеп кереп башкарылган.

Нурмөхәммәт Хисамовның монографиясе әдәбият белеменә, аның теориясенә кагылышлы бик күп проблемаларны колачлый. Ләкин төп проблема – алдарак әйтеп үтелгән төрдәшләр ясалу технологиясе. Галим Йосыф һәм Зөләйха хакындагы гарәп, фарсы, төрки телләрдә язылган әсәрләрне өйрәнеп чыкканнан соң, иң әүвәл төрдәшлекнең төп үзенчәлекләрен ачыклый, аларны өч проблем аспекттан карап тикшерә: 1. Чыганаклар һәм текст фактурасы; 2. Үзәк каһарманнар һәм идея-фәлсәфи проблематика; 3. Шигъри эшләнештә гомуми һәм индивидуаль үзенчәлекләр.

Һәр аспектка монографиядә этрафлы бүлек багышланган, һәм ул бүлекләр әлеге «әдәби-молекуляр» экспертизадан гыйбарәт тә

инде. Ә төрдәшләр ясалу технологиясенә килгәндә, автор алты ысулны аерып күрсәтә: 1. Укмаштыру; 2. Детальләштерү; 3. Мотивлаштыру; 4. Катлауландыру; 5. Психологик баету; 6. Метафоралаштыру. Китапта бу ысулларга аңлатма һәм мисаллар белән бергә, алардан файдаланып, «Кыйссаи Йосыф»ка назыйрә язган төрле гасыр шагыйрьләренең исемнәре дә, аларның шул компонентлардан, я компонентлар төркеменнән, ничек файдаланулары да бәян ителә. Әйтик, детальләштерү – Сули Фәкыйһка, катлауландыру – Хәмдигә, психологик баету – Дүрбәккә һәм Хәмдигә, метафоралаштыру исә һәммәсенә дә хас, һәм бу ысул автордан авторга катлаулана, байый бара.

Кайбер галимнәр әйтүенчә, дөньяда Йосыф белән Зөләйха язмышына багышлап язылган ике йөзгә якын әсәр бар икән. Шуларның иң соңгыларының берсен – Назыйм Хикмәтнең «Йосыф вә Зөләйха» драмасын – Нурмөхәммәт Хисамов, тискәре яктан булса да, телгә дә алып үтә. Заманасында мин дә, Кол Галигә таянып, «Зөләйха» дигән драматик поэма язган идем һәм, исеменнән үк күренгәнчә, әсәрнең үзәгенә Зөләйханы куйган идем. Вакыйгалар исә шәһре Болгарда бара иде. Поэмага композитор Рөстәм Яхин опера да язарга тотынган иде, ләкин башлаган эшен аңа төгәлләргә насыйп булмады. (Аннары бу поэма нигезендә һәм Кол Галигә ныграк таяна төшеп, мин «Йосыф кыйссасы» дигән балет либреттосы яздым, ә композитор Леонид Любовский шул исемдәге балет иҗат итте). Мин Нурмөхәммәт Хисамовның төрдәшләр ясалу технологиясе теориясен үземнең әнә шул поэмамда сынап карадым һәм бу теориянең нигезлелегенә, универсальлегенә практик рәвештә ышандым.

Нурмөхәммәт Хисамов монографиясе мине аеруча җәлеп иткән тагын бер проблемага кагыла. Бу – төрки шигърияттә яңарышлык (новаторлык) юлы, аның барлыкка килүе, алга таба хәрәкәте, заманалар менталитеты белән бәйләнеше. Бөек әсәрләргә назыйрә булып дөньяга килгән «Кыйссаи Йосыф»ның ничек итеп үзе назыйрәләр чишмәсе булып китүе, аның кайбер идеяләренең әсәрдән әсәргә күчкәндә дә сакланып калу сәбәпләре, конкрет заманга һәм халыкка бәйле рәвештә яңа мәгънәләр белән баетылу нигезләре галимнәр өчен генә түгел, ә язучылар, укучылар өчен дә кызыклы һәм гыйбрәтле дип уйлыйм.

Назыйрә үзенең булмышы белән үзгәрешкә, яңарышка бәйле. Шул ук вакытта һәр назыйрә ниндидер яңа таләпләргә җавап буларак барлыкка килә. Әгәр дә шулай булмаса, аның кирәге дә булмас иде. Ләкин һәр үзгәреш, һәр яңарыш новаторлык дигән сүз түгел әле. Әйтик, чәчмә әсәрне шигырь калыбына күчерү генә һәм, киресенчә, шигырьне проза итеп сөйләп чыгу гына новаторлык була аламы? Я булмаса, Томас Манның «Иосиф и его братья» дигән ике томлык романы Библиягә назыйрә дип аталырга хаклы, әмма ул Библиядәге шул ук сюжет белән чагыштырганда новаторлыкны дәгъва итә аламы? Назыйрәнең дә төрлесе бар. Кайбере – төп чыганак кысаларында гына сюжетны үзенчә тасвирлый. Бу очракта да яңалыкка ирешеп була, әйтик, сурәтләү чараларында. Ә кайсылары – нигез әсәрдәге сюжетка таянып, яңа идеяләр күтәрә һәм аларны яңача бирә. Беренче очракта – элекке эчтәлекне элекке форма кысаларында яңа алымнар белән тасвирлау. Икенче очракта – күнегелгән сюжетка яңа ысуллар белән яңа идеяле эчтәлек бирү.

Нурмөхәммәт Хисамов тикшеренүләреннән күренгәнчә, новаторлык дәгъва итүче әсәр төрдәшләр ясалу технологиясенә кергән барлык компонентларны да, я булмаса – күбесен, берләштерергә тиеш. Үзгәлекләр генә яңалык, яңарыш була алмый... Билгеле сюжетта элеккеге персонажларны яңача яшәтеп, аларны яңа идеяләр, гыйбрәтләр чыганагы итә алган һәм боларның барысын да, яңа калыпка салып, яңача сурәтләгән назыйрә әсәрләр генә һәм оригиналлык, һәм новаторлык таләпләренә җавап бирә алалар. «Кыйссаи Йосыф»ның бу таләпләрнең барысына да җавап бирүен дәлилле итеп исбатлаганда, Нурмөхәммәт Хисамов, новаторлык теориясен, әнә шулай, әдәбият фәне игътибарына лаеклы күзәтүләр, фикерләр белән баета. Тагын шунысын да әйтергә кирәк – Нурмөхәммәт Хисамов бу әсәре белән бүгенге җитди әдәби анализның матур бер үрнәген бирә. Чагыштырма анализның күпкырлы һәм тирән булуы, фәнни яктан ныклы нигезләнүе, фәнни аппаратның киң булуы, үзеннән элгәрерәк галимнәрнең тикшерү нәтиҗәләренә таянуы, аларның фикерләре белән чын гыйльми диалог алып бару культурасы монографияне татар фәненең һәм әдәби тәнкыйтенең казанышы дип бәяләргә мөмкинлек бирә. Әгәр дә кайбер әсәрләрнең әлегәчә нәшер ителмәгән булуларын,

төрле фәнни китапханәләрдә, архивларда кульъязма хәлендә генә саклануын, борынгы шивәләрдә язылган булуларын да искәртсәк, галим тарафыннан башкарылган хезмәтнең күләмен дә, дәрәҗәсен дә күз алдына бераз китерә алачакбыз. Гарәп, фарсы телләрен, төрки телләрнең төрле шивәләрен белми торып мондый эшкә тотынып булмаганлыгы барыбызга да билгеле. Хәтта пәйгамбәребез Мөхәммәдне Мәккәдән Иерусалимга күчергән легендар Борак тизлеге белән ярышырлык Интернет заманасында да бу эшне башкарып чыгу өчен галимнән бик күп өстәмә сыйфатларга ия булу сорала.

* * *

Татар әдәбиятының, сәнгатенең генә түгел, ә халкыбыз культурасының нигез ташы булган озын гомерле «Кыйссаи Йосыф» китабы бүген дә, XXI гасырда да, актуальлеген югалтмый. Ул әледән-әле галимнәребезгә кызыклы фәнни табышлар китерә, язучыларга, рәссамнарга, композиторларга, театр әһелләренә илһам бирә, аларның иҗади фантазияләрен уйнатып җибәрә. Мин үзем дә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ына Нурмөхәммәт Хисамов хезмәтләре ярдәмендә кердем һәм анда «Зөләйха» дигән драматик поэмама, «Йосыф кыйссасы» дигән балет либреттосына этәргеч таптым.

Бөек Кол Галинең бу әсәрен кулга алгач та «Кыйссаи Йосыф» ны дөньякүләм күтәргән, пропагандалаган, аның серләрен ачкан тылсым иясе Нурмөхәммәт Хисамов белән дә очрашасың, чөнки әсәрне хәзерге татар теленә ул тәрҗемә иткән. Мондый катлаулы эшне башкару өчен шагыйрь галим булырга тиеш, я булмаса галимнән шагыйрь булу таләп ителә. Нурмөхәммәт Хисамов бу таләпләрне үзендә берләштергән киң һәм тирән менталитетлы шәхес. Үзенең 80 еллык юбилеен егетләрчә энергия белән каршы алган Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Хисамов безне театрларда барган спектакльләре, эстрададан, радио-телевидениедән яңгыраган җырлары, китап киштәләрен бизәгән шигырь җыентыклары белән сөендереп тора һәм «төрки Йосыфнамә»нең чишмәсен киңәйтүне, тирәнәйтүне уңышлы дәвам итә.

*Ренат Харис,*
*Татарстанның халык шагыйре.*
*2007*

## НУРМУХАММЕТУ ХИСАМОВУ 70 ЛЕТ

70-летний юбилей Нурмухаммета Шагвалеевича Хисамова – большого ученого-литературоведа, поэта и переводчика, публициста и журналиста, лингвиста и общественного деятеля – большое событие в жизни научного сообщества Республики Татарстан. Мы рады возможности поздравить Нурмухаммета Шагвалеевича с замечательным юбилеем. К нашей большой радости Нурмухаммет Шагвалеевич встречает свой юбилей в добром здравии, полным сил и творческой энергии.

Со студенческих штудий Нурмухаммет Шагвалеевич 50 лет своей творческой жизни посвятил исследованиям по истории татарской литературы. В его трудах тысячелетняя история татарской литературы рассматривается как составная часть тюркской и арабо-исламской литератур.

Нурмухаммет Шагвалеевич дал возможность современному читателю увидеть творчество выдающихся авторов мусульманского Востока в их взаимодействии и взаимовлиянии в историческом развитии литературы. Он показал, что и современная татарская литература является достойной наследницей тысячелетней традиции литературы Востока.

Фундаментальную часть творчества Нурмухаммета Шагвалеевича Хисамова составляют его труды, посвященные бессмертной поэме Кул Гали «Кысса-и Йусуф» («Книга о Юсуфе»). Ему удалось раскрыть гуманистические идеи поэмы, ее художественные и композиционные достоинства. По Н.Ш. Хисамову, в поэме Кул Гали выражены чаяния народа о справедливом государственном устройстве, когда государством правит человек из народа, знающий нужды народа, одинаково справедливый и заботливый к богатому и бедному человеку. Поэма Кул Гали предстает в трудах Н.Ш. Хисамова как энциклопедия современной автору жизни народа, т.е. времени начала эпохи Ренессанса в Европе. Примечательно, что «Книга о Юсуфе» создавалась Кул Гали в то же время, что и «Слово о полку Игореве» на Руси, и поэмы Низами и Руставели на Кавказе. Нурмухаммет Шагвалеевич Хисамов показал, что традиции и образы поэмы Кул Гали проникают в тюркскую литературу Средневековья и булгаро-татарскую поэзию. Он об-

наружил образы и мотивы поэмы в творчестве великих поэтов XX века – Г. Тукая и М. Джалиля, художника Б. Урманче, современных поэтов.

Деятельность Н.Ш. Хисамова по исследованию поэмы «Книга о Юсуфе» увенчана великолепным новым переводом поэмы на современный татарский язык (Казань, 2000).

Энциклопедические знания Н.Ш. Хисамова в области истории татарской литературы использованы им в исследованиях поэзии Г. Тукая, С. Рамиева, Х. Туфана, Дардеменда, С. Хакима, современных поэтов Р. Файзуллина, Р. Хариса и других («На страже памяти», Казань, 2004). Глубокой аргументацией характеризуются выступления Н.Ш. Хисамова по вопросу о применении латиницы в татарской письменной речи.

Н.Ш. Хисамов своими научными трудами, переводами и поэзией вписал себя в тысячелетнюю историю татарско-булгарской и арабо-мусульманской литературы, за что ему Честь и Хвала.

*К.А. Валиев,*
*академик (Москва).*
*2007*

## ОЧАР ӨЧЕН ИКЕ КАНАТ КИРӘК

Татарстан Милли китапханәсендә эшләгән чакта мин көн саен диярлек аны урамда очрата идем. Яшь чамабыз да, аралашкан даирәләребез дә шактый аерылганга күрә, без бер-беребезне шәхсән яхшы ук белмибез. Әмма күрешкән-очрашкан чакта, нишләптер, күптәннән таныш кешеләр кебек сәлам бирешәбез. Олпат һәм мәһабәт буй-сыны, үз бәясен белеп кенә саллы-салмак атлап йөреше, сүзләрен үлчәп һәм бераз вәкарь белән сөйләшүе ирексездән аңа карата хөрмәт хисе уята иде. «Чын ир кеше, татарның зыялы заты шундый булырга тиештер», – дип уйлый идем мин ул чакта. Ә инде 1984 елда борынгы татар әдибе Кол Галигә багышланган саллы хезмәте дөнья күргәч, Нурмөхәммәт Хисамов исеме безнең ише каләм чарлаучылар һәм галим-голәмә арасында гына түгел, ә бөтен укымышлы татар дөньясында танылып өлгерде.

Мәктәптә борынгы татар әдәбиятын өстән-өстән генә укыткангамы, безнең өчен шигъриятебезнең башы, нигездә, Тукайдан гына килә кебек тоела иде. Әби-бабайлардан ишетеп белгән риваятьләрне санамаганда, мин үзем татар әдәбиятының, татар шигъриятенең мең еллар буена тупланып килгән байлыгы, аның бөек әдипләре белән Казан университетында укый башлагач кына таныштым, дисәм, бигүк арттыру булмастыр кебек. Безне бу иксезчиксез дәрьяга алып керүче илаһи зат – олуг галимебез Хатип Госман булды.

Нурмөхәммәт Хисамов иҗатын моңа кадәр төрле китапларда басылган лирик-фәлсәфи шигырьләре, төрле сәхнәләрдә яңгыраган җырлары аша тора-бара шактый ук яхшы белә башлаган булсам да, аның борынгы әдәбиятыбызга, Хатип Госманнан гайре моңа кадәр беркемнең дә «теше үтмәгән», яисә кыюлыгы җитмәгән өлкәгә алынуы бераз гаҗәпкә дә калдырды. Чөнки без инде соңгы елларда шагыйрьләрне бары тик Хәсән Туфан шикелле «Хода бәндәсе» итеп, ә галимнәрне социалистик реализм һәм марксизм-ленинизм тарафдарлары сыйфатында гына күрергә ияләшеп беткән идек. Кол Гали иҗатына багышланган әсәре белән ул бөек Тукайның «мин коеп куйган шагыйрь генә түгел», дигән гыйбрәтле сүзләрен үз мисалында раслады кебек.

Галим Нурмөхәммәт Хисамовны башка күп кенә галимнәрдән аерып торган төп сыйфатларның берсе – аның шагыйрьлегендәдер. Чөнки олуг шагыйрь Кол Галине аңлау һәм аңлату өчен коры гыйльми аналитик акыл гына җитми, шагыйрь рухын, шагыйрь җанын аңлау өчен, һичшиксез, үзеңә дә шагыйрь рухлы булу кирәк. Шагыйрь Нурмөхәммәт Хисамов әсәрләрендә галимлек чалымнары булу, шагыйрәнә хис белән олы тәҗрибәле акылның гел янәшә торуы – шулай ук аның иҗатының үзенчәлеген тәшкил итәдер. Аның яшәешенең, аның шәхесенең, аның иҗатының бер канаты – шигърият булса, икенчесе – фән, гыйльмияттер. Ә күккә – биеккә менү өчен кошларга ике канат кирәк.

*Разил Вәлиев,*
*шагыйрь, Татарстан Дәүләт*
*советы Президиумы әгъзасы.*
*2007*

## ТӨГӘЛ ФИКЕРЛӘҮЧЕ ҺӘМ ТӨЗ ЙӨРҮЧЕ

Юбилей уңаеннан язылган мәкаләләрнең бер кимчелеге була – жанр таләпләренә җавап биреп, аларда шәхес макталырга тиеш булу сәбәпле, аның реаль кеше икәнлеген еш кына онытып җибәрәләр. Чынлыкта исә берәү дә гел «түгәрәк» кенә булмый. Һәрберебезнең «кытыршы» яклары бар. Әмма язма героена текәлебрәк караган очракта аның кемлеген аермачык күреп була, ә инде күргәннән соң, ничек кенә тырышсаң да, ода язарга кирәк. Әгәр дә ул одага лаек түгел икән, аны я мактап булмый, я мактау ясалма булып чыга. Нурмөхәммәт ага турында язганда минем үземдә андый авырлык тумады (хәлбуки, аның «кытыршы» якларын белсәм дә), чөнки тормышта үземнең күз каршымда үткән вакыйгалардан чыгып миндә инде күптән бу шәхес турында төгәл бәя туган иде.

ТӘҺТИдә 1981 елдан бирле эшләгәнлектән, андагы төп галимнәр төркемен, шул исәптән Нурмөхәммәт аганы да, кайбер күзаллау дәрәҗәсендә беләм дип уйлыйм. Һәм бу язманың герое башкалар арасында һәрвакыт ике сыйфаты белән аерылып тора иде: фикерен гадәттән тыш төгәл һәм зәвекъле итеп формалаштыра, икенчедән, һәрвакыт гәүдәсен төз тотып, үзен әйләнә-тирәгә мәһабәтлеген саклаган хәлдә таныта ала. Билгеле, әгәр дә эчке халәттә булмаса, бу сыйфатларны ясалма рәвештә генә тудырып булмый. Төгәлрәк әйтсәк, алар акыл һәм эчке дәрәҗәлелек билгеләре. Бәлки, гомер буе урта гасыр классик әдәбиятын өйрәнү, ул әдәбиятның психологик нечкәлекләрен белү белән дә аңлатыла торгандыр мондый үзенчәлекләр. Чөнки күп күзәткәнем бар: Нурмөхәммәт ага ул чорның шигъриятен бик тирән белә, «белә» генә түгел (андыйлар бар), ә тоемлый, хәтта аның эчендә «яши», «йөзә» ала. Әйтик, нәкъ шул ягы белән кайчак безне генә түгел, төрекләрне дә шаккатыргалады. Ә соңгысы җиңел түгел – төрек интеллектуаллары тоташ берничә сәгать буе шигырь сөйләп тора беләләр.

Иҗтимагый тормыштан да читтә тормады Нурмөхәммәт ага. Монда мин ТӘҺСИ директоры булып рәсми рәвештә төрле иҗтимагый чараларга катнашуны күз алдында тотмыйм. Сүз формаль булмаган, берникадәр дәрәҗәдә «идән астында» эшләнә торган, эшләр турында бара. Әйтик, әле дә бик ачык хәтерлим: бер заман ТИҮдә акылсыз «суллар» көчәйгәч (Зиннур Әһлиуллин һәм

Кашаповлар заманы), бу оешманың пленум әгъзасы булган (бәлки, бу турыда инде күпләр оныткандыр да) галим, кызган һәм акны-караны аера алмаучылар каршында көчле нотык тотып, әйткән иде: «Бездән Махно бандалары ясамагыз, без – дәүләтчеләр, ә җимерүчеләр түгел», – дип. Бүгенге көн яссылыгында да бу сүзләр бик актуаль яңгырый. Алай гына да түгел, аларның бәясе тагы да артты һәм ул дәвердә әйтелгәннәрне, шәхси күзәтүләрем буенча, инде элекке «суллар» да аңлый башлады. Бераз соңарып булса да...

Тагы бер эпизод искә төшә. Милли хәрәкәт 1990 еллар башында икегә аерылып, таркалып көчсезләнгәч, дини оешмаларның әһәмияте арта башлады. Шул вакытта мин үзем һәм ТИҮнең кайбер элекке лидерлары Габдулла хәзрәт Галиулла тирәсендә оешып, мөфтиятне көчәйтеп, аны милли үзәк итеп файдалану турында уйланган идек. 1995 елда эш, Татарстан Президенты М. Шәймиев белән килешеп (аның киңәшчесе Р. Хәкимов аркылы), Казанда Бөтенрусия мөселманнары корылтае җыюга керешүгә барып җитте. Планнар зурдан иде: Татарстанда бердәм, Русия өчен уртак мөфтият булдыру. Ләкин Габдулла хәзрәтнең уйламыйча «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен алырга тырышуы һәм шул вакытта килеп чыккан сәяси кризис нәтиҗәсендә бу фикер тормышка ашмады. Алай гына да түгел, Татарстан мөфтиятен ныгытырга кирәклеге дә ачылды. Шул уңайдан (аның нәтиҗәсе буларак республикада тулы канлы мөселманнар съезды үтте, яңа мөфти сайланды) берничә кеше, алар арасында Нурмөхәммәт ага да, бу бик тә четерекле эшне башкарып чыгуда төп рольне уйнадылар.

Дөрес, монда «югарыдан» импульс бар иде, ләкин иҗтимагый тормышта ул гына җитми, бигрәк тә 1990 елларның урталарында зыялыларның катнашыннан башка моны ерып чыгу мөмкин түгел иде. Өч кеше (Нурмөхәммәт ага, Рафыйк Мөхәммәтшин һәм мин) корылтайның бөтен программа, резолюция кәгазьләрен яздылар, булачак мөфтигә нотыкны эшләделәр, аны арттан «терәделәр» һәм, гомумән, корылтайның эчтәлеген тәэмин иттеләр. Корылтай уңышлы үтте, республикада мөселманнар бербөтен булып тупланды, ягъни, сәяси нәтиҗә күренде. Дөрес, берничә елдан яңа мөфти аны «күтәрүчеләр» турында онытты... Әмма, Нурмөхәммәт агага да, минем өчен дә башкарылган эш әһәмиятлерәк иде: мөфтиләр алга таба да алмашыначак, әмма Татарстан мөселманнарының

Үзәк оешмасы – Дини идарә республика яшәгәндә үз урынында калачак.

Соңгы штрих итеп тагын бер мәсьәләгә тукталыйм. Бәлки күпләр аңлап та бетермиләрдер, ТӘҺСИ директоры булып эшләү ул «җылы урында» утыру түгел, чөнки бу кәнәфи аның өчен җайлашмаган. Һәм, әйтергә кирәк, Н. Хисамов бу данлыклы институтны җитәкләгән чорда коллектив өчен шактый гына уңай нәрсәләр башкарды. Мәсәлән, юлбарыс авызына кереп булса да, квартиралар алды (хезмәткәрләр моны яхшы беләләр), безнең гадәттән тыш аз күләмле булган академик бюджетка таянып, бу институтта компьютерларны күбәйтте, китаплар чыгаруны оештырды, күпсанлы (шул исәптән, халыкара дәрәҗәдә) конференцияләрне башкарып чыкты. Болар барысы да егетлек билгеләре һәм яңа буынга үрнәк.

Мин, форсаттан файдаланып, Нурмөхәммәт агага чын күңелдән иҗади уңышлар һәм озын гомер теләп калам.

*Дамир Исхаков,*
*тарих фәннәре докторы.*
*2007*

## ҖАН ИХТЫЯҖЫ

Бүген Татар Дөньясы үзенең Хәтеренә, Асылына кайту юлында. Хәзер беләбез инде: бу юл үтә дә катлаулы, каршылыклы һәм гыйбрәтле булып чыкты. Татар мәдәни, әдәби мирасының мең еллык тарихы бар, дибез икән, аның һәр елы, һәр сәхифәсе тоташ дан-шөһрәттән генә түгел, гамь-сагыштан, кан-яшьтән һәм аянычлы фаҗигаләрдән торуын да белергә тиешбез. Шушы рухи мирасыбызның бөртеген дә югалтмаска, чәчмәскә тырышып, аны бүгенге татарыбызга кайтаручы «хәтер сакчылары»ның – мөхтәрәм галимнәребезнең күңел ярсуларын, җан әрнүләрен дә тоярга тиешбез! Алар – рухи тарихыбыздан саркып чыккан серле-сихерле образларның, чынлыкта – милли символларыбызның, бүгенге тормыш фәлсәфәсенә нигез булган зиһен катламнарының һәм яшәү идеалларының беренче шаһитләре, Милләтебезнең хәтер сакчылары.

Күренекле әдәбият галиме Нурмөхәммәт Хисамовның «Хәтер сагында» («Мәгариф» нәшрияте, 2004) исемле әдәби-фәнни һәм

публицистик мәкаләләр җыентыгын кулга алгач, күңелемдә шундый уй-тойгылар туды.

Нурмөхәммәт ага – минем дә фәнни һәм рухи остазым. Профессор Хатип Госман һәм татар шигырь поэтикасына нигез салып калдырган Нил Юзиев белән бергә ул мине әдәбият гыйлеменең серләренә өйрәтте, хәтта ерак 1983 елда, «Татар балладасы» буенча диссертация яклап йөргән чорларда, минем тыйнак кына фәнни хезмәтемне югары бәяләүчеләрнең берсе булды.

Тугрылык һәм ихласлык төшенчәләрен фән дөньясына алып кергән кешеләрнең берсе ул. Күп еллар буе татар филологиясе фәненә тугры хезмәт итүче, бүгенге көндә Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтының башында торучы профессор Нурмөхәммәт Хисамов өчен фәнгә, мираска, әдәбиятка тугрылык халыкка, милләткә тугрылык белән бер дәрәҗәдә карала. Бихисап күп шәкертләре, каләмдәшләре һәм замандашлары да аны шушы сыйфаты өчен үз итәләр, хөрмәт итәләр.

Өстәвенә ул шагыйрь дә әле. Аның ихласлыгы әнә шул шагыйрьлегеннән килә дә инде. Күңелендәге «шигырь орлыгы», «шигырь тоемы» Нурмөхәммәт агага тоташ шигырь һәм моң традициясенә нигезләнгән рухи мирасыбызны аңларга, тоярга, кичерергә ярдәм итсә, шул ук вакытта, фән-гыйлем дөньясында бик үк кадере булмаган күңел сафлыгы, кешелеклелек кебек сыйфатларны сакларга, якларга булыша.

«Хәтер сагында» җыентыгы – галим өчен мәгълүм бер дәрәҗәдә нәтиҗә, йомгак китабы. Шулай була бит, кеше, мөһим бер тормыш этабын үткәч, артына борылып карый, үткәннәрне, эшләнгән эшләрне барлый, аларга үзенчә бәя бирә, үз хезмәтен халкы, милләте, Ватаны язмышы белән тәңгәл куя, киләчәккә ниятләр кора. Бөек шәхесләр гадәттә мондый эшләрне тарихның борылыш моментларында, яңа дәвергә аяк басканда, халык язмышы хәл ителгән кискен бер чорда башкаралар. Нурмөхәммәт ага Хисамов ул чорны дөрес тотып алган. Бүген – халкыбызның, милләтебезнең һәм мөстәкыйльлегебезнең хәл ителгән чагы. Бүген без үткәннәрдән акыл алып, киләчәккә яңа ниятләр корырга тиешбез. Рухыбызны ныгытырга тиешбез. Моны бары тик әдәби, мәдәни мирасыбыздан алынган образ-символларыбызны, меңәр ел буе дөнья халыклары каршында үрнәк булып торган рухиятебезне

байрак итеп күтәреп кенә эшли алачакбыз. Нурмөхәммәт аганың яңа китабы безне шуңа инандыра.

Мәҗмуга концептуаль мәгънәгә ия. «Әдәбиятта хәтернең эчтәлеген мирас тәшкил итә, – дип яза галим. – Безнең бөек әдәби мирасыбыз халкыбызның Ауразия киңлекләрендә, Шәрекь белән Гареб арасында лаеклы урын билгеләгәнлеген, кешелек дөньясы өчен гаять кыйммәтле һәм гыйбрәтле фикри проблемалар күтәргәнен искә төшереп тора. Аңардагы югалмас гамәл һәм гакыл формулалары бүгенге яшәү көрәше өчен дә әһәмиятле».

Исеме үк авторның максатын искәртеп торган бу җыентык борынгы һәм урта гасыр татар әдәбияты проблемаларын да, XX йөз башы шигърияте казанышларын, шулай ук бүгенге рухи һәм сәяси вазгыятебезне дә үз эченә ала, автор бер уңайдан татарның «сәнгатьчелек мәктәбенә», әдәбиятыбыздагы гомумилек һәм индивидуальлек мәсьәләсенә, иҗтимагый-әхлакый темаларга да кагылып үтә. Тагын бер авырткан җир: кадер проблемасы. «Бөек сәнгатькәрләребезнең үз вакытында кадерен белү – хәтер эше, – ди галим. – Бу – рухани дөньябызны фәкыйрьләтмәү, халыклар һәм тарих каршында үкенечкә калып йөз кызартмау өчен мөһим».

Китапның «Тамырлар кайдан килә?» дигән бүлеге «Яңача фикерләү һәм татар әдәбияты тарихы концепциясе» дигән принципиаль язма белән ачыла. Бу язмада автор «татар әдәбияты тарихының яңа версиясен» булдыру өчен мөһим саналган өч төп шартны ачыклап куя. Ахыр чиктә, җыентыктагы калган язмалар да шушы принципларны раслауга һәм дә дәлилләүгә хезмәт итә.

«Беренче һәм төп таләп минем күз алдына шулай килә, – дип яза Н. Хисамов, – әдәби дәверләр күпкырлы идея-сәнгатьчә эзләнүләрдән торган эзлекле, кануниятле һәм бердәм процесс рәвешендә яктыртылырга тиеш. Ул аерым күренеш һәм ядкәрләрнең бер-бер артлы тезелгән эзлекле гади хронологик чылбыры гына булмаска тиеш». Икенче таләп беренчесеннән килеп чыга. «Әдәбият үсешен, – ди галим, – XIX гасырны да кертеп, дөньяви һәм дини-рухани эчтәлекнең бердәмлеге рәвешендә тикшерергә кирәк». Бу ике шарт үзеннән-үзе өченчесен – иң әһәмиятлесен һәм иң катлаулысын таләп итә. Н. Хисамов әдәбият тарихын өйрәнү концепциясе нигезендә «әдәби күренешләрне объектив-тарихи» бәяләү ята, дигән, беренче карашка үтә дә таныш һәм аңлаешлы,

әмма моңа кадәр эчтәлеге тар мәгънәдә – танып-белү фәлсәфәсе аша гына кабул ителеп йөргән фикерне алга сөрә. «Бу исә әдәбият тарихының борынгы катламнарын тикшергәндә аларга безнең заманга хас сыйфатлар тагудан, ә яңа чор әдәбиятын анализлаганда субъективлыктан һәм дәшми узудан качарга ярдәм итәр», – ди ул. Шулай итеп, Н. Хисамов, беренчеләрдән булып, принципиаль рәвештә әдәбият тарихын өйрәнүнең яңа концепциясе мәсьәләсен күтәреп чыга һәм аны турыдан-туры объективлык, тарихилык, эзлеклелек һәм бөтенлек шартлары белән бәйли, шул ук вакытта тарихи дәвер һәм баскычлар яктыртылышында тәңгәл нисбәт саклануны таләп итә.

Н. Хисамов – ике томлык «Татар поэзиясе антологиясе»нә кереш сүз язган галим. Ул бу хезмәтендә бүгенге чор татар галимнәре арасында, беренчеләрдән булып, татар шигърияте тарихын, – ә ул тулысынча татар язма әдәбиятының да үсеш этапларын үз эченә ала, – системага салып чыкты, төп акцентларны куйды, дәвер чикләрен билгеләде. Аерым алганда, ул татар шигырен хаклы рәвештә Орхон-Енисей чөй язуларыннан алып өйрәнде, Йосыф Баласагунлы, Мәхмүд Кашгари иҗатларын олы шигърият юлының әзерлек этаплары итеп карады, ә инде Әхмәд Ясәвине (XII йөз) татар шагыйрьләренең беренче остазы дип игълан итте. «Кол Гали Әхмәд Ясәви шигъри мәктәбенә таянып эш итә. Поэманың строфасын ул туп-туры үзенең төркестанлы остазыннан алган», – дип язды ул.

Татарның беренче бөек әсәре саналган «Кыйссаи Йосыф» поэмасын өйрәнүгә аеруча күп көч куйды Нурмөхәммәт ага. Бу әсәр аның җанында, язмышында. Нинди генә хезмәткә тотынса да, ул шушы бөек әсәрдән башлап китә һәм шушы әсәрне телгә алып тәмамлый торган булды. «Кыйссаи Йосыф» поэмасы – гомумтөрки әдәбият планында булсын, болгар-татар әдәбияты тарихында булсын – этап әһәмиятенә ия, – дип белдерде ул. – Аның тарихи үзенчәлеге һәм яңалыгы, барыннан да элек, шунда була: ул – төрки язма поэзиянең зур күләмле беренче сюжетлы әсәре». Поэманың гуманитар мәгънәсен дә беренче буларак Нурмөхәммәт ага ачып бирде. Бар кыйммәтләр арасында иң олы кыйммәт – кеше шәхесе дигән идеяне әсәрнең образлар системасыннан, андагы серле дә, табигый дә язмышлардан саркытып ала белде, аеруча Йосыф-Кеше язмышын дини тәгълиматтан, хәтта мәхәббәт яссылыгыннан

калкытыбрак куя алды, аны нәсел-нәсәб, буыннар язмышына китереп ялгады, ә төп сюжет интригасын аталар һәм балалар проблемасына юнәлтте. Хәзер икеләнмичә әйтә алабыз: Нурмөхәммәт Хисамовның «Кыйссаи Йосыф» хакындагы хезмәтләре бөтен әдәбият тарихы белемендә зур ачыш булды; бу ачыш Кол Галидән соң килеп киткән бөек шагыйрьләребез иҗатын өйрәнүгә дә хәлиткеч йогынты ясады. Н. Хисамовтан соң галимнәр борынгы әдәби ядкәрләрне гуманлылык позициясеннән торып, ягъни үзәккә Кеше шәхесен куеп өйрәнә башлады.

«XIV йөз Идел буе төрки поэзиясе җәмгыятьнең гакылы һәм вөҗданы буларак калкып чыга», – дип яза Н. Хисамов. Мәсәлән, Котб каләменнән төшкән «Хөсрәү вә Ширин» әсәренең «гуманистик көче шунда: ул мәхәббәтне игелекле эшләргә этәргеч итеп тасвирлый». Харәзминең «Мәхәббәтнамә» поэмасында да, Хөсам Кятибнең «Җөмҗөмә Солтан» дастанында да мәхәббәт һәм тәкъдир мәсьәләсе кеше гомере белән тәңгәл, хәтта аның аша хәл ителә.

Сәйф Сараинең «Гөлстан бит-төрки» әсәре белән «Сөһәйл илә Гөлдерсен» поэмасын да Н. Хисамов тарихи гуманизм традицияләренә таянып бәяли. Иҗтимагый протест белән космогоник реализм (анысы Котбтан ук килә) элементлары ярылып яткан бу әсәрләр шулай ук татар әдәбияты тарихында казаныш этабы буларак каралырга хаклы.

XVI йөзнең беренче яртысында иҗат иткән Мөхәммәдъяр иҗаты да гуманистик образлылыкныраслаучы яңа этап. Аннары – Утыз Имәни дәвере, Кандалыйның демократик шигърияте, Тукайның, С. Рәмиевнең, Дәрдемәнднең «сәнгатьчәлек мәктәбе»...

Һәм менә, олы галим тарафыннан гына әйтелә ала торган мөһим сүз әйтелә: «XX гасыр башы поэзиясе, мең еллык үсеш һәм үзгәрешкә йомгак ясап, якындагы бөек яңарышка җирлек әзерләде».

Татар әдәбияты тарихының мөһим мәсьәләләрен өйрәнүгә гомерен багышлаган галим тагын ике мөһим проблеманы хәл итәргә алына.

Беренчесе – татар әдәбияты һәм ислам тәгълиматы. Н. Хисамов бу темага концептуаль эчтәлек бирә. «922 елда Болгар дәүләтенең Ислам динен кабул итүе татар халкының борынгы бабаларына шул чорның мәдәни халыклары белән бер сафка басарга

һәм кешелек прогрессының гомуми хәрәкәтенә кушылырга мөмкинлек биргән». Бу уңайдан автор мөселман Көнчыгышында әдәбиятның гаять киң төшенчәгә ия булуын ассызыклап искәртә. Ул фәлсәфи әдәбиятны да, хокук, медицина, астрономия, тарих, дин гыйлемнәренә кагылышлы хезмәтләрне дә, нәфис әдәбиятны да үз эченә алган. Н. Хисамов фикеренчә, борынгы һәм урта гасыр татар әдәбиятының синкретик характерда булуы иң элек шушы йогынты, тәэсир, традиция белән бәйләнгән. Монысы мәсьәләнең күзгә күренеп торган ягы гына. Аның эчке асылын, төп мәгънәсен галим илаһи тәгълимат белән гуманизм идеалларының гармониясенә бәйләп күрсәтә. «Илаһият, – дип яза ул, – матур әдәбиятта рәнҗетелгәннәрне яклаучы, гаделсезлектән кисәтүче, гаделлек гаранты буларак яктыртыла. Ягъни әдәбият ислам диненең абсолют авторитеты булган илаһиятне үзенең гуманистик идеалларына таяныч итеп ала». Бу принципны XIII йөз башында кыска һәм ачык итеп Кол Гали формалаштыра, ә XX йөз башында мәшһүр Тукай аны Яңа дәвер яңарыш поэзиясе рухында трансформацияли.

Кыскасы, җиде гасыр буе татар әдипләре «дин тәгълиматында эшләнгән система нигезендә әлеге ике башлангычны – тәкъдирнең алдан ук хәл кылынуын һәм кешенең ул кысалардагы хәрәкәт ирекен – берләштерергә тырышканнар».

Галимнең игътибарын һәрвакыт үзенә тартып торган тагын бер мәсьәлә – әдәби бәйләнешләр мәсьәләсе. «Хәтер сагында» җыентыгына урнаштырылган һәр мәкаләдә диярлек әдәби бәйләнешләр, йогынтылар хакында сүз бара. Бу аңлашыла да. Милли әдәбият изоляция шартларында яши алмый, бигрәк тә үсә алмый. Төрле цивилизацияләрнең, культураларның, традицияләрнең очрашу урыны буларак, Идел буе әдәбияты, башлыча, шундый рухи бәйләнешләр нәтиҗәсендә формалаша. Бу бәйләнешләр болгар-татар әдәбияты өчен генә түгел, мәдәниятнең Шәрекъ тибына караган бүтән төбәкләрдәге әдәбиятлар үсеше өчен дә зарури шарт булып торган, һәм ул процесс даими, системалы һәм диалектик рәвештә барган. Бу өлкәдә зур белгеч буларак, Н. Хисамов татар шигыренең эволюциясен дә шәркый бәйләнешләргә бәйләп аңлата. «Төрки шигырь ун гасырга якын гарәп һәм фарсыларның гаруз системасына нигезләнеп үскән», – ди ул. Ә инде «Кыйссаи Йосыф» поэмасын гомумән дә Шәрекъ әдәбияты системасының бер элемен-

ты итеп карый, аның нигезенә Табариның «Олуг тәфсир»ендәге (X йөз), Фирдәүсинең «Йосыф вә Зөләйхә» поэмасындагы (X йөз), фарсы галиме шәех Габдуллаһ Әнсаринең «Әнисел мөридин вә шәмсел мәҗалис» («Мөридләрнең дусты һәм мәҗлесләр кояшы») исемле чәчмә әсәрендәге (XI йөз) һәм фарсыча «Кыйссасел әнбия»дәге мәгълүмат салынганлыгын искәртә. Әлбәттә, монда Низами традицияләрен дә исәптән чыгарырга ярамый. Чынлыкта урта гасыр татар әдәбиятындагы һәр поэма, дастан, газәл, робагый, хикмәт, яисә хикәят белән эш шулай. Тәкълидчелек, назыйрәчелек рухы Тукайлар чорына кадәр килә, ул бүгенге көндә дә татар шигъриятендә матур традиция буларак яши.

Иң кызыгы шунда: һәр татар шагыйренең үзенә йөкләнгән традициясе, әйтергә яраса, миссиясе бар. Әйтик, Кол Гали үз иҗатында Фирдәүсигә ныграк таянса, «Низами казанышларын төрки поэзиягә алып килү бурычын XIV йөз шагыйре Котб үти». Котбтан соң килгән Харәзми дә үзенең «Мәхәббәтнамә»сендә фарсы поэзиясе белән бәйле традицияләрне дәвам итә, шулай ук Нәваи белән рухташ әсәрләр яза. Хөсам Кятиб фарсыларның XIIгасырда яшәгән суфи шагыйре Фәридетдин Гаттар әсәренә таянып, Кисекбаш темасын дәвам итә.

«Сәйф Сарайның Сәгъди “Гөлстан”ын (XII) төркичәгә тәрҗемә итүендә дә актив ярыш элементлары ярылып ята». Н. Хисамов төрки-татар поэтик мәктәбенең, иң элек, фарсы шигърияте казанышларына таянып, хәтта алар белән ярышып үсүен искәртә һәм бу багланышларның нигезендә мөселман культурасы белән бәйле традицияләр генә түгел, бәлки, борынгылыктан – халыкның легендар мирасыннан килгән, чын тарихка кадәрге кан-җан, нәселнәсәп багланышларының ятуын да әйтә. Бу бүгенге әдәбият гыйлемендә өр-яңа сүз иде.

Җыентыкка урнаштырылган бер мәкалә «Әдәби мирас һәм милләт бердәмлеге» дип атала. Ә бит Нурмөхәммәт аганың һәрбер язмасына шушы исемне биреп булыр иде. Остазым бу ике төшенчәне бервакытта да аерып карамады: мирас һәм милләт. «Кыйссаи Йосыф» поэмасына багышланган фундаменталь хезмәтләрендә дә (аларда бүген безгә җитеп бетми торган бердәмлек, тугрылык, зирәклек, батырлык сыйфатларына дан җырлана), Әхмәд Ясәвигә («Әхмәд Ясәви һәм Кол Гали»), Утыз Имәнигә («Г. Утыз Имәни –

«Кыйссаи Йосыф» текстологы»), Котб, Харәзми, Хөсам Кятиб, Сәйф Сараи иҗатларына («XIV йөз татар шигъриятендә кеше идеалы»), Кол Шәриф мирасына («Казан ханлыгы шигърияте»), Г. Тукайга, Дәрдемәндкә, С. Рәмиевкә багышланган мәкаләләрдә милләт язмышы беренче планга чыга.

XX гасыр башы татар әдәбияты хакында галим менә ничек яза: «XX йөз башында татар әдәбияты гигант сикереш ясый. Үсеш инерциясе, алгарыш куәсе узгандагы озын гомерле һәм бай мираска таянмаганда бу мөмкин булмаган эш. Ходайга шөкер, безнең андый мирасыбыз бар. Болгар дәүләте дәвере дә, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорлары да безгә бөек мәгънәви мирас калдырган. [Бу мирас]... халкыбызга һәрвакыт үзенең бөеклеген тоеп яшәргә нигез биргән бәрәкәтле байлык. Шушы мәгънәви мая татар халкына, дәүләтсез калып бәйсезлеген югалткач та, бөтенләй гаҗизлеккә төшмәскә, яшәүгә һәм җиңүгә ихтыярын җуймаска ярдәм иткән».

Икенче бер урында автор Тукай, Дәрдемәнд һәм С Рәмиев хакында: шагыйрьләрнең өчесе дә «милләтнең лаеклы яшәешкә хокукын раслаучылар, аның ихтыяҗларын, тарихка, язмышка, дәүләткә карата дәгъваларын гәүдәләндерүчеләр», дип яза. Шул ук вакытта Н. Хисамов бу өч шагыйрьнең гражданлык миссиясен бер-берсенә тәңгәл куймый. Аныңча, Тукай шигъриятендә тарихи зар да, яшәешкә һәм яңарышка ихтыяр да иҗтимагый актив, максималистларча кискен гәүдәләнсә, С Рәмиев лирикасында шәхеснең мохиткә, иҗтимагый шартларга ярсу таләпләре һәм ризасызлыгы яңгырый. Дәрдемәндтә исә мәсьәләләр тарих һәм галәм киңлегендә куелып, фәлсәфи планда ячтыртыла.

Гомумән, шигърият белгече буларак, Н. Хисамов татар шигърияте мәйданында исем йөрткән һәр шагыйрьгә үзенең төпле бәясен бирә, аларның татар дөньясында тоткан урынын, ролен төгәл билгели. Бу XX гасырда яшәгән әдипләргә дә, бүгенге көн шагыйрьләренә дә бердәй кагыла. Менә аның Такташка биргән бәясе: «Яңа чорның давыллы, өермәле рухына тәңгәл, үзенең тулы хөрлектән гыйбарәт җанына, тулысынча чишелгән рухиятенә тапкыр гайрәт һәм темпераментны чагылдырган шигъри аһәң һәм стиль җирлегендә Һади Такташ татар һәм бөтен төрки шигъри дөньясында өр-яңа дәверне башлап җибәрде». Шунысы мөһим, автор

күренекле шагыйрьләребезнең иҗатына кыска һәм төгәл бәя бирә, шушы кыска гына бәядә шагыйрьнең иҗат зурлыгын, иҗтимагый миссиясен һәм поэтик үзенчәлеген, шигъри мәктәбен, традициясен ачып салырга өлгерә. «Аның гражданлык батырлыгы, – дип яза ул Х. Туфан феномены хакында, – тирән милли гамь белән сугарылган һәм компромиссыз инсани гаделлек таләбен эченә алган шигърияте үзенең актив иҗтимагый пафосы белән турыдан-туры Тукайдан үсеп чыкса, лирикасының фәлсәфи тирәнлеге, шигъри тасвир җәһәтеннән тыгыз тәнле сәнгать күренеше булуы һичшиксез Дәрдемәнд мәктәбеннән килә».

Равил Фәйзуллин иҗатына багышланган хезмәт үзенең исеме белән үк нинди мәгънәви егәрлекне дәгъва итүен әйтеп тора: «Тирән хакыйкатьләр дөньясы». Н. Хисамовта шулай гына була ала; ул шагыйрь иҗатының иң нечкә кылларын чиртеп уйный, иң егәрле буыннарын алып, аны халык, милләт язмышы белән сыный, һәм менә нәтиҗә: «Равил Фәйзуллин – “фәлән мәктәп” шагыйре түгел, ... ул үзе мәктәп». Шулай ук традицияләр дә ачыклана: «Шагыйрьнең чордашларына әхлак, иман, гамәл өлгесе булырлык шигъри формулалары, афористик төгәллектә юралган хакыйкатьләре аны Сәйф Сараилар һәм Дәрдемәнд мирасын дәвам итүче сыйфатында күз алдына бастыра».

Автор Ренат Харис иҗаты хакында да моңа кадәр беркем әйтмәгәнне әйтә алган. Шагыйрьне «бүтән шагыйрьләрдән аерып торган сыйфат ул – аның бөтен иҗатын сугарып килгән этнографизм, – ди ул. – Ягъни шагыйрь халкының тарихтан килә торган гүзәл гореф-гадәтләрен үтә кадерләп барлый, бу исә аның шигырьләренә халыкчан затлылык һәм югары яңгыраш бирә».

«Зиннур Мансуров, – дип яза галим „Күңел тирәнлеге” дигән мәкаләсендә, – тирән кичерешле, аз сүзле шагыйрь. Ул уйларын ачып, сүзен әйтеп бетерми. Укучының үзенә уйланырга калдыра. Аның иҗтимагый колачлы шигырьләреннән башлап, интим-мәхәббәт шигырьләренәчә сер тулы. Серлелек – безнең бөек классикларыбыздан килә торган сәнгати, талантлы сыйфат».

Шигъриятнең үзәк хасиятләрен һәм фәлсәфи-сәнгати нечкәлек, поэтика, стиль, традициялелек кануннарын белеп эш иткән галим бүгенге чор татар әдипләренең иҗади, поэтик үзенчәлекләрен, гражданлык позицияләрен гаять төгәл билгели. Аның

Г. Афзал, И. Юзиев, Рәшит Әхмәтҗанов, Ә. Баян, Х. Әюпов, Ш. Маннур, М. Әгъләмов, Зөлфәт, Р. Гаташ, Р. Миңнуллин, Г. Морат иҗатларына биргән бәяләмәләре бүгенге көндә әдәби тәнкыйтьнең югары үрнәге булып тора.

Гыйльми институт директоры, профессор Нурмөхәммәт Хисамов татар дөньясында мәшһүр исем булдырган галимнәр хакында язмаса, бик сәер тоелыр иде. «Хәтер сагында» җыентыгында андый характердагы мәкаләләр шактый. Габдрахман Таһирҗанов, Мөхәммәт Гайнуллин, Нәкый Исәнбәт, Хатип Госман, Нил Юзиев, Мансур Хәсәнов, Илбарис Надиров, Хуҗи Мәхмүтов, Шәйхи Садретдинов – боларның барысы да төрки-татар әдәбият гыйлеменең тарихын язган, бу данлы тарихта үзләренең фәнни мәктәпләрен, сәхифәләрен булдырган мәшһүр затлар. Хәтер сагында торучылар. Милләт сакчылары. Татарның танылган шәхесләре хакында язганда автор укучының башын катырмыйча, җиңел, җанлы сөйләм теле кулланып, татар әдәбият гыйлемен халык арасында популярлаштыра. Аның милләтебезнең горурлыгы булып әверелгән танылган композиторларыбыз, җырчыларыбыз хакындагы язмалары (Илһам Шакиров, Айрат Арсланов, Әлфия Афзалова, Рәшит Ваһапов, Рөстәм Яхин, Хәйдәр Бигичев, Зилә Сөнгатуллина) аеруча җылы һәм ягымлы өслүбтә язылган. Аларны да Нурмөхәммәт аганың никадәр киң диапазонлы, һәр нәрсәдән хәбәрдар һәм бай рухи дөньяга, күңел тоемына ия булган талантлы, ихлас кеше икәнлегенә сокланып һәм сөенеп укыйсың. Аларда да шул үк милләт, милли моң мәсьәләсе, рухи мирас һәм сәнгать язмышы. Еш кына борчулы ноталар да яңгырап китә. Әмма Нурмөхәммәт аганың күңеленә һәм каләменә бер сыйфат хас – аның һәр язмасы укучы күңелендә өмет калдыра, тормышка, киләчәккә ышанычны, яшәүгә дәртне ныгыта.

Җыентыкның «Республикам – горурлыгым» дигән бүлегенә актуаль-публицистик язмалар тупланган. Монда да шул ук фикер, шул ук хис: хәтерне саклау, хәтергә кайту. Бу юлы хәтер төшенчәсе мөстәкыйльлек, милләтпәрвәрлек төшенчәләре белән тәңгәл куела, демократиягә, халык мәнфәгатьләренә тугрылык, телгә, мираска игътибар, бәйсезлек идеологиясе, Татарстан ватандарлыгы идеясе кебек иман шартлары белән ныгытыла. Остазымның дәүләтчелек, вөҗдан иреге, милләтнең рухани саулыгы, тел сафлыгы, милли

әхлак, милли генофонд проблемалары хакындагы фикерләре бүген дә көн тәртибеннән төшмәгән әле.

Милләт, мирас язмышына кагылган мәсьәләләрдә кискен, принципиаль дә була белә Нурмөхәммәт ага («Килешмәскә рөхсәт итегез», «Бирешмик, сынатмыйк», «Кем гаепле?»). Ә менә туган төбәге, туган авылы, нигезе хакындагы язмаларда ул кинәт басылып, моңсуланып, сагышланып кала, әмма бу очракта да үзенең миссиясен онытмый – якташларының борчылуын уртаклашырга тырыша, авыр мәсьәләләрне хәл итәргә алына.

Кыскасы, безнең алда – олы шәхеснең олы дөньясы. Ул – борчулы да, мәшәкатьле дә, өметле дә. Кайчандыр татар рухына көч биргән, аны милләт буларак тәрбияләгән Ш. Мәрҗаниләргә, Р. Фәхретдиновларга тиң галим язмышы, һәм аның күңел кыйбласы, иманы: «Милли рух һәм аның телдәге, рухи дөньядагы чагылышы кемнәрнеңдер тырышлыгына салынмыйча, һәр шәхеснең җан ихтыяҗы булырга тиеш. Шунсыз зыялылык мөмкин түгел».

*Галимҗан Гыйльманов,*
*язучы, Татарстанның*
*атказанган сәнгать эшлеклесе.*
*2007*

## УЧЕНЫЙ, НАСТАВНИК, ЧЕЛОВЕК

В дни юбилея Нурмухаммета Шагвалеевича Хисамова наверняка будет сказано немало добрых слов о его многолетней и плодотворной научной деятельности. И в самом деле, на эту тему можно говорить долго, поскольку ученый сделал невероятно много для татарской гуманитарной науки и до сих пор продолжает активную научную работу.

Мне, как бывшему аспиранту Н.Ш. Хисамова, хотелось бы рассказать о своем научном руководителе как о наставнике и просто человеке.

Мое знакомство с Нурмухамметом абый (ученый предпочитает такое традиционное татарское обращение) состоялось в начале 1990-х годов. В то время я обучался на факультете татарской филологии, истории и восточных языков КГУ. Мы изучали

арабский язык и, конечно же, мечтали о поездке на Восток, чтобы усовершенствовать свои познания в языке. Именно тогда Нурмухаммет абый занялся вопросами нашей стажировки в арабских странах. Казалось бы, зачем человеку, работающему в другом научном заведении и не имеющему прямого отношения к процессу обучения студентов татфака, взваливать на свои плечи эту проблему? Смысл этого мне удалось понять позже. Ученый беспокоился о будущем науки, о том, кто придет на смену старшему поколению татарских ученых-литературоведов, текстологов и археографов. В те годы гуманитарная наука испытывала острый дефицит в специалистах, владеющих восточными языками и, прежде всего, арабским, персидским, турецким. Старшее поколение ученых, которые получили образование еще в дореволюционных медресе, уже ушло, а среднее поколение ученых в силу известных обстоятельств советской действительности не владело восточными языками.

Позже, когда я окончил Казанский университет и прошел языковую стажировку в Ливане, решил поступать в аспирантуру Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова. Моим научным руководителем стал Нурмухаммет Шагвалеевич, который и предложил невероятно интересную, но и одновременно с этим невероятно сложную тему, связанную с изучением древних арабо-персидских источников средневековой татарской литературы. В частности, речь шла об известном персидском богослове и историке Абу Джагфаре Ибн Джарире ат-Табари (X в.), комментарии Корана которого, по некоторым предположениям, стали источником вдохновения для булгаро-татарского поэта Кул Гали. У моего научного руководителя, конечно же, были свои наработки в этом направлении, но для того, чтобы получить окончательный результат, необходимо было, бросив все, заниматься только этой темой. Таким образом, эта тема перешла «по наследству» мне. Четыре года напряженной работы с источниками, и предположения Нурмухаммета Шагвалеевича были подтверждены. Но разговор сейчас не об этом, а о самом Нурмухаммете абый и его методах научного руководства.

Необходимо заметить, что почти все аспиранты, которые проводили научные исследования под его руководством, успешно за-

щитились и теперь занимаются активной научной и общественной деятельностью в самых различных академических институтах, вузах и школах, других организациях, а некоторые из них уже сами стали докторами наук и теперь готовят своих аспирантов. В чем же секрет его такого удачного наставничества? Секрет прост. Нурмухаммет абый никогда не занимается мелочной опекой своих аспирантов, предоставляя им свободу научного творчества. Но наряду с этим он умеет жестко спрашивать за конечный результат, поскольку не терпит любительщины, непрофессионализма, а также поверхностного изложения изучаемого предмета. Настоящий ученый в его понимании должен не только досконально знать предмет исследования, но и разбираться в философии, литературе, искусстве – говоря иначе, быть всесторонне развитым человеком.

Нурмухаммет абый – очень тактичный и интеллигентный человек. Эта интеллигентность и даже некоторый аристократизм имеют глубокие корни – родители и предки ученого были образованными людьми, интеллектуалами своего времени. Все это сказывается и на характере ученого-литературоведа. Если Нурмухаммет абый будет недоволен результатом, то никогда не станет читать нотаций или повышать голоса, а просто спокойно и аргументированно выскажет все свои претензии. Заслужить его доверие сложно, еще труднее получить его положительную оценку по отношению к научному продукту, который, как уже было сказано, в понятии Нурмухаммета Хисамова должен соответствовать самым высоким требованиям. Образцом для него являются работы лучших российских и зарубежных тюркологов, поэтому он и требует от своих учеников как можно выше поднимать планку научных исследований.

Нурмухаммет Шагвалеевич Хисамов относится к разряду тех ученых, для которых научная истина дороже всего. Он никогда не стремился выдавать научный продукт на-гора, оставался верным своей теме, даже в годы так называемого развитого социализма, когда от ученых требовали верности генеральной линии партии, «выверенных» трактовок, которые по сути сводились к одной мысли: все, что было до 1917 года, – отсталое и загнивающее, а после – цветущее и развивающееся. Что греха таить – многие ученые слепо следовали этим установкам, не каждый мог высказать свою

мысль прямо и открыто. Доходило до смешного. Если речь шла о памятнике средневековой татарской литературы, то говорили, что автор «не дорос до уровня „Божественной комедии" Данте», если о произведении XIX века, то необходимо было отметить «отсталость» в сравнении с трудами, например, Александра Герцена.

А ведь Н.Ш. Хисамов всю жизнь занимался достаточно «горячими» темами. Еще в годы учебы в университете он взялся за изучение творчества тогда еще опального поэта Дэрдменда, позже начал исследовать памятник татарской литературы XIII века «Кысса-и Йусуф» Кул Гали. Это были не то чтобы «не модные», а по настоящему опасные темы. Изучение их было сродни хождению по лезвию ножа: шаг влево – и ты уже «националист», шаг вправо – и на тебя навешивают ярлык «сочувствующего феодалам и баям».

Я хорошо знаком с научным творчеством Нурмухаммета Хисамова и могу точно сказать, что ни в одной своей статье, ни в одном абзаце своих книг он никогда даже не пытался трактовать исследуемые им источники с точки зрения идеологических императивов или постулатов воинствующего атеизма. И это происходило в те времена, когда слова «Аллах» и «Коран» писались с маленькой буквы! Все его труды характеризуются верностью научной мысли и начисто лишены какой-либо идеологической тенденциозности. Поэтому, наверное, его книги пользовались большой популярностью и уже давно стали библиографической редкостью.

Несмотря на врожденную интеллигентность и стремление решать все проблемы мирным путем, Нурмухаммет абый бывает крайне принципиальным в некоторых вопросах. Он не терпит пустословов, высокомерных и двуличных людей, которые под маской учености, псевдозваний и псевдорегалий скрывают свою глупость и необразованность. С такими людьми Нурмухаммет абый обращается без всяких церемоний, называя вещи своими именами.

Став руководителем Института языка, литературы и искусства, Нурмухаммет Шагвалеевич сумел обеспечить продуктивную работу этого научного учреждения. Много сделано в области литературоведения, текстологии и языкознания. Десятки и десятки научных трудов, выпущенные в последние годы Институтом языка, литературы и искусства, занимают почетное место на полках российских и зарубежных ученых.

Нурмухаммет Шагвалеевич Хисамов продолжает активную научную и педагогическую деятельность. Потенциал ученого велик, и он еще не раскрыл всех «тайников» своего богатого интеллектуального архива. Мы, его ученики, ждем от него новых научных достижений и открытий и надеемся, что он еще долгие годы будет радовать нас своим добрым, наставническим словом.

*А.М. Ахунов,*
*кандидат филологических наук.*
*2007*

## ЯРКИЙ ТАЛАНТ И ЩЕДРОСТЬ ДУШИ

Вот уже несколько десятилетий о Нурмухаммете Шагвалеевиче Хисамове можно говорить в первую очередь в связи с поэмой «Кысса-и Йусуф» Кул Гали. Великий Тукай писал: «Мало кто из татар не проливал слезы в детстве, читая „Книгу Йусуфа"». Это о книге прославленного в веках татарского поэта Кул Гали (XIII в.) «Кысса-и Йусуф». В емкой фразе поэта сказано все о роли и значении поэмы в жизни и миропонимании татар. Революция 1917 года отодвинула арабскую графику и книги, написанные на ней, на задворки нашей культуры, а затем многое было попросту уничтожено. Так боролись с религией – «опиумом» для народа. Остались единицы, кто знал, мог и смел заниматься древней татарской литературой. Одним из таких оказался тогда еще сотрудник отдела народного творчества Нурмухаммет Хисамов. Темой его научной работы стала поэма о Йусуфе Прекрасном. Известно, что люди к литературе с религиозным содержанием приходят не случайно. Этому способствуют воспитание в семье, знание языков, личные качества, в том числе духовность, человеколюбие.

Н.Ш. Хисамов имел счастье родиться в семье с твердыми народными, религиозными традициями. Отец, Шахвали абый, был человеком глубоко верующим, сведущим в религиозной литературе, философского склада ума. Он оказал исключительное влияние на сына, обозначив линию его жизни. Хаджар апа, мать их большого семейства, любила в редкие свободные минуты брать в руки «Книгу Йусуфа» и нараспев читать любимые стихи, исполняла она и мунаджаты.

В 70-е годы, когда я пришла в Институт языка, литературы и истории, в нем оставался оазис национальной культуры, царил дух свободомыслия, хотя и под неусыпным оком Обкома партии. Я, недавняя выпускница КГУ (отделения русского языка и литературы), погрузилась в мир родной татарской литературы, истории. Тон в Институте задавали такие эрудированные, увлеченные, принципиальные люди, как Нурмухаммет абый. Он неторопливо вел беседы по татарской, арабской, персидской литературе. Прекрасно знал русскую, немецкую, французскую, англо-американскую литературы, свободно оперировал сведениями из Корана, Библии, приводил неизвестные факты из истории.

О «Кысса-и Йусуфе» Кул Гали, которая стала главной книгой его жизни, он мог и может говорить часами, свободно оперируя огромным количеством источников.

Я, придя на работу в Институт в 1977 году, оказалась в одной комнате с сотрудниками отдела народного творчества, а также под духовным влиянием человека блестящего ума, эрудита, оратора. Поражаясь широте познания, я восхищалась его рассказами об известных людях татарского народа, богатством исторических, литературных, религиозных, философских суждений, изяществом цитируемых отрывков из мировой поэзии. Это – целый мир. Из отдела народного творчества Нурмухаммет абый вскоре перешел в отдел татарской литературы. Но я уже была увлечена богатством восточной литературы, мощью исламской культуры, священного Корана. Я пришла, спустя многие годы, к теме «Ислам и татарское народное творчество». Ученые нашего Института, доктора наук Нурмухаммет Шагвалеевич и Хузиахмет Шагиахметович Махмутов, стали научными консультантами моей докторской диссертации.

Н.Ш. Хисамову присущи широта души и стремление помочь людям. Он полон научных идей и щедро делится ими с каждым, особенно со студентами, со своими учениками – аспирантами. Он вырастил много кандидатов, несколько докторов наук.

Уже после 60 лет Н.Ш. Хисамов стал заведующим отдела текстологии и рукописей, этот отдел при нем заметно вырос и в научном, и в кадровом отношении. Став директором Института, Хисамов проявил яркий организаторский талант и в то же время добрые человеческие качества. Он с присущей ему энергией хло-

потал и хлопочет о нуждах каждого сотрудника. Шамаил, висящий в его кабинете, словами поэта Дердменда демонстрирует его характер как руководителя:

Килсә кулдан, шат кыл һәр җанны –
Кем ханлык будыр.
Тәхет кыл кырмысканың күңелен –
Сөләйманлык будыр.

(Если можешь, радуй каждую душу –
Вот дело, достойное хана.
Сделай троном душу муравья –
Вот дело, достойное Соломона.)

За пять лет работы директором он помог получить 5 сотрудникам (семьям) квартиры. На спецсовете по защите диссертаций организовал защиту около 100 человек. Среди них и я защитила докторскую, мой сын Марат – кандидатскую диссертации.

Мы очень благодарны этому поистине необыкновенному человеку, поэту, ученому. Пусть будут благословенны отец и мать, подарившие миру хорошего, доброго человека. Он осуществил на деле свой принцип: «Руководитель должен любить и ценить людей».

*А.Х. Садекова,*
*доктор филологических наук.*
*2006*

## ГАСЫРГА ЛАЕК ЮЛ НИНДИ?

*Нурмөхәммәт Шаһвәлиевич, Сез Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җитәкчелегенә яңа гасыр башында килдегез. Символик хәл бу. Яңа гасыр коллективыгыз алдына нинди бурычлар йөкли?*

Дөресрәге, мин Сезнең соравыгызда аталган институт җитәкчелегенә ике гасыр арасында килдем. Бу исә үзеңнең гамәл-ниятләреңә, вазгыятькә хас проблемаларны һәм киләчәкне концептуаль күзаллавыңа хәлиткеч йогынты ясый. Мондый эпохаль күчеш аралыгында традиция һәм яңарыш нисбәтен төгәл

тоемлаганда гына нәтиҗәле һәм файдалы гамәл кылырга мөмкин. Конкрет минем очракта бу ни дигән сүз?

Безнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының уннарча ел дәвамында туплаган бай тәҗрибәсе һәм шул нигездә шәкелләнгән ныклы традициясе бар. Бер генә яңарышчы да аны төбеннән җимереп, алга җибәрә алмый. Чөнки бу – академик фән дөньясы, анда тотрыклы система хакимлек итә. Минем идарәгә аяк басу чорына институт ирешкән җитди казанышлар алга таба хәрәкәт итү өчен төп җирлек булып тора. Оешмабызда эшләнелә торган фәннең һәр тармагында гомумиләштерү сыйфатына ия зур хезмәтләр бар. Телчеләр дөньяга чыгарган өч томлык «Татар теле грамматикасы», фольклорчыларның жанрларны тарихи яссылыкта яктырткан хезмәтләре һәм халык иҗаты әсәрләре, заманга хас, идеологик басымнан азат проблематик тикшеренүләр, сәнгатьчеләрнең режиссура, сынлы һәм музыкаль сәнгать темасына караган монографияләре, әдәбиятчыларның «Әдәбият тарихы»ның 6 томын төгәлләүләре, урта гасыр әдәбияты тарихын тулаем һәм конкрет авторлар нигезендә яктырткан монографик хезмәтләр, Кол Гали иҗатының төрки шигърият үсешенә ясаган тәэсирен өч гасырлык әдәби тарих күләмендә ачкан тикшеренү, татар диалектларын, сөйләшләрен, топонимиясен өйрәнүгә багышланган китаплар, икетелле сүзлекләр – институт эшчәнлегенең соңгы елларын гәүдәләндергән мөһим нәтиҗәләр шулар. Сүзлекчелек өлкәсендә яңа баскыч – татар теленең 4 томлык аңлатмалы сүзлеге. Зур теоретик һәм гамәли бу хезмәт инде әзер.

Әлеге тикшеренүләр минем күз алдында эшләнде. Алар арасында минем хезмәтләр дә бар. Мәсәлән, «Урта гасыр татар әдәбияты» дигән колачлы китапның концепциясен, проспектын мин эшләгән идем, авторлар коллективын үзем житәкләдем, мөһим теоретик һәм конкрет очерк характерындагы бүлекләрне, кереш һәм йомгакны мин яздым, китапның фәнни мөхәррирлеген башкардым. Катнашкан авторларыбыз да бу өлкәдә абруйлы затлар булды. Алда барлап узылган тикшеренү цикллары да, асылда, филология һәм сәнгать фәненең ветераннары тарафыннан башкарылды. Академик М.З. Зәкиев, профессор Ф.И. Урманчеев, мөхбир әгъза Ф.Ә. Ганиев, баш гыйльми хезмәткәр Х.Ш. Мәхмүтов, профессор Ф.М. Мусин, профессор Г.М. Арсланов, фән докторлары М.И. Әхмәтҗанов,

Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова, профессор Ф.Г. Гарипова, фән докторы И.Б. Бәширова, өлкән фәнни хезмәткәрләр Д.К. Вәлиева, Т.Х. Хәйретдинова, З.З. Рәмиев – әлеге гыйльми гвардиянең тулы булмаган исемлеге шушы. Болар янында докторлык чигендәге урта буын вәкилләренең дә саллы хезмәтләре бар. Рәмил Исламовның урта гасыр шагыйре Шәрифнең «Төрки шаһнамәсе»н яктырткан күләмле һәм бай эчтәлекле монографиясе, Айсылу Садыйкованың ислам идеологиясе һәм татар фольклорын бәйләп тикшергән кызыклы һәм юнәлеше белән яңа хезмәте, Фәрит Бәшировның татар прозасына багышланган тикшеренүе, Гүзәл Сәйфуллинаның дини дога һәм гыйбадәт көйләрен тикшергән гаять кызыклы һәм тирән китабы, Ким Миңнуллинның татар җырларының шигърияτен яңача ачкан докторлык диссертациясе мөһим казанышларыбыздан саналырга лаек. Кыскасы, мин институт идарәсенә гыйльми барышның кайнап торган шушындый дәверендә килдем. Әлеге гыйльми көчләр һәм фәнни хезмәтләр алга барышның да тыелгысыз инерциясен билгели. Башланган яңа гасыр, әлбәттә, алдыбызга яңа бурычлар куя. Дәүләт мөстәкыйльлеге һәм милли-мәдәни үсеш язмышының Русия күләмендә җитди сынаулар чорына килеп керүе татар халкын саклап калу һәм үстерү проблемасын аеруча кискенләштерә. Безнең институт өчен бу – аның вазифасын һәм эшчәнлек эчтәлеген тәшкил иткән проблема. Әдәби мирасны барлап халыкка кайтару булсын, сәнгать традицияләрен һәм үсеш мөмкинлекләрен тирән яктырту булсын, сүзлек байлыгын туплап милләт кулына тоттыру булсын, тарихи җир-су атамаларын тулы теркәү һәм саклау булсын, тел сәясәтен дөрес билгеләү һәм бу өлкәдәге барыш киләчәген прогнозлау булсын – боларның барысы да әлеге җитди вазгыятьтә милләтнең яшәү тонусын күтәрүгә хезмәт итәргә тиеш. Татар филологиясе, гомумән инсани фәннәр төрки дөньяда һәм халыкара күләмдә югары бәяләнә. Безнең бурычыбыз – хезмәтләребезне шушы дәрәҗәдән югарырак күтәрүгә ирешү.

*Бүгенге фән матди мохтаҗлыкта яшәвен дәвам итә. Бигрәк тә гуманитар фәннәр. Якын киләчәктә бу хәлдән чыгу юллары күренәме соң?*

– «Бүгенге фән» дигәндә, тулаем узган гасырның 90 нчы елларына хас халәт күзаллана. Әйе, фәнни тормышның тораташ хәленә калган еллары булды. Ягъни шок халәтендә булып алдык. Узган

хезмәтләребез басылудан туктады, наширләр химаячеләр табуны таләп итте. Бу хәл, асылда, әле дә дәвам итә. Мәсәлән, алдарак телгә алып киткән «Урта гасыр татар әдәбияты» дигән хезмәт 1989 елда төгәлләнгән иде. Әмма ул гасыр азагында гына басылып чыга алды. Ул арада сәяси һәм идеологик вәзгыять тамырдан үзгәреп өлгерде. Дөрес, тикшеренү үзгәртеп кору елларында башкарылганга, аның мәгънәви үзәге сәламәт булып чыкты, хезмәткә күп төзәтү кертергә туры килмәде. Басмалар тоткарлану әле дә еш була. Шулай да бу өлкәдә сөенечле хәрәкәт тә бар. Дәүләт һәм Фәннәр академиясе җитәкчелеге хезмәтләрне дөньяга чыгару өчен мөһим чаралар таба. Мәсәлән, тел законын тормышка ашыруга билгеләнгән акчалардан һәм республикадагы икътисади табышның мәгълүм процентыннан файдалану мөмкинлеге туды. Соңгысы фундаменталь тикшеренүләрне күздә тотып оештырылган НИОКР фондыннан гыйбарәт. Төрле-төрле нәшриятлар барлыкка килү хезмәтләр бастыру юлларын ишәйтә. Һәрхәлдә, безнең институт галимнәре соңгы вакытта елга уртача 40 лап китап чыгарып килә. Әмма басманы көтеп яткан хезмәтләр күпкә артык. Әйтик, бер текстология бүлегендә генә дә 20 ләп том әзер хезмәт бар. Без өметләребезне республика икътисадындагы үсешкә баглыйбыз. Шушы нигездә дәүләтнең фән үсешенә игътибары артуын һәм инсани фәннәрнең матди нигезен ныгытуын көтәбез.

*Кыенлыклар күп булуга карамастан, фәнгә яшьләр дә тартыла. Аларның перспективалары нидә? Россиядәге бүгенге вазгыять фонында татар милли фәненең киләчәге бармы?*

– Бу – бик мөһим сорау. Фәнгә яшьләрнең тартылуы бернинди кыенлыкка карамастан дәвам итә. Соңгы елларда бу тенденциянең көчәюе күзәтелә. Безнең институтта 80 ләп аспирант белем ала. Моннан берничә ел элек, абитуриентлар килмәү сәбәпле, бирелгән урыннарның буш калу очраклары бар иде. Хәзер кайбер бүлекләрдә бер урынга икешәр кешелек конкурс килеп чыга. Гуманитар уку йорты һәм факультетларның артуы моның ышанычлы җирлеге булып тора. Яшьләрнең перспективалары дигәндә, бүгенге милли мәдәни тормышыбызда тел, әдәбият, фольклор һәм сәнгать белгечләренә ихтыяҗ артты. Мәктәпләрдә, гимназияләрдә, махсус урта уку йортларында, музейларда, төрле идарә оешмаларында шушындый яшь белгечләрне кирәксенү бар. Аннары үзе-

безнең гыйльми оешмалардагы табигый яңарыш процессы яшь алмаш үстерүне сорый.

Русиядәге бүгенге вазгыять фонында татар милли фәненең киләчәген шик астына алу өчен нигез күрмим мин. Илнең икенче зур милләтен фәнсез, мәдәниятсез калдырырлык көч юк, минемчә. Аннары татар милли уянышының, яңарыш инерциясенең көче, потенциалы бик зур. Аны бастырырга тырышу теләсә кайсы мәркәз өчен акылсызлык булыр иде. Андый омтылыш конкрет чараларга күчсә, дәүләтне котылгысыз таркалу юлына этәрер иде. Шуңа күрә татар милли фәненең киләчәге бар, дия алабыз.

*Соңгы елларда галимнәребезнең чит ил гыйльми үзәкләре белән элемтәләре ныгыды. Моның нәтиҗәсе күренәме?*

– Моның нәтиҗәсе, әлбәттә, күренә. Галимнәребез үзләренең теоретик карашларын һәм табышларын дөнья сынавына кую мөмкинлеген алдылар. Тикшеренү ысулларын камилләштерү, яңа чыганаклар үзләштерү мөмкинлеге күренекле чит ил галимнәре белән аралашу нигезендә арта. Мәсәлән, Казанның 1000 еллыгы мәсьәләсе әнә шушындый багланышлар нәтиҗәсендә ышанычлы чишелде. Багланышларның файдасы барлык инсани фәннәрдә дә сизелә. Тел, әдәбият, фольклор һәм сәнгать фәннәренең барлык тармаклары да моңа мохтаҗ. Урта гасыр әдәбиятын, мәсәлән, Төркиядәге чыганаклардан башка тулы яктырту мемкин түгел. Казан ханлыгы чорыннан калган мөһим ядкәрләрнең төрек мирасханәләрендә саклануы мәгълүм. Мөһаҗирлектә иҗат ителгән әдәбият, аерым алганда Гаяз Исхакый мирасы, башлыча, Төркиядә саклана.

*Инде үзегезнең фәнни эшчәнлегегезгә килсәк, Сез татарның бөек борынгы әдәбиятын киң фәнни җәмәгатьчелеккә таныткан шәхес. Борынгы мирасыбызны өйрәнүнең бүгенгебез өчен әһәмияте нидә? Моңа ихтыяҗ бармы? Әлеге өлкәдә хәл итәсе нинди проблемалар бар?*

– Борынгы әдәби-мәдәни мирасны өйрәнү бүгенге шартларда аеруча актуаль бурычларның берсенә әйләнде. Бу – милләтнең уянышы, аны тергезү, яңарту ихтыяҗына бәйле. Татарныкы кебек мең еллык бай һәм бөек мирас дөньяның бик күп халыкларында бар димәс идем. Шуны тулы һәм нәфис төгәллегендә халык кулына тапшырсаң, анаң үзаңы күпкә югары күтәрелер һәм

дөньяда үзен хис итеше чагыштыргысыз көр булыр иде. Урта гасыр әдәбиятында фәлсәфи, гыйльми һәм сәнгати фикер гаять югары булган. Шул мирасны үзләштереп, бүгенге яшәеш өчен бик күп файдалы гыйбрәтләр алырга мөмкин. Бу – халык әхлагын һәм гамәлен күздә тотып кына түгел, дәүләт хакимиятен кайгыртканда да мөһим. Чөнки урта гасыр әсәрләрендә даһилык дәрәҗәсендәге бөек формулалар бар.

Хәл итәсе бөек проблемалар дигәндә, урта гасыр әдәбияты белгечен әзерләү зуррак вакыт сорый. Ә өйрәнелмәгән ядкәрләр бик күп. Димәк, беренче нәүбәттә күбрәк белгечләр кирәк. Ядкәрләрнең өйрәнелгәнен бастырып чыгару, яңаларын чит илләрдән кайтарту, үзебездә булганнарының текстын нечкәләп тикшерү һәм нәшергә әзерләү зур чыгымнар сорый. Биредә дәүләтнең җитди ярдәме кирәк.

*Нурмөхәммәт ага, Сез яшьтән шигърият белән мавыгып, татар дөньясына, галим буларак кына түгел, шагыйрь буларак та танылдыгыз. Күңелегездәге галимлек һәм шагыйрьлек үзара көрәшмәделәрме?*

– Әйе, миңа гыйлем да, шигърият, шигъри иҗат та газиз. Мин үз аңымда һәм җанымда аларның каршылыгын тоймадым. Чөнки фәндә алынган өлкәм дә шигърият. Үземнең шигъри иҗат кешесе булуым урта гасыр шагыйрьләрен дә, XX йөз башы авторларын да, бүгенге шагыйрьләрне дә тирәнрәк төшенергә ярдәм итә дип саныйм. Яраткан остазым Хатип ага Госман «Бөек язмышлы әсәр» дигән китабым белән танышкач, минем гыйльми уңышларымда шагыйрьлекнең дә катнашы барлыгын әйткән иде, киләчәктә аспирант итеп шагыйрь алырга васыять итте. Үзе шагыйрь җанлы галим бу ике башлангыч уртаклыгын бәрәкәтле итеп күргәндер.

*Шигырь укучылар кими бара кебек. Гомумән, халкыбызның рухи дөньясы да тарая бара түгелме? Чит идеология, чит гадәтләр басымы да көчәйде. Бу хәлдән чыгу юллары бармы икән соң?*

– Мин: «Шигырь укучылар кими бара», – дип кистереп әйтә алмыйм. Безнең халык элек-электән шигъри җанлы булган. Шулай булмаганда, борынгы әсәрләребез бүгенгә йөзләгән кульязмада килеп ирешә алыр идеме? Укучыларның арта яки кими баруын социаль сорашу юлы белән генә ачыкларга мөмкин. Ки-

тапларның зур тираж белән басылмавы аларның укылмавы дигән сүз түгел. Басмаларның кыйммәткә төшүе тиражны чикләргә мәҗбүр итә. Әмма яхшы шигырь укучысыз яки тыңлаучысыз калмый. Безнең академик әдәби журналларыбыз да шигърият мәйданы бит. Халкыбыз һәм дәүләтчелегебез кичергән бүгенге сынаулар, аларның киләчәге өчен тирән хәвефләнү һәм милләтне мәңге яшәтерлек рухани-тарихи маяны барлаудан торган, үзәк өзгеч тирән шигъри кичерешләр белән сугарылган әсәрләр берничек тә укучысыз калмый. «Казан утлары»нда басылган Зиннур Мансуров шигырьләре, Равил Фәйзуллин, Газинур Морат, Рашат Низамиев яки Салисә Гәрәева әсәрләре, Рәдиф Гаташның робагый һәм газәлләре, Флера Гыйззәтуллинаның лирик бәйләмнәре иман борчылуы белән яшәгән берәүне дә битараф калдырмагандыр дип ышанам. Үзебез яши торган дәверне тирән чагылдырган Ренат Харис поэмалары, Роберт Миңнуллинның мәгънәле һәм җор шигырь китапларыннан башка бүгенге милләттәшнең рухани дөньясы һәм барышны күзаллавы җитәрлек якты була алмас иде.

Халыкның рухани дөньясы тараю дигәндә дә минем шигем бар. Халык төшенчәсендә дөньяга карашы, үзаңы формалашкан, үз көнен үзе күрергә сәләтле буыннар берлеген күз алдында тотам. Бу катлауларның рухани дөньясы тараюга мин ышанмыйм. Матди шартлары гәзит-журнал яки китаплар алырга мөмкинлек бирмәү, әлбәттә, үзен нык сиздерә. Әмма бу хәл рухани ихтыяҗны юкка чыгара алмый. Халык театрга йөри, радио тыңлый, телевизион тапшыруларны карый. Чит идеология һәм гадәтләрнең тормышка бәреп керүе яшь буынның рухани һәм әхлакый саулыгына җитди куркыныч тудыра билгеле. «Бу хәлдән чыгу юллары» дигәнче, «моны булдырмау юллары бармы?» дияр идем мин. Бар, дип саныйм. Эзлекле милли тәрбия генә моңа киртә була ала. Кешене ата-анага, әби-бабага якын тота ала торган ясле-бакчалар, татар мәктәбе һәм шуларны логик дәвам итеп очлап куя торган милли югары мәктәп. Кеше дөньяны туган халкына таянып үзләштергәндә генә бөтен һәм сәламәт шәхес була ала. Нигезендә үз ана теле, үз көй-моңнары, үз әдәбияты-шигърияте ятканда гына бүтән халыкларның – русларның, төрек, алман, инглизләрнең рухани хәзинәсен дөрес, төгәл бәяли ала. Ансыз аның эчке дөньясы гарип

булучан. Кыскасы, матди һәм рухани сау җәмгыять кенә әле Сез әйткән шаукымга каршы тора алыр.

*Без бик кызыклы чорда яшибез. Минем уемча, татар халкының ерак киләчәктәге язмышы нәкъ менә без яши торган чорда хәл ителә кебек (дәүләтчелек проблемалары, графика мәсьәләсе һ.б.). Бу караш белән килешәсезме? Милләтебезнең киләчәге якты булсын өчен, Сезнеңчә, бүген иң беренче чиратта ниләр эшләргә кирәк?*

– Әйе, бу мәсьәләдә Сез бик хаклы. Халкыбызның ерак киләчәге, аның тарихи язмышы бүген хәл ителә. Бар нәрсә дә дәүләтчелек проблемасына тоташа, тулы канлы, көр хис итешле яшәеш халык тормышы дәүләтчелек белән ныгытылганда гына мөмкин. Бу – үзе җитештергән байлыкның төп хуҗасы үзе булу, үзенең хөрмәтле дәүләт теле булу, үсә торган алдынгы мәдәнияте булу дигән сүз. Язуның латин әлифбасы нигезенә кайтарылуы да шул ук системадагы чаралардан. Милләтне инкыйраздан саклауның бу – гаять җитди гамәле. Нәкъ шулай булганга да мәркәзнең мәгълүм көчләре аңа ярсып ябырылды. Латинчылык элек ул дәрәҗәдә актуаль булмагандыр. Хәзер исә безнең, күпчелек булмаса да, бик күп балаларыбыз белемне русча алып, үз теленә кирилл хәрефе аша күчкәндә, татар авазларын рус әйтелешендә яңгырата. Бу исә чын татар теленең югала баруын тизләтәчәк. Моны әллә нинди тузга язмаган яманлыклар белән куркытып сәясиләштерергә ничек кенә тырышмасыннар – бу чара халыкны саклап калуның органик ихтыяҗы. Яшәү, дөньяда милләт буларак саклану мәсьәләсе – ул халыкның бары үз эчендәге һәм үз хокукындагы өлкә. Үзен саклау өчен һәр халык бар тырышлыгын куеп әрсезләнергә хаклы. Милләтебезнең киләчәге якты булсын өчен бүген без дәүләтчелегебезне сакларга һәм ныгытырга, мәдәниятебезгә һәм мәгарифебезгә лаеклы чаралар тудырырга, эзлекле милли мәгариф системасын төзергә тиешбез. Болар милләтнең, аеруча зыялыларның, югары җаваплылыгы һәм бердәмлеге шартларында гына мөмкин. Вак талашлар – халыкны һәлакәткә илтү юлы.

*Әңгәмәдәш В. Гарифуллин.*
*«Татарстан» журналы,*
*2001 ел, № 11*

## ПОЦЕЛОВАННЫЙ АНГЕЛОМ

Татары являют себя миру как народ с древней государственной и культурной традицией, сохранившие свою этническую идентичность и активно развивающие ее в наше время. Имея ярко выраженную ментальную и языковую самобытность, они выделяются среди многочисленных народов России высоким уровнем цивилизационного развития. На фоне эпохальных исторических событий, связанных с существованием Казанского царства, Астраханского и Крымского ханств, татары воспринимались как народ, сильно отличающийся от русского по языку и вере. Вероятно, такой образ был верен. Но с течением времени их роль изменилась, они стали жить в русском народе своими великими представителями и развивать его язык, культуру, науку, образование и т.д. Г.Р. Державин, первый поистине великий русский поэт, внес огромный вклад своими произведениями в создание русского литературного языка. На этом же поприще работали Н.М. Карамзин, Н.П. Огарёв, И.С. Тургенев. Все они воспринимаются как русские поэты и писатели, так же, например, как самым русским поэтом предстает А.С. Пушкин, имеющий по родословной, написанной им самим, прусские и африканские корни.

Великолепный образ татар, ассоциируемый с Республикой Татарстан и с городом Казанью, одним из самых значительных цивилизационных, культурных, научных и экономических центров России, вызывает бесконечное уважение. Он показывает, как многого может достигнуть народ, ценящий свою самобытность и развивающий ее. Он же опровергает мнение о том, что национально-государственные образования (Татарстан, Башкортостан, Чувашия, Удмуртия, Коми, Марий Эл, Мордовия и др.) угрожают стабильности России, ее целостности и суверенитету. Наоборот, они скрепляют Россию как железные обручи, ибо подавляющее большинство великих россиян, отличившихся беззаветным служением своей стране, вышли из татар, удмуртов, марийцев, чувашей, башкир, коми, эрзян и т.д.

Огромный цивилизационный и духовно-культурный потенциал позволил татарам создать национальную Академию наук, в которой работают ученые мирового уровня.

В сентябре 2000 года я оппонировал на защите кандидатской диссертации по фольклористике в Институте языка, литературы и искусств им. Г. Ибрагимова АН Республики Татарстан. Председательствовал на диссовете Н.Ш. Хисамов. Заседание диссовета проходило в обстановке подлинной академичности, высочайшей компетентности и было похоже на хорошо срежиссированное театрализованное действо. Я был очарован происходящим и проникся огромным уважением к институту, его директору Н.Ш. Хисамову и сотрудникам. Центральной фигурой в диссовете был Н.Ш. Хисамов, молодой, импозантный и романтичный человек, предельно корректный и красноречивый. Его ораторское искусство казалось недосягаемым.

После заседания диссовета, когда речь зашла о том, над какой научной проблемой я работаю, я сказал, что подготовил к защите докторскую диссертацию по фольклористике. Тема исследования «Мордовский героический эпос: Сюжеты и герои». Н.Ш. Хисамов спросил, где планирую провести защиту. Я назвал Московский университет, где прошла апробацию кандидатская диссертация. «А почему бы Вам ни защититься в нашем совете?» – предложил он. Я сразу же согласился, ибо впечатление о диссовете и процедуре защиты сложилось очень хорошее. Через 15 месяцев, 2 марта 2002 года, я защитил докторскую диссертацию в диссовете под председательством Н.Ш. Хисамова.

Я предварил свои слова о Н.Ш. Хисамове высказыванием о татарском народе по той причине, что Н.Ш. Хисамов тоже является его олицетворением. Он входит в плеяду выдающихся людей Татарстана, а в его контексте – и России: и как ученый, и как писатель, и как руководитель научного учреждения, и как гражданин.

В течение полутора лет (сентябрь 2000 – март 2002) в период подготовки и организации защиты докторской диссертации я обращался за советами и помощью к Н.Ш. Хисамову – и всегда получал от него поддержку. Я видел: передо мной человек, которому присущи мудрость, светлая душа и безупречная цивилизованность. Они заложены в его онтологии.

Мы все измеряем друг друга своей мерой. Своей мерой руководствуется и Н.Ш. Хисамов. Но у него такая мера, которая годит-

ся для человека-интеллектуала любой национальности. Благодаря его благословению я стал доктором наук и профессором. И, разумеется, благодаря его напутствию в большую науку после защиты диссертации опубликовал 10 книг («Масторава» (2003, в моем переводе на русский язык), «На земле Инешкипаза» (2006, поэзия и проза), «Масторава» (2010, в дополненном виде), «... откуду пошла Русская земля...» (2012, историческая монография), «Потехония» (2012, фантастическая повесть), «Эрзя, Меря, Русь в историографии России» (2013, монография), «Планета Эра» (2014, поэзия и проза), «Масторава» (2014, Таллин, с приложением); опубликована «Масторава» в переводе на венгерский язык (2010) и финский язык (2015).

Во мне, хочу я того или нет, живет и работает Н.Ш. Хисамов, его благородный образ стал составной частью моего менталитета. Близок мне Н.Ш. Хисамов и потому, что я, как и он, занимаюсь литературно-художественным творчеством. Сочетание научного дарования с художественный талантом – довольно редкое явление. И человек, предстающий одновременно в образе ученого и писателя, поэта, безусловно, обладает уникальными гуманитарными качествами. В его мышлении силлогизмы обретают крылья художественного образа, а художественные образы - сияния и прозрения силлогизмов. Мировой Разум, создавший все сущее и управляющий им, при рождении Н.Ш. Хисамова послал ангела, который его поцеловал и в лоб, и в сердце. И он обрел двуединую сущность, благодаря которой создает замечательные научные и художественные произведения, имея светлое сознание ученого и доброе сердце поэта.

Такие люди, как Н.Ш. Хисамов, возвеличивают имя своего народа, делают его уважаемым, разносят о нем добрые вести по миру.

*А.М. Шаронов,*<br>
*доктор филологических наук, профессор,*<br>
*член Союза писателей России (Саранск).*<br>
*2017*

## ПОСОЛ ДОБРА И ДРУЖБЫ

*(80-летию со дня рождения Н.Ш. Хисамова)*

Нурмухаммет Шагвалеевич Хисамов, известный литературовед, заслуженный деятель науки Республики Татарстан, лауреат премии АН РТ им. Ш. Марджани на долгое время останется в научной среде и в нашей памяти выдающимся ученым, автором исследований по средневековой тюрко-татарской поэзии XIII–XV вв. и редкостной души замечательным человеком. Всем тем, кто общался с Нурмухамметом Шагвалеевичем, он запомнился как умный, творчески мыслящий, неординарный ученый, покоряющий своими рассуждениями, глубиной и обстоятельностью мысли, исследователь. Этим он более похож на мыслителя, философа.

Нам, его аспирантам и докторантам, он прививал стремление и умение самостоятельно мыслить, творчески работать. Личность неординарная, свободная, он смог увлечь филологией целую группу аспирантов, докторантов, которые добились больших результатов.

Он был дитем своего времени и впитал с молоком матери высокую культуру общения, чувство такта и уважения ко всем без исключения людям, а поэтому по жизни всегда был сдержан, тактичен, справедлив, никогда не обижал людей. На службе кристально честен и порядочен. Ему была свойственна пунктуальность, обязательность, он всегда держал данное слово. В манере его поведения, в извиняющемся голосе была какая-то застенчивость, свидетельствующая о глубокой внутренней интеллигентности и добропорядочности. Про таких говорят: «Меченый богом»! В момент его рождения аллах, наверное, распределял доброту и щедрой рукой отсыпал ему целую колыбель. Кто знает, а может, как знаки судьбы, добра и любви, ему светили купола и полумесяцы мечетей, в которых его прадеды и деды были сельскими духовниками-муллами. Поэтому и воцерковленность в душе Нурмухаммета Шагвалеевича видна невооруженным взглядом. Ведь только трава растет безучастной ко всему происходящему. А человек, человек он другой, он живет душой и провидением божьим… Так и шел Нурмухаммет Шагвалеевич по земной юдоли, выполняя божью заповедь и заветы предков – делиться добром, любить и уважать людей.

Да и быть, наверное, по-другому не могло. Родиться и зваться Нурмухамметом в селе, где твои предки вместе с верующими общались с Аллахом, самой своей природой человеку на скрижалях судьбы предначертано угождать, служить людям. Выше нет и призвания, чем выполнять предначертанное судьбою и богом.

Все успел Нурмухаммет Шагвалеевич по жизни. Достиг вершин в науке, воспитал детей, увидел внуков. Живет без шума, без зла, тихо, творит добро, созидает на земле истово как крестьянин, как и сотни лет до него его предки. Верно, известен ему смысл жизни, положенные человеку пределы…

В годы работы директором ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова профессор Н.Ш. Хисамов был сильнейшим управленцем, который предложил и реализовал долговременную стратегическую программу развития филологической науки в Татарстане, определил уровни взаимодействия с коллегами из других регионов, наладил подготовку кадров высшей квалификации не только для татарского народа, но и для других тюркских и финно-угорских республик Урало-Поволжья. Десятки кандидатов и докторов филологических наук получили путевку в жизнь возглавляемом им диссертационном совете ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. С его именем связано становление фольклористики нового времени в Республике Мордовия. Им подготовлена целая плеяда ученых из соседней республики. Здесь, в Казани, в аспирантуре и докторантуре Института им. Г. Ибрагимова получили экспертную оценку, прошли защиту, апробацию кандидатские и докторские диссертации Т.П. Девяткиной, А.М. Шаронова, В.И. Рогачева, М.М. Акашкина, Е.А. Федосеевой, Н.Н. Вирясовой и других. В институте эти соискатели выступали на научно-практических конференциях, получили поддержку, квалифицированные научные консультации, нашли рецензентов и оппонентов для своих диссертаций. Коллектив ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, возглавляемый Н.Ш. Хисамовым, протянул руку помощи и дружбы представителям мордовской филологии, фольклористам. Отсюда начиналось возрождение мордовской фольклористики, результативно проявляющей себя на современном этапе.

Нурмухаммет Шагвалеевич отличается мягкостью и добротой, ровным, спокойным характером, ни с кем не конфликтует, ни на кого не повышает голос. По жизни всегда уравновешен, выдержан,

рассудителен, добр. Отличается вдумчивостью и мудростью при решении проблем. Тщательно обдумывает все свои действия, советуется с коллективом ученых, единомышленниками. Его отличительными чертами являются открытость, справедливость, доброта, располагающий характер. Букашку не убил, на муху за свою жизнь не замахнулся, добрейшей души человек. Нельзя не верить, что сам бог щедрой рукой отвесил ему добра в долгую земную дорогу. Наверное, бог посылает таких иногда на землю, чтобы люди на них в смирении и добрых делах равнялись.

Нурмухаммет Шагвалеевич всегда был справедливым, открытым для помощи. Никогда не обижал сотрудников ни словом, ни делом. Мы, докторанты, по этому поводу шутили, что такие люди бывают только у бога на посылках по добрым делам. Он всегда говорит спокойно, тихо, больше слушает собеседника, размышляет. Смеется редко, никогда не делает это громко. Есть в нем какая-то глубинная крестьянская культура, народная интеллигентность.

Многое объясняется атмосферой жизни, условиями, в которых рос Нурмухаммет Шагвалеевич. Трудолюбие, простота и доброта, любовь к людям, стремление помочь друг другу – это норма для жителей села Мунчали, где рос и воспитывался он. Все довоенные и послевоенные годы его односельчане до последнего куска хлеба, мяса, материи (как будто имели собственную мануфактуру), овчинки отдавали государству. А сразу после войны до последней копейки спешили, бежали, несли в сельсовет на заемные облигации. Понимали, верили, что государству плохо, тяжко миленькому. И помогали. Последний жевок вытащат изо рта собственного ребенка и отдадут государству! И это ведь не сказка, не выдумки. Это быль. Найдите в мире таких верующих, таких государственников, таких святых, как жители села Мунчали, с ног собьетесь – не сыщете! Днем с огнем не найдете! Даже в близком окружении самого Аллаха таковых не обнаружится! А на тебе – жители села Мунчали, где рос Нурмухаммет, были такими! Именно здесь, в такой атмосфере происходило становление Н.Ш. Хисамова – патриота и государственника.

Нурмухаммет был одним из наиболее разносторонних и результативных учеников за всю историю школы Мунчали. Книго-

чей и библиофаг – он унаследовал любовь к книге от своих родителей и дедов, бывших на службе у бога и верующих.

Есть люди, которым от природы все легко дается. Они нравятся, их любят друзья и учителя, обожают женщины. Таков и Нурмухаммет Шагвалеевич. В нем чувствуется интеллигентность, врожденный эстетизм. Он всегда хорошо одет, рубашки, брюки, костюмы идеально выглажены, обувь доводится до зеркального блеска. Эта юношеская привычка сопровождает его всю жизнь. Аккуратист. Пунктуален. Всегда выполняет данное слово. К нему вполне применимо выражение «аристократ духа и поведения». Наверное, это семья, школа, он сам, определили весь его характер, поведение. Он публичен, легко общается, уживчив, бесконфликтен, идет на компромиссы не в ущерб делу. Он приятен людям, общение с ним желанно. Нурмухаммет Шагвалеевич никогда, условно говоря, «не заезжает на чужую территорию». Многое объясняется его ментальностью. Человек, получивший огромный заряд любви в детстве, возвращает это обратно людям в стократном размере. На добро он ответит добром сто раз, а зло просто не заметит. Отвечать на зло – это слишком мелко и низменно для его благородной натуры, и он никогда не позволяет опуститься до этого. Этот человек живет на волне оптимизма и благородства. Государственник по духу до мозга костей. Нурмухаммет Шагвалеевич кристально честен в работе, во взаимоотношениях с людьми, максималист по жизни. Во все времена требователен к себе и подчиненным. Но справедливость, добро и сердечность у него всегда стоят на первом месте. И это то, что им взято из села Мунчали, из сельской культуры в дальнюю дорогу. Быть добрым – это аксиома в поведении сельского человека. Работая на ответственных должностях в институте, он горой стоял за своих подчиненных, отстаивая их честь и достоинство. Сослуживцы доверяли ему, и он никогда их не подводил. Помимо научных и служебных вопросов, Нурмухаммет Шагвалеевич помогал решать подчиненным бытовые вопросы, устроиться по жизни. Во все времена и на всех должностях отличался исключительной человечностью, тактом, ответственностью и порядочным отношением к людям. Выделялся высокой культурой и интеллигентностью. Он нес людям отцовскую заботу и понимание. Был щепетилен и предупредителен,

мягок и добр, ответственен за свои поступки. Умен. Вел себя с подчиненными спокойно, достойно, помогая людям в самых сложных условиях 2000-х гг. сохранять чувство собственного достоинства. Проявлял аристократизм духа и выдержку в самых сложных ситуациях. И здесь нет случайностей. Его духовный мир, парадигма поведения своими корнями опираются и прорастают в систему ценностей, российского крестьянства, в систему духовных координат села Мунчали. Глядя на него, нельзя не подумать о том, как красив мир, как сложен и прекрасен человек, связанный мириадами нитей с прошлым и будущим, друзьями и родственниками, с родной землей и работающий на созидание и перспективу. Это о таких замечательных людях, как Нурмухаммет Шагвалеевич, столь вдохновенно и точно сказал эрзянский поэт-интернационалист, уроженец Чувашии, И.Д. Пиняев:

Человеку надо быть красивым,
Но не только росчерком бровей.
Надо, чтоб сверкали переливы,
Самоцветов и в душе твоей.

Человек не птица в зоопарке,
Что лишь опереньем хороша.
Главное в нем это без помарки,
Звонкая, поющая душа!

Не случайно всевышний посылал Нурмухаммета Шагвалеевича на землю, недаром живет он на свете. Добрый и долгий земной путь прошел человек, хорошую память оставил о себе, хорошие семена посеял на земле крестьянский сын, добрые всходы взлелеял, урожай богатый пожал. Живет он под богом и по справедливости, добрым умом живет человек!

Нельзя не верить, что сам бог посылает таких как Нурмухаммет Шагвалеевич иногда на землю, чтобы люди на них в служении добру и смирении равнялись, гордыне и злу в душе своей укорот давали!...

*В.И. Рогачев,*
*доктор филологических наук, профессор (Саранск).*
*2017*

## ОЛУГЛАР ДӘРӘҖӘСЕН РУХТАШЛАРЫ КҮТӘРӘ

Тормышта әледән-әле расланып торганча, талант иясе зуррак максатларга хезмәт иткән саен, аның иҗат көче бермә-бер арта гына бара. Гадәттә, андый затлар үткән белән бүгенгегә киләчәк биеклегеннән карап фикер йөртүләре, инанганлык ныклыгы, халыкның олуг идеалларына күзне киңрәк итеп ачтырулары ягыннан аерылып тора. Табигый ки, аларның тирән нигезле эшчәнлеге үзеннән-үзе иҗтимагый югарылыктагы эчтәлек ала һәм соңгы исәптә милләт рухын көчәйтерлек саллы хезмәткә әверелә. Бу җәһәттән әдәбият галиме Нурмөхәммәт Хисамов, һичшиксез, иңенә күпне салган ир-егетләребез җөмләсенә керә. Һәрхәлдә, аның язма мирасыбыз тарихындагы төрле чорларга караган концептуаль эзләнүләре, бүгенге әдәби хәрәкәткә баглы яңача күзәтүләре шулай расларга җирлек бирә. Әлбәттә, әлеге мөхтәрәм галимебезнең мәгълүм хезмәтләрен күздән кичергәндә, атаклы «Кыйссаи Йосыф»ыбыз беренче булып хәтергә килә, чөнки Нурмөхәммәт Хисамовның академик фән өлкәсендә абруй казануы, башлыча, нәкъ менә шушы поэманы өйрәнүдән башланды. Ә «Кыйссаи Йосыф» исә гади генә әсәр түгел.

Ничектер, шулай тоела: җирдәге адәм балаларын халык итеп оештырган шәфкатьле Аллаһ әйтерсең «Йосыф китабы»н безнең кавемгә өстәмә рәвештә иңдергән. Чыдамлы мөэминнәрен бүләкләүче хикмәт иясенең тугрылыклы габиды булган Кол Гали күктән шигъри вәхи төсендә ишетелгән сүзләрне гүяки кәгазьгә күчереп торган. Коръән Кәримдә искәртеп үтелгәнчә, «Йосыф белән кардәшләре арасындагы вакыйга кешеләргә бер сабактыр». Бу уңайдан «Кыйссаи Йосыф» гыйбрәт өчен бар кылынган башкачарак гыйлавә, тормыш сынаулары вакытында үзенчә вәгазьләүче дәреслек буларак күз алдына килә. Чыннан да, безнең өчен мөкатдәс саналган әлеге дастани фолиант инде сигез гасырга якын шушы тәрбияви вазифаны башкара, шулай итеп сурәтләнгән каһарманнары язмышында калку итеп күрсәтелгән кешелеклелек сыйфатларын татар халкының холык-фигыленә торган саен тирәнрәк сеңдерә бара. Мондый хәл-халәттә барысы да үзен бәхетле тоярга хаклы: «Кыйссаи Йосыф» дастаны да, Кол Гали үзе дә, аларга мөнәсәбәтле өммәт тә...

«Шөкрана кылу» сүзен суза төшеп әйткәндә, халкыбызга руханә хезмәт итүдә тиңе булмаган «Кыйссаи Йосыф» үзен һәрьяклап өйрәнергә алынган әдәбият галимнәреннән дә уңды. Гыйльми шәрехләүне көткән мәдәни ядкәребез, әйе, берсеннән-берсе яхшырак кулларга күчә торды. Хәтта «Йосыф китабы»н тәфсир кылучыларның эзлекле дәвамчанлыгын тәэмин итүдә дә күңел генә тоемларлык ниндидер илаһи кайгыртучанлык сизелеп тора шикелле. Белгәнебезчә, поэманы фәнни кимәлдә ныклап өйрәнү классик шагыйребез Габдерәхим хәзрәт Утыз Имәнинең бисмиллалы эшчәнлегеннән башлана, тәгаенрәк әйткәндә, әсәрнең дистәгә якын күчермәсен чагыштыру юлы белән аның җыйналма нөсхәсе китап итеп чыгаруга әзерләнә. Гомер чагыштырмача кыска, «Кыйссаи Йосыф» чиксез. Кол Галиче галимнәр буыны бербер артлы алышына торды. Әйтергә кирәк, шул элгәрләре арасында Нурмөхәммәт Хисамов, әдәбият тарихы белгече буларак, яңача фикерләве, новаторлыгы белән, заманча концепциягә иҗади таянып, мәшһүр әсәребезне өйрәнү эшен моңарчы күрелмәгән баскычка күтәрүе ягыннан үзгәрәк урында тора.

Мәгълүм ки, бездә һәрбер күренешне үзара чагыштырып карарга яратучылар сәнгатьне – «мин», фәнне «без» рәвешендәрәк күрергә тели. Әлбәттә, болай аңлатуда хаклык бар, әмма күмәклек һәркайда кирәк. Шулай ук «мин»нең калку булып күренүе акылхис эшчәнлегенең һәрбер тармагында да сорала. Бу уңайдан Нурмөхәммәт Хисамов «Кыйссаи Йосыф»ны өйрәнүдә, әүвәлгеләр казанышына таянып, «мин» дип шикләнмичә әйтерлек эшләр башкара алды. Искәртеп кителгәнчә, җитди бурычларны үтәүгә галимебез яшьли тотынды. Беренче зур эшен тәкъдирләп, СССР Фәннәр академиясенең Дөнья әдәбияты институтында Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре буенча кандидатлык диссертациясе яклады. Аның шул ук институтта докторлык дәрәҗәсен дәгъва кылуы да алда сөйләнгән олы темага бәйле иде: «Урта гасыр төрки-татар шигъриятендә (XIII–XV йөзләр) Йосыф – Зөләйхә сюжеты (төрдәшләр проблемасы)». Галимнең төрле елларда чыккан китапларында да шушы юнәлештәге фәнни тикшеренүләр дәвам иттерелә. Сүз дә юк, эзләнү үҗәтлеген таләп иткән гыйльми эшчәнлекнең асылы сорауларга дөрес җавап табуга гына кайтып калмый. Хикмәт – мәсьәләне дөрес куюда. Ошбу күзлектән

караганда, Нурмөхәммәт Хисамовның өстенлекле ягы шунда ки, ул мәсьәләне һәрвакыт дөрес билгели белде. Алай гына да түгел, яңача дөрес куя алды. Белгәнебезчә, Кол Галинең бәгырьләргә үтәрлек «Кыйссаи Йосыф» лиро-эпик поэмасы дөнья мәдәниятенә яхшы мәгълүм булган Тәүрәт-Коръән сюжетына нигезләнгән. Илаһилык белән өртелгән әлеге охшаш темага башка халыкларда янә йөзләп әсәр язылган. Шунысыннан да хәбәрдарбыз: төрки телле авторлар арасында безнең Кол Гали беренчесе. «Күктән иңдерелгән» нәкъ менә шушы сюжетка шагыйребез ни өчен мөрәҗәгать иткән соң? Очраклылык күренешеме бу, әллә максатчан иҗат нәтиҗәсеме? Күпләрне кызыксындырган мондый сораулар уңаеннан Нурмөхәммәт Хисамов икеләнергә урын калдырмый. «Шагыйрь, әлеге әсәрен язганда, иҗтимагый һәм эстетик җәһәттән ике максатны күздә тоткан, – дип басым ясап искәртә ул «Татар поэзиясе» дигән мәкаләсендә. – Монголларның беренче һөҗүмен кире кагып, җитди хафага төшкән болгар җәмгыятен ихтимал афәт алдыннан бергә туплау өчен, туганлыкны данлаган көчле әсәргә ихтыяҗ булган... Аны (Йосыф хакындагы кыйссаны. – *З.М.)* төрки әдәбиятлар тарихында беренче буларак эшкәртеп, ул үз халкын һәм киң мәгънәсендә бөтен урта гасыр төрки әдәбиятын кешелек дөньясының гүзәллек һәм затлы әхлак идеалын эзләү хәрәкәтенә китереп кушкан».

Игътибар иткәнсездер, татар шигърияте турындагы гомуми хезмәтендә әйтеп үтелгән әлеге сүзләрдә галимнең «Кыйссаи Йосыф»ны өйрәнүдә дөрес табылган методологик ачкычы күзаллана. Фәнни эзләнүләрдәге шушы өстенлекле юнәлешне ныгыту җәмәгатьчелек өчен зарурлык дәрәҗәсендәге ихтыяҗ иде. Югыйсә төрки әдәбиятларда Йосыф – Зөләйхә сюжетына иҗат ителгән чагыштырмача таррак фабулалы әсәрләр, укучы аңында буталыш тудырып, Кол Гали поэмасының тематик нигезен кайчак егет-кыз мәхәббәтенә генә кайтарып калдыруга китерде. Ә изге күңелгә шигъри вәхиләр рәвешендә салынган кыйсса биниһая киңлектәге гомумкешелек проблемаларын колачлый, һәм шагыйрь үзенең дастанына нәкъ менә шундый күп сыйдырышлы сюжетны мәгънәви үзәк итеп ала. Чыннан да, адәм баласының рухи сыйфатларына бәйле нинди генә мәсьәләләр күтәрелми анда: яхшылык белән явызлык көрәше дә, инсаннарның насыйп бәхеткә хокуклылыгы

да, әхлакый камиллеккә омтылу вазифасы да... Әлеге рухи сынауларның барысы да хакимлек итү җирлегендә яктыртыла. Ата белән бала арасындагы мөнәсәбәтләр (Йосыф – Йагъкуб юнәлеше) поэманың икенче темасын тәшкил итә. Күпләр тарафыннан беренче урынга куелган мәхәббәт исә сюжет конфликты үсешендә төп вакыйга хәрәкәтен билгеләми. Ни гаҗәп, хәтта Изге Китабыбызның «Йосыф» сүрәсе аятьләрендә дә шундыйрак эзлеклелектәге тематик нисбәт сакланган кебек, ягъни анда да гыйшыклык бәйләнеше гомуми җирлектән җете төстәге җептәй күзгә бәрелеп тормый.

Күңел инануы тора-тора ныгый: газиз кавеме яшәү белән үлем арасындагы авыр сынауларны кичергәндә, шагыйрь ничек инде интим хисләр хакында җырлау белән генә чикләнсен?! Үтә сизгер тоемлау сәләте һәрбер язганында сизелеп торган әдәбият галиме Нурмөхәммәт Хисамов дастан авторының уй-ниятен әле япь-яшь шәкерт чагында ук бөтен тирәнлегендә аңлагандыр сыман тоела. Әлеге әсәрнең идея-сәнгатьчә асылын нәкъ менә шушы дөрес юнәлештә төрле яклап өйрәнүгә багышланган монографияләрендә ул «Кыйссаи Йосыф»ның милли яшәешебез нигезе белән ныклы бәйләнешен күкләр биеклегеннән карагандай ачып күрсәтүгә иреште. Аның хезмәтләре белән танышып чыккач, шундый нәтиҗә үзеннән-үзе өстенлек ала: юк, безнең бу үлемсез дастаныбыз әдәбияттагы аерым хәрәкәт кенә түгел икән бит, ул үзе тулаем төрки мәдәниятнең ифрат бәрәкәтле хәрәкәте булып гәүдәләнә ләбаса.

Ничек кенә сәер яңгырамасын, Кол Гали кебек олуг әдипләрнең берсе дә, гадәттә, үз әсәрләре турында күпкырлы хөкем йөртә алмый. Ә менә шагыйрьгә Нурмөхәммәт Хисамовның язганнарын укырга насыйп әйләгән булса, кем белә, аның галәми киңлектәге горур күңеле тагын да үсебрәк китәр иде. Чыннан да, галим халык рухы тирәнлекләрендә туган әсәрнең бөеклеген классик фәннең байтак алымнары белән ачарга омтыла. Әүвәл барлык сюжет чыганаклары өйрәнелеп, аларга төрле яклап анализ ясала. Авторның сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләре дә гомумиләштерү өчен теркәп барыла. Дастанга угыз эпосыннан үтеп кергән мотивлар да төпченүчән эзләнүченең игътибарлы карашыннан читтә калмый. Мәгълүм фарсы чыганакларының котылгысыз йогынтысы

да микъдари куллану дәрәҗәсендә күрсәтеп бирелә. «Кыйссаи Йосыф»ның угызчылык өлеше өстенлек иткән катнаш угыз-кыпчак телендә язылуыннан да галимебез төрки әдәбиятлардагы тәгъбирләр системасына кагылышлы кайбер кызыклы нәтиҗәләр чыгара. Шул ук вакытта бөек язмышлы шушы дастаныбызны үзәккә алып, урта гасыр төрки ядкәрләрен өйрәнүнең заманча үзенчәлекләрен дә ача...

Җитеп торыр. Әгәр Нурмөхәммәт Хисамовның ошбу юнәлештәге эшчәнлеген колачларга алынсак, ирешелгән казанышларны санау өлеше шактый озакка сузылыр иде. Шулай да «Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә» (XIII–XV йөзләр)» китабы уңаеннан галимнең таулар күчерерлек кодрәткә ия булган сабырлыгына риясыз соклануымны белдермичә үтү мөмкин түгел. Биниһая көч салынган мондый этрафлы эзләнүләр энциклопедик шәкелдәге фундаменталь хезмәт рәвешендә кабул ителә. Шагыйрьнең күпгасырлык төрки «Йосыфнамә» үсешенә йогынтысын ачыклауга багышланган әлеге тикшеренүләрендә дә Нурмөхәммәт Хисамов элгәрләре сөргән чирәмне бөтенләй башка тирәнлектә эшкәртүгә ирешә. Тәгаенрәк итеп әйткәндә, уртак сюжетның төрле каләм әһелләре тарафыннан үзләштерелүендә тоемланган эзлеклелек аша ул урта гасыр төрки шигърияте үсешендәге гомуми кануниятләрне яктыртып күрсәтте. Бу уңайдан галим алдына куелган бурычлар байтак иде: Йосыф һәм Зөләйхә турындагы төрки поэмаларны аларның иҗат ителү ысулына карап төркемләү; яңа төрдәшләр барлыкка килүнең җыелма кисәкләрен ачыклау; аерым текст төсмерләренә чагыштырма анализ ясау; уртак сюжет персонажларын гәүдәләндерүдә авторларның сурәтләү үзенчәлекләрен күрсәтү; безгә мәгълүм төрдәш әсәрләрне камилләштерү юлларын күзәтеп чыгу... Күренә ки, белгечләр төркеменә тапшырырдай бурычлар! Ә хезмәтнең авторы аларны фидакярлек белән башкарып чыккан.

Татар халкының сөекле шаһәсәренә болай озаклап тукталу очраклы гына түгел, чөнки Нурмөхәммәт Хисамовның галимлек асылы әлеге дастанга мөнәсәбәттә тулырак ачыла. Хәер, болай әйтүнең дөреслеккә туры килүен фәнебез хадиме үзе дә раслый. «Урта гасыр әдәбиятына кагылышлы хезмәтләрем үзәгендә Кол Гали иҗаты тору хөрмәтле укучыларымны гаҗәпләндермәстер, –

дип, үзенчә ачыклык кертә ул „Хәтер сагы" исемле мәкаләсендә. – Чынлыкта минем гомеремнең иң зур өлеше аның үлемсез дастанын тикшерүгә багышланды». Гомернең аеруча мөһим максатын үтәүгә юнәлдерелгән иҗтиһат, күргәнебезчә, мәдәниятебезнең офыкларын киңәйтерлек нәтиҗәләрне артыгы белән бирде. Галимебез тырышлыгы белән озын-озак еллар дәвамында көчәйтелгән расламалар «Кыйссаи Йосыф»ка бирелгән гомуми бәяләмәне тагын да ныгытты: чыннан да, безнең бәхеткә насыйп булган әлеге әсәр халкыбызның этик кагыйдәләрен калыплауга, әдәби телебезне торгызуга, халык авыз иҗатының яңача үсеп китүенә бәһаләп бетергесез өлеш кертте. Бу җәһәттән Нурмөхәммәт Хисамов хезмәтләрендә поэманың мөселман Көнчыгышы әдәбиятындагы канунлы үз урынын билгеләүгә, аның мотлак татар халкы хәзинәсе булуын раслауга хезмәт иткән дәлилләр дә мулдан иде. Хәзер инде Алла биргән дастаныбызны дәгъва итүче халыклар бүтән юк бугай.

Совет чоры дәреслекләре хәтеребезгә шулай сеңдергәнме, татар әдәбиятын укып үскән күп кенә буын өчен Кол Гали моңарчы ниндидер ялгызак йолдыз кебек тоела иде. Әйтерсең ул фәрештәләр йөри торган рәхмәт юлыннан Җиргә төшкән дә, «Кыйссаи Йосыф»ны язып, безгә әлегәчә билгеле булмаган шартларда янә ничектер юкка чыккан. Юк, аның тәрҗемәи хәле Идел-йортыбыз белән аерылгысыз бәйләнгән, гадәти каләм әһеле шикелле, шагыйребез төрки әдәби-мәдәни мохиттә иҗтимагый тәрбия алган. Бу яктан да Нурмөхәммәт Хисамов безнең мәгълүмати хәтерне тирәнәйтә төшә. Зур тарихлы гарәп-фарсы әдәбиятын нечкәләп белгән Кол Гали, баксаң, күпмедер дәрәҗәдә Әхмәд Ясәвинең шәкерте булган икән бит. Урта Азия шагыйренең мавыктыргыч мәктәбе Мәүлә Колыйга да йогынты ясаган. Өч төрки халыкның өч шагыйре – Кол Гали, Әхмәди һәм Дүрбәк – иҗатларын өйрәнеп тә, бу чорлар әдәбиятыннан яхшы хәбәрдар галимебез мәдәни бәйланышлар географиясен киңәйтердәй кызыклы күзәтүләр ясый: чынлыкта Идел буе, Урта һәм Кече Азия уртак мәдәни тормыш белән яшәгән, берсенең әдәби иҗатта ирешкән уңышы шундук икенчесенең дә казанышына әйләнгән, алай гына түгел, санап үтелгән каләм әһелләренең һәркайсы башка әдипләр өчен җирлек әзерләгән.

Шөкер, татар әдәбияты тарихының да пәрдәләре отыры ачыла. Дөрес, әгәр Кол Гали исеменнән анкета тутырырга алынсак, безләргә әле байтак мөһим мәгълүматлар билгеле түгел: шагыйрьнең мәңгелек йортына күчкән төгәл вакыты да, истәлек тактасы тәгаенләп куярлык туган нигезе дә... Бәлки, легенда ачылып бетмәскә тиештер?! Ничек кенә булмасын, мәшһүр элгәребезнең олы иҗатын академик нигезгә куеп өйрәнү буенча соңгы берничә дистә елда алга таба зур сикереш ясалды. Галимнәребезнең тәфсилле эзләнүләре сокландыра. Шулар арасыннан җентекле анализ остасы Нурмөхәммәт Хисамов «Кыйссаи Йосыф»ның һәрбер күзәнәгенә, филигран пөхтәлеге белән аның тукымасындагы һәрбер атомга үтеп кергәндер сыман. Аңлашыла ки, урта гасыр шагыйренең бармак эзе калган кулъязмалар безнең заманнарга кадәр килеп җитә алмаган, әмма аның ил-көн гаме белән тулы йөрәк эзен галимебез барыбер табып күрсәтүгә ирешге.

Галим иҗатындагы үзәк темага кагылышлы фәнни хезмәтләрне күпмедер барлап чыккач, немец драматургы Бертольт Брехтның берьяклы хөкем йөртүгә мөнәсәбәте искә төште. «Бары бөекләрне генә тану әдәбиятта бернәрсә дә аңламаудан килә, – дип искәрткән әдип. – Күк беренче зурлыктагы йолдызлардан гына тормый...». Иманым камил, зирәк акыллы Нурмөхәммәт Хисамов әлеге хакыйкатьне яхшы аңлыйдыр. Әгәр очсыз-кырыйсыз «Кыйссаи Йосыф» дастанын өйрәнү дәвамында шулкадәр зур тәҗрибә туплап, гомуми нигездәге уртак фәнни методологияне үзенең алымнары белән баеткан хәлдә, татар әдәбиятының төрле чорларына караган башка каләм әһелләре иҗатына игътибар итмәсә... Бу аның өчен үкенечле беркатлылык, кискенрәк төстә әйткәндә, талантын исраф итү булыр иде. Афәрин, татар әдәбияты үсешенең безгә мөһим саналган һәрбер өч дәверен өйрәнүдә дә ул үзенең анализын көчле интеллекты белән баета алган белгеч дәрәҗәсендә кала. Бу яктан Нурмөхәммәт Хисамовның урта гасыр, XX йөз башы, совет чоры һәм соңгы еллар әдәбиятына багышланган хезмәтләрен, тулаем алганда, төрледән-төрле буын милләттәшләребезне уртак җирлектә калку итеп күрсәткән рухият тарихының табигый эзлеклелектәге сәхифәләре итеп кабул кыласы килә. Ирексездән уйлап куясың: әйе, аерым әдипләр белән нәрсәдер бөтенләйгә китә, нәрсәдер киләчәк мирасы рәвешендә гомерлеккә кала. Һәм

бер чордагы язучыларның язмышы икенче чорныкына бигүк охшамый, әмма алар арасында ниндидер өзеклеккә китерердәй аңлашылмаучылык упкыны юк. Вакыт бөтенесен бәйли. Галим гомуми әдәби барышны менә шундый бөтенлектә күрсәтеп кенә калмый, башкалар алдына да язма сәнгатебезне объектив-тарихи бәяләү буенча таләпләр куя. «Әдәби дәверләр күпкырлы идея-сәнгатьчә эзләнүләрдән торган, эзлекле, кануниятле һәм бердәм процесс рәвешендә яктыртылырга тиеш, – дип, үзенчә катгыйлык белән белдерә ул «Яңача фикерләү һәм татар әдәбияты тарихы концепциясе» исемле мәкаләсендә. – Ул аерым күренеш яки ядкәрләрнең бер-бер артлы тезелгән эзлекле гади хронологик чылбыры гына булмаска тиеш». Безнең халык теле белән әйткәнне иңе белән күтәргән затларны ярата. Бу җәһәттән Нурмөхәммәт Хисамов әдәбиятның аерым концептуаль-теоретик мәсьәләләрен күтәргәндә дә, төрле буын шагыйрьләренең иҗатына тәнкыйди бәя биргәндә дә, бүгенге яшәешебезнең көнүзәк мәсьәләләренә публицистларча мөнәсәбәтен белдергәндә дә, үзенә йөкләнгән җаваплы урыннарда хезмәт вазифаларын башкарганда да, көндәлек яшәү рәвешендә дә яшьли инанган принципларына һәрдаим тугрылык саклый. Отыры ныгый барган менә шундый ихлас бирелгәнлек аның унике гасырлык татар әдәбиятына күзәтү ясалган хезмәтендә дә, безнең әдәбият белемендәге шәрекъчелек нигезләрен ачыклауны максат кылган эзләнүләрендә дә, урта гасыр мирасы милли экология яссылыгына куеп барланган тикшеренүләрендә дә, әдәби мирасның милләт бердәмлегенә турыдан-туры йогынты ясавын чагылдырган уйлануларында да, «Татар поэзиясе антологиясе»нең ике томлыгына махсус язылган кереш мәкаләсендә дә, «Татар әдәбияты тарихы»ның I, IV һәм VI җилд кисәкләрен чыгарышудагы фәнни эшчәнлегендә дә таныш чалымдай ачык төсмерләнә.

Шунысы да сөендерә: Нурмөхәммәт Хисамов, язма мирасыбыз тарихының борынгы катламнарын тикшергәндә, аерым әсәрләргә безнең заманга хас сыйфатлар тагу, ә бүгенге чор әдәбияты казанышларын бәяләгәндә, үтә субъектив карашларга өстенлек бирү ягына беркайчан да авышмады. Алмашынып торган хакимиятләр идеологиясеннән чыгып кына фикер йөртүләр рухиятебезгә инде болай да озакка сузылган шаукымын салырга өлгерде. Реаль

тәнкыйть җирлегендә кала алган каләм иҗат әһеленә бернәрсәне дә көчләп такмый. Галәбәле рухның кылган гамәлләре, гадәттә, һәр заман өчен кадерле. Әлбәттә, әдәбият белгече үз чорының караш-омтылышларыннан тулысынча азат була алмый, әмма ул рух тирәнлегеннән күтәрелгән идеяне барыбер дөрес ачарга бурычлы. Хәер, мәңгелекне тоя белүче галим һәр буын әдибенең әсәрен үзеннән-үзе яшәешнең гомуми шартлары белән бәйләргә омтылып тәфтишли. Шундыйлар рәтендә торучы Нурмөхәммәт Хисамовны да сүз сәнгатендәге рух казанышлары күбрәк кызыксындыра. Аның хезмәтләрендә «рух», «рухи», «рухани» кебек сүзләрнең адым саен диярлек очравы да галимнең әдәбият үсешен нинди призма аша карап өйрәнүен раслый булса кирәк. Хәтта «руханият» сүзен дә ул лексиконына кертеп җибәргән...

Чынбарлык күрсәткәнчә, чын галим өчен үз фәнеңне ниндидер күтәренкелек белән сөю генә җитми, күп кенә очракта талчыктыргыч кара эш башкарырга сәләтле булуың да сорала. Күз алдына килә: табигате буенча һәрнәрсәне бөтен ваклыклары белән аңлатучы Нурмөхәммәт Хисамовка галимлек эшчәнлегендә күтәрелгән чирәм тузанын шактый йотарга туры килгәндер. Яңача фикерләү яклы таләпчән белгеч буларак, татар әдәбияты үсешен өйрәнүдә һәртөрле «изм» тарафдарлары тарафыннан җибәрелгән хата-ялгышларны юл уңаеннан төзәткәләп баруны да, ягъни рухиятебезнең шактый бозылган җирлегенә хәлкадәри рекультивация үткәрүне дә ул үзенең изге бурычы итеп санады. Узгынчы идеология коткысына бирелеп, кайбер классик әдипләребезгә үзебез үк таккан яман ярлыкны алып ташлауда да туры сүзен хакыйкать дәрәҗәсенә күтәрә белгән галимебез кире кагылгысыз өлеш кертте. Бер генә мисал.

1979 ел иде. Минем «Социалистик Татарстан» газетасында эшләп йөргән чагым. Көннәрнең берендә әдәбият-сәнгать бүлегенә Нурмөхәммәт Хисамов килеп керде һәм шагыйрь Дәрдемәнднең юбилее уңаеннан язылган мәкаләсен калдырып китте. Бәхәс купты: галимнең язганнарын газетада чыгарыргамы, әллә инде кире кайтарыргамы? Хәтта редколлегия дә икеләнеп калды. Шикләнү урынлы булгандыр, чөнки югары партия әһелләренең күпчелеге өчен Дәрдемәнд әлегәчә «буржуаз шагыйрь» исемлегендә иде. Әмма әдәбиятны ихлас яраткан мөхәррир Шәмси Хамматов,

тәвәккәлләп, шау-шу тудырачак әлеге мәкаләне басарга рөхсәт бирде... Сыйнфый яктан үтә уяу бәндәләр өлкә комитеты секретарена шикаятьләр яудырды. Китте «келәм»гә чакырулар. Зур йортта мөхәррирне хәтта эшеннән алу белән янаулар булды. Безнең бүлеккә дә шактый эләкте. Шөкер, күңелсез мәрәкә югалтуларга китермәде. Киресенчә, Нурмөхәммәт Хисамовның үзенә генә хас тасыл белән җиренә җиткереп башкарылган мөһим хезмәте халык хәтереннән нахакка сөрелгән кабатланмас асыл шагыйребезне тулаем «реабилитацияләү эше»н тизләтүгә китерде.

Әгәр сәнгатькяр тарихчы да, шагыйрь дә, философ та, күзәтүче дә булырга тиеш икән, әдәбият үсешен зурдан кубып өйрәнергә алынган әһелдә нигә әле шундый сәләтләр чагылыш тапмаска тиеш?! Бәхеткә, үз чорының алдынгы карашларын шәхси казанышына әверелдерә алган Нурмөхәммәт Хисамовта безнең галим-голәмәгә аеруча кирәк булган әлеге сыйфатларның бөтенесе дә бар. Инде күргәнебезчә, әдәби тамырлар тирәнлегенә төшкән тикшеренүчебез үткәннәр тарихын да, шулай ук бүгенгенең социаль күренешләрен дә яхшы белә. Ә инде аның шагыйрьлеген исбатлап та торасы юк. Хәтерлим, мин әле 8 нче сыйныфта укыган чакта, ул, Мирсәй Әмир, Сибгат Хәким, Нури Арслан, Нәби Дәүли белән бергә, безнең мәктәпкә яшь шагыйрь буларак килгән иде. Соңрак аның «Яз миңа чәчәкләр китерә» исемле шигъри җыентыгын беренче тәэсирләндергәч танышуымның үзенчәлекле дәвамы төсендә кабул иттем. Татар әдәбиятының барлык чорлары горурлыгы саналган ядкәребез Нурмөхәммәт Хисамовның хәтта шигырьләр язуыннан да уңды: әлеге дә баягы «Кыйссаи Йосыф» дастанын ул хәзерге әдәби телебезгә шигъри тәрҗемәдә чыгарды. «Йосыф – Зөләйхә» дигән драма да иҗат итте. Галимдә олпат әдиплек сыйфатларының да барлыгын раслап, аның бериш мәкаләләрен искә төшереп үтәргә кирәктер. Кемнәр генә үзәккә алынмаган аларда: галимнәр дә, композиторлар да, рәссамнар да, җырчылар да, актерлар, сәясәтчеләр, милләтпәрвәрләр дә... Әлеге һөнәр ияләрен борчыган мәсьәләләр Нурмөхәммәт Хисамовны да тынгысызлап тора.

Галим көндәлек матбугат телендәге гайре табигый чуарлыкка да, милли исемнәр сайлаудагы талымсызлык күренешенә дә, латин алфавитын торгызуның билгесезлектә калуына да, хәтта

гүзәллек конкурсын үткәрү тәртибенә дә битараф түгел. Язын шомырт агачларының вәхшиләрчә сындырылуы да шагыйрь җанлы галимнең йөрәген әрнетә. «Әгәр мин шомырт булсам, бөтенләй чәчәк атмас идем», – дип көтмәгәнчә искәртә ул. Чыннан да, әгәр шомыртлар, шулай талана-талана, бервакыт чәчәк ату һөнәрен «онытсалар»?

Кызганыч, безнең күп кенә әдәбият галимнәренә милләтебез, Идел-йортыбыз хакына кайгыртучан әдипләрчә яну җитми.

Борынгылар киңәш биргәнчә, зурдан кубып язу-сызу эшенә алынганчы, әүвәл яхшылап фикер йөртергә өйрән. Шәхсән мин шулай тоям, әдәбият галиме Нурмөхәммәт Хисамовның язганнарында анализлы «фикер йөртү» өстенлек аладыр. Шагыйрь буларак, ул үзенә фәндә илһамланып эшләргә дә ирек бирә булса кирәк, әмма соңгы исәптә объективлык һәм төгәллек кысаларыннан барыбер читкә чыкмый. Акылга муафыйк чама хисе тиешенчә саклана. Барысы да аңлаешлы, чөнки башыңдагы фикереің ачык булгач, язганың да ачык килеп чыга. Әйе, рух тирәнлегенә төшүче каләмдар фикер иясе булырга тиеш. Бит, асылда, әдәбиятны гыйлем зәминеннән аерырга мөмкин түгел, шул исәптән әдәбиятны үзәккә алган фәнни эшчәнлекне дә. Менә шуңа күрә дә заманның интеллектуаль биеклегендә торган Нурмөхәммәт Хисамов, язма сәнгатебез тарихын өйрәнгәндә, берничек тә «беркетмәче» булып кала алмый. Хәтта ул фактларны да иң элек чимал сурәтендә күрә, зиһене аша кат-кат үткәргәч кенә аларны хакыйкать итеп таный. Кай очракта танымый да. Кыскасы, әгәр әдәбият белеме өлкәсендә эшләүче галимнәребездә фәнни потенциаль төрлелек күзәтелә икән, бу җәһәттән Нурмөхәммәт Хисамовның хезмәтләре фәлсәфи тирәнлек ягыннан да аерылып тора.

Чыннан да, бөтен сәнгатьләрнең анасы саналган әдәбиятны тирәнтен өйрәнү өчен, галим байтак һөнәр ияләренең осталыгын үзенчә үзләштерергә тиеш. Аерым әсәрләргә чагыштырма анализ ясау, әйе, күзәтүче булуны да таләп итә. Әле югарыда күздән кичерелгән мөһим сыйфатлар да җитеп бетми – язма мирасыбыз белгеченә текстолог вазифаларын да башкарырга туры килә. Кулына каләм тотып эш итүче әдәбият галименә, әлбәттә, күпмедер күләмдә лингвистлык сәләте дә артык түгел. Ә соңгысында үзенне иркен тояр өчен язма телне мөкәммәл дәрәҗәдә белү лазем.

Гомумән, әдәбият белеме хезмәтләре халык тарафыннан мөмкин кадәр күбрәк укылсын дисәк, аларның авторлары чын мәгънәсендә сүз остасы югарылыгында торырга тиеш. Аңлашылганча, әлеге таләпләр Нурмөхәммәт Хисамовка мөнәсәбәтле рәвештә искә төшерелә, чөнки аның галимлек талантына боларның бөтенесе дә салынган. Дөресен генә әйткәндә, ул хәтта филология белгечләрендә дә сирәк очрый торган, олпат әдипләрнекен күпмедер хәтерләтеп куйган тел-өслүп осталыгына ия. Юк, бу очракта ике оппоненттан гайре укучысы булмаган диссертация әһелләре хакындагы каһкаһәле киная киң даирә тарафыннан яратып кабул ителгән китаплар авторына берничек тә туры килми. Хәер, сигез гасыр дәвамында дөньяда булып киткән йөзләрчә миллион татарның милли бестселлеры саналган «Кыйссаи Йосыф», тулаем алганда, шигърият турында укый башлауга ук гайрәт чигерә торган алама телдә язылырга тиеш тә түгелдер.

Тормышта расланган хакыйкать: даими үсештәге иҗат биеклегендә калу өчен, әүвәл кешелек таланты белән бүләкләнүең зарур. Бу яктан Нурмөхәммәт Хисамовның яхшы тәрбия алган, күпьяклы руханә әзерлекле шәхес булуы сизелеп тора. Болары бай китапханәле «халык тарихчысы» Шаһвәли абзыйның малае булудан һәм буыннан буынга килгән руханилар нәселендә тупланып торган бәрәкәтле маядандыр, һәрхәлдә галим хезмәтләрендәге фәлсәфи-эстетик башлангычның тәгаен күзалланган җирлеге бар. Аның затлы шагыйребез Дәрдемәндкә тартылуы да күпмедер дәрәҗәдә рухи ихтыяҗга бәйледер. Ә эстетик хис-тойгы – яхшылыкның нигезе ул. Әхлаклылык чагылышы. Минем уйлавымча, Нурмөхәммәт Хисамовның шигырьләр иҗат итүе дә аңа зәвекъ офыкларын киңәйтергә булышкандыр. Галимнең затлылыгы йөзенә чыккан. Теләсә кемгә килешмәгән аксөякләр смокингы да аның мәһабәт гәүдәсенә ятышып тора. Табигый ки, эчке затлылык үз-үзен тотышында да, шулай ук сөйләшендә дә сизелә. Фикере төпле. Уен уйдырып әйтә белә. Монологлары мавыктыргыч. Җорлык та хас үзенә. Тын алышы морзабыз Әмирхан Еникинекен хәтерләтә. Туры сүзле. Үтләре сытылучан бәгъзе мизантропларны үзенең дошманына да әверелдерергә мөмкин. Аның холык-фигыленә мәгълүм микъдарда педантлык та сеңдерелгән – кемнәрдер биргән киңәшкә колак салмау гадәте дә бар. Мөгаен, гаиләсендә

дә ул шундыйдыр. Яхшы мәгънәдәге таләпчән «вакчыллыгы» аны хәләл җефете – профессор Фәһимә ханым Хисамова белән бәхәскә кертәдер. Әлбәттә инде, телебез хакында һәм һөнәрмәндлек дәрәҗәсендә. Аннары рәссам буларак танылган улларына аталарча гына түгел, сынлы сәнгать серләрен нечкәләп тойган белгечләрчә теләкләрен белдерәдер. Фәнни эшләрен туктатып торып, газиз әнисе Һаҗәр апаның яки улы Ниязның үзенчә манер белән сурәтләрен ясап куядыр... Менә шундыйрак зат ул Нурмөхәммәт Хисамов.

Беркадәр гөман кылып караганда, галим Нурмөхәммәт Хисамов хезмәтләрендә үзәккә алынган шәхесләр үзләре бер дөнья булып күз алдына килә. Менә алар мәһабәт зур бинага ниндидер мәслихәт мәҗлесенә җыеласы иткән. Әлбәттә, иң түрдә – Кол Гали. Аның тирәсендә Алтын Урда, Казан ханлыгы, Урта һәм Кече Азия шагыйрьләре урын алган. Шушында ук Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Һади Такташ, Хәсән Туфан да күренә. Бирегә «Кыйссаи Йосыф» дастанын өйрәнгән галимнәр дә чакырылган. Алар арасында немецлардан Карл Броккельманн, Эберһард Һилшер, голландлардан Мартин Һоутсма, азәриләрдән Халыйк Күроглы, төрекләрдән Мехмед Фуад Күпрелезадә, руслардан Александр Самойлович, Евгений Бертельс, татарлардан Габдерәхим Утыз Имәни, Шиһабетдин Мәрҗани, Гали Рәхим, Габдрахман Таһирҗанов, Хатип Госман һ.б. бар. Әнә, әлеге очрашуга аерым мәкалә каһарманнары – композиторлар Рөстәм Яхин белән Сара Садыйкова да, җырчылар Рәшит Ваһапов белән Хәйдәр Бигичев тә килгән... Түгәрәкләп әйткәндә, кунаклар санап бетергесез. Монда яшьрәк буын фән эшлеклеләре дә, әдәбият һәм сәнгать әһелләре дә байтак.

Ап-ачык итеп күзаллыйм: барлап үтелгән әлеге күренекле шәхесләр янәшәсенә куеп караганда, Нурмөхәммәт Хисамов үзе дә чит-ят булып күренми икән.

*Зиннур Мансуров.*
*2007*

# БЕР КАНАТЫ – ФӘН, ИКЕНЧЕСЕ – ШИГЪРИЯТ

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ УН ГАСЫРЫ

«Укый һәм яза белмәгән татарга якташлары түбәнсетеп караган, һәм гражданин буларак андыйлар башкаларның хөрмәтеннән мәхрүм кала», – дип язган 1844 елда Казан табибе һәм этнограф Карл Фукс «Статистик һәм этнографик нисбәттән Казан татарлары» дигән китабында.

Татарларның тарихи язмышы – ул татар әдәбияты язмышы да. Галимнең колачлы күзәтүдән торган әлеге мәкаләсе әдәбиятыбыз үсешенең төрле этаплары, күренекле исемнәр һәм әсәрләр хакында киң мәгълүмат бирә.

Карл Фукс: «Читтән килгән һәр кешегә, һичбер шиксез, Казан татарларында, гомумән әйткәндә, хәтта кайбер Европа халыкларыннан да гыйлемлерәк халык күрү сәер тоелыр иде», – дип язган. Аның бу китабы авторның татарлардагы көндәлек тормышны күп еллар дәвамында күзәтүдән туган һәм хөкем йөртүенең, нәтиҗәләр ясавының төгәллеге белән аерылып тора.

Татарлар төрле эчтәлектәге китаплар укыганнар. Илаһият гыйльме дисеңме, фикх (мөселман юриспруденциясе), медицина, педагогика, астрономия, фәлсәфә һәм, әлбәттә, матур әдәбият даими кулланылышта булган. XIX гасырда башланган китап басуга кадәр халык кулъязма китаптан файдаланган, татарларда, бөтен мөселман Көнчыгышындагы кебек үк, кулъязма китаплар бик нечкә һәм катлаулы һөнәрдән хисапланганга, кыйммәт бәяләнгән. Шуңа карамастан, алар киң таралган.

Рус дәүләте татар милли мәктәбенә бернинди ярдәм күрсәтмәгән. Шуңа күрә дәреслекләр һәм башка китаплар мәдрәсә шәкертләре тарафыннан арзанлы рус кәгазенә күчереп язылган.

Вакыт узган саен кулъязма китаплар бик күп туплана барган. XX йөзнең 20–30 нчы елларында котырып юкка чыгаруга карамастан, гарәп язуындагы китаплар археографлар тарафыннан уннарча мең данәдә табыла торган. Безнең үзбәк аркадашларыбыз Нәваи китапларын Париж китапханәләреннән күчереп алалар. Ә аның «Хәмсә»сенең тулы һәм югары сыйфатлы күчермәсе Казанда саклана.

Ә болгар-татар әдәбиятының XIII гасыр башындагы бөек классигы Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы, күчермәләре табылган нөсхәләр буенча санаганда, өч йөзгә җитә. Илаһиятче галим Г. Баруди коллекциясендәге XVI гасыр кулъязмасы иң искесе дип хисапланган. Әмма бу имамның кыйммәтле бүтән китаплары белән бергә мәгълүм 20 нче елларда юкка чыккан. Исән калган кулъязмалар арасында иң иске данә булып Дрезден нөсхәсе санала. Аны Зентель дигән кеше «Яңа бистә татары Динмөхәммәт Суттовтан» алган булган. Үзенең барлык билгеләре белән бу күчермә XVII гасырга карый.

Китап басу татарларга бары XIX йөзнең 30 нчы елларында гына рөхсәт ителгән. Китапларга сорау гаять зур булган, һәм татар китабын ташып йөрүчеләр аларны үз кавемдәшләре арасында гына түгел, ә башка тугандаш халыклар: башкортлар, казахлар арасында да таратканнар. Зур тиражлар белән басу урта гасырның күп кенә кыйммәтле ядкәрләренең юкка чыгуыннан коткарган. Рабгузиның «Кыйссасел әнбия» (1310 ел), Хөсам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» (XIV йөз), «Коръән тәфсирләре», Шәрекъ галимнәренең һәм шагыйрьләренең (Ибне Сина, Сәгъди, Гаттар һ.б.) күп кенә китаплары мәдрәсәләрдә уку әсбабы һәм халыкның укымышлы катлавында мавыгып уку әсәрләре булып саналган. Алар кулъязма хәлендә дә һәм басма рәвештә дә таралыш тапкан.

Татар халкының рухани-әхлакый тормышында аерым бер хөрмәтле урынны югарыда телгә алган «Кыйссаи Йосыф» поэмасы биләгән. Ул Гүзәл Йосыф турындагы Тәүрат-Коръән сюжетына таянып иҗат ителгән. Мөселман Көнчыгышында әсәрнең каһарманы Йосыф Ситдыйк (Тугры Йосыф) дип аталган. Бу әсәр изге

бурычка, атага, ватанга тугрылык турындагы китап булып, туганнар ызгышын гаепләгән, хисләр сафлыгын данлаган. Ата-аналар «Йосыф китабы»н (халыкта поэма шулай аталган) кәләшнең бирнәсенә кушып сала торган булганнар. Пугачев явында катнашкан бер кешенең конфискацияләнгән милке турындагы актта кыйммәтле әйберләр арасында әлеге китап та телгә алына. Татар хатын-кызлары аны кышын җыелып кич утырганда көйләп укыганнар.

Урта гасырларда әдәбият мәсьәләсендә «үзебезнеке» яки «читтән китерелгән» дигән төшенчә булмаган. Ә Идел буеның китап репертуары бик киң булган. Мәсәлән, Төркестанның суфи шагыйрьләре Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакыргани (XII гасыр) татар укучылары өчен үзләренеке булып саналган.

Казан ханлыгы Мәскәү дәүләте тарафыннан яулап алынгач, әдәби тормыш, бөтен рухани эшчәнлек сыман ук, озак вакыт гаҗиз хәлгә төшкән килеш аптырауда калган. Хәлбуки шигъри иҗат традициясе шулчаклы көчле булган ки, күренекле авторлар һәм мәшһүр әсәрләр дөньяга килү туктамаган.

XVI гасырның беренче яртысы Казан ханлыгының мәдәни чәчәк ату дәвере буларак, тарихта *Мөхәммәдьяр, Гаифбәк, Кол Шәриф һәм башка авторлар* исеме белән теркәлеп калган. Казан ханы Мөхәммәд Әмин шагыйрь дә булган. Аның Болгарны җимергән Аксак Тимергә ачу һәм каһәрләү тулы шигырьләре хәзергәчә сакланып калган. **Мөхәммәдьяр «Төхфәи мәрдан» («Ирләр бүләге») һәм «Нуры содур» («Йөрәкләр яктысы») дигән бөек поэмалар иҗат иткән.** Аларда гаделлек һәм мәрхәмәт идеяләре җырлана.

XVI йөзнең икенче яртысында Мәскәү әсирлегендә дипломат Аднаш ибне **Адниш тарафыннан «Сиражел-колюб» («Йөрәкләр яктырткычы») исемле зур трактат язылган.** Анда автор гарәб-мөселман тарихы материалында читләтелгән формада 1552 елдагы җиңелүнең сәбәпләре турында уйлана.

XVI–XVII гасырларда татар эпосын булдыру омтылышлары ясала. Халык хәтерендә газаплар эчендә туып килгән эпосның колоритлы, шигъри камил фрагментлары сакланып калган. Аларда хатирәләр һәм реаль шул заман контрастында персонажларның трагик халәте чагылган.

Әмма **«Чура батыр»** дастаны да, телгә алган фрагментлар да татар халкының бөек эпосы **«Идегәй»** дастаны дәрәҗәсенә ирешә

алмаган. Дәүләтчелекне һәм тарихи оптимизм хисен югалту халкының эпик фикерләвендә кризис китереп чыгарды. Шушындый тарихи җирлектә язма әдәбият белән фольклор чигендә моңарчы билгесез лиро-эпик жанр – *бәетләр* барлыкка килде. Аларда шәхси һәм иҗтимагый тормышның фаҗигале коллизияләре хикәяләнгән.

Әдәбиятта мистицизм, ягъни тормыштан бизү һәм ахирәт турында кайгырту төсмеренә өртелгән суфичылык идеологиясе өстенлек ала.

Әмма татар әдәбиятының ныклык запасы югары булган. Суфичылык җирлегендә XVII гасырда **зур лирик шагыйрь Мәүла Колый** күтәрелеп чыга. Ул үзенең остазлары **Әхмәд Ясәви һәм Бакыргани** традицияләрен дәвам итә. Аның кайнар дәртле лирикасында ике мотив: тәкъвалыкка, илаһият белән кушылуга омтылу һәм җир сөрүченең хезмәтен данлау бергә үреләә. Аның икенче төркем хикмәтләрендәге фикерләүнең кыю реализмы һәм гуманизмы тарихи яңа нюанслар белән байый. Мәсәлән, ул «Илаһият каршында икмәк үстерүче мөселман яки башка дин вәкиле бер үк дәрәҗәдә югары» дип кайнар раслый.

XVII гасыр татар халкының иҗтимагый-рухани тормышында иң авыр чор булып санала. Дини көчләү үтә рәхимсез төс ала. Епископ Лука Канашевич заманында унбер ел эчендә 538 мәчетнең 418 е, яннарындагы мәктәпләр белән бергә, ватып юкка чыгарыла. Татарлар илдәге массакүләм протест хәрәкәтендә кайнар дәрт белән катнашалар. Пугачев явында татар полковниклары зур ашкыну белән «император Петр Федорович өчен», ягъни Емельян Пугачев өчен, почта элемтәсен һәм акча җыюны җайга салалар. Бу исә рус халкы белән бергә хәрәкәт итүнең үзенә күрә мәктәбе була.

Габдулла Алиев (Батырша) җитәкчелегендәге татар-башкорт баш күтәрүе иҗтимагый-сәяси фикер тарихында тирән эз калдырган. Бу уңышсыз чыккан баш күтәрүнең сәбәпләре һәм максатлары Шлиссельбург крепостена ябылган Батыршаның күләмле «Гарызнамә»сендә («Протест язмалары») бәян ителгән. Шушы социаль-публицистик трактат патша чиновникларының татар һәм башкортлар арасында уздырган чыдагысыз башбаштакларны һәм көчләүне фаш иткән. Анда ак патшаның гаделлегенә ышану социаль утопия төсмеренә манчылган. Шул ук вакытта автор кыюланып,

императрица Елизавета Петровнаны дәүләтендә нәрсәләр барганны күрмәгән өчен шелтәли.

Зур-зур социаль-сәяси вакыйгалар тәэсирендә татар шигърияте стилистик һәм идея ягыннан традиционнардан нык аерылып торган мотивлар барлыкка килә. Мәсәлән, дидактик шагыйрь Габди үз чоры дөньясын бәяләүдә аек фикер йөртергә чакыра.

Алданмагыл нәҗес торыр бу дөньяга, бал санып,
Аздырмага алдар сәне хәйлә белә әл сонып,
Көн дә бизәп йөзен төзәр, алданмагыл хур санып,
Мескен Габди дога кылыр, Казан җирен Тур санып.

Татар шигыренең яңару процессы бигрәк тә Габдессәлам Ураевта ачык чагыла. Аның мәхәббәт лирикасы, Шәрекъ шигърияте традициясендәге газәл формасында гына түгел, фольклорча шаян интонациядә дә яңгырый. Әмма әсәрләрнең психологик эчтәлегендә дә, социаль тетрәүләр нәтиҗәсе буларак, принципиаль яңа күренешләр күзәтелә. Мондый тенденциянең характерлы чагылышы булып Пугачев яуларында катнашкан мәгълүм шәхес Габделмәннан Мөслимовның язмышы һәм иҗаты күз алдына килә. Аның шигырьләрендә эчке кичерешләрнең тирән драматизмы чагыла.

Нәчә дорсаң, бу дөньядин кидәрсән,
Куелачак йирә ахыр кидәрсән.
Изге гамәл сән гарипдә вармыдыр?
Тар кабердә нә кыйлырсән, нидәрсән?

Татарларның гомумрусия иҗтимагый хәрәкәтендә актив катнашуы һәм моның фольклорда гәүдәләнүе татар җәмгыятендәге тирән үзгәрешләрне күрсәтә. Шулар буенча хөкем йөрткәндә, татар халкы яңа тарихи шартларга тулысынча ияләшеп җиткән. Е.И. Пугачев турындагы халык җырларында егетләрнең кыю батырлыкны һәм каһарман эшләрнең колачын сагынуы чагыла:

Пугачау патша бар диләр,
Постау бишмәтләре тар диләр,
Җаек та буе яу җирләрен
Айкап та йөргән шул диләр.

Пугачау патшаны күрсә идең,
Алларыннан буй бөгеп узса идең,

Аргамак менеп, дан тотып,
Җаек яуларында йөрсә идең.

Шунысы игътибарга лаек, халык шигърияте һич тә бунт белән фетнәне идеаллаштырмый, ә Пугачев сурәтендә («Патша Петр Федорович») лигитим хакимиятне күрә. Татарларның Пугачев яуларында катнашуыннан һәм аларның хөкүмәт гаскәрләрен яклавыннан төп сабак патшабикә Екатерина II өчен шундый булган ки, ул татарларда реаль көч күрә һәм, моның белән исәпләшергә кирәк, дип саный.

1782 елда Казанда ратуша төзелә, ә 1789 елда мөселманнарның Рухани идарәсе оештырыла. Ә моннан алдарак патша хөкүмәте төбәкне христианлаштыру үзәген – Яңа чукындырылганнар мәктәбен (Новокрещенская школа) юкка чыгара, татарларның сәүдә эшләрен чикләүне бетерү турында указ игълан итә. Шул рәвешле, империядә дини түземлек сәясәте игълан ителә.

Татар әдәбияты XIX гасырга яңарыш рухы белән килеп керә. Татар халкының гомумрусия икътисади һәм социаль-сәяси процессына көчлерәк тартыла баруы моңа ярдәм иткән. Милли сәүдәгәрләр Урта Азия һәм Көнчыгышның башка илләре белән сәүдә итүдә активрак катнаша башлыйлар. Әдәбиятта маҗаралы тематика белән кызыксыну көчәя.

Фарсычадан тәрҗемәдә бөтен бер бәйләм «Мәҗмугыл-хикәят» маҗаралы хикәяләре пәйда була. Шушындый дөньяви бәяннарга ихтыяҗ халыкның көр хис итеше турында сөйли.

Әдәбиятта дөньяви башлангычның көчәюе 1812 елгы Ватан сугышында җиңүдән соң аерымачык булып күренә башлый. Гомумхалык шатлыгы дулкынында «Рус-француз сугышы турында» дигән бәет иҗат ителә. Ягъни язма шигърият белән фольклор арасындагы әсәр туа. Анда шушы вакыйганың катнашучысы Россия армиясе сугышчыларының каһарман эшләрен бәян итә. Традицион-трагик жанр кысаларында оптимистик, якты рухлы әсәр килеп чыга:

Бу бәетне язган чакта
Каләмнәр камыш иде.
Өйгә керсәм, тышка чыксам,
Шатлыклы тавыш иде.

Җиңү белән кайткан көннең шат рухы хакында билгесез автор әнә шулай язган.

XIX гасырда халыкта көр рух уянуы талантларның бөтен бер плеядасын тудырган. Шагыйрь һәм энциклопедист галим Габдрәхим Болгари-Утыз Имәни фәлсәфи-этик эчтәлекле уннарча трактат-поэмалар һәм үзенең читен язмышы турында тирән кичерешле бик күп лирик шигырьләр язган.

Бу гасыр әдәбияты татар җәмгыятенең кичерешләр һәм фәлсәфи-әхлакый эзләнүләренең бөтен бер гаммасын чагылдырган. Патша Россиясе шартларында интеллектуаль хезмәтнең бары бер төре – илаһият гыйльме белән генә шөгыльләнүгә юл куелган, шуңа күрә интеллектуаль иҗат потенциалы муллалар мохитендә генә тупланган. Алар арасыннан **Һибәтулла Салихов һәм Шәмсетдин Зәки** кебек зур суфи шагыйрьләр килеп чыккан. Аларның тирән фәлсәфи шигърияте хакында тарихчы һәм күренекле фикер иясе Ризаэддин Фәхретдин: «Аларның шигырьләрендәге камиллек өчен бер гасырда да кызарырга туры килмәс», – дип язган.

**Мулла Габделҗәббар Кандалый** сөеклесенә лирик хатлардан торган искиткеч поэмалар шәлкемен иҗат иткән, ә сөеклесе аның гыйшкын кабул итмәгән.

**Шиһабетдин Мәрҗани** татар халкының Болгар һәм Казан чоры тарихы буенча күптомлы хезмәт язган, аларда фәлсәфә һәм әдәп проблемаларын яктырткан. Аның авазы бөтен мөселман дөньясында яңгыраган, рус һәм Европа галимнәре аның хезмәтләренә җанлы кызыксыну күрсәткәннәр. Ул татар җәдитчелегенең теоретикларыннан берсе булган.

Икенче бер мулла – **Каюм Насыйри** татар тормышын европалаштыруның эшлекле тарафдары булган, татар теле грамматикасы буенча хезмәтләр язган, сүзлекләр төзегән, һәр елны халыкта популяр булган календарлар чыгарган.

XIX гасырда татар шигърияте алдагы өч гасыр дәвамында югалтылган биеклекне тулысынча кайтарды. Ул үзенең идея-тематик палитрасы ягыннан күп жанрлы һәм күпкырлы рәвешкә керде.

Татар прозасы өлкәсендә кызыклы тәҗрибәләр килеп чыкты: **Муса Акъегетнең,** Ростов ахуны һәм XX гасырдагы атаклы илаһият белгече **Муса Бигиевнең** бертуганы **Заһир Бигиевнең** романнары языла. Мәгърифәтчел эчтәлекле татар драматургиясе

формалашып җитә. Бу жанрда Габдрахман Ильяси һәм Фатих Хәлиди юл яручылар булган.

XIX һәм XX гасыр чигендә талантлы шагыйрь **Мифтахетдин Акмулла** иҗат иткән. Шиһабетдин Мәрҗанинең мәгърифәтчел идеяләрендә тәрбияләнгән шагыйрь татар халкының үзаңын уятудагы олы хезмәтләрен ялкынлы кайнарлык белән данлаган. Аның зирәк афористик лирикасы татар язма шигъриятенең сәнгатьчә казанышларын да, башкорт чичәннәренең һәм казах акыннарының шигъри иҗат традицияләрен дә үзендә туплаган. Шуңа күрә бу халыклар, татарлар белән берлектә, аны үз шагыйрьләре дип саныйлар.

Акмулла татарның XX гасырдагы иң зур шагыйрьләре **Габдулла Тукай һәм Дәрдемәнд** иҗатына, татар һәм башкортларның уртак олы шагыйре **Мәҗит Гафури** шигъриятенә бәрәкәтле йогынты ясаган.

XX йөз башында татар милләте үзенең киләчәгенә оптимистик карый башлый. 1905–1907 еллар революциясе нәтиҗәсендә Россиянең иҗтимагый – сәяси тормышында барлыкка килгән либераль үзгәрешләр татарларның милли уяныш процессына үтә җитди тәэсир иткән. Газета һәм журналларның киң челтәре, гамәлдәге китап нәшриятлары белән берлектә, яшь талантларның үсеше өчен киң мәйдан хасил иткән. Татар әдәбияты XX йөз башында үзенең үсешендә гаять зур сикереш ясый. Ул үзенә узган юлның барлык мөһим үзенчәлекләрен туплый һәм яңа идея-эстетик ихтыяҗларга туры китереп трансформацияли.

Узган гасыр башындагы әдәби хәрәкәтнең төп тенденцияләренең берсе сәнгатьчә фикерләүнең ашкынып европалашуы булды. Бу – мәгърифәтчеләр эшчәнлеге, гомумроссия иҗтимагый хәрәкәтләре йогынтысы, татар яшьләренең Париж, Истамбул, Берлин һәм Европаның башка мәдәни үзәкләрендә белем алуы, татар зыялыларының рус университет даирәләре белән аралашуы һәм рус вакытлы матбугаты белән танышып баруы аркасында мөмкин булды.

XX гасыр башының бөек прозаиклары **Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирханның** әсәрләре шундый коллизияләрне фикердән кичерүгә багышланган. Көнчыгыш – Көнбатыш синтезы бигрәк тә шигърияттә ачык чагылды. Әгәр Тукайның иярү һәм алынмаларына язган искәрмәләргә игътибар итсәк, Шекспир,

Гөте, Һәйне, Толстой, Пушкин, Лермонтов кебек Европа даһиларының бөтен бер букетын күрербез.

Тукай үзенең мәхәббәт лирикасы мотивларын Байрон, Һәйне, Пушкин һәм Лермонтов исемнәре белән бәйли.

Романтик шагыйрь С. Рәмиев Шиллер шигырьләрен тәрҗемә итә, С. Сүнчәләй Һәйненең «Әлмансур» трагедиясен тәрҗемә итә. Шагыйрьне дини көчләүгә протест темасы җәлеп иткән.

Эре алтын сәнәгатьчесе, нашир һәм җәмәгать эшлеклесе (кадетлар партиясеннән Дәүләт Думасы депутаты) **Дәрдемәнд** формасы белән камил, строфикасы белән традицион шигърият өчен үзенчәлекле һәм яңа, фәлсәфи эчтәлеге белән тирән шигырьләр иҗат итә. Аның лирикасында Көнчыгыш – Көнбатыш синтезы бик органик чагыла. Пейзаж этюдларындагы галәми колач исә Гөтегә тарта, кеше язмышын фикердән кичерүе, кыска шигырьләрендә кешенең тарихи һәм табигый процесстагы урынын күзаллавы лирикада Гомәр Хәйямга тарта. Дәрдемәндтәге табигать тасвирендә Европа, хосусан француз шигъриятендәге сәнгатьчә-эстетик эзләнүләрнең кайтавызы, француз рәссамнары һәм шагыйрьләренә хас импрессионистик-сюрреалистик нюанслар сиземләнә.

Яңа дәвер герое – оптимизм һәм трагизм үрелешенннән торган катлаулы шәхес. Кичерешләр гаммасының бай тупланышы, милли хисләр, югары дәрәҗәдәге Россия патриотизмы һәм киң социаль-фәлсәфи күз күреме Тукай лирикасында тулы чагылыш тапты. XX гасыр башының идея юлбашчысы, һичшиксез, Гаяз Исхакый булды, милли гамьне гәүдәләндерүче һәм уйларның чын хакиме Тукай иде. 27 яшьтә үтә аз гомер кичереп дөньядан киткән шагыйрь татарлар өчен шигъри камиллек өлгесе булып кала. Яңа, совет чорына татар әдәбияты көчле, нык үскән, зур социаль-тарихи һәм сәнгатьчә әһәмияткә ия тема һәм проблемалар күтәрергә сәләтле дәрәҗәдә, җитлеккән әдәби-тәнкыйди фикергә ия хәлдә килеп керә. Большевизмны кабул итә алмаган Гаяз Исхакый Россияне калдырып чит илгә китә.

Яңа әдәбиятны башлап җибәрүчеләр дан казанган осталар **Галимҗан Ибраһимов, Галиәсгар Камал, Мәҗит Гафури, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин** һәм башка әдипләр булды. Тукайдан соңгы шагыйрьлек вакуумын яңа дәвер җырчысы **Һади Такташ** биләде.

Әдәбият белеме татар әдәбияты тарихын булдыруга ихтыяҗ кичерә башлады. 1921–1923 ачлык елларында әдәбиятчы **Гали Рәхим** белән тарихчы **Газиз Гобәйдуллин** ике томлы «Татар әдәбияты тарихы»н язалар. Соңрак ике автор да репрессияләнәләр һәм аларның хезмәте уннарча ел дәвамында тыюда кала.

Татар совет әдәбияты зур-зур әдәби әсәрләр белән үзеннән хәбәр бирде. **Г. Ибраһимов «Безнең көннәр»** эпопеясен бастырып чыгарды. Анда ул 1905 ел революциясенең татар халкы тормышындагы әһәмиятен күрсәтте. Аның «Ачлык кушты» дигән повестендә Идел буендагы 1921 елгы ачлык трагедиясе турында кырыс хакыйкать күрсәтелә. Бу язучының «Тирән тамырлар» романы коллективлаштыру чорындагы драматик коллизияләрне күрсәтә.

Әдипләрнең ХХ гасыр башындагы милли күтәрелеш тарафыннан мәйданга китерелгән буыны 30 нчы еллар репрессияләрендә тамырыннан ук туралып юк ителә. Әмма татар зыялылары зур өметләр баглаган 1917 ел революциясе тудырган рухани күтәрелеш талантлы әдипләрнең яңа буынын барлыкка китерде. Аларга бөтен совет чоры әдәбиятының йөзен билгеләү насыйп булды.

Сүз прозаиклардан **Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Афзал Шамов, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Габдрахман Әпсәламов** хакында бара. Аларның роман һәм хикәяләре татар укучыларында гына түгел, ә бөтен Советлар Берлегендә кызыксыну уятты. Бигрәк тә әсәрләрендә эпик колач һәм психологик тирәнлек осталары Гомәр Бәширов белән Әмирхан Еники, алгы планга чыгып, зур абруй казандылар.

Күп кенә татар әдипләре Бөек Ватан сугышында һәлак булды. Алар арасында Россия укучысына яхшы билгеле **Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй** бар. Җәлилнең солдат һәм иҗат батырлыгы бөтен дөньяга билгеле.

Бөек татар шагыйре Такташның фикердәше, Тукай һәм Дәрдемәнд традицияләренең дәвамчысы Хәсән Туфан уннарча еллар буена гомерен сөргендә үткәрде. Ул КПССның ХХ съездыннан соң гына кайтып, татар шигъриятенә зур йогынты ясады. Хәсән Туфан шигъри осталык планкасын югары күтәрде, һәм бу бөтен татар шигърияте өчен ориентир булды. Күренекле шагыйрьләрдән

**Сибгат Хәким** белән **Нури Арслан** яңа сыйфат биеклегенә күтәрелделәр. Татар шигъриятенең патриархы Хәсән Туфан белән берлектә алар бөек татар шагыйрьләренең өчлеген хасил иттеләр.

Алтмышынчы еллар шагыйрьләре **Роберт Әхмәтҗанов, Равил Фәйзуллин, Рәшит Әхмәтҗан, Рөстәм Мингалим, Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхим һәм шигърияткә алардан соң килгән шагыйрьләр Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Рифә Рахман** әдәбиятта югарыдагы бөек өчлекнең бәрәкәтле йогынтысында формалашып ныгыдылар.

Язмышы драматик булган (студент елларында репрессияләнгән) компромиссыз принципиаль һәм намуслы **Аяз Гыйләҗев** укучыларны сәнгатьчә ачыш буларак әсәрләндергән роман һәм повестьләр язды. XX йөзнең соңгы илле елында бик зур эшлекле булган Гариф Ахунов вафатыннан соң татар әдәбиятында буыннар алмашынуы төгәлләнде. 99 яшьтә прозаның бөек остасы Гомәр Бәширов дөньядан китте, аңардан соң Ә. Еники вафат булды.

Киткән һәм хәрәкәттәге буыннар арасында бәйләүче катлам булып өлкән буынның талантлы прозаик һәм шагыйрьләре **Нурихан Фәттах, Гамил Афзал, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Илдар Юзиев, Туфан Миңнуллин, Шәүкәт Галиев, Әхсән Баян** калды. Драматург, прозаик һәм публицист **Диас Вәлиев** шул ук буынга керә. Ул әсәрләрен русча яза иде.

Татар әдәбиятының ун гасырлык үсешенә алты томлык «Татар әдәбияты тарихы» һәм «Татар поэзиясе антологиясе» йомгак ясады. Әдәби процессның үсеш һәм яңарыш инерциясе иҗат аренасына талантлы шагыйрь һәм прозаикларның яңа плеядасын китерде. Алар – **Рүзәл Мөхәммәтшин, Айгөл Әхмәтгалиева, Йолдыз Миңнуллина, Эльвира Һадиева, Фирүзә Җамалетдинова, Луиза Янсуар, Рөстәм Галиуллин.** Бу плеяданың иң күренекле фигурасы булып якты талантка ия **Ленар Шәех** санала. Аның шигърияткә килүен Зөлфәт һәм Роберт Миңнуллин алкышлап каршы алды.

*2016*

# КОЛ ГАЛИ ҺӘМ АНЫҢ «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» ДАСТАНЫ

Соңгы вакытта урта гасырдагы бөек шагыйребез Кол Гали дастаны белән кызыксыну нык җанланып китте. Күптән түгел генә Ульяновскида «Кыйссаи Йосыф» авторына һәйкәл ачылды. Бу – чыннан да, тарихи факт. 2005 елда Казанның 1000 еллыгына шул исемдәге паркның нәкъ үзәгендә шагыйрьгә беренче монумент куелды. Ә татарлар сан ягыннан шактый урын биләгән күрше өлкәдә һәйкәл ачылу вакыйгасы һичшиксез мактауга лаек.

Болгар шәһәрендә тарихи истәлекләрне торгызу эшчәнлеге һәм анда салыначак музейда шагыйрьгә яңа һәйкәл куелачагы турындагы хәбәр аның мирасы актуальләшә баруын күрсәтә. Бу эшләрнең башлануы һәм гомумән тормышка ашырылуы беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев җитәкчелегендә башкарыла.

Әмма Кол Галинең «биографиясенә» кагылышлы кайбер нигезсез уйдырмалар аңлатма бирүне таләп итә. Әлеге вакыйга һәм хөрмәтле «Татарстан» журналындагы «календарь мәгълүматлар» (№ 10, 2008) «шагыйрьнең тууына 825 ел тулуга» туры китерелгән. Еллыкны мондый «төгәл» исәпләү өчен тарихта һәм шагыйрьнең биографиясендә бернинди нигез юк.

Барысы да шуннан башланды. 1983 елның 12 мае. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының төгәлләнүенә 750 ел тулып килә. Без бу вакыйганы билгеләп үтәргә җыендык. Партиянең үзәк органнары белән килештерү башланды. Анда мондый юбилей өчен түгәрәк дата кирәклеген төшендерделәр, һәм Казанда андый дата «800 еллык була ала» дигән фикергә киленде. Чөнки поэмасы төгәлләнгән вакытта шагыйрьгә 50 яшьтән ким булмагандыр дип гөман кылынды. Олырак яшь булуы да ихтимал. Без менә шулай Кол Галинең «800 еллыгын» бәйрәм иттек. Әмма борынгы һәм урта гасыр шагыйрьләренең күпчелегенә хас булганча, Кол Гали хакында да поэманы төгәлләү датасыннан башка бернинди биографик мәгълүмат юк. Ләкин 2008 елгы берничә публикациядә гүяки, шагыйрь үзенең дастанын Кодес (Иерусалим) шәһәренә сәяхәт кылганнан соң язган, дигән «мәгълүмат» күзгә чагылып китте. Тик моны раслырлык бернинди чыганак та юк. Бу – нибары хыял җимеше.

Ул урта гасыр әдәбиятын белмәүне генә күрсәтә. Кол Гали бит безнең республика газеталары журналисты түгел, ул юлъязма чыгармый. Йосыфлы кәрванның Кодес аша узуы Тәүратта да, «Кыйссасел-әнбия»ләрдә дә, Коръән тәфсирләрендә дә һәм, иң мөһиме, «Кыйссаи Йосыф»ның төп чыганагы – Һират шәехе Габдуллаһ Әнсаринең «Әнисел-мөридин» (XI гасыр) әсәрендә дә бар. Алга таба Йосыф белән Зөләйхә турындагы поэмаларның барлык авторлары да кәрванның Кодес аша узуын яза. Урта гасыр мөселман авторына сюжеттагы вакыйганың урынын тикшереп кайту бөтенләй мәҗбүри булмаган. Ул әзер материал белән эш иткән. Бу – урта гасыр әдәбиятының төп сыйфаты.

Менә шушындый хәл безне ядкәрнең барлыкка килү төбәге һәм әсәрнең эчтәлеге буйлап йөреп чыгарга мәҗбүр итә.

Кол Гали, Болгар иле шагыйре булса да, асылы белән болгар булмаган. Аның поэмасы – туксан процентка угыз әсәре, шагыйрь исә үзе дә табигате белән угыз булган. Мәсьәләгә зурдан кубып якын килсәк, «Кыйссаи Йосыф» катнаш угыз-кыпчак телендә язылган. Бу мәгънәдә Кол Гали Идел буе әдәби теленә нигез салучы булып санала. XIV йөз Идел буе төрки шигъриятенең зурзур поэмалары: Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е һәм Харәзминең «Мәхәббәтнамә»се шул ук катнаш угыз-кыпчак телендә язылган.

Телнең шушындый катнаш булуы аркасында Европа галимнәре «Кыйссаи Йосыф»ны Харәзм ядкәре дип санадылар. Харәзм, чыннан да, угызлар белән кыпчаклар тыгыз аралашып яшәгән төбәк булган. Хәлбуки күренекле төркиятче, МДУ профессоры Әмир Нәҗип, «Кыйссаи Йосыф» кайдадыр Иделнең түбән агымында иҗат ителгән, дип санады. Ул – һичшиксез, Саксин шәһәре булган. Анда әдәби мохит хөкем сөргән. Саксиндә Сөләйман бине Дауднның мәшһүр «Зөһрәтер рияз» трактаты язылган. Андалузиядән (Испания) килгән гарәп сәяхәтчесе Әбү Хәмид әл-Гарнати, XII гасырда Саксин шәһәрендә дә булып: «Саксиндә кырык угыз кабиләсе яши, аларның башлыгы – болгар әмире, ә шәһәр үзәгендә җамигъ мәчете бар»[1], – дип язган. Шуны да өстәргә кирәк: алар кыпчаклар белән аралашып яшәгән. «Кыйссаи Йосыф» телендә

---

[1] Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.). М., 1971. С. 27.

угыз эпосыннан («Китаби Дәдәм Коркыт») алынган фразеологизмнар, метафоралар һәм теленең фонетик-морфологик үзенчәлеге шагыйрь Кол Галинең органик рәвештә угызча фикерләвен күрсәтә. Кече Азиядәге угыз шагыйрьләренең, ягъни Төркиядәге сәлҗуки һәм госманлы шагыйрьләрнең Кол Гали поэмасында тел җәһәтеннән бернинди киртә очратмавы шул ук хакыйкатьне раслый. Мәсәлән, XIII гасыр төрек шагыйрьләре Шәйяд Хәмзә белән Сули Фәкыйһ Кол Гали фразеологиясен һәм метафораларын тулысынча кабул иткәннәр. XIV йөз шагыйре Әхмәди телендә дә шул ук хәл күзәтелә. Аның «Йосыф вә Зөләйхә»сендә Кол Галинең колоритлы гыйбарә һәм метафораларын төп-төгәл табып була.

«Кыйссаи Йосыф» кулъязмаларының Дрездендә һәм Берлиндә саклана торган күчермәләре Казаннан алып кителгән. Дрезден нөсхәсенең тышлыгында китап хуҗасының исем-фамилиясе язылган («слободской татарин Динмухаммет Суттов»). Кулъязманы ул «тылмач Зентель»гә биргән яки саткан. Мин аның күчермәсен 1977 елда Гөрлиц шәһәренең обер-бургомистры Һайнц Лөшнер ярдәмендә алдырган идем. Кандидатлык диссертациямдә һәм монографияләремдә мин аннан киң файдаландым. Бу кулъязма – табылганнар арасында иң искесе. Тышлыктагы рус язуы буенча хөкем йөрткәндә, ул XVII–XVIII йөзләрдә күчерелгән булырга охшый.

XX гасырда, «Кыйссаи Йосыф» телендә угыз компонентының өстенлек итүен һәм Европа галимнәренең (Карл Броккельманн һәм Мартин Һоутсма) фикерләрен истә тотып, Төркия, Азәрбайҗан һәм Төркмәнстан әдәбиятчылары Кол Гали поэмасын үзләренеке дип дәгъвалый башладылар. Үзбәкләр аеруча катгый дәгъва белдерде. Әмма безнең тикшеренүләрдән һәм халыкара конференцияләрдә ясаган докладлардан соң алар Кол Гали поэмасының татар әдәбиятына каравын берсүзсез таный башлады.

* * *

Урта гасыр ядкәрләре арасында татар әдәбияты тарихына Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны кебек тирәннән тоташкан бүтән әсәр, мөгаен, юктыр. Идел буе шигъриятенең XIII йөздән соңгы бөтен үсеш юлы шушы поэма традицияләре белән сугарылган. «Кыйссаи Йосыф» – татар халкы аны «Йосыф китабы» дип йөртә – хаклы рәвештә болгар-татар әдәбиятының безгә исән-имин килеп җиткән иң борынгы ядкәре хисаплана.

Шәһри Болгарда 1299 елда куелган кабер ташында Кол Гали әсәре каһарманының улы «Мамил» исеме теркәлгән. Шунысы кызык: дастанның төгәлләнү елы белән таш куелу датасы арасында уртача бер кеше гомере озынлыгына тиң вакыт ята. Бу исем Идел–Чулман Болгарстанының төрле чорга караган җиде ташында очрый[1].

Кол Галинең тормыш юлына кагылышлы мәгълүматлар, күп кенә урта гасыр авторларыныкы сыман ук, сакланмаган. Аның Идел буенда туып, Харәзм якларында белем алуы һәм мөдәррислек итүе турында кайбер мәгълүматлар бар. Болгар дәүләтен монголлар басып алганда һәлак булган дип гөман кылына. Әлеге мәзкүр әсәрен ул 1233 елның 12 маенда, үзе язганча, 630 елда, рәҗәб аеның 30 ында тәмамлаган.

Идел буе төрки әдәбиятының барлык мөһим ядкәрләрендә бу дастан теленең һәм фәлсәфи-сәнгатьчә яңгырашының тәэсирен гасырдан-гасырга күзәтергә мөмкин. Яңа дәвер татар шигъриятендә ул йогынты Тукайгача һәм соңгы чор шагыйрьләренәчә сузыла. Әсәр татар күчереп язучыларының армас-талмас эшчәнлеге һәм Казан басмалары аркасында безгә килеп җиткән. Бүгенге көнгә аның табылган күчермәләре саны 300 гә якын. 1839 елдан 1918 елга чаклы ул якынча 80 тапкыр басылып чыккан. 1983 елда «Кыйссаи Йосыф»ның күренекле тел галиме Ф.С. Фәсиев тарафыннан эшләнгән тулы тексты дөнья күрде.

Кол Гали әсәре гасыр ярымнан артык татар, төрек, рус һәм Европа галимнәренең игътибарын җәлеп итеп килә. Аның теле, язылу ватаны, халыкта таралышы һәм кайбер шигъри үзенчәлекләре Г. Флейшер, В. Перч, Ш. Мәрҗани, М. Һоутсма, К. Броккельманн, М. Күпрелезадә, Г. Рәхим, А. Самойлович, Е. Бертельс, Г. Таһирҗанов, Ә. Нәҗип, Х. Күроглы һ.б.ның хезмәтләрендә тикшерелә.

Татар филологиясендә дастанны махсус тикшерү эшен Җ. Алмаз башлап җибәрде. Татар әдәбият белемендә һәм фольклор фәнендә бу теманы эшләүгә Б. Яфәров, М. Гайнуллин, Х. Госман, Г. Халит, Н. Юзиев, Ш. Абилов, Х. Мөхәммәдов, И. Надиров, М. Җәләлиева, С. Шәйдуллин, Р. Ганиева, Х. Миңнегулов,

---

[1] *Хакимзянов Ф.С.* Язык памятников Волжской Булгарии (на материале эпитафий XIII–XIV вв.): автореф. дис. … канд. филол. наук. М., 1976. С. 16.

Р. Әмирханов төрле дәрәҗәдә өлеш кертteләр. 1979 елда Мәскәүнең «Наука» («Фән») нәшриятында һәм 1984 елда Казанда безнең дә әсәрне әдәби ядкәр буларак тикшерүгә багышланган монографик хезмәтләребез дөнья күрде[1]. 2001 елда әсәрнең халыкара кыйммәтен яктырткан яңа монографиябез[2] басылып чыкты.

Поэманың эчтәлеге кыскача болай.

Йагъкубның унбер яшьлек улы Йосыф төшендә кояш, ай һәм унбер йолдызның, күктән төшеп, үзенә баш июләрен күрә. Атасы моны, патша һәм пәйгамбәр булачаксың, ә унбер кардәшең сиңа хезмәт күрсәтәчәк, дип юрый. Йагъкубның үги кызы боларны тыңлап тора һәм Йосыфның агаларына сөйләп бирә. Көнчелектән ярсыган агалары, бу эшне булдырмас өчен, энеләрен үтерергә ант итәләр. Алар аны, яландагы матур күренешләр белән кызыктырып, үзләре белән барырга үгетлиләр. Ялвара торгач, аталарын моңа күндереп, малайны алып китәләр һәм бер урында һөҗүм итеп үтермәкче булалар. Ләкин миһербанлырак Йәһүдә киңәше белән, аягын-кулын бәйләп, коега салалар. Күлмәген бәрән канына буяп, «Йосыфны бүре ашады» дип, аталары каршына китереп салалар.

Кое яныннан узып барган сәүдә кәрваны башлыгы Малик Дугыр углы хезмәтчеләренә су алырга куша. Чиләккә тотынып чыккан гүзәл угланны күргәч, Малик аһ итә. Шунда Йосыфның агалары килеп җитә һәм сәүдәгәрдән малайны бирүен таләп итәләр, «ул безнең качкан колыбыз иде» диләр. Сәүдәгәр аны үзенә сатуларын сорый, һәм агалары малайны унсигез ярмакка[3] сатып җибәрә.

Мәгъриб патшасының кызы Зөләйхә Йосыфны төшендә күрә һәм гашыйк була. Бу хакта атасы Таймуска сөйли, йокыдан яза һәм ашаудан баш тарта. Бер елдан тагын шул ук төшне күрә, әмма егет бары: «Син – минеке, мин – синеке», – диярргә генә өлгерә. Тагын бер ел уза, кыз төшендә: «Кем соң син, торган җирең кайда?» – дип сорый. Егет: «Мин – Мисыр патшасы, мине күрергә теләсәң,

---

[1] *Хисамов Н.Ш.* Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул ‘Али. Анализ источников сюжета и авторского творчества. М.: Наука, 1979. 254 с.; *Хисамов Н.Ш.* Бөек язмышлы әсәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

[2] *Хисамов Н.Ш.* Сюжет Йусуфа и Зулейхи в тюрко-татарской поэзии XIII–XV вв. (Проблема версий). Казань: Идел-Пресс, 2001.

[3] *Ярмак* – вак акча.

Мисырга кил», – дип җавап бирә. Ләкин ул: «Ашыкма, бу эштә сабыр ит, сабыр белән генә максатка ирешәләр», – дип кисәтә.

Тик Зөләйхә үгетне тыңламый, әтисенә соңгы төшен сөйләп, үзен Мисыр патшасына кияүгә бирүне сорый. Таймус белән Мисыр хөкемдары Кыйтфир (Тәүрат буенча – Потифар яки Пентефрей) арасында хатлар алышу була. Мисыр патшасы Мәгъриб патшасының кызын алырга ризалыгын белдерә, һәм Таймус Зөләйхәне бай бирнәләр белән Мисырга озата. Тик кызны бик зур күңелсезлек көтә: төштә күргән гүзәл егет урынына бөтенләй ят ирне күреп, ул һуштан яза, әмма, хезмәтчеләренең киңәшен тотып, сабыр итәргә була.

Менә Малик сәүдәгәрнең гадәттән тыш кыйммәт, бәһале колын сатуга куюы хакында хәбәр ишетелә. Колны күргәч, Зөләйхә янә аңын җуя. Аңына килгәч, хезмәтчеләренә, сәүдәгәр күпме бәһа сораса да, сатып алырга куша. Кыйтфир колны хәзинәдәге барлык малы бәрабәренә сатып ала һәм: «Безнең балабыз юк, бу безнең улыбыз булсын», – дип, Зөләйхәгә тапшыра.

Зөләйхә егеткә Кыйтфир күрмәгән хөрмәтләрне күрсәтә: һәр көнне яңа күлмәк кидерә, чәчен толымлап үрә. Һәм, ниһаять, аңа үзенең серен ача, ягъни кайнар мәхәббәтен белдерә. Егет нык тора һәм мәгънәле итеп җавап бирә: «Газиз (Мисыр хөкемдары титулы. – *Н.Х.)* мине угыллыкка кабул кылды, атама ничек хыянәт итим?!» – ди.

Гаҗизлеккә төшкән Зөләйхә серен даясенә, ягъни сөт әнкәсенә ача. Ул исә егетнең хыялын биләрлек сарай төзетергә киңәш итә, шулай эшләсәң, колың, һичшиксез, теләгеңә буйсыныр, ди.

Кыйтфир кушуы буенча, гаҗәеп сарайны төзеп бетерәләр. Аңа көмеш агачлар утыртып, ботакларына алтын кошлар кундыралар. Терәкләр арасына алтын ат бастыралар, ә аларның төбенә көмеш үгез сыннары куялар. Зөләйхә Йосыфны чакыртып китерә. Егет, бу күренешкә таң калып: «Нигә монда газиз күренми?» – дип сорау бирә. Патшабикә сарайны Йосыф өчен салдыруын әйтә һәм аның гүзәл сыйфатларын берәм-берәм санап чыга, эчке һәм тышкы матурлыгын нечкәләп тасвир кыла. Хатынның көйдереп алырлык кайнар мактауларыннан соң каһарман бирешү чигенә җитә. Ләкин шунда югарыдан кисәтү өне яңгырый һәм атасының шәүләсе күренә. Егет үзен кулга ала һәм йөгереп чыгып китә. Зөләйхә аның ар-

тыннан чаба, һәм алар икесе дә ишек төбендә газизгә тап булалар. Аптыраштa калган ире алдында акланып, Зөләйхә Йосыфка яла яга һәм егетне зинданга яптыруга ирешә. Каһарман анда унике ел ята.

Шул арада Кыйтфир үлә, тәхеткә аның энесе мәлик Рәййан утыра. Мәликкә каршы фетнәдә гаепләнеп, аның шәрабчысы һәм икмәкчесе зинданга ябыла. Аларның икесе дә төш күрә. Йосыф, шәрабчыга котылачагын, икмәкчегә җәзаланачагын хәбәр итеп, төшне юрап бирә. Юраган юш килә.

Бервакыт хөкемдар да борчулы төш күрә. Төшендә ул җиде тук башак һәм җиде ач башак күрә. Соңгылары беренчеләрен юк итә. Аннары патша җиде симез сыер һәм җиде арык сыер күрә. Арык сыерлар симез сыерларны кабып йота. Юраучылар моны берничек тә шәрехли алмый. Шәрабчы шунда Йосыфны исенә төшерә һәм моны хөкемдарга сөйли. Хөкемдар аны зинданга җибәрә. Йосыф төшне, җиде ел туклык була, аннары җиде ел ачлык булачак, дип юрый. Рәййан Йосыфны тоткынлыктан азат итәргә боера һәм яраннары белән бергә аны каршыларга килә. Йосыф, зиндандагы барлык тоткыннар да азат ителгәнче, иректән баш тартуын белдерә. Рәййан зиндан әһелләрен тулысынча азат итә. Шуннан соң: «Падишаһлык миннән сиңа лаеграк, барыгыз да аның әмерен тотыгыз», – дип, тәхетне Йосыфка тапшыра.

Вәзир мәсьәләсе туа. Илаһият Җәбраил аша Йосыфка юлга чыгарга һәм беренче очраган кешене вәзир итеп куярга куша. Беренче очраган кеше бик фәкыйрь кыяфәтле була. Йосыф башта икеләнеп тора, тик Җәбраил бу фәкыйрьнең бишектәге бала көе Кыйтфиргә Йосыфның Зөләйхә каршында гаепсезлеге хакында таныклык биргәнлеген әйтә. Шуннан соң Йосыф, бернинди икеләнүләрсез, бу кешене вәзир итә. Вәзир булгач, әлеге фәкыйрь Йосыфка лаек акыллы эшләр башкара.

Каһарман бервакыт юл чатында йончыган бер хатынны очрата. Ул Зөләйхә булып чыга. Тетрәнеп калган Йосыф: «Кайда синең зифа буең, соклангыч гүзәллегең?» – дип сорый. Хатын: «Боларның барысы да – синең дәртең, берсе калмый югалды мал вә мөлкәт, вәләкин югалмый гыйшык вә хәсрәт», – дип җавап бирә. Җәбраил канаты белән Зөләйхәнең йөзен сыйпауга, аның яшьлек гүзәллеге яңадан кайта. Каһарман белән яшь кәләшнең зур туе була, алар бәхетле тормыш кичереп, унике угыл үстерәләр.

Йосыф илне корылыкка әзерләү өчен эшлекле чаралар күрә: амбарлар төзетә, мая туплый, корылык башлангач, иген чәчмәскә боера.

Корылык Йосыфның ватаны Кәнган җиренә дә килә. Йагъкуб үзенең улларын, гадел хөкемдардан ашлык сорау өчен, Мисырга җибәрә. Йосыф үзен рәнҗеткән агаларын якты чырай белән кабул итә, аларга мул итеп икмәк бирә, әмма үзенең кемлеген ачмый. Тегеләрнең икенче килүенә махсус сарай салдырып, аның диварларын агалары кылган явызлыкны чагылдырган сурәтләр белән бизи. Бу – дөнья әдәбиятында сыналган алым. Гамлетны гына искә төшерик: ул сәхнәдә атасы белән бертуган агасының җинаятен уйнап күрсәтә, ә үзе аның бу эшләрне ничек кабул итүен күзәтә. Йосыф, кунакларның телен аңламаган булып, тәрҗемәче аша сөйләшә. Ә тегеләр үзара: «Монда безнең яман эшләребез хакында язылган», – дип сөйләшәләр һәм тамактан язалар. Йосыф аларны башка бүлмәгә күчерә. Агалары бу килүләрендә Йосыфның бер анадан туган энесе Ибнейәминне дә үзләре белән алалар. Ике туганның яшерен очрашуы вакытында Йосыф, энесен үз янында калдыру өчен, бер чара уйларга вәгъдә итә. Ул энесе Ибнейәмин йөгенә алтын савытын яшертә, аннары тентү вакытында аны нәкъ шуннан «табалар». Мисыр патшасы аны «кулга алдыра» һәм «угры» буларак «ябып куя». Агаларыннан берсе энеләре янында кала. Йагъкуб бу хактагы күңелсез хәбәрдә шатлык ихтималын күрә: «Инша Аллаһ, өч улымны бер җирдә күрермен», – ди.

Өченче килүләрендә Йосыф сандыктан бер язу чыгара. Коллыкка сатканда, аны агалары язган була. Анда сатылучының өч төрле гаебе язылган: «ялганчы, качкын, угры». Агалары монда сүз нәрсә турында барганлыгын аңламаган булып кыланалар, аннары: «Чыннан да, безнең бер колыбыз бар иде, бу язу аның турында», – диләр. Йосыф аларны кискен фаш итә, күзләрен бәйләтә, һәрберсенең берәр кулын кисү һәм муеннарыннан асу белән яный. Агалары күп хәсрәт күргән аталары хакына мәрхәмәт күрсәтүен сорап ялваралар, һәм Йосыф елап җибәрә, агаларының күзләрен чишәргә куша. Тегеләр исә, гаҗәпләнеп, хөкемдарның Йосыф икәнен таныйлар һәм бер-берсенең кочагына ташланалар.

Икенче юлы агалары үзләре белән аталары Йагъкубны да алып киләләр. Йосыф аны Зөләйхә һәм үзенең унике улы белән таныштыра.

Йагъкуб, вафаты якынлашканын тоеп, Кәнгангә кайтып китә. Сюжет каһарманнарның үлеме белән тәмамлана. Башта Зөләйхә үлә. Йосыф яңадан өйләнми, балаларын тәрбияләү белән мәшгуль була. Аннары ул да дөнья куя.

«Кыйссаи Йосыф» дөнья әдәбиятында, аеруча Көнчыгыш әдәбиятларында, Йосыф сюжетына язылган күпсанлы әсәрләрнең бер төрдәше санала. Әмма төрки әдәбиятларда ул – Йосыф темасына язылган иң беренче дастан. Бу әдәбиятлар өчен аның гаять зур әһәмияте шушы бәрәкәтле сюжетның төрки укучылар өчен дә рухани ләззәт чыганагы булуына бәйле. Кол Галидән соң төрки әдәбиятларда, башлыча госманлы төрекләре әдәбиятында, әлеге әсәрнең яңадан-яңа төрдәшләре дөньяга килә.

Идел буе шагыйренең Йосыф сюжетын эшкәртүгә керткән барлык яңалыкларын аның Кече Азиядәге дәвамчылары тулысынча күтәреп ала. Болгар-татар әдәбиятында исә «Кыйссаи Йосыф» бу темага язылган бердәнбер шигъри әсәр булып кала, һәм ул, татар укучыларының яңадан-яңа буыннарына эстетик хезмәт күрсәтеп, зәвекъләрен канәгатьләндереп килә. Әсәрнең мондый даны аның халыкчан шәкеленә, фикер һәм мотивларның инсан-чыллыгына бәйле. Анда халыкның төрле катлауларына якын тыныч һәм бәхетле тормыш хыялы чагыла.

Әлегә кадәр төрки әдәбиятларда Йосыф-Зөләйхә сюжетына язылган башка әсәрләр схемасын механик рәвештә Кол Гали поэмасына да күчереп, аның тематик нигезен егет-кыз мәхәббәте рәвешендә билгеләү хөкем сөрде. Хәлбуки Е.Э. Бертельс үк Фирдәүси поэмасы кебек җитди версияләрдә мәхәббәт сызыгы сюжетның ярдәмче элементы гына[1] дигән фикерне әйткән иде. Соңрак ул Дүрбәк поэмасына карата да шуны язды[2]. Кол Гали әсәренә бу фикерләр тулысынча туры килә, чөнки поэманың исеме үк аның Йосыф хакындагы әсәр икәнен күрсәтеп тора. Ягъни сюжет нигезендә ата-угыл мәхәббәте, Йосыфның Йагъкубка тугрылыгы ята. Каһарман язмышындагы иң зур фаҗига дә аның атасыннан аерылуына бәйле.

---

[1] *Бертельс Е.Э.* Абу-л-Касим Фирдоуси и его творчество. Л.; М., 1935. С. 61.

[2] *Бертельс Е.Э.* Узбекский поэт Дурбек и его поэма об Иосифе Прекрасном // Дар. Ташкент, 1944. С. 171.

Шагыйрь әсәрнең үзәгенә хөкемдар һәм халык бәхете проблемасын куя. Калган барлык мәсьәләләр иҗтимагый, әхлакый, эстетик планда шушы үзәк тирәсенә туплана.

Проблема каһарман образы аша хәл ителә. Хөкемдар шәхесе нинди булырга тиеш? Шагыйрь, шул сорауга җавап бирү өчен, каһарманны бала чагыннан ук төрле сынаулар аша уздыра, шулар аша аның кешелек сыйфатларын ача.

Кол Гали әсәрендә Йосыфның хәлиткеч сыйфаты итеп тугрылык тасвирлана. Сюжетның Көнбатыш версияләрендә каһарман даимән «Гүзәл Йосыф» дип аталса, «Кыйссаи Йосыф»та ул – «Йосыф Сыйддыйк», ягъни Тугры Йосыф.

«Тугрылык» дигәндә, шагыйрь барыннан да элек атага тугрылыкны күздә тота. Бу мотив каһарманның төш юратуыннан башланып атасы белән янә күрешүенә чаклы үстерелә. Әсәрдәге төрле шартларда аның бу сыйфаты антка, бурычка тугрылык, ахыр чиктә туган халкына, аның гореф-гадәтенә тугрылык рәвешен ала.

Йосыф язмышындагы иң кискен очрак – Зөләйхә вәсвәсәсенә бирешми калу да – «Кыйссаи Йосыф»та атага тугрылыкны сынау төсен ала. Йосыфны сатып алгач, бары Кол Гали поэмасында гына Мисыр газизе Кыйтфир Зөләйхәгә: «Безим бу углымыз улсун имди»[1], – ди. Шушы факт Йосыфның Зөләйхә каршында үз-үзен тотышына бөтенләй башка яңгыраш бирә. Хатынның юмарт мактауларына, үгет һәм ялваруына карамастан, каһарман, үтә акыллы һәм тыныч итеп:

Бәни ул угыллыкка кабул кылди,
Атама нәтә хаин улам имди, –

дип җавап бирә. Бу инде колның хуҗага тугрылыгыннан күп өлеш мәгънәлерәк, кешелеклерәк. Шулай итеп, шагыйрь каһарманның яңа иҗтимагый хәләтенә ата-угыл мөнәсәбәтен күчерә. Ә инде Йосыф Зөләйхә сүзләреннән эреп елмаеп куйгач, аны хата эшләрдән кисәтеп, күз алдына атасы Йагъкуб килеп баса, һәм егет үзендә яңадан ныклык таба. Атасының истәлеге һәрвакыт аның вөҗданы сагында тора. Сюжетка төрки шагыйрь алып килгән шундый нюанслар әсәргә яңачарак, үзенчәлекле яңгыраш бирә.

[1] Кыйссаи Йосыф. Казан: Казан ун-ты табыгханәсе, 1839. Б. 57.

Тугрылык идеясе – «Кыйссаи Йосыф» поэмасының лейтмотивы. Бу әхлак сыйфатының бәхеткә ирешүдә төп шарт икәнне шагыйрь Зөләйхә язмышы белән раслый. Әсәрнең хатын-кыз каһарманы, кырык ел тугрылык саклап, сабыр итүе нәтиҗәсендә, Йосыфка тиң һәм лаек була.

* * *

«Кыйссаи Йосыф» – борынгы төрки поэзиянең сюжетлы беренче әсәре. Аның сәнгатьчә эшләнешендәге үзенчәлекләр дә шуңа бәйле. Әле сюжетлы әсәр коруда төрки әдәбиятның мөстәкыйль казанышлары җитәрлек булмаганлыктан, шагыйрь фольклор тәҗрибәсенә таяна. Сурәтләрне эшләүдә, сюжет борылышларын кору, стилистик ялгамнарны тәэмин итүдә ул тылсымлы әкият һәм каһарман эпос тәҗрибәсеннән файдалана. Аның сәнгатьчә фикерләве дә, нигездә, эпик поэтика кысаларында бара.

Менә әсәрнең иң әһәмиятле эстетик мәсьәләләреннән каһарман проблемасын хәл итүне алыйк. Монда шагыйрь эпик идеаллаштыру кануннарына буйсына.

Йосыфны уңай герой итеп күтәргән төп сыйфатлар – тугрылык һәм зирәклек. Ә инде матурлыгы – аның тумыштан бирелгән һәм дөньякүләм данын тотып торган үзенчәлеге. Мисырда аны кабат сату вакытында базар хәбәрчеләре ун сыйфатыннан берсе итеп батырлыгын да телгә алалар:

Алтынчы: камулардан бик куәтлү –
Кырык ирдән ку эти артык имди.

Әсәр эчендә Йосыфка физик көч күрсәтү бөтенләй кирәк тә булмый. Әмма шагыйрь төрки укучының каһарман дастаннар традициясендә тәрбияләнүен истән чыгармый, ә аларда геройның беренче сыйфаты – батырлык.

Эпик идеаллаштыруның иң мөһим күрсәткечләреннән берсе булып магик көчкә – тылсымга ия булу санала. Эпоста бу – каһарманның өстенлеген тәэмин итү өчен кирәк. Кол Гали поэмасында Йосыф та шул сыйфатка ия итеп тасвирлана. Мәсәлән, Кодес (Иерусалим) бәге, Йосыфны алып калу өчен, кәрван артыннан куа чыккач, каһарманның бер күз карашыннан унике меңле гаскәре белән өч көнлек йокыга тала.

Йагъкуб сурәтендә дә эпослардагы зирәк аксакал гәүдәләнә. Бу, барыннан да элек, аның фикер йөртүендә, сөйләмендә чагыла. Үгет бирәме ул, кисәтәме, үз-үзен тынычландырамы – һәр очракта аның сүзләре мәгънәле, гыйбрәтле.

Зирәк аксакалның үлемен тасвирлаганда, дәдә Коркыт турындагы легендаларга һәм угыз-кыпчак дастаннарына хас мотивлар килеп керә. Йосыф сюжетына Кол Галидән элек иҗат ителгән әсәрләрдә Йагъкубның тере көе үзенә кабер казучыларга юлыгуы тасвирланмый. Бары «Әнисел-мөридин»дә генә аның мәетен бабалары күмелгән мәгарәгә алып килүләре һәм, шартлы сүзләр белән эндәшкәч, мәгарә ишеге ачылып, табутны эчкә кертүләре языла.

«Кыйссаи Йосыф»та исә Йагъкуб, туган җиренә кайтып барышлый, кабер казучы фәрештәләргә тап була, кабернең эчен күрергә дип кереп китә һәм шунда җан бирә. Бу – дәдә Коркытның үлемнән качып йөргәндә дөньяның дүрт тарафында да үзенә кабер казучыларга юлыгуы хакындагы легендаларны[1] хәтерләтә. Себер татарларыннан язып алынган «Ак Күбәк» дастаны каһарманның атка атланган көе кабергә кереп китүе һәм шунда күмелүе белән тәмамлана[2]. Ак Күбәкнең кабер казучылар белән сөйләшүе гаҗәп дәрәҗәдә Йагъкубның фәрештәләр белән әңгәмәсенә охшаган. Шунысы кызык: кешенең кабер казучыларга юлыгуы һәм тере көе кабергә керүе турындагы легендалар Татарстан авылларында хәзер дә очрый.

Күпсанлы шушындый детальләр Кол Гали поэмасына төрки колорит бирә һәм сюжетның төрки җирлектәге үзенчәлекле сәнгатьчә яшәешен тәэмин итә. Зөләйхә, мәсәлән, Йосыфның чәчен толымлап үрә. Йосыф сюжетының Кол Галигә кадәрге чыганакларында бу деталь бөтенләй юк, һәм ул булырга мөмкин дә түгел. Чөнки, затлы нәсел күрсәткече буларак, ирләрнең толым йөртүе борынгы төркиләргә хас күренеш[3]. Соңрак Рабгузиның «Кыйсса-

---

[1] *Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос: избранные труды. Л., 1974. С. 547.

[2] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи, Ч. 4. СПб., 1872. С. 58; *Урманчеев Ф.И.* Героический эпос татарского народа. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. С. 139.

[3] *Вайнштейн С.И., Крюков М.В.* Об облике древних тюрков // Тюркологический сборник. М., 1966. С. 177–187.

сел-әнбия»сендә дә Йосыф толымлы итеп сурәтләнә. Бу очракта Кол Гали кыпчак мохитенә якынрак тора.

Эпик башлангыч Йосыф сурәтен эшләүнең бүтән якларында да чагылыш таба. Каһарманның үзен рәнҗеткән агаларына карата олы җанлылык күрсәтүе сюжетның тәүге чыганакларында ук урын алса да, төрки поэмада ул герой проблемасын хәл итүнең башка аспектлары белән тыгыз бәйләнештә бирелә, ягъни идеаллаштыруның эпик кануннарына туры килә. Төрки эпосның нинди генә сюжетын алсаң да, каһарманның олы җанлылыгы даими күренеш буларак тасвирлана. Мәсәлән, төрки халыкларда киң таралган «Алпамыш» дастанында, бигрәк тә аның «Дәдә Коркыт» циклына кергән «Бамсы-Бәйрәк» төрдәшендә, шушындый хәлне күрәбез. Кол Гали бу цикл белән таныш булган дияргә нигез бар[1].

Зинданнан чыккач, Йосыфның, рәхәткә чумарга ашыкмыйча, башта үзенең тоткын иптәшләрен азат итү турында кайгыртуында да эпик каһарман характеры чагыла[2].

Зөләйхә сурәтенең нигезендә дә эпик башлангыч ята. Кол Гали бу сурәткә мөһим иҗтимагый-әхлакый вазифа йөкли, шунлыктан аның иҗат ихтыяры монда аеруча көчле сизелә.

Мәгълүм булганча, Тәүрат белән Коръәннән башлап сюжетның барлык җитди чыганакларында Мисыр газизенең хатыны (Асенат; Т. Манндa – Мутеменет; «Зөләйхә» исемен башлап Фирдәүси бирә) бары Йосыфка бәла-каза китерүче тискәре сурәт буларак гәүдәләнә. Аны уңай образ итеп иң әүвәл Фирдәүси эшли. Хәлбуки бөек фарсы шагыйрендә дә сурәт каршылыклы кала. Беренчедән, ул үзе, ир хатыны була торып, Йосыф каршында коточкыч әдәпсезлек күрсәтә. Икенчедән, Йосыфның инде, аңа өйләнгәндә, кәнизәктән ике баласы туган була. Фирдәүси поэмасында Зөләйхә «кыйбти хатын», ягъни Мисыр кешесе итеп бирелә.

«Әнисел-мөридин»дә китерелгән бер риваять буенча, Зөләйхә – башка ил патшасының кызы. Үзенең бу ягы һәм Йосыфка аны төштә күреп гашыйк булуы, сөеклесе артыннан бүтән патшалыкка китүе белән дастаннар традициясендә тәрбияләнгән төрки

---

[1] *Хисамов Н.Ш.* Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул ‘Али. Анализ источников сюжета и авторского творчества. М.: Наука, 1979. С. 93–95.

[2] Шунда ук. Б. 95.

шагыйрь күңеленә ул хуш килә. Көнчыгыш поэзиясе тарихында беренче буларак, Кол Гали сюжетның мәхәббәт сызыгын гыйшык дастаннары схемасына кора. Кыз Мисырга алдан ук төштә күргән Йосыфы өчен килгәч, соңыннан газиз хатыны була торып, «әрсезлек» күрсәтүе һәм әхлакый, һәм психологик яктан тулысынча аклана. Шул рәвешле Кол Гали сурәтне эчке каршылыктан тәмам азат итә.

Аның әсәрендә Зөләйхә – Йосыфның бердәнбере. Шагыйрь бу фикерне ассызыклап әйтә. Әсәрнең каһарманнары мисалында мәхәббәт һәм гаилә мәсьәләсен хәл итеп, ул үз чоры Көнчыгышындагы күпхатынлылыкка каршы чыга.

Атасы Йагъкуб белән очрашкач, Йосыфның балаларын бабалары каршына китергәндә әйткән сүзләре мәгълүм дәрәҗәдә ата белән угылның тормыш принципларын каршы кую булып та яңгырый:

Андин дагый Йосыфның угланлари,
Йагъкуб сурдый Йосыфдан һәм анлари.
Йосыф әйдер: «Угланларим безим бари –
Җөмләси Зөләйхәдән улур имди.

Зөләйхә вафатыннан соң да шагыйрь аларның мәңгелек тугрылыгына басым ясый:

Андин соңра Зөләйхә вафат улди,
Йосыф аның хәсрәт илә мәгъмум улди.
Андин соңра айрук йәнә ивләнмәди,
Угланларин башарубән ирәр имди.

Шул рәвешле шагыйрь, бердәнбер мәхәббәт һәм хатын идеясен алга сөреп, каһарман һәм, гомумән, Йагъкуб гаиләсе өстенә килгән бәла-казалар, кардәшләрнең ата мәхәббәтен бүлешә алмыйча ызгышулары – барысы да күпхатынлылык бәласе дигән фикерне үткәрә. Поэзиядә Йосыф сюжетын эшкәртү тарихында ул бу яктан беренче юл яручы була.

Мондый тәвәккәл идеяләрне күтәреп чыгу өчен, ниндидер тарихи-иҗтимагый шартлар яисә, шуңа өстәп, эстетик факторлар этәргеч бирергә тиеш. Бу очракта этәргечнең берсе төрки фольклор булса, икенчесе – мөселман Көнчыгышы әдәбиятында гу-

манизмның (инсанчылыкның) чәчәк атуы. Шагыйрьгә бер яктан моногамияне яклаган халык шигърияте тәэсир итсә, икенче яктан Көнчыгыш әдәбиятын яңа баскычка күтәргән Низами иҗаты йогынты ясый. Шушы ике чыганакны искә алганда гына, Кол Гали әсәрендә куелган мәсьәләләрне һәм сюжеттагы мәхәббәт сызыгының хәл ителеш үзенчәлеген аңларга мөмкин. «Кыйссаи Йосыф» язылган чорда инде Көнчыгыш әдәбиятының йөзен Низаминең мәхәббәт поэмалары билгели. Бу дәвердә мәхәббәттә тиңлекне һәм берхатынлылыкны эзлекле рәвештә яклаучы бөек гуманист үрнәгеннән беркем дә азат була алмый. Алай гына да түгел, Кол Гали иҗатының гомуми әһәмияте төрки шигъриятне Низаминең идея-эстетик казанышларын үзләштерүгә тәмам якынайтудан гыйбарәт. «Кыйссаи Йосыф»ның фактурасында исә Низами әсәрләрендәге детальләрне дә аермачык күрсәтеп була. Мәсәлән, Зөләйхә сараеның эче сандал агачыннан бизәлү Низаминең «Җиде гүзәл» поэмасындагы Бәһрам шаһның Рум патшасы кызына салдырган сараен искә төшерә.

Зөләйхә сарае – автор фантазиясенең байлыгына дәлил. Сарай бизәлешен тасвирлаганда, Кол Гали, үзенең Көнчыгыштагы элгәреләре белән чагыштырганда, шактый мөстәкыйль эш иткән. Аерым мотивлар Фирдәүсидән һәм «Әнисел-мөридин»нән алынса да, бизәлешенең әхлакый-эстетик һәм башкарылыш яклары гаять үзенчәлекле. Барыннан да элек шагыйрьнең төрки укучы каршында үтә әдәп саклавы күзгә ташлана. Фирдәүсидә Зөләйхә Йосыфны тәхеттә ялангач утырып каршылый, һәм Йосыф, күзен кая төбәсә дә, көзгеләрдә аның чагылышын күрә. «Әнисел-мөридин»дә дә эротик мотивлар ярылып ята. «Кыйссаи Йосыф» авторы үсемлек, кош-корт һәм хайван сурәтләренә киң урын бирә.

Сарай нәкышенең композиция һәм фактурасында эпик башлангыч өстенлек итә. Алтын агачларга кунган кошлар, ул агачлар янында иярле алтын ат, көмеш үгезләр борынгы төркиләрнең ышануларына һәм мәҗүсилек чоры сәнгатенә барып тоташа. Бизәлештәге үзәк мотивларга төрки дастаннардагы нәсел агачы тасвиры күчерелгәнлеген күрү читен түгел. Казан татарларының чигү сәнгатендә нәсел агачының ике ягына утыртып ясалган алтын яисә көмеш кош сурәтләрен соңгы чорларга кадәр күзәтергә мөмкин. Мәсәлән, калфакка чигелгән шушындый сурәт

бик кызыклы[1]. Түбәсенә алтын һәм көмеш кәккүк кунган, алтын һәм көмеш яфраклы тирәк төбенә бәйләп куелган алтын төкле ат алтай эпосының борынгыдан килә торган тотрыклы мотивы санала[2].

Сюжетның хәлиткеч буынын – кульминацияне дә шагыйрь үзенчә корган. Бу исә аның әсәрдәге үзәк проблеманы халыкчан хәл итүенә бәйле.

Хөкемдар һәм халык проблемасы башлангыч төстә сюжетның барлык эшкәртмәләрендә куела. Әмма аңа халыкчан яңгыраш биргән беренче автор Кол Гали була. Аңа кадәрге чыганакларның берсендә дә Йосыф чын мәгънәсендәге хөкемдар түгел. Тәуратта һәм Коръәндә, тәфсир һәм «Кыйссасел-әнбия»ләрдә Йосыф Мисыр патшасының вәзире булып күтәрелә. Фирдәүсидә аның күтәрелүе берничә баскыч үтә. Башта ул фиргавеннең якыны була, ачлык чорында, үзе үләр алдыннан, фиргавен тәхетне аңа васыять итә. «Әнисел-мөридин»дә Мисыр мәлиге үзенең төшен юраган Йосыфка тәхет һәм таҗ тәкъдим иткәч, каһарман баш тарта. Мәлик аны үзенең хәзинәдары ясый.

Бары «Кыйссаи Йосыф»та гына каһарман төшне юрауга ук патша була. Шагыйрь биредә, тылсымлы әкият схемасына таянып, эпизодны «читен мәсьәлә чишү һәм патшалыкка ирешү» мотивы нигезендә эшкәртә[3]. Мәликнең Йосыфка патшалыгын тапшыруы да әкияткә хас стилистик калыпта башкарыла:

Падишаһлык бәндән сәңа лайык дорыр,
Аның әмрин барча кабул дотың имди.

Йосыфның идарәсен шагыйрь байга да, ярлыга да тигез караучы «идеал» итеп тасвирлый. Бу – асылда, Йосыф Баласагунлыдан башлап, татар әдәбиятында мәгърифәтчеләргәчә дәвам иткән прогрессив-демократик, әмма хыялый-утопик идея. Кол Гали аңа үзенчәлекле төсмер өсти: ул, илдәге идарә гадел булсын өчен, хөкемдар түбәннән, халык күргән мәшәкатьләрне үзе кичереп

---

[1] *Валеев Ф.Х.* Орнамент казанских татар. Казань, 1969. С. 102.

[2] *Хисамов Н.Ш.* Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул ‘Али. Анализ источников сюжета и авторского творчества. М.: Наука, 1979. С. 171–173.

[3] *Пропп В.Я.* Морфология сказки. Л., 1928. С. 68, 71.

күтәрелергә тиеш, дип саный. Бу исә татар мәкалендәге «Карадан чыккан хан яхшы» дигән фикергә аваздаш.

Гадел идарә өчен хөкемдарның түбәннән күтәрелү зарурлыгын шагыйрь вәзир эпизоды белән кабат раслый. Йосыф тәхеткә утыргач, аның вәзире мәсьәләсе килеп баса. Каһарман сәйранга чыкканда беренче очраган кешене үзенең вәзире итәргә була һәм шулай эшли дә. Ул, үтә йолкыш, кыяфәтсез, фәкыйрь бер кешегә юлыгып, шуны вәзир итә. Вәзир исә Йосыфка лаек акыллы һәм гадел булып чыга. Бу эпизод башлап Кол Галидә очрый. Мәсьәләнең хәл ителешендәге әкиятчелек беренче очраган кешене сайлап алуда чагыла. Моңа охшаш хәлне бик күп татар әкиятләрендә күрергә мөмкин.

Әсәрдәге башка күп кенә детальләрне Кол Галинең үзгәртеп бирүе дә каһарман проблемасын хәл итүгә буйсындырылган. Мәсәлән, сюжетта Йосыфның кардәшләре кылган явызлыкны фаш итүдә мөһим роль уйнаган алтын савыт Кол Галинең элгәреләрендә реалистик планда эшкәртелсә, төрки шагыйрь бу детальгә әкияткә хас фантастик яңгыраш бирә. Әйтик, Фирдәүсидә Йосыф үзенең кардәшләренә аларның яман эшләрен савыт чыңгыравын «тәрҗемә иткән» булып сөйләсә, «Кыйссаи Йосыф»та савытның үзеннән хикәяләтә. Чөнки алдашу аның каһарманына күләгә төшерә. Деталь әкияттәге «каһарманның тылсымлы булышчылары» мотивына[1] корылган.

Әлбәттә, мондый детальләр әдәби әсәрдә аерым-аерым алынса, беркадәр гадилек булып та яңгыравы мөмкин. Әмма әсәрнең проблематик контекстында аларның эчке логикасы бар, шунлыктан сәнгатьчә хакыйкать буларак ышандыралар.

* * *

«Кыйссаи Йосыф» поэмасы – әдәбият тарихының ялгыз бер күренеше булмыйча, үзенә кадәрге әдәбият үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килеп, үзеннән соңгы төрки әдәбият үсешенә дә йогынты ясаган әсәр. Аның эчтәлегенең нинди чыганаклардан алынуын билгеләү һәм сәнгатьчәлегенә йогынты ясаган факторларны ачу әдәбият тарихында традицияләр формалашуны күз алдына китерү өчен дә мөһим.

[1] *Пропп В.Я.* Исторические корни волшебной сказки. Л., 1948. С. 173.

Гасырлар буе эшкәртелеп, камилләштерелгән сюжетка төрки авторның үзеннән яңалыклар өстәве нинди юллар белән барган? Моны ачу урта гасыр төрки әдәбиятында сәнгатьчәлек тәҗрибәсен туплауның мөһим ысуллары һәм этаплары хакында нигезле хөкем йөртү өчен кирәк.

Геройны иҗат итү, сюжет төеннәрен оештыру, үзенчәлекле эпизод һәм детальләр кертүнең аерым мисалларын инде өлешчә карап үттек һәм шагыйрьнең башлыча эпос һәм тылсымлы әкият традицияләренә таянуын күрдек. Сәнгатьчәлек мәсьәләләрен хәл итүдә фольклорның башка жанрлары да шагыйрь өчен нәтиҗәле чыганак булган.

Мәсәлән, ата белән угыл арасында хәбәрләшүнең үтә драматик моментларын шагыйрь үзенчә хәл итә. Менә күзгә иң бәрелеп торган Кәнган гарәбе эпизоды. Аның Мисырга килешли зиндандагы Йосыф белән сөйләшүе «Әнисел-мөридин»дә үк бар. Йосыф сәүдәгәрдән туган җире һәм атасы турында сораша, кайткач, сәлам тапшыруын үтенә. Бу сөйләшү анда ачыктан-ачык, бернинди тел яшерүсез эшләнә.

Кол Гали үзенең каһарманын гарәп сәүдәгәре каршында серле зат итеп калдыра. Шагыйрь социаль психологияне һәм момент үзенчәлеген нечкә тоемлап эш итә. Йосыф үз каршында тукталган узгынчыга сорауларын табышмакка төреп бирә:

Йосыф әйдер: «Кәнгандән кәлүрмусән,
Анда бер каба йегач белүрмусән,
Чәүрәсендә ботаклари белүрмусән,
Ул ботаклар ун икимү тәмам имди?»

Теге дә төшеп калганнардан түгел – табышмакны тиз аңлап ала:

Гарәп әйдер: «Аңладым бу сүзеңни,
Белдем, фәһем әйләдем бу разыңни,
Вәләкин дыңлыйурмән бу сүзеңни,
Бу эш ичрә нә хикмәт вар», – дәйүр имди.
Каба йегач дидекең Йагъкуб дорыр,
Ун бер углы хезмәтендә хазир дорыр,
Ун икинчи Йосыф адлу гаиб дорыр,
Хакыйкатьдә ани корд йиди имди.

Бу аңлашудагы «каба йегач» метафорасы игътибарга лаек. Ул «биек агач» дигән мәгънәне аңлата. Борынгы төркиләрдә нәсел агачын шулай атап йөрткәннәр. «Дәдә Коркыт» дастаннарында, мәсәлән, бу метафора тотрыклы рәвештә бик еш очрый. Коркыт атаның имләү-теләкләрендә («каба агачың егылмасын»), шигъри өзекләрдә шушы гыйбарә нәсел-ыру яшәячәгенә мәңгелек өметне гәүдәләндерә. Кыскасы, нәсел агачы мотивы төрки эпосларда даими күренеш булып йөри. Кол Гали шушы традициягә таяна.

Табышмаклы аңлашу исә гомумән борынгы дәвердә яшерен телнең актив кулланылуын чагылдыра. Дастаннарда, экиятләрдә, никахлашу һәм туй йолаларында яшерен тел, ягъни метафорик аңлашу, зур урын тоткан.

«Патша, вәзир һәм тегермәнче» дигән татар халык экияте тулысынча шуңа корылган.

Элгәреге чыганакларда сюжеттагы роле пассив булган персонажларны җанландыру өчен, шагыйрь гаять оригиналь алым куллана. Мәсәлән, Йосыфның бер анадан туган кардәше Ибнейәминнең рухани һәм әхлакый дөньясын балаларының исемнәрендә чагылдыра.

Мәгълүм ки, төрки халыкларда балага исем кушканда, ата-ананың изге теләкләре, бала язмышын алдан юрап кую яисә аны бәла-казадан саклау нияте чагылыш таба. Ибнейәмин балаларының исемлегендә дә шушы хәлне күрәбез.

Бу деталь Кол Галигә кадәрге чыганаклардан беренче тапкыр «Әнисел-мөридин»дә очрый. Анда Йосыфның, энесе белән күрешкәч, аның гаилә хәле, балалары хакында сорашуы бирелә. Йосыф аларның исемнәре белән кызыксына. Энесе җиде улы, өч кызы барлыгын, ә исемнәренең «Йосыф, Бүре һәм Кан» булуын әйтә. Чыганакта шул рәвешчә өч исем генә аерым атала. Күрәсең, автор шулар белән генә чикләнгәндер дә. Чөнки Кол Гали поэмасына һәм «Әнисел-мөридин»гә таянып эш иткән Шәйяд Хәмзә әсәрендә дә шушы исемнәр генә телгә алына[1].

«Әнисел-мөридин»дә Йосыф, энесеннән мондый исемнәр куюның сәбәбен сорагач, тегесе: «Аларны чакырганда, сине дә

---

[1] *Hamza Ş.* Yusuf ve Zeliha. Istanbul, 1946. S. 106.

искә төшерәм»[1], – дип җавап бирә. Төрки шагыйрь бу детальнең сәнгатьчә мөмкинлекләрен абайлап ала һәм, аны тулыландырып, персонажның бөтен бер әхлак кодексын ачып бирә. Балаларының санын ул, сюжет нигезендәге символик санга туры китереп, унике итә, «Әнисел-мөридин»дәге ике исемне генә ала: Корт һәм Кан. «Йосыф» исеме аның өчен бердәнбер, һәм ул үзенең кабатланмас кыйммәтен сакларга тиеш.

Персонажның олы улына ул Диңгез исемен куша. Бу, әлбәттә, «Угызнамә» традициясеннән килә: Угыз каганның алты улыннан берсе шулай аталган, Һун патшасы Атилланың улы да Диңгез исемле булган. Идел буенда угыз ыруларының таралган булуы һәм шактыеның татар халкы составына да кергәнлеге тарихи, археологик, тел һәм топонимик мәгълүматлардан билгеле.

Ибнейәмин балаларының исемлеген шагыйрь болай төзи: Диңгез, Корт, Койу, Кан, Гар, Дар, Гүр, Арыслан, Моздур, Гариб, Кайгу, Кол. Икенче исем, һичшиксез, борынгы төркиләрнең тотемистик ышануларына бәйләнгән. Чыганагы белән төрки булмаган сюжеттагы исемнәрнең төрки булуы кызык: шагыйрь әсәргә һәрьяклап җирле колорит бирергә, аны үз халкының тел, әдәбият, фольклор стихиясенә якынайтырга тырыша. Тулаем исә исемлек шактый ямансу эчтәлекле.

Шагыйрь исемнәрнең мәгънәсен ачуның үзенчәлекле композицион алымын эшләгән. Строфаның һәр юлы бер исемгә карый, нәүбәттәге строфа исә шуның эчке мотивын бәян итә. Мәсәлән, беренче дүрт исемгә бәйләп, Ибнейәмин болай ди:

Диңгезләр катында чук агладым,
Тагдагый кортларга чук ант вирдем,
Канли күнләкеңи тутуб чук йалвардым,
Чук койу лар иченә бакдим имди[2].

Шушындый шәрехләүчән строфаларда персонажның рухани дөньясы үтә эмоциональ булып гәүдәләнә. Ул үзенең агасын го-

---

[1] Әнисел-мөридин вә шәмсел-мәҗалис: Лондон кулъязмасының фотокүчермәсе. Г. Ибраһимов исем. ТӘҺСИ архивы, ф. 69–1–385. Б. 155 (фарсы телендә, гарәп графикасында).

[2] Дрезден нөсхәсе. Б. 56 а.

мер буе эзләгән, балаларына да Йосыф истәлеген яңартучы итеп кенә караган романтик шәхес булып күз алдына баса. Шагыйрь бу сурәттә тылсымлы әкияттәге агаларын эзләү юлында зур газаплар кичерүче кече энекәш[1] мотивын гәүдәләндергән.

Ибнейәминнең иҗтимагый-әхлакый дөньясы бигрәк тә соңгы дүрт исемдә һәм шуларны шәрехләгән строфада ачык чагыла:

Тукызынчысының адин Моздур[2] дидим,
Унынчысының адин Гариб дидим,
Ун беренчесенең адин Кайгу дидим,
Ун икинчесенең адин Кол дидим имди.
Кол(лари) күричәк хуш дотар идим,
Гариб(лары) күричәк сурар идим,
Кайгулари күричәк аглар идим
Һәм колларга миһербан улдум имди.

Шул рәвешчә, колларга мәрхәмәт күрсәтүдә шагыйрь персонажны Йосыфка тиң итеп тасвирлый. Монда да аның яраткан алымы – «кабат раслау» чагыла.

Эпик башлангыч поэманың стилендә дә өстенлек итә. «Кыйссаи Йосыф»ны шул сюжетка язылган барлык әсәрләр арасында аерып торган мөһим үзенчәлек – сөйләмнең диалогка корылуы. «Йагъкуб әйдер», «Йосыф әйдер», «Зөләйхә әйдер» кебек композицион-стилистик ялгамнар, һичшиксез, төрки халыклар фольклорындагы әйтешләргә һәм дастан поэтикасына барып тоташа.

Диалог шагыйрьгә сөйләмне мәгълүм дәрәҗәдә индивидуальләштерергә мөмкинлек бирә. Дөрес, урта гасыр әдәбиятында аңлы бер сәнгатьчә күренеш буларак индивидуальләштерү бөтенләй диярлек очрамый. Бу – чорның гомуми үзенчәлегеннән килеп чыга: сәнгатьчә фикерләүнең һәр өлкәсендә гомумилеккә омтылу, күренешләрне шартлы символларда чагылдыру, индивидуаль сыйфатлардан бигрәк уртаклыкка, гомумилеккә игътибар итү урта гасыр эстетикасының йөзен билгели. Менә шушы шартлар эчендә Кол Гали персонажларны ике гомумилеккә: уңайга һәм тискәрегә

[1] «Ак бүре», «Унберенче Әхмәт» кебек татар халык әкиятләрен кара.

[2] Бу исем башка кульязмалар буенча төзәтеп бирелде. Югыйсә Дрезден нөсхәсендә ялгыш «Корд» (икенче тапкыр) диелгән.

аера. Каһарманнарның уңай булуына беренче шарт итеп ул зирәклекне куя. Табигый ки, андый персонажларның теле дә афористик.

Афоризмнар башлыча Йосыф һәм Йагъкуб сөйләменә хас. Зөләйхәгә төшендә каһарманның сабырлык турында биргән киңәше афористик формада Йагъкуб телендә дә, сарай хезмәтчеләренең Зөләйхәне юатуларында да үзгәрешсез диярлек кабатлана: «Сабыр берлә морад хасил улур имди». «Сабыр иткән морадына җиткән» дигән татар халык мәкале башлап Кол Гали поэмасыннан алынса кирәк.

Үз-үзен тотышындагы акыллылык һәм афористик тел каһарманның рәнҗетүчеләре каршында өстенлеген, вакыйгалардан югары була белүен күрсәтә. Мәсәлән, үзен коллыкка саткан агалары турында ул сәүдәгәргә: «Һәр кеши үз лайыкын эшләр имди», – дип җавап бирә. Малик Дугырның «әле хатаны төзәтергә соң түгел» дигәненә каршы: «Кәчән сүз кирү кәлмәз», – ди.

Йагъкуб сөйләмендәге мәкальләр зирәк картның, кайгы эчендә югалып калмыйча, улын күрәчәгенә өмет өзмәвен чагылдыра.

Шул рәвешле, Кол Гали үзенең эрудициясе һәм талант көче нәтиҗәсендә гаять җаваплы һәм читен иҗади бурычны хәл кылган: инде Шәрекъ дөньясында күптән оешып утырган сюжетка яңа тормыш көче биргән, оригинальлек дәрәҗәсе югары булган әсәр барлыкка китергән.

*2004*

## МӨБАРӘК ТӘСБИХНЕҢ БЕР БУЫНЫ

Әдәбият галиме ул популяр зат түгел. Эстрада алкышлары күбрәк шагыйрьләргә һәм мәзәк остасы булган кече жанр әһленә насыйп. Галим исә, үз һөнәренә тулысынча тугры икән, узгынчы шөһрәткә бөтенләй битараф була. Шау-шулар дөньясына чумып, фән эшләп булмый. Әмма иҗат әһле, сәнгатькәрләр дөньясы һәрвакыт гыйлем иясен үзенең эстрада мәнфәгатьләренә тартырга тырышкан. Шулар даирәсенең мәгълүм бер төркемен данлауга күчкән гыйлем иясен фани дөньяның алдагыч бизәкләренә төргән, эстрада лаврларыннан аларга да өлеш чыгарган. Гомерләрен фәнни иҗатка багышлап, безнең күз алдында бакый дөньяга кичкән

гали затларның берсе дә андый алкышларны күрмәде һәм моны трагедия дип тә санамады. Вафатларыннан соң да зур үкенүләр, вөждан газабыннан тирән уфтанулар сизелми. Чөнки аларның хезмәт мирасы гаять бөек, кылган эшләренең мәгънәви тамырлары тирән. Шунлыктан аларны иңләү һәм төшенү өчен вакыт кирәк. Ә... шул ук вакыт ул мирас һәм эшчәнлекнең, ул бай һәм катлаулы шәхесләрнең бик күп кыйммәтле төсмерләрен юып та узачак. Шунлыктан аларны теркәп, тарихта беркетеп калдыру – кичектергесез намус бурычы хисапланырга тиеш.

Менә алар – бу галәмнән кичеп, Ясәвиләр, Кол Галиләр, Мәрҗаниләр, Җамал Вәлидиләр, Гали Рәхимнәр янына барып кушылган затлар: Мөхәммәт Гайнуллин, Хатип Госман, Гали Халит, Ибраһим Нуруллин һәм Нил Юзиев. Аларның берсе дә академик түгел. Дөрес, Нил ага мөхбир әгъза иде. Аның вафаты, Ибраһим Нуруллинныкы кебек үк, җан әрнеткеч үкенечле булды. Алар бик иртә киттеләр. Әмма бу бишәү гәүдәләндергән әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть тарихта беркайчан кабатланмас олуг дәвер булып кала.

Минем әле язарга алынган могтәбәр каһарманым – ул Хатип ага Госман. Былтыр аңа туксан яшь туласы иде. Матбугат бу вакыйганы билгеләп тә үтте. Аерым алганда, күләмле бер язмада мәрхүмнең батыр рухы, педагогик эшчәнлеге яктыртылды. Хәлбуки Хатип ага күпкырлы, киң колачлы талант иде. Холкы белән гаять катлаулы, Шекспир характерлары сыман көчле һәм кискен гайрәткә ия, әдәби осталыкка һәм гыйльми намуска, гражданлык кыюлыгына һәм фидакярлеккә карата максималистларча таләпчән галим булды. Аның көйдергеч тәнкыйтен һәм нәфрәтен татып калган кешеләр аны гомергә кичермәделәр. Аның эстетлегенә, эрудиция һәм теоретик зирәклегенә гашыйк кешеләр аны остаз итеп, изге зат күреп тәкъдирлиләр. Шуларның берсе, әлбәттә, мин.

Хатип ага, дәрәҗәләре югары булса да, конъюнктурадан өстен торып, милләткә, республикага киң колачлы фидакяр хезмәтне үзенең иман эше иткән шәкертләрен, дусларын дөньясын онытып ярата, хөрмәтли, данлый иде. Андый бәхетне өзлексез татыган кешеләр ул чактагы вице-премьер Мансур Хәсәнев, мәгариф министры вә академик Мирза Мәхмүтов һәм Хатип ага тарафыннан «фәннең рыцаре» дип аталган профессор Рәфыйк Нәфигов булды.

Ул заман яшь галим хисапланган Фатих Урманчеев белән Миркасыйм Госмановка Хатип ага зур өметләр баглады.

Галимнең истәлегенә тел-теш тидерүдән ерак торган киң гаммә бар: ул – аның меңләгән студентлары.

Мин университетка килгәндә, инде моңарчы да язганымча, Хәсән Туфан, Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Мөхәммәтгани, Мансур Крымовлар хакында беркадәр хәбәрдар идем. Алар турында укытучым – Такташ шәкерте, шагыйрь, көйче, гармунчы һәм рәссам Абдулла ага Абязов сөйләгән иде. Уналты яшьтән Байрончылык белән авырган, Такташка гашыйк, Маяковский һәм Назыйм Хикмәт рухында шигырьләр язган, Гаяз Исхакый һәм Әхмәтзәки Вәлиди хезмәтләреннән беркадәр мәгълүматлы, Мәрҗани һәм Риза Фәхретдиневне ихтирам итүче, Илья Эренбург белән хатлар алышкан, кайбер шагыйрьләр белән якыннан таныш, шигырьләрем һәм мәкаләләрем матбугатта чыккан бер егет идем мин. Өйдәге «Шура» журналы төпләмнәрен әтиебез гомер буе гаиләдә кычкырып укыды. Бала һәм яшүсмер колагына аз булса да эленеп калгандыр. Әмма Хатип аганың беренче лекциясен тыңлагач, үземне гаять фәкыйрь һәм кечкенә итеп сиздем. Дөнья мәдәнияте ничаклы серләрне үзенә җыйган, дип хәйран калдым. Шул ук халәтне барлык сабакташларым да кичерә иде.

Хатип ага үзенең язма хезмәтләрендә, киң карашлы теоретик буларак, даһилык чигендәге ачышлар һәм гомумиләштерүләр ясаса да, ул, башлыча, үзенең лекцияләрендә тиңдәшсез галим һәм сәнгатькәр булды. Аның шигърият хакындагы лекцияләре шигъриятнең үзеннән дә гүзәлрәк шедеврлар иде. Әдәбият фәненең кайсы гына төшенчәсен ачуга алынса да, ул дөнья поэзиясеннән Вергилий яки Данте, Шекспир яки Гөте, Шиллер яки Һәйне, Пушкин яки Фет иҗатлары аша узган системаны тасвирлап бирә, әлбәттә инде Тукайны я Такташны сөйли, борынгы юнан, Рим, Көнбатыш Европа, рус, украин, лях, латыш, үзбәк, азәрбайҗан шагыйрьләренең гүзәл әсәрләреннән озын-озын өзекләрне яттан укый. Нәтиҗәдә татар әдәбият галиме татар студентларына дөнья шигъри сәнгате бай һәм аерылгысыз бербөтен дигән төшенчәне бирә, киң карашлы эрудитлар тәрбияли. Галимнең шул чактагы йөзен, чыраен күрсәгез! Андый рухланган гүзәл йөзне мин бүтән беркайда, бер җирдә һәм беркемдә күргәнем булмады. Беренче лекциясеннән мин аңа

тәмамән әсир булдым, бүген дә шул халәттә калам. Гаять киң эрудицияле кызыклы галимнәр бар. Әмма аларның әңгәмәсе файдалы булса да, корырак була. Хатип ага лекциясенә мин могҗиза итеп карый идем. Хикмәт аның шагыйрь дә булуында икән.

Бервакыт студентларның фәнни түгәрәгендә – Хатип ага тәкъдиме белән мин аның рәисе идем – мөхтәрәм остазыбыз үзенең гыйльми иҗат тәҗрибәсен уртаклашты. Элек шигырьләр язуын сөйләде, кайбер әсәрләрен укып та күрсәтте. Күтәренке рухлы романтик шигырьләр... «Мин шагыйрь була алмадым», – диде ул аннары уфтанулы аһәң белән һәм шигърият галименнән таләп ителгән сыйфатлар турында сөйләп китте. Ләкин Хатип ага шигырь укыса да, шигърият хакында сөйләсә дә, йөзләренә һәм тавышына илаһи рухлану төсмере чыга иде. Аналитик акыллы, киң колачлы теоретик, шигъри иҗат тәҗрибәсен узган шагыйрь табигатьле титан, сәнгати матурлыкның тирәндә яткан серләрен тугызынчы дулкын биеклегенә күтәреп, аудиторияне сихерли, гүзәллеккә сугара.

Мин 1981/82 уку елында, инде фән кандидаты көе, «Татар әдәбияты тарихы»ның борынгы дәверен яктырткан 1 нче томын редакцияләп бетергәч, Фәннәр академиясе стажеры булып Ленинград университетының Көнчыгыш факультетына киттем. Минем гарәп һәм фарсы филологиясе буенча дәресләрем программасын төзегәндә, кафедра лаборанты Яна Александровна Александр Николаевич Болдыревның фарсы әдәбияты лекцияләренә йөрергә тәкъдим итте. «Монсы сезгә филармония урынына», – диде. Чыннан да мәрхүмнең дәресләре йотылып тыңларлык күркәм иде. Әмма Хатип ага лекцияләрен тыңлап үскән кешене берни белән дә гаҗәпләндерә алмыйсың.

Алтмышынчы елларда язучыларның Тукай клубында бер әдәби җомга Бакый ага Урманчене Тукай бүләгенә тәкъдим итүгә туры китерелде. Бөек рәссам һәм сынчының «Дәрдемәнд» сурәтен эшләүдәге талантлы уңышын яктыртып, Хатип ага шагыйрь иҗатын бәяләүдә уннарча елларга сузылган ялгыш карашларны сүтте, аның әсәрләрен укып анализлады. Совет идеологиясенең нәфрәт объекты булган шагыйрьнең капиталистлыгына кагылып: «Аның гүзәл шигъри таланты янәшәсендә капиталистлыгы фәкыйрь, хәерче бер нәрсә. Ә шигъри мирас байлыгы мәңге югалмас алтын хәзинә», – диде. Язучылар рәхәтләнеп кул чапты. Тәнәфестә

Фатих Хөсни, Хатип аганы биленнан кочып: «Сине әдәбият фәненә җибәреп, галим иткәндә ничаклы дөрес эшләгәнбез!» – диде. Әдип үзе дә 50 нче еллар матбугатында Дәрдемәндне яклап кыю мәкалә белән чыккан кеше.

1958 ел. Җәмгыятьтә XX съезд һәм Хрущев идарәсенең шактый бәрәкәтле җылысы хөкем сөргән чор. Без – якташым һәм сабакташым Шәйхи Садретдинов белән дүртенче курс студентлары. Икәү киңәштек тә, беребез Сәгыйть Рәмиев иҗатын, икенчебез Дәрдемәндне тикшеренү темасы итеп безгә бирүен сорарга Х. Госман янына киттек. Хатип ага безнең тәкъдимгә бик сөенеп кушылды. Шушы темага – курс эше, аннары диплом эше яздык. Шәйхи – «Рәмиевче», мин «Дәрдемәндче» булып киттек. Диплом яклаганда, Әхмәт Исхакны оппонент итеп чакырдык. Мәгәр ул минем хезмәткә кискен каршы чыкты. «Шушы буржуаз шагыйрьне Тукай белән янәшә куясыз!» – дип гаепләде үземне. Оппонентлыкны әдәбият кафедрасының яшь укытучысы, факультетның декан урынбасары Мансур Хәсәнев үз өстенә алды һәм диплом эшенә, дипломчының үзенә үтә юмарт, югары бәя бирде. (Соңрак язмыш шушы вазгыятьне фән өчен иң югары кимәлдә, докторлык яклаганда кабатлады: Дөнья әдәбияты институтында минем хезмәтнең беренче оппоненты академик Мансур Хәсәнев булды.) Бик канәгать Хатип ага мине аспирантурага чакырачагын әйтте, һәм ике елдан, район газетасын калдырып, мин аның аспиранты булдым. Безнең арада үтә җылы, яратулы мөнәсәбәт дәвам итге. Бу хәл миннән олы курс аспирантлары М. Мәһдиев белән Ф. Миңнуллинның бераз эчләрен пошырганны да сизгәли идем.

Минем шигырьләр язып бастыруымны һәм нәшриятка җыентык туплап тапшыруымны белгәч, Хатип ага миңа суына башлады. Бу суыклык әкренләп ачуга һәм үчегүгә күчте. Аңа тугрылыкны үземнең әхлакый гамәлем иткән минем өчен бу хәл гаять газаплы иде, яраткан өч улым, гаиләм булуга карамастан, вакыт-вакыт хәтта яшисем килмәгән чаклар да булды. Хикмәт бары шунда иде: Хатип аганың өмет баглаган шәкертендә үз «ялгышлары»н күрәсе килмәгән, бернинди «чит мавыгуларсыз» бары үзенең гыйлеменә хезмәт иттереп, фән үрләренә тиз күтәрәсе килгән.

Безнең яратышу тирән һәм органик булганлыктан, мөнәсәбәтләребез соңрак иске эзенә кайтып төште. Тел, әдәбият һәм

тарих институтының фольклор бүлегендә минем Кол Гали әсәренә багышланган монографиямне тикшергәндә, Хатип ага Лобачевский скверында мине көтеп утырган. Чыксам – ашыга-ашыга каршыма килә: «Тикшерү ничек узды?» – ди. Мин тирән рәнҗү белән: «Хезмәтемне аңламадылар!..» – дидем. «Бары ике кеше: Нил абый Юзиев һәм Флора Әхмәтова төшенеп һәм хуплап сөйләде. Дөрес, Курбатов: «Бездә әле мондый монументаль хезмәт язылганы юк иде», – дип бәяләмә җибәргән, ләкин аны укуны кирәк тапмадылар», – дидем. Хатип агам: «Бу – Сезнең бәхетегез, димәк, хезмәтегез озын гомерле булыр», – дип юатты. Нил Юзиев аның гомер буе яраткан шәкерте булып калды.

Менә «Әдәбият тарихы»ның 1 нче томын редакцияләргә дип, мине әдәбият бүлегенә чакырып алдылар. Дөньямны онытып, илһамланып эшләп йөргән чагым. Хатип ага Лобачевский бакчасына чакырып чыгарды. Пенсиягә киткән. Мине университетка кодалый: «Лекцияләр курсымны тулысынча Сезгә бирәм, докторлык эшләү өчен барлык шартлар да тудырылачак, кафедра мөдире Альберт Яхинның Сезгә мөнәсәбәте бик яхшы», – ди. Бу – минем өчен көтелмәгән тәкъдим иде, уйлау өчен бер атна вакыт сорадым.

Бер атнадан шул ук урында очрашабыз. «Ничек?» – ди Хатип ага, бернинди кереш сүзсез һәм түземсезләнеп. «Нил абый зур ышаныч белән мине башка сектордан чакырып алды, дирекциянең мөнәсәбәте үтә яхшы, фатир чиратым да якын...» – дип башлаган идем, Хатип ага үзе дәвам итте. «Мин бу хакта нык уйландым да, әгәр Сез чын кеше икән, риза булмассыз, дидем» – ди. «Хатип ага, Сез мине чын кеше дип санагыз», – мәйтәм, җитди дә, бераз шаярып та. Профессор кызгану белдерде, сүз шунда төкәнде.

Еллар узды. Ринат Мөхәммәдиев Хатип аганың «Шигърият гомере» дигән китабына «Казан утлары» өчен рецензия язуымны үтенде. Биш көн эчендә хезмәтне укып, рецензияне язып чыктым. Галимнең олы талантына һәм аналитик куәтенә сокланып, илһамланып яздым. Автор классик әдәбияттан яңа әдәбиятка күчеш күперләрен барлый, зирәк гомумиләштерүләр ясый, ачышларында әледән-әле даһилык чигенә килеп чыга. Мәкаләне «Бөек яңарышның чишмәләре» дип атадым. Хатип ага, аны журналда укыгач, яныма килеп, тирән канәгатьләнүен белдерде, үзе турындагы язмалардан беренче тапкыр шулай җан рәхәтлеге алуын әйтте,

бәяләмәнең исемен мактады. Дөрес, язма кемнәрнеңдер эчен дә пошырды.

Хатип ага белән соңгы мәгънәви әңгәмәбез минем «Бөек язмышлы әсәр» дигән китабым чыккач булды. 1984 ел. Кол Галинең 800 еллыгын бәйрәм итүгә нәкъ бер ел үткән. Телефоннан сүз куешкач, китапны алып, остазымның өенә киттем. Багышлау язмасын укып, китапны игътибар белән актарып чыккач, күзләрен кыса төшеп, йөзенә илһамлы алсулык йөгертеп, минем өчен көтелмәгән, әмма онытмаслык сүзләрен әйтте:

– Нинди бәхет: миннән соң Сез бар! Тик миннән катгый васыять Сезгә: үзегездән соң шәкертләр калдырыгыз. Ләкин шагыйрьләр алыгыз. Сез үзегез шагыйрь булганга, шигырьләр серен эчтән төшенеп язасыз...

Шулай итеп, безнең остаз-шәкерт коллизиясенең, гайрәт чигүдән соң янә рухани кардәшлеккә әверелүенең диалектик спирале шигырь тикшерү өчен шагыйрь булырга кирәклекне тануга кайтып төште.

Юк, юк. Минем Хатип Госманга җуелмас ихтирамым һич тә аның миңа җылы мөнәсәбәтенә генә бәйләнмәгән. Ул миңа үтә тискәре караштa чагында да мин аны яратудан туктамадым. Моны Хатип агага төрле елларда якын торган даирә кешеләре яхшы беләләр: Марсель Бакиров, Альберт Яхин, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Галимҗан Гыйльманов, Җәмил Зәйнуллин моңа һәрвакыт шаһитләр.

Хәлбуки һич кенә дә бөекләр ялгышмый дигән сүз түгел. 1979 елда Дөнья әдәбияты институтында минем кандидатлык диссертациясен тикшергәндә, Г. Ломидзе, Р. Йосыпов, З. Османова һәм Х. Күроглы кебек олы галимнәр, хезмәтемне тулаем хуплаганнан соң, Кол Галине «Көнчыгыш Ренессансы» дигән төшенчә белән бәйләгән өчен нык кына тәнкыйтьләделәр. Асылы белән антик сәнгати кыйммәтләргә әйләнеп кайтуны күздә тоткан саф Европа мәдәни күренешен, терминның яңгыравык булуына кызыгып, Шәрекъ әдәбиятына карата куллануны бөтенләй нигезсез, диделәр. Чөнки Шәрекъ инсанияте (Көнчыгыш гуманизмы) – Европа Ренессансыннан иртәрәк туган, аңардан баерак һәм уникаль күренеш. Аның чагылыш сыйфатларында Европа Ренессансына охшаш типологик билгеләр булса да, үзенең икътисади, сәяси һәм мәдәни алшартлары белән дә, нәтиҗәви үсеше белән дә Шәрекъ Инсани-

яте кабатланмас үзенчәлеккә ия. Мин хөрмәтле оппонентларыма дәлил итеп академик Н.И. Конрад тәгълиматын китердем. «Даһи булса да, бу очракта Конрад ялгышкан», – диделәр. Мәсьәләне махсус өйрәнә торгач, аларның хаклыгына ышандым.

Хатип аганың җитди ялгышы татар шигъриятендә гаруз бөтенләй булмаган дигән карашны уздыруында иде. Аннары исә икенче ялгышка тайпылды, янәсе гаруз төрки шигъриятнең үз табигатендә үк бар. Бу хата фикернең безнең өчен аяныч нәтиҗәсе шунда булды ки, без әле хәзер дә классик шигырьне дөрес ритмик тынышлар белән укый белмибез. 1986 елда Тукайның 100 еллыгы уңае белән ясаган фәнни докладта, галимнең исемен әйтмичә генә, мин бу карашны тәнкыйтьләп чыктым. Хатип ага бер ел рәнҗеп йөрде. Әйе, аның шәхесендәге чагылыш гаммасы гаять бай һәм катлаулы иде.

Урта гасыр шигъри мирасын халыкка кайтаруның авыр һәм колачлы эшләрен, үзенең тирән белеме һәм кодрәтле абруе белән Хатип ага башлады һәм юлга салды, аспирантура аша шушы өлкәнең белгечләрен әзерләде. Камил Дәүләтшин, Хатыйп Миңнегулов, Әнвәр Шәрипов, Нәҗип Исмәгыйлев – шушы исемнәр үзләре генә дә галимнең күркәм мирасы була ала. Мине исә мәрхүм профессор XX йөз башы татар лирикасы белгече итеп чыгарды. Минем әүвәлге тикшеренү өлкәм Тукай, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев шигърияте иде.

Әдәбиятның зур программ тарихы языла башлаганчы, Х. Госманның «Татар поэзиясе антологиясе»нә кереш, яки «Татар поэзиясе тарихында Тукайның урыны» кебек концептуаль платформа сызган күләмле тикшеренүләре кирәк булды. Галим гомеренең соңгы елларына чаклы кызыклы, яңарып, сафланып тора торган шәхес булды. Чөнки ул гомер буе өйрәнде, дөнья әдәбиятына, бөтендөнья әдәбият фәненә, гыйльми яңарышка карата үзен тикшеренүче теоретик итеп кенә түгел, комсызлык белән гыйлем эстәүче шәкерт итеп тә тойды. Бу мәгънәдә ул барлык буыннар өчен өлге булып кала. Аның иң соңгы фундаменталь хезмәте төрки-татар шигыренең ритм-калып-сәнгати тамырларын ачкан һәм нигез үзенчәлекләрен яктырткан китаплары булды. Бүгенге шигъриятта гайрәтле каләм тибрәтүчеләрдән Әхсән Баян, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ, Рәшит Әхмәтҗан, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин,

Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Рифә Рахманнар сафы турыдан-туры Хатип аганың матурлык мәктәбеннән юл алган. Мәңгелек пантеонга керү өчен бу абруй үзе генә дә җитәр иде.

*2004*

## НИНДИ ГАМЬНӘР ШАГЫЙРЬ КҮҢЕЛЕНДӘ?

Кайсы гына шагыйрьнең иҗатын анализларга алынсаң да, иң әүвәл аның әсәрләрен тематик-проблематик яктан төркемләргә, сурәт һәм мотивларын системага салырга тиеш буласың. Роберт Миңнуллин иҗатын яктыртканда исә, бу – үтә дә авыр эш. Чөнки аның киң колачлы иҗатында иң характерлы, иң яхшы шигырьләрне аерып, сайлап алырга мөмкин түгел. Аның һәр шигыре Робертча, һәр шигыре – бөтен, тирән һәм тәмамланган әсәр. Ул – шагыйрь иҗатының барлык яхшы сыйфатларын сыйдырган булыр. Шушы бер мисал нигезендә тел, аһәң, моң, иҗади тапкырлык, ритм һәм рифма хакында бер мәкалә күләмендә фикер йөртергә мөмкин.

Тик шулай да Робертның бөтен иҗатына скрипка ачкычы сыман алып керә торган шигырьләр бар. Минем һәм бик күпләр өчен шагыйрьне төшенергә ярдәм итә торган ул шигырь, дөресрәге, ул җыр – «Әнкәй» әсәре.

Әнкәй безне
Сөннән алып кайткан,
Сөн суында юган иң элек.
Бишек җыры көйләп төннәр буе,
Без үскәнне көткән тилмереп.
Без биш бала үстек – бер йодрык!
Тик үсмәдек иркә кочакта.
Без әнкәйнең биш шатлыгы булдык,
Биш кайгысы булдык кайчакта.

Бу – Сөн буенда туып үскән бер егетнең күпмедер шаяру катыш биографик истәлеге генә түгел. Шушы җырда мин тирән драматик аһәңнәр тоям. Көйче дә аңа шундый яңгыраш биргән.

Безнең бөек Сара апабыз шигырьнең тирәндәге мәгънәсен, эчке моңын шулай төгәл тоючан иде.

Шагыйрьнең әнкәсе сугыш һәм сугыштан соңгы чор әнкәләренең җыелма сурәтен күз алдына бастыра. Ул – чыннан да, шундый бөек Ана, каһарман хатын-кыз. Биш баланы ил күрерлек кеше итеп үстергән олы җанлы, гүзәл йөзле апай-ханым... Без ул балаларны аерым-аерым беләбез. Аларның һәрберсе үз өлкәсендә, үз юнәлешендә зур уңышларга ирешкән шәхесләр (галим улы – филология фәннәре докторы Ким Мөгаллим улы Миңнуллинны да белмәгән кеше юк). Ләкин төп горурлыгы – кара мыеклы, акыллы, моңлы һәм шаян күзле зур шагыйрь Роберт Миңнуллин!

Аны бик күпләр «юморист шагыйрь» диләр. Берәүләр «балалар шагыйре» ди. Барысы да хаклы. Әмма ул аерым гына балалар шагыйре дә, шаян шагыйрь дә, гамь шагыйре дә түгел, ул – гомумән шагыйрь.

Гел елмая бу, димәгез,
Мин бит елыйм эчтән.
Сезнең хәсрәтләрегез дә
Минем җанга күчкән.
Сезнең мине яратканны
Мин бит белеп торам.
Мин үзем дә, мин үзем дә
Сез дип үлеп торам...
Сез булганда язам әле,
Яна әле күңел...
Сездән башка мин беркем дә,
Мин беркем дә түгел, –

ди ул «Укучыларыма» дигән ихлас шигырендә. Ә аның укучылары – бөтен татар халкы. Аның тирән гаме дә – яшәү өчен җан тартышы кичергән туган халкы, аның үзәген өзгән төп мотив – татар язмышы.

Шагыйрь бу мотивны төрле яклап кичерә, аны төрле контекстта яктырта. Халкына кагылышлы яман сүз дә, хуплау сүзе дә аның сизгер колагыннан читтә калмый. Ул, Маргарет Тэтчерның «Татарлар – бик горур кешеләр...» дигән сүзләрен нигез итеп алып, «Кага халкым тузаннарын» дигән шигырендә болай яза:

Бар дөньяны ничә гасыр
Татар белән өркеткәннәр,
Бармак төртеп күрсәткәннәр,
Кушаматлар беркеткәннәр...

Шагыйрь азаккы юлларга бик тирән мәгънә салган: шушындый мөһим икърарлардан соң татарның чын бәһасен бөтен кешелекнең төшенүенә өметләнә ул. Халкының көнитеш, язмыш үзенчәлеген ул төрле яклап төшенергә, танып белергә омтыла. Татарларның традицион төбәкләрен күздән кичереп чыккач, аларның милли яшәешен автор шушындый сурәттә гомумиләштерә:

Бу татар, һай, сибелгән...
Рәсәйнең бөтен картасы
Татар белән чигелгән.

Татар балаларының кадерен белмәгән зур Ватанга аның дәгъвалары ярсулы. Солдаттагы улыннан «иртәгә Чечнягә җибәрәләр» дигән хәбәр алгач, ул болай яза:

Тик сугышта кирәк шул без, –
Татар әллә колыңмы?!
Үземә дә берәү генә –
Кайтар, Рәсәй, улымны!

Атаның гадел һәм изге гаме анда милләтнең гомуми халәтен кичерү белән бергә үрелә. Әмма аның дәгъвалы эндәшүендә туксанынчы-ике меңенче еллар татарының горурлыгы да чалымлана. Ул инде кол түгел һәм кол булмаячак та!

Милләт темасы шагыйрьдә төрле яклап ачыла. Ул халкындагы яшәү-алгарыш көчен, аның нигезен, чишмәләрен барлый. Ул Сабантуй батырларында халык яшәүчәнлегенең ныклы терәген күрә:

Батыр татар малайлары! –
Иң зур шатлык минем өчен.
Алар барда, җаным тыныч
Халкым өчен,
Илем өчен.

Батырлык һәм батырлар темасын Роберт кайта-кайта эшкәртә. Муса Җәлилнең соңгы монологына ул шушындый юлларны сала:

Ә халыкка кирәк батырлары! –
Була алмый батырларсыз халык.
Туган илем нишләр, халкым нишләр,
Яу кырында батырларсыз калып?!

Халкының холкын, гүзәл гадәт-йолаларын шагыйрь яхшы белә. Аның кунакчыллыгын узган гасыр этнографлары да тирән ихтирам белән билгеләп үткәннәр. Россия зыялылары моны хәзер дә күреп, икърар итеп тора. Роберт шушы сыйфатны классик формулада гомумиләштерә:

Кунакчыл ул безнең халык,
Аның йорты – кунак йорты.

Робертны тематик чикләргә салу мөмкин түгел дигән караштa торам мин. Тик шулай да аның иң бәрәкәтле шигырь бәйләмнәре үзәгендә өзлексез яңгырый торган берничә олы хис, шуларны сугарган үтәли мотив бар: ул – Анага мәхәббәт, туган якка тугрылык. Бу үзенчәлекне аның иҗатын күздән кичергән каләмдәшләре дә билгеләп үтә. Хосусан Галимҗан Гыйльманов: «Туган илгә, туган йортка тугрылык дигән бер хис булса, Р. Миңнуллин лирикасы, һичшиксез, әнә шул хистер», – дип яза. Сүз уңаеннан шуны билгеләп үтәргә кирәк ки, Галимҗан Гыйльманов шагыйрьнең «Талбишек» дигән китабына язган кыска гына сүз башында аның иҗатына хас үзәк сыйфатларны гаҗәп дәрәҗәдә төгәл тотып алган: «Сөн буйларыннан башланып китә аның поэзиясе», – дип, бик дөрес яза тәнкыйтьче.

Роберт шигырьдән шигырьгә туган ягының нечкә серләрен ача бара. Илеш – Актаныш табигатенең байлыгын, юмартлыгын ул болай тасвирлый:

Чишмәләр чылтыравыннан
Дөнья җырларга тора.
Ныграк басып биесәң дә,
Чишмә чыгарга тора.

Шигърияттендәге эчке бөтенлек авторның бу төркем шигырьләрендә күзгә бәрелеп тора:

Хәтта Сөн үзе дә тора
Чишмә суыннан гына.

Үкенмим шуңа – тугач та
Сөндә юылганыма.

Шагыйрьнең үзәген өзгән темасы – әнкәсенә багышланган шигырьләр. Безнең әдәбиятта бу – тирән эшкәртелгән тема. Тукайның туң җаннарны да тетрәндерерлек шигъри юлларын гына алыйк. Аның ятимлеге өчен җан әрнүе кичереп язган үкенеч тулы шушы юллары хисапсыз татарны күз яше түгеп үксеткәндер:

Күз яше дә кипмичә еглап вафат булган әни!
Гаиләсенә җиһанның ник китерден ят кеше?
Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабереӊ ташы, –
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

Һади Такташның Ана турындагы даһи юллары иң төгәл гомумиләштерүгә ия («Ана – бөек исем...»).

«Әнкәй» темасы Сибгат Хәкимнең тирән һәм юмарт лирикасында кабатланмас колорит белән яктыртылды:

Студент чакта җибәргән
Бүләкләрем фәкыйрьләр.
Үзе фәкыйрьлектә үскән –
Әнкәй мине бәхилләр.

XX гасыр дәвамында Ана темасын бөтенләй үзенчә һәм лирик нечкәлек белән Илдар Юзиев яңгыратты. Мин һич икеләнмичә әйтә алам: Роберт Миңнуллин шигъриятендәге «Әнкәй» бу темада өр-яңа ачыш булып тора. Аның лирик «әнкә»се – үзе бер зур дөнья. Бу төркем әсәрләрдә шагыйрь бай һәм нечкә хисле шәхес, олы инсанчы булып күз алдына килә:

Әнкәйләргә Алла ярдәм бирсен!
Аларгадыр бөтен авырлык.
Әнкәйләргә безнең
Йолдызлардан
Я кояштан һәйкәл салырлык.

Мондый глобаль гомумиләштерүгә ул үтә шәхси кичерешләр һәм үзенең бай тәҗрибәсе аша килә. Аның әнкәсе турындагы ихлас һәм тирән ярату белән язылган шигырьләреннән һәм җырларыннан Ананың һәйкәлдәй сурәте пәйда була:

Хатлар укыйм,
Кат-кат укыйм
Мин Әнкәйнең хатларын –
Әнкәйнең, гади Әнкәйнең
Даһи тәгълиматларын.

*(«Әнкәй хатлары»)*

Бик килешә аклары да,
Сагынам карасын да,
Мин агарткан чәч тә бардыр
Ул чәчләр арасында.

*(«Әнкәйнең ак чәчләре»)*

Сөн буенда Әнкәй басып тора,
Безне сагнып көткән чагыдыр.
Канат чыгаруга бишесе дә
Очып киткәч, кем дә сагыныр.

*(«Сөн буенда Әнкәй басып тора»)*

Күрәсезме, «Әнкәй» анда һәр очракта да баш хәрефтән языла! Балалары шәһәрдә торган юмарт авыл әнкәйләренең уртак халәтен ул шулай тасвирлый:

Кучтәнәч көткәнмени ул?
Безне көткән! Күптәннән!
Очып кына йөри Әнкәй,
Талчыкса да көткәннән...

Ә ялдан соң Әнкәйдән без
Фатиха алабыз да,
Авыл күчтәнәче төяп,
Китәбез калабызга.

*(«Кучтәнәч»)*

Робертның киң кырлы иҗатында калку күренеп торган өч юл күрсәткече бар: Сөн, Әнкәй һәм мәхәббәт. Соңгысы аның шигырь китапларында аеруча зур урын били. Яшьлек хисләре, беренче мәхәббәт, кызлар һәм егет горурлыгы, әрнүле хатирәләр, эзлекле тугрылык, батыр икърарлар һәм сызлануны шаянлык белән җиңү.

Бу зур төркем шигырьләрдә Робертның үз хисси дөньясы, үз күңел тирәнлеге һәм кешелек дәрәҗәсе гәүдәләнә.

Мәхәббәт лирикасы шагыйрьләрнең иҗат йөзен билгеләүдә, кагыйдә буларак, үзәк урынны биләгән. Юкка гынамыни бөек Тукаебыз:

Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – төшми яңгыр тамчысы;
Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы.
Бер гүзәлдән кайсы шагыйрь, әйтегез, рухланмаган?
Байроның, Лермонтовыңмы, Пушкинеңме – кайсысы? –

дип язган?!

Әлбәттә, иң бай палитралы мәхәббәт лирикасы Пушкинда. Әмма бу мәңгелек хисне бер генә шагыйрь дә җырлап бетерә алмаган. Даһи Такташ та моны бик төгәл күргән:

Мәхәббәт –
Ул үзе иске нәрсә,
Ләкин
Һәрбер йөрәк аны яңарта...

Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Такташ, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким... Исемнәрен генә санаганда да, мәхәббәт лирикасының бездәге байлыгы, тирән традициясе күз алдыннан уза. Дәрдемәндтә Шәрекъ традициясен дәвам итү, халык шигърияте аһәңнәре белән сугару («Видагъ»), фатализмны җиңеп узган мәңгелек яшәү фәлсәфәсе («Хәят»), Сәгыйть Рәмиевтәге романтик кайнарлык, Һади Такташтагы сурәт нәфислеге һәм нечкә психологизм, Муса Җәлилдәге үзәк өзгеч фаҗигалелек («Сулган чәчкә»), Хәсән Туфандагы драматизм һәм үкенечле югалту хисе, Сибгат Хәкимдәге яшәү тулылыгы һәм бәхет мотивы... Шагыйрьләрнең үзенчәлекле хисси дөньясын Илдар Юзиевнең психологик романтизмы, Равил Фәйзуллин һәм Ренат Харистагы ихласлык һәм фәлсәфи тирәнлек, Рәдиф Гаташтагы тыелгысыз кайнарлык белән дәвам итеп булыр иде. Алар хакында инде байтак язылды да.

Роберт шигырьләренең лейтмотивы ул – тик берәүгә тугрылык, бер мәхәббәт, бердәнбер хис:

Залдагылар исә ничә кабат
Алкышлары белән бүлделәр.

Сиңа дигән шигырьләрне алар
Безгә укый диеп белделәр.

*(«Шигырь кичәсендә»)*

Яисә:

Соңгы поезд... соңгы сөю...
Ул көтеп тормаячак.
Сизәм, сизәм – өлгермәсәм,
Башкасы булмаячак!

*(«Оныт»)*

Аның сөю шигырьләрендә дә драматизм җитәрлек. Шунлыктан ул ахырдан әлеге хисне мондый диалектик формулага төрә:

Сөю – бәхет, газапларны
Бәхет диеп атасак.

*(«Мәхәббәт бәхете»)*

Шагыйрьләрнең шагыйрьләргә багышланган шигырьләре аеруча тирән хисле, мәгънәле һәм тәэсирле булучан. Дөнья шигъриятендә алар бөек җаннарның бер-берсенә аваз бирүен хасил кыла. Шагыйрьләр алар – кешелекнең намус, әхлак, рухани хөрлек һәм бәхет сакчылары. Аларның бер-берсенә багышлаган шигырьләре шигъриятнең олы миссиясен ничек төшенүләрен, үзләренең дөньяны ничек күрүләрен һәм үзләрендәге җан байлыгының ни дәрәҗәдә киңлеген чагылдыра.

Француз шагыйре Андре Шеньенең якобиннар тарафыннан җәзалап үтерелүе уңаеннан, Пушкин:

Плачь, муза, плачь!..–

дип яза. Чувашларның Пушкинга гашыйк шагыйре Педер Хузангай Федерико Гарсия Лорканың җәзалап үтерелү хәбәрен алгач, рус шагыйренең әлеге сүзләрен шигыренә эпиграф итеп китерә.

Шагыйрьләрнең кайсы шагыйрьләр фаҗигасенә өзгәләнүенә карап, үзенең дә нинди шагыйрь икәнлеген белеп була.

Роберт Миңнуллинның багышлауларында Виктор Хараны, Гарсия Лорканы очратабыз. Татар шагыйренең җәзалап үтерелгән

Чили шагыйре өчен йөрәге әрнүе бик табигый. «Виктор Хара монологы»на ул шундый юлларны сала:

Мин – Лорка!
Мин – Җәлил!
Мин – Фучик!
Шагыйрьләр җиңелми көрәштә.
Соң ничек җиңмисең, иң кайнар
Җырыңны меңнәргә өләш тә!

Гаять дәрәҗәдә җитлеккән шигъри фикерләү бу. Безгәме – Җәлилле халыкка – моны аңламаска?! Безнең Мөхәммәдъярыбыз да бит тоткында үтерелгән. Шагыйрьләр – ирек җырчысы. Аларны тоткын иткән ил – рухи коллык иле ул.

Төркиядә бер кибеткә кергәч, сатучы миннән:

– Назыйм Хикмәтне беләсезме? – дип сорады.

Мин аңа төрекчә:

Бән янмасам,
Сән янмасан,
Биз янмасак,
Насыл чыкар
каранлыклар
айдынлыга? –

дигән юлларын укыдым. Сатучы мине шундук аскы катка алып төште. Кыз оныгыма матуррак спорт костюмы алу иде теләгем. Сатучым коммунист икән. Янә сорау бирә:

– Сезнең Татарстанда хәбестә (төрмәдә. – *Н.Х.)* шагыйрьләр бармы? – ди.

– Юк, – мин әйтәм. – Бездә демократия, – дим. Теге дәвам итә:

– Әгәр шагыйрьләрне хәбестә тотсалар, мин андый демократиягә «тфү!» дим.

Назыйм Хикмәтнең күп еллар зинданда ятуына әрнеп әйткән сүзләр бу.

Робертның зур төркем шигырьләрендә Тукай, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким иҗатын һәм шәхесләрен төшенү, күрү үзенчәлегендә үзенең дә иҗат һәм шигърият идеалы гәүдәләнә.

Хәсән Туфан язмышын ул җаныннан кат-кат үткәрә. Аңа булган хөрмәте, яратуы, соклануы, аның китеп баруына моңлануы үтә нәфис шигъри сурәтләрдә чагыла:

Өзгәләнми дә моңланмый,
Сокланмый түзеп кара:
Аккош күленең бердәнбер
Аккошы китеп бара!

*(«Аккош»)*

Классикның кабатланмас бөеклеген ул төгәл чалымлый:

Җанланып китте күңелләр,
Йөрәкләр типте: Ту-фан...
Елмайды Җәлилләр төсле,
Елмаеп китте Туфан...
Карагыз – Туфан йолдызы
Чыкты икән кай турга?!
Бөтенләйгә китте Туфан –
Бөтенләйгә кайтырга!

*(«Туфанны озату» циклыннан)*

Сибгат Хәким истәлеге – Роберт өчен изге истәлек. Шагыйрьнең ул җан нечкәлеген, нәфис сурәтле шигъри фикерләвен шушындый юлларда чагылдыра:

Күпме моң туа җанында,
Ә күпмесе – бөредә.
Сибгат Хәким моңы белән
Сайрый кошлар бирeдә...

Шагыйрьне бу яланнарга
Туачак Моң, Көй дәшә.
Гөлләргә шигырь укый ул,
Урман белән сөйләшә.

*(«Яланнарда йөри шагыйрь»)*

Роберт шулай ук заманыбызның гали затларына – кардәш башкорт шагыйрьләренә бөтен бер шәлкем шигырьләрен багышлый. Исемнәрен генә карагыз: Мостай Кәрим, Нажар Нәҗми, Әнгам

Атнабай... Без күптән түгел Башкортстанда Салават Юлаевның 200 еллыгы бәйрәмендә булдык. Арабызда мөхтәрәм затлар – академик Индус Таһиров, профессор Җәмил Нигъмәтов, галим һәм әдип Фоат Галимуллин, җәмәгать эшлеклесе Илсур Һадиуллин бар. Роберт Миңнуллин да безнең белән. Башкорт шагыйрьләре иң беренче аны кысып кочакларына алалар. Равил Бикбай, Сафуан Алибай һәм бүтән шагыйрьләр, әдәбият галимнәре аңа кайнар ярату, хөрмәт белән карый. Мондый хөрмәтне иҗатың һәм гүзәл шәхесең белән казанырга кирәк.

Шагыйрь – нечкә юмор иясе. Аның бүтән бер юмористта да очрамый торган үз көлү үзенчәлеге, наян елмаю чалымы һәм тел тапкырлыгы бар. Шагыйрь һәм әдипләргә, артист һәм галимнәргә, сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклеләренә багышланган шигырьләрендә аның күрү төгәллеге һәм тапкырлыгы классик дәрәҗәдә камил.

Менә аның Татарстан Сабан туенда катнашып, чүлмәк ваткан каракалпак шагыйре Ибраһим Йосыповка багышланган шаян шигыре ничек йөгерек һәм камил яңгырый:

Үз язмышын, үз бәхетен
Чүлдә тапкан Ибраһим;
Чүлдән килеп, Сабантуйда
Чүлмәк ваткан Ибраһим.

«Иң оста чүлмәк ватучы»
Дип ат алган Ибраһим.
«Йөз чүлмәк булса да ватам», –
Дип мактанган Ибраһим.

Чүлмәк ватып, кызлар күзен
Яндырган ул Ибраһим.
Татарстанны чүлмәксез
Калдырган ул Ибраһим.

Роберт тел белән виртуозларча эш итә. Аның бөти итеп тагарлык үткен юллары бар:

Үз илеңдә яшәү бәхеттер ул,
Тупсасы да аның тәхеттер ул.

Яки:

Тыйнак кына яшибез дә
Китәбез тыйнак кына.
Без бу җиргә хуҗа да бит,
Дөньяда – кунак кына.

Аның кайбер тапкыр юлларында зирәклек көтелмәгән парадоксальлек булып яңгырый:

Бөек булу безгә берни тормый,
Була белик инде гади дә!

Шагыйрьләр иманында алтын темасы җан сафлыгы өчен көрәш чагылышы булып йөри. Тукайның «Даһига» яки «Алтынга каршы» шигырен алыйк. Роберт үз шигырен «Алтынга мактау» дип атый. Аның ул әсәрендә халкыбыз тормышының гасыр дәвамында күргән иксез-чиксез михнәтләре шәйләнә һәм шул михнәтләрне батырларча кичергән хатын-кызларга рәхмәт хисе яңгырый:

Мактау җырлыйм дөньядагы барлык
Кара, ак һәм яшел алтыннарга,
Әнкәй кебек, алтын алкаларсыз
Күп балалы алтын хатыннарга,
Алтын йөзек киеп карамаган
Хатыннарның алтын кулларына.
Мактау җырлыйм алтын кояшыма,
Туган җирнең алтын кырларына.

Тормышның һәм җирнең чын кыйммәтен шагыйрь бөек гуманистларча күрә. Кыскасы, аның күңелендәге тирән гамьнәрнең үзәк эчтәлеге – туган халкын бәхетле, азат, тигез итеп күрү хыялы.

*2004*

## РЕСПУБЛИКАМНЫҢ КАЙНАР КӨННӘРЕ

*Шаулый диңгез...*
*Җил өрәдер...*
*Җилкәнен киргән кораб!*
*Төн вә көндез*
*Ул йөрәдер:*
*Юл бара ят ил карап...*
Дәрдемәнд

Тарихның хәтере камил. Ул бер генә әһәмиятле күренешне дә онытмый, бер генә вакыйганы да төшереп калдырмый. XX йөз башында татар милләтенең куәтле уянышын, иҗтимагый һәм сәяси кузгалышын бөек шагыйрь кулы белән әнә шулай теркәп калдырган. Алай гына да түгел, гомуми барышның хәвефле юралышын да тирән тоемлаган:

Чыкты җилләр,
Купты дулкын –
Ил корабын җил сөрә!..
Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!.

Тарихи оптимизм белән мәйданга күтәрелгән милли зыялыларның җанын даулаячак упкын ерак булмый. Татар халкының мең газап белән кадерләп үстергән асыл зыялыларының бихисап җаны коелды. Әмма мең еллык мәдәниятен, күп гасырлык дәүләтен хәтерендә саклаган халыкны тәмамән тез чүктереп, юкка чыгарып яки коллыкта калдырып булмый, чөнки аның, Хәсән Туфан әйтмешли, «башын исә дә үзе, йөрәге аягүрә».

Тарих кабатлана. XX гасырның соңгы унъеллыгы безнең алга янә шушындый форсатны ачты. Милләт уянды, күкрәген киереп басты, тәвәккәл хәрәкәткә кучте. Илдәге гомуми үзбилгеләнү дулкынына кушылып, без дә күп нәрсәгә ирештек, милли азатлык хәрәкәтенең дәүләт суверенлыгы игълан итүдән башлап, җөмһүриятебезнең илбашын – беренче Президентын сайлау белән тәмамланган гаять мөһим әүвәлге этабын уздык. Хәзер без – Президентлы дәүләт!

Бу тарихи казанышка ирешү ай-һай җиңел булмады. Республикабызның югары статусы идеясен күтәреп чыккан Татар иҗтимагый үзәгенә, ул хәрәкәтне җитәкләгән зыялылар, эшчеләр, игенчеләр, элекке хәрбиләр исеменә республиканың ул чактагы җитәкчеләре, консерватив аппарат һәм торгынлыктан чыгып җитмәгән матбугат авызыннан күпме каһәрләү, яла һәм гайбәт яңгырады. Әмма Марат Мөлеков, Фәүзия Бәйрәмова, Габделбәр Фәйзерахманов, Дамир Исхаков, Рафаэль Хәкимов, Гаял Мортазин, Рәшит Ягъфәров кебек каһарман затлар барлык һөҗүмнәрне гладиаторлар сыман намуслы һәм куркусыз каршылап, кире кайтара тордылар. «Вечерняя Казань» газетасы тирәсенә тупланган шовинистик көчләр нинди генә мәкерле тозаклар корырга маташмадылар. Мәгәр республикага исем биргән халыкның гадел һәм хак көрәшен туктатырга, кирегә борырга беркемнең дә көче җитмәде. Бу – тарих хөкеме һәм заман таләбе иде. Моны иң беренче булып республиканың дәүләт, хөкүмәт һәм партия җитәкчелеге аңлады. Нәтиҗәдә бәйсезлек көрәше конституцион-парламент хәрәкәте төсе алды. Хакимият җөмһүриятебездәге иҗтимагый-сәяси хәлне дөрес бәяләп җиткермәгәндә, халык мәйданнарга чыкты, тавышын чукраклар да ишетерлек итеп яңгырата алды. Һәрхәлдә, 27 май кичәсендә Ирек мәйданына 50 меңләп кеше җыелу тикмәгә түгел иде. Моны Татар иҗтимагый үзәгеннән, «Иттифак» фиркасеннән һәм «Суверенитет» комитетыннан башка республикадагы бер генә иҗтимагый төркем яки фирка дә эшли алмый иде. Димәк, дәүләт бәйсезлеге вә тигезлеге идеясе татар халкында, республика җәмәгатьчелегендә шул чаклы тирән тамыр җәйгән. КПССның республика комитеты бу шартларда дөрес һәм принципиаль юл сайлады.

Бу яз һәм җәй Казан мәйданнары татар халкы өчен дә, республиканың башка милләт вәкилләре өчен дә куәтле иҗтимагый сәяси академия булды. Ул академияне, һич икеләнмичә, йөзләрчә мең кеше узды, дия алабыз.

Татарстанда РСФСР Президентын сайлауга каршы Фәүзия Бәйрәмова игълан иткән ачлыкны язучы Зәки Зәйнуллин, шагыйрьләр Рәшит Әхмәтҗанов, Газинур Моратов, язучылар Әхәт Мушинский, Заһид Мәхмүди, драма артисты Илдус Әхмәтҗанов, Чаллыдан яшь ханымнар, ир-егетләр, авыл эшчәннәре, дин әһелләре кебек фидакяр затлар күтәреп алды. Халык таңнан төнгә

кадәр мәйданга агылды. Халкыбызның газиз кызы, милли азатлык хәрәкәтенең асыл байракчысы Фәүзия фидакярлеге бөтен республиканы, илдәге барлык татар җәмәгатьчелеген тетрәтте.

Республикабыздагы сәяси хәлнең кискенлеге хатын-кызларыбыздагы моңарчы күренми яткан искиткеч сыйфатларны ачып җибәрде. Ул – фидакярлек, батырлык, милләтпәрвәрлек. Сәяси ачлык эстафетасын ир якташларына тапшырып китүче Чаллы хатыннарыннан берәүнең шушындагы эсседә, ачык һавада утырып калган иптәшләренә хушлашу сүзләрен әйткән чакларында җан тетрәп китте: «Шушындый асыл ир-егетләре булганда, милләтем беркайчан тез чүкмәс!» Ихтыярсыздан XIX йөз азагында чыра яктысында балалар укытып, күзләре сукырайган һәм кырык яшендә көе вафат булган әбиемнең соңгы сүзләре искә төште: «Мин сукырайсам да үкенмим, чөнки күзләремне халкыма багышладым...» Яшәсен безнең фидакяр, гүзәл хатын-кызларыбыз!

Ниһаять, мәйданнар тынып калды, ярсу иҗтимагый хәрәкәтнең төп максатына ирешелде. Татарстан Президентын сайлауда республика халкының 70 ләп проценты катнашты. Россия Президенты өчен бирелгән тавыш 30 проценттан аз гына артык булды. Бу – гаять мөһим нәтиҗә, ул асылда референдумга тиң. Халыкның өчтән ике өлеше җөмһүриятебезнең мөстәкыйльлеген яклый, ягъни референдум таләп иткән сан чагыштырмасы килеп чыга. Бу йомгак күп нәрсә турында сөйли. Татар халкының мөстәкыйль дәүләт идеясен, димәк, татар булмаган сайлаучыларның 20 проценттан артыгы яклый. Алар – әлбәттә, безнең даими тату күршеләребез чувашлар, марилар, удмуртлар, мордвалар. Бу аңлау, бу теләктәшлек, бу бердәмлек өчен без аларга рәхмәт укыйбыз, туганлык хисләре юллыйбыз. Алар татардан беркайчан кыерсыту күрмәгән, шуңа күрә безгә ышаналар, дустанә карыйлар.

Хәлбуки бу санның зур ук өлеше русларга туры килә. Монысы тагын да мөһим. «Демократлар»ның, даими спекуляция объекты булган республиканың рус рәгыйяте шактый күләмдә дәүләтебезнең мөстәкыйльлек идеясен яклауга кушыла, үзе өчен Татарстан гражданлыгын өстен күрә. Бу – безнең өчен бик кыйммәт, һәм без моның кадерен белербез. Без аларга – уртак илебезнең лаеклы гражданнарына – рәхмәт укыйбыз, туганлык кулы сузабыз. Кыскасы, шушы зур сәяси кампания республикада милли консенсус

беләп тәмамланды. Бу – безнең иң кыйммәтле казанышыбыз, һәм моның белән Татарстан бөтен Союзга үрнәк күрсәтә. Калган рус кешеләренең дә мөстәкыйль Татарстанны төзүгә ихлас катнашачакларына өмет бар.

Республикадагы бу бердәмлек, килешеп эш итү һәм тупланган традицияләр, тәҗрибә нәтиҗәсе (татар халкыннан бер халык та җәбер-золым, начарлык күргәне юк, үзе күп гасыр изелгән халык башкаларга аны күрсәтми дә) һәм соңгы чорда алып барылган акыллы сәясәт җимеше булды. Рус илдәшләребез татар милли хәрәкәте турындагы ялганнарны кабул итмәде, провокаторлар коткысына бирелмәде. Бу хәл аларның намусын югары куя. Аннары илнең башка өлкә һәм республикаларында булып үткән ачы сабак та роль уйнагандыр. Акны-караны белмичә, милли җәнҗалга ташлану яхшыга илтми. Тормыш шартлары да, Ходайга шөкер, авыр булса да, башка төбәкләрдәге кебек үк коточкыч түгел. Моның кадерен белергә тырышу да чагыладыр.

Милли хәрәкәт җитәкчелеге шушы искиткеч кискен шартларда дөрес юл тапты. Руслар белән каршылыкка кермичә, аларны татулыкка, бердәм хәрәкәткә, уртак бәхетне бердәм тырышлык белән төзергә чакырды.

Республика җәмәгать тормышының соңгы вакытта мөһим яңалыгы да шунда иде: ТИҮ, «Иттифак» яки «Суверенитет» комитеты оештырган чараларга руслар да күпләп йөри башлады. Фәүзия Бәйрәмова һәм аның фикердәшләре уздырган сәяси ачлык вакытында Ирек мәйданына изге ният белән килгән рус кешеләре милли хәрәкәтнең максатлары, Фәүзия һәм аның «Иттифак» фиркасе тоткан мәсләк белән кайнар кызыксынып сорау бирәләр, теләктәшлек белдерәләр, хәрәкәт кассасына акча салалар һәм петициягә кул куялар иде.

Рус кешеләре хаклы рәвештә татар милли-демократик хәрәкәте хакында мәгълүмат юклыктан зарландылар. Бу чыннан да шулай. Рус матбугаты чын мәгънәсендә информацион блокада оештырды. Бу телдәге җәмәгатьчелеккә объектив мәгълүматны бары митингта гына җиткерергә мөмкин иде. Шөкер, хәзер Әмир Мәхмүдов тырышлыгы белән «Суверенитет» комитетының шул исемдәге газетасы чыга башлады. Бу җәһәттән татар матбугаты да үзенең укучыларын объектив, тулы информациягә кинәндерде

дип булмый. Мәсәлән, иң абруйлы газеталарыбыз да 50 меңлек митингтан аерым эпизодларны гына басып чыгарды. Димәк, татар җәмәгатьчелеге үзе дә хак информациядән шактый мәхрүм калды.

Митингларда рус кешеләренә дустанә, туганнарча мөрәҗәгать еш яңгырады. Бу бик кирәк иде һәм моның нәтиҗәсе дә булды.

Нәтиҗәсе шул: бездә Карабах беркайчан да булмаячак. Нәтиҗәсе шул: Татарстан гражданнарының абсолют күпчелеге суверенитет өчен тавыш бирде һәм дәүләтебезнең Президенты итеп Минтимер Шәймиевне сайлады.

Минтимер Шәймиев... Бу исем бер елдан артык инде республика һәм ил теленнән төшми. Җөмһүриятебездә төрле һәм үтә кискен вакыйгалар булды. Союздашлык статусы өчен көрәшү чоры. Мәйданнар гөр килә. КПСС өлкә комитетын җитәкләгән шушы лидер исеменә үтә кискен лозунглар, таләпләр, сораулар яңгырый: «Камыр булма, Минтимер!», «Син татармы, Минтимер?» һ.б., һ.б. Акыллы җитәкче шушы шартларда дөрес мәсләк таба алды, буталмады, ашыкмады, анык, төгәл карарга килде, җөмһүриятнең Югары Советын конструктив эшкә туплады. Тарихи Декларация кабул ителде. Әмма Союз һәм РСФСР җитәкчелеге үҗәтләнеп-үҗәтләнеп мөһим яңа реальлелекне күрмәмешкә салышты. Югары Совет рәисебез ил парламентында, микрофон һәм экран аша эзлекле һәм принципиаль рәвештә республиканың статусын яклады, көрәште. Үзен ил күрде, республика халкы бәяләде. Минтимер Шәймиев хөкүмәт җитәкчесе Мөхәммәт Сабиров белән алмаш-тилмәш Декларациябезне икътисади һәм сәяси тормышка ашыру өчен көч куйдылар. Илдә һәм республикада хәлләр җиңел булмаса да, халыкны тукландыру чарасын күрәләр, шәһәрләребездә юллар төзекләндерелә, тормыш дәрәҗәсе Союздагы гомуми торыштан чак кына яхшырак хәлдә саклана.

Хәзер җөмһүрият өчен хәлиткеч сынаулар чоры килде: Татарстан халкының Бөтенсоюз референдумында үзенең тигез хокуклы республика буларак яңартылган берлекне төзүдә катнашуына ышанып, СССР Президенты куйган сорауга бердәм рәвештә диярлек бирелгән уңай җавабын ил җитәкчелеге дөрес бәяли белмәде. Сүз беркетешкән тугыз союздаш республика белән берлектә М.С. Горбачев безнең суверенитетыбызны Союз күләмендә реальләштерүгә аяк чала. Җөмһүриятебез Президенты Минтимер Шәрип улы Шәй-

миев республика халкы теләген үтәп, аның ихтыярын каһарманнарча яклап килә. Бу аңа ихтирам өсти, ышаныч уята.

Әмма аның бик нык уйлап ясаган акыллы белдерүләрендә күңелгә шом сала торган төсмерләр дә шәйләнеп китә. Республика эчендә да, ил күләмендә дә: «Безнең суверенитет милли төсмерле була алмый», – дигән сүзләре күпләрне сәерсендерә. Безнең республика да, – башка республикалар кебек күп милләтле булса да, милли республика. Ул, барыннан да элек, татар халкының дәүләтчелеген гәүдәләндерә. Әгәр аңардан бу төсне алып ташлыйсың икән, аның асылында бернинди мәгънә калмый. Төссез республика беркемнеке дә түгел, дигән сүз. Безгә кайсы республикага барып үз төсебезне эзләргә кала? Татар милли төсмере Татарстанда гаделсезлек булып кабул ителә алмый. Бездә яшәүче барлык милләт вәкилләренең дә үз милли республикалары бар. Биредә аларга тулы канлы милли яшәеш гарантияләнә. Әмма безнең халкыбызның милли бишеге үз төсенә ия булырга тиеш.

Президентыбызның республикадагы барлык халыкларга тигез каравы рус җәмәгатьчелегенә бик ошады. Аның мондый зирәклеге барыбызга да ошый. Әмма республика исеме һәм бу җирнең борынгы вә төп хуҗасы истән чыгарылмасын иде. Шул вакытта Президентыбыз үз туган халкыннан да тимер кебек яклау табар.

*2004*

## ГАЛИМНЕҢ БИБЛИОГРАФИЯСЕ

### а) китаплар, монографияләр

Яз миңа чәчәкләр китерә. Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. – 24 б.

Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул ʻАли (Анализ источников сюжета и авторского творчества): автореф. дис. ... канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФ АН СССР. – М., 1979. – 18 с.

Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул ʻАли. Анализ источников сюжета и авторского творчества. – М.: Наука, 1979. – 254 с.

Бөек язмышлы әсәр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 336 б.

Бәрәкәтле чишмәләр: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 150 б.

Сюжет Йусуфа и Зулейхи в средневековой тюрко-татарской поэзии XIII–XV вв. (Проблема версий): дис. ... д-ра филол. наук в форме науч. докл.; ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. – М., 1996. – 96 с.

Сюжет Йусуфа и Зулейхи в тюрко-татарской поэзии XIII–XV вв. (Проблемы версий). – Казань: ГУП ПИК «Идел-Пресс», 2001. – 216 с.

Тукайны төшенү юлында («Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсенә материаллар) / Җаваплы мөхәррир – филология фәннәре докторы З.З. Рәмиев. – Казан: ТаРИХ, 2003. – 80 б.

Хәтер сагында: Әдәби-фәнни мәкаләләр, иҗат портретлары һәм публицистика. – Казан: Мәгариф, 2004. – 641 б.

Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә». – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 208 б.

Язгы шәфәкъ (шигырьләр һәм драма). – Казан: «Дом печати» нәшр., 2007. – 283 б.

Татар шагыйрьләре. – Казан: Татар. кит нәшр., 2012. – 287 б.

Остазлар. – Казан, 2012. – 102 б.

Kul Alirec türkçe Yusufnâme. – Ankara, 2014. – 179 s.

Тукай: бөеклеге һәм фаҗигасе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 125 б.

### ә) төзүче, җаваплы мөхәррир, редколлегия әгъзасы

Татар әдәбияты тарихы: алты томда / баш редколлегия: Юзиев Н.Г. (баш редактор), Абдуллин Я.Г., Ахунов Г.А., Абилов Ш.Ш., Гайнуллин М.Х., Гыйззәтуллин Н.Г., Мусин М.М., Мусин Ф.М., Мөхәррәмов М.К., Халитов Г.М., Хәсәнов М.Х., Шәрәфетдинов Г.Н., Яхин А.Г. Том редколлегиясе: Абилов Ш.Ш. (җаваплы редактор), *Хисамов Н.Ш. (җаваплы редактор урынбасары),* Миңнегулов Х.Ю. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 1 т. Урта гасырлар дәвере. – 567 б.

Поэт-гуманист Кул Гали: матер. юбил. торжеств и науч. конф., посв. 800-летию со дня рождения и 750-летию его поэмы «Кысса-и Йусуф» / редколлегия: Н.Г. Юзеев, *Н.Ш. Хисамов (отвественный редактор),* Я.Г. Абдуллин, Ш.Ш. Абилов, Н.Ф. Исмагилов (составитель). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – 264 с.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда / баш редколлегия: Абдуллин Я.Г., Абилов Ш.Ш., Гыйззәтуллин Н.Г., Зәкиев М.З., Миңнуллин Т.А., Мусин Ф.М., Халитов Г.М., Ханзафаров Н.Г., Хәсәнов М.Х., Шәрәфетдинов Г.Н., Юзиев Н.Г. (баш редактор), Яхин А.Г., Әхмәдуллин А.Г. Том редколлегиясе: Юзиев Н.Г., *Хисамов Н.Ш. (җаваплы редакторлар),* Халитов Г.М. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 4 т. Татар совет әдәбияты (1917–1941). – 568 б.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда / баш редколлегия: Абдуллин Я.Г., Абилов Ш.Ш., Гыйззәтуллин Н.Г., Зәкиев М.З., Миңнуллин Т.А., Мусин Ф.М., Халитов Г.М., Ханзафаров Н.Г., Хәсәнов М.Х., Мөхәммәдиев Р.С., Юзиев Н.Г. (баш редактор), Яхин А.Г., Әхмәдуллин А.Г. Том редколлегиясе: Гыйззәтуллин Н.Г. (җаваплы редактор), Ханзафаров Н.Г., *Хисамов Н.Ш.* – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 5 т. Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941–1960). – 544 б.

Гали Кул. Сказание о Йусуфе / перевод Сергея Иванова. *Автор предисловия и комментариев, научный редактор кандидат филологических наук Нурмухаммет Хисамов;* Кул Гали. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. – 524 с.

Гали Кол. Кыйссаи Йосыф: Поэма / *хәзерге әдәби телгә шигъри күчермәне Нурмөхәммәт Хисамов эшләде;* Кол Гали. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. –221 б.

Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.) / редколлегия: Абилов Ш.Ш., кандидат филологических наук, Асылгараев Ш.Н., кандидат филологических наук, Галимуллин Ф.Г., кандидат филологических наук, Махмутов Х.Ш., доктор филологических наук, *Хисамов Н.Ш.,* доктор филологических наук. *Руководитель авторского коллектива и научный редактор Н.Ш. Хисамов.* – Казань: Фэн, 1999. – 240 с.

Дәрдемәнд. Агарган кыл = Поседевшая струна: Шигырьләр = Стихи / төзүчесе һәм кереш сүз авторы Ренат Харис; *фәнни редакторы филология фәннәре докторы Нурмөхәммәт Хисамов* = составитель и автор предисловия Ренат Харис; научный редактор доктор филологических наук Нурмухаммет Хисамов; Дәрдемәнд. – Казан: Мәгариф, 1999. – 111 б.

Татарское возрождение. Эпоха и личности / редколлегия: Академик РАН и АНТ К.А. Валиев (главный редактор), *доктор филологических наук Н.Ш. Хисамов (ответственный редактор),* Ф.А. Табеев, академик РАН и АНТ А.И. Коновалов, член-корреспондент АНТ В.Н. Лихачев, доктор филологических наук Н.М.Валеев, доктор филологических наук

Ф.М. Мусин, профессор Б.Ф. Султанбеков, член-корреспондент РАН и АНТ И.Б. Хайбуллин, доктор экономических наук Д.С. Хайруллов, И.Р. Каримов (ученый секретарь). – Казань: Фән, 2000. – 440 с.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда / баш редколлегия: Абилов Ш.Ш., Әхмәдуллин А.Г., Галимуллин Ф.Г., Гыйззәтуллин Н.Г., Зәкиев М.З., Миңнуллин Т. А., Мусин Ф.М., Халитов Г.М., Ханзафаров Н.Г., Хәсәнов М. Х. (баш мөхәррир), Хисамов Н.Ш., Юзиев Н.Г., Яхин А.Г. Том редколлегиясе: Бәширов Ф.К. (фәнни мөхәррир ярдәмчесе), Галимуллин Ф.Г., Мусин Ф.М. (том җитәкчесе һәм фәнни мөхәррир), Ханзафаров Н.Г., *Хисамов Н.Ш. (җаваплы мөхәррир).* – Казан: Раннур, 2001. – 6 т. 60–90 нчы еллар әдәбияты. – 544 б.

Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: тууына 115 ел тулуга багыш. фән. конф. материаллары / редколлегия: М.Х. Хәсәнов (баш мөхәррир), М.Г. Арсланов, Р.У. Әмирханов, М.З. Зәкиев, Р.Ф.Исламов (төзүче), Ф.М. Мусин, *Н.Ш. Хисамов,* Ф.И. Урманчеев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 272 б.

Проблемы развития татарской нации (языковой, литературно-фольклорный и искусствоведческие аспекты) / *ответственный редактор Н.Ш. Хисамов;* редколлегия: М.Г. Арсланов, Р.З. Закиров, М.З. Закиев, Ш.Н. Асылгараев, Р.Ф. Исламов (составитель), Ф.И. Урманчеев. – Казань: Изд-во «Фән» Академии наук РТ. – 2004. – 240 с.

Инсани фәннәр: эзләнүләр һәм табышлар: ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 2002 һәм 2003 еллар өчен еллык фәнни конф. матер. / *җаваплы мөхәррир – Н.Ш. Хисамов;* редакцион коллегия: М.Г. Арсланов, Ф.А. Ганиев, М.З. Зәкиев, Р.Ф. Исламов, Д.Э. Нигъмәтуллина (төзүче), Ф.И. Урманчеев, З.Р. Шәйхелисламов. – Казан: Фикер, 2004. – 576 б.

Татар фольклоры мәсьәләләре. Күренекле галим-фольклорчы Хәмит Ярминең 100 еллыгына багышлана / редколлегия: Х.Ш. Мәхмүтов, К.М. Миңнуллин, Ф.И. Урманче, *Н.Ш. Хисамов;* төзүче һәм мөхәррир: И.Г. Закирова. – Казан: Фикер, 2004. – 168 б.

Татар шигърияте. XX йөз башы / баш редколлегия: З.Р. Вәлиева, А.Г. Әхмәдуллин, Р.И. Вәлиев, Т.Н. Галиуллин, Д.Ф. Заһидуллина, Х.И. Миңнегулов, *Н.Ш. Хисамов,* М.Х. Вәлиев; китапны төзүче, текстларны басмага әзерләүче, кереш мәкалә, искәрмә һәм аңлатмалар авторы Зөфәр Рәмиев. – Казан: Мәгариф, 2004. – 447 б.

Мифтахова М.А. Поэзия Хасана Туфана 60–80 гг. XX века. Проблема лирического героя. Методика изучения в татарской школе / научные редакторы: *доктор филологических наук, профессор Н.Ш. Хисамов,* профессор С.Г. Исмагилова; М.А. Мифтахова. – Казань, 2005. – 204 с.

История татарской литературы средневековья (XIII–XVIII вв.) / *руководитель авторского коллектива и научный редактор Н.Ш. Хи-*

*самов;* редколлегия: Ф.Г. Галимуллин, Ф.М.Мусин, Р.Ф.Исламов, Х.Ш. Махмутов, З.Р. Шайхисламов, *Н.Ш. Хисамов.* – Казань, 2005. – 356 с.

Тукай Г. Сайланма әсәрләр: ике томда / *томны төзүчеләр: Нурмөхәммәт Хисамов,* Зөфәр Мөхәммәтшин; искәрмәләр һәм аңлатмаларны әзерләүче Марсель Әхмәтҗанов; *җаваплы мөхәррир Нурмөхәммәт Хисамов.* – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 1 т. Шигырьләр, истәлекләр. – 271 б.

Җәлил М. Әсәрләр: биш томда / редколлегия: Вәлиева З.Р., Ибраһимов И.М., *Хисамов Н.Ш.,* Шакиров Д.С., Мостафин Р.Ә., Әхмәтҗанов М.И., Шәйхелисламов З.Р.; томны басмага әзерләүче Зөфәр Мөхәммәтшин; фәнни мөхәррире Зөфәр Рәмиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 1 т. Шигырьләр (1921–1941). – 431 б.

Җәлил М. Әсәрләр: биш томда / редколлегия: Вәлиева З.Р., Ибраһимов И.М., *Хисамов Н.Ш.,* Шакиров Д.С., Мостафин Р.Ә., Әхмәтҗанов М.И., Шәйхелисламов З.Р. Томны басмага әзерләүче Гөлчирә Ханнанова. Фәнни мөхәррире Зөфәр Рәмиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 2 т. Шигырьләр (1941–1944). – 382 б.

Җәлил М. Әсәрләр: биш томда / редколлегия: Вәлиева З.Р., Ибраһимов И.М., *Хисамов Н. Ш.,* Шакиров Д.С., Мостафин Р.Ә., Әхмәтҗанов М.И., Шәйхелисламов З.Р.; томны басмага әзерләүче Эльмера Галимҗанова; фәнни мөхәррире Зөфәр Рәмиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 3 т. Шигырьләр, поэмалар, тәрҗемәләр. – 368 б.

Җәлил М. Әсәрләр: биш томда / редколлегия: Вәлиева З.Р., Ибраһимов И.М., *Хисамов Н.Ш.,* Шакиров Д.С., Мостафин Р.Ә., Әхмәтҗанов М.И., Шәйхелисламов З.Р.; томны басмага әзерләүче Фирдәүсә Кадыйрова, Гөлназ Хөснетдинова; фәнни мөхәррире Зөфәр Рәмиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 4 т. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм биографик материаллар. – 318 б.

Җәлил М. Әсәрләр: биш томда / редколлегия: Вәлиева З.Р., Ибраһимов И.М., *Хисамов Н.Ш.,* Шакиров Д.С., Мостафин Р.Ә., Әхмәтҗанов М.И., Шәйхелисламов З.Р.; томны басмага әзерләүче Заһир Шәйхелисламов; фәнни мөхәррире Зөфәр Рәмиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. –5 т. Сәнгать турында мәкаләләр һәм хатлар. – 319 б.

Садыйков Р.Х. Хәсән Туфан шигъриятендә сәнгатьчә тасвир / *җаваплы мөхәррир: Н.Ш. Хисамов – филология фәннәре докторы, профессор.* – Казан, 2006. – 144 б.

Урманчеев Ф. Каһарманнар йолдызлыгы. Тарихи-фольклористик очерклар / редколлегия: филология фәннәре докторлары, профессорлар Х.Ш. Мәхмүтов (төзүче-мөхәррир), К.М. Миңнуллин, *Н.Ш. Хисамов.* – Казан: Дом печати, 2006. – 288 б.

**б) мәкаләләре**

Үсү юлында [Язучы Хисам Камалов иҗаты турында] // Совет әдәбияты. – 1960. – № 4 – Б. 145–150. (Ә. Рәшитов белән берлектә)

Дәрдемәнд поэзиясендә туган ил мотивы // Совет мәктәбе. – 1969. – № 2. – Б. 26–29.

Матурлык хакына [Рец. кит.: Афзал Г. Өф-өф итеп. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. – 187 б.] // Совет әдәбияты. – 1969. – № 6. – Б. 143–149.

Үлемсезлек җырчысы [Шагыйрь Шәрәф Мөдәррискә 50 яшь тулу уңае белән] // Казан утлары. – 1969. – № 11. – Б. 152–156.

Эзләнү һәм табыш шатлыгы [Казанның Совет районы Культура сарае каршындагы татар халык театры артисткасы Т. Сафина турында] // Соц. Татарстан. – 1969. – 2 дек.

Дәрдемәнд шигырьләре рус телендә // Казан утлары. – 1971. – № 1. – Б. 163–168.

Тынгысыз иҗатчы [Шагыйрь Зәки Нурига 50 яшь тулу уңае белән] // Татарстан яшьләре. – 1972. – 8 гыйнв.

Кешелекле көлү [Шагыйрь Гамил Афзал иҗаты турында] // Татарстан яшьләре. – 1972. – 22 апр.

Гасырлар тирәнлегеннән [Әдәби традицияләр турында] // Казан утлары. – 1973. – № 4. – Б. 181–186.

Көмеш елганың тирән җирендә [Язучы Ләбибә Ихсановага 50 яшь тулу уңае белән] // Соц. Татарстан. – 1973. – 26 авг.

«Кыйссаи Йосыф» поэмасының халыкта яшәеше // Казан утлары. – 1974. – № 9. – Б. 175–182.

«Кыйссаи Йосыф» әсәренең халык версияләре // III научная конференция молодых ученых: тез. докл. – Казань, 1974. – Б. 25–26.

Заманнар кичеп // Азат хатын. – 1974. – № 12 – Б. 16–17.

Шаһимәрдан бабайның хәтер сандыгы // Татарстан яшьләре. – 1975. – 2 окт.

Заман һәм шагыйрь [Шагыйрь Зәки Нури иҗаты турында] // Совет әдәбияты. – 1975. – № 2. – Б. 168–178.

Бөек тарихның бер мизгеле // Соц. Татарстан – 1971. – 19 сент.

Хикмәт назлылыкта мени? [Драматург Кәрим Тинчуринның «Назлы кияү» спектакле турында] // Татарстан яшьләре. – 1975. – 15 нояб.

«Киссаи Йософ» поэмаһында мәкәлдәррең эстетик вазифаһы // Башҡорт филологияһы. – Пермь-Стәрлетамак, 1975. – Икенсе китап. – Б. 92–95.

Сказочные мотивы в поэме «Киссаи Йусуф» Кул Али // IV конф. молодых науч. работников: материалы. – Казань, 1976. – С. 100–102.

Кол Галинең сәнгатьчә тасвирында халыкчан афоризмнар // Татар теле һәм әдәбияты. – Казан, 1976. – Бишенче кит. – Б. 284–294.

«Кыйссаи Йосыф» поэмасында әдәбият-фольклор бәйләнешләрен өйрәнүгә карата // Татар теле һәм әдәбияты / научные редакторы: А.Г. Ахмадуллин, Н.Б. Бурганова, А.М. Шарипов. – Казан, 1977. – Алтынчы кит. – Б. 150–157.

Тукай иҗатында борынгы әдәбият традицияләре // Казан утлары. – 1978. – № 4. – Б. 141–147.

Традиции древней литературы в поэзии Тукая // Габдулла Тукай: материалы науч. конф. и юбил. торжеств, посв. 90-летию со дня рожд. поэта / редакционная коллегия: А.Г. Ахмадуллин, Г.М. Халитов, М.Х. Хасанов, Н.Г. Юзеев; научный редактор Г. Халит; составители: Ф. Макаев, А. Садекова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1979. – С. 106–114.

Яңарыш чишмәләре [Рец. кит.: Госман Х. Шигъри‌ят гомере. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 206 б.] // Казан утлары. – 1979. – № 10. – Б. 170–171.

Кадерле мирас [Шагыйрь Шәрәф Мөдәрриснең тууына 60 ел тулу уңае белән] // Соц. Татарстан. – 1979. – 1 нояб.

Шигъри осталык мәктәбе (Дәрдмәнднең тууына 120 ел тулуга карата) // Соц. Татарстан. – 1979. – 23 нояб.

«Кыйссаи Йосыф» поэмасының халык поэзиясенә тәэсире // Урта гасыр татар әдәбияты тарихы / фәнни редакторлар: филол. фәннәре кандидатлары Н.Г. Гыйззәтуллин һәм Н.Ш. Хисамов. – Казан, 1981. – Б. 23–37.

Әдәбиятка тарихи караш [Рец. кит.: Таһирҗанов Г. Тарихтан – әдәбиятка. – Казан, 1979. – 167 б.] // Казан утлары. – 1981. – № 1. – Б. 183–185.

Шагыйрьнең күңел яктысы [Рец. кит.: Нури З. Күңел яктысы. Шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 464 б.] // Казан утлары. – 1981. – № 10. – Б. 169–172.

Ил өчен яну [Шагыйрь Зәки Нурига 60 яшь тулу уңае белән] // Соц. Татарстан. – 1981. – 24 дек.

Дәрдмәнд әсәрләренең яңа басмасы [Рец. кит.: Дәрдмәнд (Закир Рәмиев). Исә җилләр: Шигырьләр. Истәлек-парчалар. Вак хикәяләр / төзүчесе һәм искәрмәләрне язучы Р. Даутов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 256 б.] // Казан утлары. – 1982. – № 3. – Б. 163–166. (М. Госманов белән берлектә)

Сквозь призму поэзии [Рец. кит.: Ханзафаров Н.Н. Исәнбәт драматургиясе (Жанр, конфликт һәм герой проблемалары) / фәнни редакторы Азат Әхмәдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 190 б.] // Сов. Татария. – 1983. – 9 янв.

«Кыйссаи Йосыф» поэмасының идея-проблематикасы һәм сәнгатьчә эшләнеше // Казан утлары. – 1983. – № 9. – Б. 53–61.

Певец гуманизма // Веч. Казань. – 1983. – 10 окт.

Шагыйрьнең бөек әсәре // Соц. Татарстан. – 1983. – 11 окт.

Итоги задачи изучения «Кысса-и Йусуф» Кул ‘Али // Сов. тюркология. – 1984. – № 2. – С. 72–75.

«Мин хәтерлим гаҗәп бер мизгелне...» [Шагыйрь Нури Арслан иҗаты турында] // Татарстан яшьләре. – 1985. – 23 апр.

Олы гамь белән [Рец. кит.: Мәхмүтов Ә. Матурлык тантанасы. Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 80 б.] // Соц. Татарстан. – 1984. – 5 май.

Хисамов Н. Өч милләтнең җырчысы [Рец. кит.: Акмулла. Шигырьләр / төзүчесе һәм искәрмәләрне әзерләүче М. Госманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 271 б.] // Соц. Татарстан. – 1984. – 5 авг.

Кул Гали и его поэма «Кысса-и Йусуф» // Кул Гали. Сказание о Йусуфе / перевод С. Иванова; автор предисловия и комментариев, научный редактор кандидат филологических наук Нурмухаммет Хисамов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. – С. 5–18.

Тарихның бер сәхифәсе [Рец.: Хәбибуллин М. Кубрат хан. Роман // Казан утлары. – 1984. – № 8. – Б. 22–74; – № 10] // Соц. Татарстан. – 1985. – 31 март.

Яңа сәяхәт, яңа табышлар [Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фольклор бүлегенең эшчәнлеге турында] // Соц. Татарстан. – 1985. – 12 апр.

Особенности современного этапа исследований средневековых тюркских литературных памятников // Историко-культурные контакты народов алтайской языковой общности: тез. докл. XXIX сессии пост. междунар. алтаистической конф. (PIAC) (Ташкент, сентябрь, 1986 г.) / редколлегия: В.М. Солнцев (председатель), Д.Д. Васильев, С.Г. Кляшторный, Х.Г. Короглы, Б.А. Назаров, В.З. Церенов. – М., 1986. – Ч. 1. История. Литература. Искусство. – С. 117–118.

Особенности современного этапа исследований средневековых тюркских литературных памятников // Сов. тюркология. – 1987. – № 3. – С. 110–112.

XIII–XIV йөз Идел буе төрки поэзиясе / Н. Хисамов // Казан утлары. – 1987. – № 4. – Б. 174–178.

Итоги и задачи изучения «Кысса-и Йусуф» Кул Гали // Поэт-гуманист Кул Гали: материалы юбил. торжеств и науч. конф., посв. 800-летию со дня рождения 750-летию его поэмы «Кысса-и Йусуф». – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – С. 74–88.

Итоги и задачи изучения «Кысса-и Йусуф» Кул ‘Али // Tatarica. Studia in honorem Ymer Daher. – Helsinki: Vammala, 1987. – С. 354–363.

«Йосыф китабы» турында [«Кыйссаи Йосыф» дастанының телевизион вариантын карагач туган уйлар] // Соц. Татарстан. – 1986. – 13 авг.

Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул ‘Али и задачи сопоставительного изучения тюркских версий сюжета Йусуфа // Вопросы советской тюркологии:

материалы IV Всесоюз. тюркологич. конф. / отв. ред. Б.Ч. Чарыяров. – Ашхабад: Ылым, 1988. – Ч. 2. – С. 43–47.

Халкыбызның шигъри юлдашы // Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. Хәзерге әдәби телгә шигъри күчермәне Нурмөхәммәт Хисамов эшләде. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 5–16.

Халкыбызның затлы хәзинәсе [«Татар халык иҗаты»ның уникетомлыгы басылып чыгу уңае белән] // Татарстан яшьләре. – 1989. – 20 апр.

Борынгы әдәбиятыбыз // Соц. Татарстан. – 1989. – 22 авг.

Янам, яктыртам, җылытам... [Шагыйрь Ренат Харис иҗаты турында] // Татарстан яшьләре. – 1989. – 22 апр.

Дәрдемәнд (Тормышы һәм иҗаты турында очерк) // Казан утлары. – 1989. – № 12. – Б. 165–175.

Дәрдемәнднең «Хәят» шигыре // Азат хатын. – 1989. – № 12. – Б. 14.

Некоторые трудности в постижении лирики Тукая // Поэт свободы и правды: материалы Всесоюз. науч. конф. юбил. торж., посв. 100-летию со дня рожд. Габдуллы Тукая / редколлегия: М.Х. Хасанов (председатель), М.З. Закиев, Т. М. Миннуллин, Ф.М. Мусин, Г.М. Халитов, Н.Г. Юзеев, Р.А. Ахметов (научный редактор). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. – С. 250–255.

О русском «демократизме» и татарском «национализме» // Комсомолец Татарии. – 1991. – 1 февр.

Татар сылуы (Матурлык конкурсына бер караш) // Шәһри Казан. – 1991. – 27 март.

Исемең матур, кемнәр куйган // Шәһри Казан. – 1991. – 25 июнь.

Республикамның кайнар көннәре // Ватаным Татарстан. – 1991. – 5 июль.

Яңача фикерләү һәм урта гасыр әдәбиятын өйрәнүнең принципиаль мәсьәләләре // Казан утлары. – 1991. – № 7. – Б. 182–184.

Кемгә таянырга? // Соц. Татарстан. – 1991. – 24 сент.

Derdmend (Hayati ve eserleri hakkinda bir deneme) // Kardas edebieyatlar. – 1991. – № 20. – S. 14–25.

Йосыф-Зөләйха: тарихи драма // Мирас. – 1992. – № 6–7. – Б. 38–59; 45–69.

Милләткә ярдәм ит, «Мирас»! // Мирас. – 1992. – № 8. – Б. 3–5. (Р. Ягъфәров белән берлектә)

Татар поэзиясе // Татар поэзиясе антологиясе: ике китапта / төзүчесе Гәрәй Рәхим. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – II кит. – Б. 424–446. (Т. Галиуллин белән берлектә)

Бирешмик, сынатмыйк! // Шәһри Казан. – 1992. –17 март.

Әдәбиятыбызның аксакалы [Язучы, драматург, шагыйрь Нәкый Исәнбәткә 90 яшь тулу уңае белән] // Татарстан. – 1992. – № 9–10. – Б. 54–58.

Кыйммәтле кулъязма: «Кыйссаи Йосыф»ның Ленинградта саклана торган бер кулъязмасы // Мирас. – 1992. – № 11. – Б. 41–46.

Ул безнең күңелләрдә [Шагыйрь Мостафа Ногманның тууына 80 ел тулу уңае белән] // Шәһри Казан. – 1992. – 26 дек.

Җөмһүриятнең рухани саулыгы // Ватаным Татарстан. – 1993. – 22 гыйнв.

Бал кортына ничә яшь [Фольклорчы-галим Хуҗи Мәхмүтов турында] // Ватаным Татарстан. – 1993. – 10 февр.

Духовное здоровье республики // Независимость. – 1993. – № 2. – С. 2.

Шагыйрьнең публицистикасы [Рец.: Рәшитов Ә. Иман яңартканда. Публицистика, тәнкыйть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 159 б.] // Татарстан. – 1993. – № 6. – Б. 52–53.

Урта гасыр әдәбиятында бәйләнешләр // Татарстан. – 1993. – № 10. – Б. 89–93.

Чүпрәлеләр // Мәгърифәт. – 1994. – 7 май.

Кол Галинең бөек әсәре // Мирас. – 1994. – № 5–6. – Б. 13–15.

Кыйссаи Йосыф [Текстны гамәлдәге татар теленә башкаручы Н. Хисамов] // Мирас. – 1994. – № 5–6. – Б. 16–29.

Алтын Урданың шигъри мәдәнияте // Казан утлары. – 1994. – № 5. – Б. 174–177.

Зиярәтләребез хакында // Ватаным Татарстан. – 1994. – 11 окт.

Җан авазы // Ватаным Татарстан. – 1994. – 18 нояб.

Әхмәд Ясәви һәм Кол Гали // Мирас. – 1994. –№ 10. – Б. 35–38.

Урта гасыр әдәбиятын яңача өйрәнү // Мирас. – 1995. – № 5–6. – Б. 36–40.

Җырга гашыйк галим [Н. Хисамов белән әңгәмә] // Ватаным Татарстан. – 1995. – 14 апр.

Төрдәшләр ничек ясала? (Урта гасыр шигъриятендәге бер сюжет мисалында) // Мирас. – 1995. – № 7–8. – Б. 49–51.

Шәмдәлләрдә генә утлар яна [Композитор Сара Садыйкованы искә алу: Г. Зәйнәшева, Ә. Баян, Н. Хисамов һ.б. / язып алды Н. Акмал] // Мәдәни җомга. – 1995. – 17 нояб.

Газиз мирасыбыз [Финляндиядә яшәүче шагыйрә Гәүһәр Туганай турында] // Мирас. – 1996. – № 1. – Б. 90.

Бәла урынына хафа кирәкмәс // Ватаным Татарстан. – 1996. – 26 гыйнв.

Утыз Имәни – «Кыйссаи Йосыф» текстологы // Мирас. – 1996. – № 1–2. – Б. 68–69.

Төрки «Йосыф-Зөләйхә»ләр арасында Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы (Урта гасыр татар-төрек әдәби бәйләнешләре) // Zaman-Татарстан. – 1996. – 23 фев.

Әдәби мирасны бәяләүдә гадел булыйк (Ф. Мусин, М. Гайнетдинов, Н. Хисамов, Н. Ханзафаров чыгышлары) // Мәдәни җомга. – 1996. – 16 февр.

Тамырлар [Шигърият турында уйланулар] // Мәгърифәт. – 1996. – 29 март.

Зәңгәр күзле Бизнә егете [Әдәбият галиме Шәйхи Садретдиновны искә алу] // Мәгърифәт. – 1996. – 7 июнь.

Намус белән әдәп бергәме? // Ватаным Татарстан. – 1996. – 26 июнь.

Илаһи моң (Рөстәм Яхинга бәйләнешле истәлекләр) // Ватаным Татарстан. – 1996. – 21 авг.

Тукайның шигъри фикерләвендә шәркый сурәтләр // Ватаным Татарстан. – 1996. – 20 сент.

Татарлар да төрки дөнья бизәге [Татар галимнәренең Төркия президенты С. Дәмирәл белән очрашулары турында] // Zaman-Татарстан. – 1996. – 11 окт.

XIV йөз шигъриятендә кеше идеалы // Казан утлары. – 1997. – № 3. – Б. 157–171.

«Йусуф и Зелиха» Шаййада Хамзы – перенесенный на аруз «Кысса-и Йусуф» Кул Али // Языки, духовная культура и история тюрок: традиции и современность» (Казань. 9–13 июня 1992): в 3-х том.: тр. междунар. конф. – М.: Инсан, 1997. Т. 2. – С. 78–80.

Фикер һәм хис дөньясыннан лирик репортаж [Шагыйрь Ренат Харис лирикасы турында] // Zaman-Татарстан. – 1997. – 28 март.

Тукайның шигъри фикерләвендә шәркый сурәтләр // Тукай и духовная культура XX века: мат-лы науч. конф., посв. 110-летию со дня рожд. Тукая. – Казань, 1997. – Б. 69–72.

Базар һәм шагыйрь [Шагыйрь Ренат Харис иҗаты турында] // Ватаным Татарстан. – 1997. – 16 май.

Нәселдәге зыялылык югалмый, кайсыдыр бер буында бәреп чыга [Н. Хисамов белән Р. Мөхәммәтова әңгәмәсе] // Сабантуй. – 1997. – 5 июль.

Авылым өметләре// Ватаным Татарстан. – 1997. – 31 авг.

Изге мирасыбыздан беренче карлыгач [Рец. кит.: Ал-Булгари Таджаддин. Большой тирйак (Большое противоядие) / издание текста, перевод с арабского, предисловие, комментарий А.Б. Халидова; научный редактор М.А. Усманов. – Казань, 1997. – 52 с] // Мәдәни җомга. – 1997. – 3 окт.

Йосыф-Зөләйха сюжеты (Чагыштырмалы ысул һәм аның нәтиҗәләре) // Татарстан. – 1997. – № 10. – Б. 77–80.

Илаһи моңга – илаһи яңгыраш [Татарстанның халык артисты Хәйдәр Бигичев турында] // Мәгърифәт. – 1997. – 1 нояб.

Бу дөнья изге ат белән хуш ул... [Котбның тууына 700 ел тулу уңае белән] // Мәдәни җомга. – 1997. – 21 нояб.

Академик М.З. Зәкиев һәм халкыбызның милли яңарышы // Академик Мирфатых Закиев: К 70-летию со дня рождения / редакторы-составители: Ф.И. Урманче, доктор филологических наук, профессор Х.Ш. Махмутов, доктор филологических наук, главный научный сотрудник. – М.: Инсан, 1998. – Б. 247–255.

Төрки-татар тарихының яңа сәхифәләре // Академик Мирфатых Закиев: К 70-летию со дня рождения / редакторы-составители: Ф.И. Урманче, доктор филологических наук, профессор Х.Ш. Махмутов, доктор филологических наук, главный научный сотрудник. – М.: Инсан, 1998. – Б. 367–375. (Х.Ш. Мәхмүтов, Ф.М. Хисамова, Ф.И. Урманче белән берлектә)

Ике канат – иман һәм гыйлем [Ф. Бәйрәмова, М. Шәмсетдинова, Н. Хисамов, Т. Галәүетдинова белән Р. Туфитуллова әңгәмәсе / язып алучы – Н. Шәйдуллина] // Сөембикә. – 1998. – № 1. – Б. 8–11.

Руханият дигән гыйлем бар // Мәдәни җомга. 1998. – 8 гыйн.

Халыкның ул үз сынына охшаган // Мәдәни җомга. – 1998. – 24 апр.

Аны тыңлау үзе бер бәхет иде [Татарстанның халык артисты Рәшит Ваһапов турында] // Шәһри Казан. – 1998. – 8 май.

Төрки-татар тарихының яна сәхифәләре // Ватаным Татарстан. – 1998. – 3 июнь. (Х. Мәхмүтов, Ф. Хисамова, Ф. Урманче белән берлектә)

Су төбендә асылташ, су тулкытсаң чыгадыр [Академик Мирфатыйх Зәкиевкә 70 яшь тулу уңае белән] // Мәдәни җомга. – 1998. – 2 окт.

Халыкның хәтер сагында [Язучы Нурихан Фәттахка 70 яшь тулу уңае белән] // Ватаным Татарстан. – 1998. – 4 дек.

Тирән елга тын ага [Н. Хисамов белән Р. Рахман әңгәмәсе] // Мәгърифәт. – 1998. – 5 дек.

Тукайның шигъри фикерләвендә шәркый сурәтләр // Тукаевские чтения = Тукай укулары / составитель Э.С. Вильданова. – Казань, 1999. – Вып. 1. – Б. 62–67.

Тирән хакыйкатьләр дөньясы [Шагыйрь Равил Фәйзуллин иҗаты турында] // Мәдәни җомга. – 1999. – 23 апр.

Мөбарәк тәсбихнең бер буыны [Әдәбият галиме Хатип Госман турында] // Казан утлары. – 1999. – № 6. – Б. 158–162.

Мирас һәм милли экология // Татарстан. – 1999. – № 8. – Б. 48–49.

Г. Таһирҗанов һәм аның Кол Галигә нәзыйрәсе // Мирас. – 1999. – № 9. – Б. 15.

Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул ‘Али // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.) / редколлегия: Абилов Ш.Ш., кандидат филологических наук, Асылгараев Ш.Н., кандидат филологических наук, Галимуллин Ф.Г., кандидат филологических наук, Махмутов Х. Ш., доктор филологических наук, Хисамов Н. Ш., доктор филологических наук; ру-

ководитель авторского коллектива и научный редактор Н.Ш. Хисамов. – Казань: Фэн, 1999. – С. 50–62.

Поэты XIV века Кутб, Хорезми, Хусам Кятиб, Сейф Сараи и социально-философская проблематика их произведений // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.) / редколлегия: Абилов Ш.Ш., кандидат филологических наук, Асылгараев Ш.Н., кандидат филологических наук, Галимуллин Ф.Г., кандидат филологических наук, Махмутов Х.Ш., доктор филологических наук, Хисамов Н.Ш., доктор филологических наук; руководитель авторского коллектива и научный редактор Н.Ш. Хисамов. – Казань: Фэн, 1999. – С. 73–91.

Роль взаимосвязей в средневековой литературе // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.) / редколлегия: Абилов Ш.Ш., кандидат филологических наук, Асылгараев Ш.Н., кандидат филологических наук, Галимуллин Ф. Г., кандидат филологических наук, Махмутов Х.Ш., доктор филологических наук, Хисамов Н.Ш., доктор филологических наук; руководитель авторского коллектива и научный редактор Н.Ш. Хисамов. – Казань: Фэн, 1999. – С. 224–229.

Тукай шигъриятендә һөҗү // Тукаевские чтения = Тукай укулары (Апрель 1999 г.): сб. ст. / составители: Э.С. Вильданова, Н.М. Гафиятуллина. – Казань, 2000. – Б. 57–65.

Остаз һәм дус [Фольклорчы-галим Илбарис Надировка 75 яшь тулу уңае белән] // Фәнни эзләнүләр юлында / редколлегия: Урманче Ф.И. (җитәкче), Асылгәрәев Ш.Н., Зәкиев И.М., Мәхмүтов Х.Ш. (мөхәррир-төзүче). – Казан: Фикер, 2000. – Б. 24–27.

XIII–XV гасыр төрки шигъриятендә Йосыф-Зөләйха сюжеты (Чагыштырмалы ысул һәм аның нәтиҗәләре) // Фәнни эзләнүләр юлында / редколлегия: Урманче Ф.И. (җитәкче), Асылгәрәев Ш.Н., Зәкиев И.М., Мәхмүтов Х.Ш. (мөхәррир-төзүче). – Казан: Фикер, 2000. – Б. 180–186.

Тамырлар кайдан килә? // Татарское возрождение. Эпоха и личности / Редколлегия Академик РАН и АНТ К.А. Валиев (главный редактор), доктор филологических наук Н.Ш. Хисамов (ответственный редактор), Ф.А. Табеев, академик РАН и АНТ А.И. Коновалов, член-корреспондент АНТ В.Н. Лихачев, доктор филологических наук Н.М. Валеев, доктор филологических наук Ф.М. Мусин, профессор Б.Ф. Султанбеков, член-корреспондент РАН и АНТ И.Б. Хайбуллин, доктор экономических наук Д.С. Хайруллов, И.Р. Каримов (ученый секретарь). – Казань: Фэн, 2000. – Б. 121–127.

Востоковедческие основы татарского литературоведения // Татарское возрождение. Эпоха и личности / редколлегия: академик РАН и АНТ К.А. Валиев (главный редактор), доктор филологических наук Н.Ш. Хисамов (ответственный редактор), Ф.А. Табеев, академик РАН

и АНТ А.И. Коновалов, член-корреспондент АНТ В.Н. Лихачев, доктор филологических наук Н.М. Валеев, доктор филологических наук Ф.М. Мусин, профессор Б.Ф. Султанбеков, член-корреспондент РАН и АНТ И.Б. Хайбуллин, доктор экономических наук Д.С. Хайруллов, И.Р. Каримов (ученый секретарь). – Казань: Фән, 2000. – С. 328–331.

Күңелдәге сурәт // Нил Юзеев шигъри җанлы акыл иясе / под общ. ред. д-ра филос. наук А.Н. Юзеева. – Казан: Мастер-Лайн, 2000. – Б. 118–126.

Халкыбызның шигъри юлдашы // Кол Гали. Йосыф кыйссасы / хәзерге әдәби телгә шигъри тәрҗемәне Нурмөхәммәт Хисамов эшләде. – Казан: Раннур, 2000. – Б. 5–14.

Тел дигән дәрья бар... [Н. Хисамов белән Ә. Сафиуллин әңгәмәсе] // Ватаным Татарстан. – 2000. – 4 март.

Безнең ханымнар, безнең сеңелләр // Сөембикә. – 2000. – № 3. – Б. 47.

Коеп куйган шагыйрь [Сәгыйть Рәмиевнең тууына 120 ел тулу уңае белән] // Ватаным Татарстан. – 2000. – 7 апр.

Безнең фольклор фәне һәркайда хөрмәтле булды [Фольклорчы Илбарис Надиров белән Н. Хисамов әңгәмәсе] // Мәдәни җомга. – 2000. – 14 апр.

Тамырлар тирәннән килә... [Академик Мансур Хәсәновка 70 яшь тулу уңае белән] // Мәдәни җомга. – 2000. – 23 июнь.

Тарихи төгәл, шигъри гүзәл // Мәдәни җомга. – 2000. – 15 сент.

Кунакчыл Төркия галимнәрне җыя // Мәдәни җомга. – 2000. – 17 нояб.

Персидские источники поэмы «Кысса-и Йусуф» Кул ‘Али // Россия и Иран. Иранистика в Татарстане: сб. ст. – М.: ПАЛЕЯ-Мишин, 2001. – С. 197–200.

Шәймиев юллары // Татарстан. – 2001. – № 3. – Б. 20–21.

Дороги Шаймиева // Татарстан. – 2001. – № 3. – С. 20–21.

Тукай һәм Аурупа шигърияте // Мәдәни җомга. – 2001. – 20 апр.

Гүзәл җырлар әнкәсе [Композитор Сара Садыйкова турында] // Мәдәни җомга. – 2001. – 2 нояб.

В слове история народа // Казань. – 2001. – № 12. – С. 47–51. (в соавторстве Д. Нигматуллиной)

Тукай һәм Аурупа әдәбиятлары // Творчество Тукая в контексте евразийской культуры / редколлегия: Р.Г. Абузяров, Р.К. Ганиева, Х.Ю. Миннегулов, М.Т. Низамеев, З.З. Рамеев; ответственный редактор: Н.Ш. Хисамов: материалы конф. – Казань: Фикер, 2002. – Б. 108–113.

Литературное наследие как фактор этнокультурного единства нации // Единство татарской нации: мат-лы науч. конф. АН РТ «Цивилизованные, этнокультурные и политические аспекты единства татарской нации» (Казань, 7–8 июня 2002 г.). – Казань: Фэн, 2002. – С. 95–99.

Литературное наследие и единство нации // Татарстан. – 2002. – № 8–9. – С. 104–105.

Чабаталы чорда югалмаган Татарстанлы чорда югалмас // Мәдәни җомга. – 2002. – 11 окт.

Галимнәр иҗатында милләт гаме // Мәдәни җомга. – 2002. – 1 нояб.

Татар әдәбияты тарихында Казан ханлыгы чоры шигърияте // Татар халкы 1552 елдан соң: югалтулар һәм табышлар (Казан шәһәре, 2002 елның 4 октябре): фән.-гамәли конф. мат.-ры. – Казан, 2003. – Б. 52–60.

Казан ханлыгында шигърият // Идел. – 2003. –№ 2. – Б. 24–26.

Татарский мир и двенадцать столетий татарской литературы // Татарский мир = Татар дөньясы. – 2003. – Апр. (№ 7).

Өч халыкның өч шагыйре (Кол Гали, Әхмәди, Дүрбәк) // Казан утлары. – 2003. – № 5. – Б. 141–149.

Үлемсез сюжет // Татарстан. – 2003. – № 6. – Б. 47–49.

Благодатный и прекрасный сюжет: три поэта трех народов (770 лет поэме Кул Гали) // Татарстан. – 2003. – № 6. – С. 46–49.

«Кыйссаи Йосыф»та угыз эпосы мотивлары // Мәдәни җомга. – 2003. – 16 май.

Фидакарь хадим [Фольклорчы Хуҗи Мәхмүтов турында] // Ватаным Татарстан. – 2003. – 14 февр.

Җәүһәрче [Фольклорчы-галим Хуҗи Мәхмүтовка 75 яшь тулу уңае белән] // Фәнни Татарстан. – 2003. – № 2. – Б. 79–80. (Ф. Урманче белән берлектә)

Исхакый мирасы илгә кайта // Мәдәни җомга. – 2003. – 19 апр.

Исхакый мирасы илгә кайта // Ватаным Татарстан. – 2003. – 19 апр.

Без беренче чиратта фәнни сафларны яшәртергә бурычлы [Н. Хисамов белән Г. Морат әңгәмәсе] // Мәдәни җомга. – 2003. – 14 март.

Күңел тирәнлеге [Язучы Зиннур Мансуров иҗаты турында] // Шәһри Казан. – 2003. – 11 апр.

Шагыйрьнең публицистикасы [Шагыйрь Әхмәт Рәшитов публицистикасы турында] // Мәйдан. – 2003. – № 4. – Б. 205–206.

«Кыйссаи Йосыф»та угыз мотивлары // Мәдәни җомга. – 2003. – 16 май.

Каһарман чат, онытылмас кеше [Әдәбият галиме Мөхәммәт Гайнуллинның тууына 100 ел тулу уңае белән] // Мәдәни җомга. – 2003. – 19 сент.

Тукайга якынаю [Рец. кит.: Габдулла Тукай. Стихотворения и поэмы. Автобиографическая проза / переводчик и составитель В.С. Валиева. – М.: Инсан, 2002. – 160 с] // Мәдәни җомга. – 2003. – 14 нояб.

Дердменд (1859–1921) // История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX века) / руководитель авторского коллектива и

научный руководитель Г.М. Халитов; редколлегия: Н.Ш. Хисамов (ответственный редактор), Р.Ф. Исламов, Ф.М. Мусин, З.З. Рәмиев. – Казань: Фикер, 2003. – С. 301–315.

Илаһи моң // Рустем Яхин в воспоминаниях современников: 2-е изд., допол. / составитель-редактор Ф.И. Хасанова. – Казань, 2004. – Б. 217–221.

Фольклор фәнендә Хәмит Ярми мәктәбе // Татар фольклоры мәсьәләләре. Күренекле галим-фольклорчы Хәмит Ярминең 100 еллыгына багышлана / редколлегия: Х.Ш. Мәхмүтов, К.М. Миңнуллин, Ф.И. Урманче, Н.Ш. Хисамов. Төзүче һәм мөхәррир: И.Г. Закирова. – Казан: Фикер, 2004. – Б. 4–5.

Некоторые аспекты концепции истории татарской литературы (опыт прошлого – под углом нового мышления) // Проблемы развития татарской нации (языковой, литературно-фольклорный и искусствоведческие аспекты) / ответственный редактор Н.Ш. Хисамов; редколлегия: М.Г. Арсланов, Р.З. Закиров, М.З. Закиев, Ш.Н. Асылгараев, Р.Ф. Исламов (составитель), Ф.И. Урманчеев. – Казань: Изд-во «Фән» Академии наук РТ. – 2004. – С. 10–13.

Казан ханлыгында шигърият // Инсани фәннәр: эзләнүләр һәм табышлар: ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының 2002 һәм 2003 еллар өчен еллык фәнни конф. материаллары / җаваплы мөхәррир – Н.Ш. Хисамов; редакцион коллегия: М.Г. Арсланов, Ф.А. Ганиев, М.З. Зәкиев, Р.Ф. Исламов, Д.Э. Нигъмәтуллина (төзүче), Ф.И. Урманчеев, З.Р. Шәйхисламов. – Казан: Фикер, 2004. – Б. 226–232.

Исемең матур, кемнәр куйган // Мәдәни җомга. 2004. – 30 гыйнв.; – 6 февр.

Кем гаепле? // Мәдәни җомга. – 2004. – 19 март.

Нинди гамьнәр шагыйрь күңелендә? [Шагыйрь Роберт Миңнуллин турында] // Мәдәни җомга. – 2004. – 8 окт.

Введение // История татарской литературы средневековья (XIII–XVIII вв.) / руководитель авторского коллектива и научный редактор Н.Ш. Хисамов; редколлегия: Ф.Г. Галимуллин, Ф.М. Мусин, Р.Ф. Исламов, Х.Ш. Махмутов, З.Р. Шайхисламов, Н.Ш. Хисамов. – Казань, 2005. – С. 3–13.

Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул ‘Али // История татарской литературы средневековья (XIII–XVIII вв.) / руководитель авторского коллектива и научный редактор Н.Ш. Хисамов; редколлегия: Ф.Г. Галимуллин, Ф.М. Мусин, Р.Ф. Исламов, Х.Ш. Махмутов, З.Р. Шайхисламов, Н.Ш. Хисамов. – Казань, 2005. – С. 92–110.

Поэты XIV века Кутб, Хорезми, Хусам Кятиб, Сейф Сараи и социально-философская проблематика их творчества // История татарской литературы средневековья (XIII–XVIII вв.) / руководитель авторского

коллектива и научный редактор Н.Ш. Хисамов; редколлегия: Ф.Г. Галимуллин, Ф.М. Мусин, Р.Ф. Исламов, Х.Ш. Махмутов, З.Р. Шайхисламов, Н.Ш. Хисамов. – Казань, 2005. – С. 125–150.

Роль взаимосвязей в средневековой литературе // История татарской литературы средневековья (XIII–XVIII вв.) / руководитель авторского коллектива и научный редактор Н.Ш. Хисамов; редколлегия: Ф.Г. Галимуллин, Ф.М. Мусин, Р.Ф. Исламов, Х.Ш. Махмутов, З.Р. Шайхисламов, Н.Ш. Хисамов. – Казань, 2005. – С. 338–345.

Заключение // История татарской литературы средневековья (XIII–XVIII вв.) / руководитель авторского коллектива и научный редактор Н.Ш. Хисамов; редколлегия: Ф.Г. Галимуллин, Ф.М. Мусин, Р.Ф. Исламов, Х.Ш. Махмутов, З.Р. Шайхисламов, Н.Ш. Хисамов. – Казань, 2005. – С. 346–348.

Дәрдемәнд (1859–1921) // Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): биобиблиографик сүзлек / фәнни редактор: Зөфәр Рәмиев, филология фәннәре докторы. – Казан, 2005. – Б. 80–82.

Всё ближе к Тукаю // Тукай Г. Избранное / перевод с татарского В.С. Думаевой-Валиевой. – Казань: Магариф, 2006. – С. 229–235.

Кул Гали и его поэма «Кысса-и Йусуф» // История татар с древнейших времен в семи томах. – Т. 2. Волжская Булгария и Великая Степь. – Казань: «Рух Ил», 2006. – С. 583–587.

Шигърияттә Тукай феномены // Казан утлары. – 2006. – № 4. – Б. 11–15.

Шигърияттә Тукай феномены // Тукай Г. Сайланма әсәрләр: ике томда / томны төзүчеләр: Нурмөхәммәт Хисамов, Зөфәр Мөхәммәтшин; искәрмәләр һәм аңлатмаларны әзерләүче Марсель Әхмәтҗанов; җаваплы мөхәррир Нурмөхәммәт Хисамов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 1 т. Шигырьләр, поэмалар. – Б. 7–14.

Кем ул нәкышче? // Мәдәни җомга. – 2006. – 10 март.

Тукай: величие и трагедия // Татарстан. – 2006. – № 4. – С 37–39.

Величие и трагедия поэта // Татарские новости. – 2006. – № 6 (143).

Почему молчит честь // Звезда Поволжья. – 2006. – 3–9 августа.

Кол Галигә беренче нәзыйрә // Мәдәни җомга. – 2006. – 4 авг.

Эпоха, в которую мы живем // Татарстан. – 2006. – № 8. – С. 6–7.

Узган юлларга күз салсак... [Н.Ш. Хисамов белән Г. Морат әңгәмәсе] // Мәдәни җомга. – 2006. – 25 авг.

Фольклор фәнендә Урманчеев мәктәбе // Урманчеев Ф. Каһарманнар йолдызлыгы. Тарихи-фольклористик очерклар / редколлегия: филология фәннәре докторлары, профессорлар Х.Ш. Мәхмүтов (төзүче-мөхәррир), К.М. Миңнуллин, Н.Ш. Хисамов. – Казан: Дом печати, 2006. – Б. 3–4.

### в) Н. Хисамовның үзе турында

Ахунов Г. Галимнең гаилә бәхете [Н. Хисамовка 60 яшь тулу уңае белән] / Г. Ахунов // Мәдәни җомга. – 1997. – 30 май.

Әхмәтҗанов М.И. Мирасханә: фонд һәм коллекцияләр күрсәткече / М.И. Әхмәтҗанов. – Казан, 2005. – Б. 79, 105, 106.

Вәлиев М. Колач һәм тирәнлек / М. Вәлиев // Хисамов Н.Ш. Хәтер сагында: әдәби-фәнни мәкаләләр, иҗат портретлары һәм публицистика / Н.Ш. Хисамов. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 613–618.

Галимуллин Ф. Казан яндин бер гаҗәеб нул калыкдый / Ф. Галимуллин // Мирас. – 1995. – № 11–12. – Б. 103–109.

Гариф Р. Шагыйрь җанлы фән докторы / Р. Гариф // Zaman-Татарстан. – 1996. – 27 дек.

Зәйдуллин Р. Кол Гали – юлда / Р. Зәйдуллин // Яшь ленинчы. – 1987. – 25 март.

Каримуллин А.Г., Каримуллин Ш. А. Указатель авторефератов и диссертаций по татарской филологии по состоянию на 1998 год / А.Г. Каримуллин, Ш. А. Каримуллин. – Казань: Фикер, 2000. – С. 92, 122.

Надиров И. Галим, шагыйрь, шәхес [Н. Хисамовка 60 яшь тулу уңае белән] / И. Надиров // Ватаным Татарстан. – 1997. – 30 май.

Нурмөхәммәт Хисамов // Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә / Редакцион коллегия: Т. Миңнуллин, Ф. Миңнуллин, Ә. Кәримуллин, С. Хәким, Г. Шәрәфетдинов, Н. Юзиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б. 500.

Нурмөхәммәт Хисамов // Даутов Р.Н., Гамбәров Н.Г. Балачак әдипләре: биобиблиографик белешмәлек. – Казан: Мәгариф, 2005. – Өченче кит. – Б. 302–312.

Рәшитов Ә. Мирас / Ә. Рәшитов // Соц. Татарстан. – 1987. – 24 март.

Ягъфәров Р. Исәнме, яңа доктор! / Р. Ягъфәров // Шәһри Казан. – 1996. – 27 дек.



*«Күпкырлы фәнни эшчәнлеге һәм ирешкән дәрәҗәләренә карамастан, Фәһимә Миргали кызы, иң беренче чиратта, искиткеч саф күңелле Шәхес булып кала. Фәнни казанышлары турында сөйләгәндә, ул һәрвакыт үзенең остазы – күренекле тел галиме, профессор Д.Г. Тумашеваны искә ала, аның якты истәлеге алдында баш ия».*

Искәндәр Гыйләҗев

*«Фәһимә ханым һаман да яшьләрчә якты итеп елмая, хезмәттәшләре белән дә, дуслары белән дә һәрчакта да итагатьле-сөйкемле, эчкерсез-мөлаем».*

Илида Бәширова

*«Фәһимә Миргали кызы әле дә эзләнүдә. Ул әле дә телнең үткәне, хәзергесе, киләчәге өчен җан атып яши. Аның һәр сүзендә, һәр хәрәкәтендә үз эшенә чын күңелдән бирелгәнлек, яңалыкка омтылыш сизелә».*

Гөлназ Гайнуллина

# ФӘҺИМӘ ХИСАМОВА ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ

## ГАЛИМ, ОСТАЗ, ШӘХЕС

Ә. Еники үзенең бер мәкаләсендә болай дип яза: «Мин борынгы зыялыларны күреп калган кеше. Аларның бөтен нәрсәләрендә – үз-үзләрен тотуларында булсын, сөйләшүләрендә булсын, ниндидер бер мәдәнилек сизелеп тора иде. Бик чиста, пөхтә киенәләр. Зыялы кешенең тышкы кыяфәте генә түгел, күңеле дә матур булырга тиеш бит әле». Зыялылыклары белән аерылып торган, үзләренә күпләрне җәлеп иткән шәхесләр, килешерсез, бүгенге көндә дә юк түгел. Сүзебез бүгенге сирәк зыялыларның берсе, исеме җисеменә туры килгән Фәһимә Миргали кызы Хисамова хакында.

Фәһимә Миргалиевна – кабатланмас, эрудит шәхес. Андый шәхес белән таныш булу – үзе бер бәхет. Хәтердә Фәһимә апа белән беренче очрашу мизгелләре яңара. Сүзен кыска тота торган һәм үтә дә таләпчән булып күз алдына килгән профессор бөтенләй башкача булып чыкты! Ике сәгатькә сузылган күрешүдә тема да ачыкланды, эшнең төзелеше дә билгеләнде, хәтта тормыш нечкәлекләре турында да сөйләшергә вакыт калган. Ул вакытта Фәһимә апа грамматиканың үзе кебек ифрат та төзек җөмләләре, каядыр яшерелгән таләпчәнлеге белән дә үзенә җәлеп итте. Фәһимә Миргалиевна безгә – укучыларына төпле киңәш, дөрес юнәлеш биреп, гыйльми иҗат ирегенә дә урын калдыра, ләкин шул ук вакытта эшнең нәтиҗәле, системалы булуын да таләп итә белә.

Фәһимә Миргали кызы Хисамова – беренче чиратта, татар тел белеме фәнендә үз урынын тапкан күренекле галим. 1971 елда

Д.Г. Тумашева җитәкчелегендә «Хәзерге татар әдәби телендә сыйфат фигыль» дигән темага язылган кандидатлык диссертациясен уңышлы яклый. 1995 елда исә «Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности XVI – I половины XIX в.» дип аталган докторлык диссертациясе дә югары бәяләнә, бераздан «Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – начало XIX вв.) (2012) монографиясе дә дөнья күрә. Күпсанлы архивларда гарәп графикасындагы кулъязмаларны табып, укып, аларның күчермәләрен алып тикшеренүләр үткәрү нәтиҗәсендә Ф. Хисамова, беренчеләрдән булып, татар теле рус дәүләтендә дипломатия теле буларак 2–3 гасыр кулланылышта була, дигән нәтиҗәгә килә.

Фәһимә Миргали кызы Хисамова – татар филологиясендә беренче фән докторы, Казан университетының иң беренче хатын-кыз деканы, татар хатын-кызларыннан иң беренче булып академик дәрәҗәсенә ирешкән күренекле тюрколог Диләрә Гариф кызы Тумашеваның шәкерте, остазының лаеклы дәвамчысы. Фәһимә Миргали кызы фәнни-тикшеренү эшләренә юнәлеш биргән, морфология фәненә кызыксыну уяткан, грамматик категорияләрнең хасиятен төшендергән фәнни җитәкчесен ихтирам белән искә ала.

2011 елда журналистларга биргән бер интервьюсында Фәһимә Хисамова: «Безнең бурыч – телебез бик борынгыдан алып бүгенге көнгә кадәр нинди үзгәрешләр кичергәнлеген барлап, тарихи грамматиканы эшләү» – дигән иде. Әйтергә кирәк, галимә бу юнәлештә дә үзеннән саллы өлеш кертте. Аның «Татар теленең тарихи грамматикасы. Фонетика. Морфология» исемле яңа фундаменталь хезмәте бик күп галимнәрнең өстәл китабы булачагына шигебез юк.

Галимәбезнең фәнни тикшеренү өлкәләренең, хәтта борчыган өлкәләренең берсе – татар теленең графикасы һәм орфографиясе. Латин язуының зарурлыгын фәнни дәлилләп, «Татар теле: латин әлифбасына кайтуның фәнни нигезләре» (2004) хезмәтен татар һәм рус телләрендә бастырып чыгарды.

Фәһимә Миргалиевна татар телендә чыга торган газета-журнал битләрендә, радио-телевидение сөйләмендә, Интернетта тел кимчелекләренең, һәртөрле хаталарның күп булуына игътибар итә. Шул нисбәттән телебезнең грамматик төзелеше өлкәсендәге кимчелекләрне, сөйләм нормасын бозу очракларын искәртеп, редакция хезмәткәрләре, язучылар алдында чыгышлар ясый, мәка-

ләләр бастыра: «Телебез төзек һәм матур булсын» (1985), «Көндәлек матбугатта тел культурасы» (2005), «Вакытлы матбугатта тел культурасы мәсьәләләре» (2005), «Ана теле һәм милли матбугат» (2014) һ.б.

Фәһимә Миргалиевнаның мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп укучылары, тәрбиячеләре, укытучылары өчен төзелгән методик хезмәтләре дә фәнни-педагогик җәмәгатьчелек арасында лаеклы урынын тапты. «Татар теле өйрәнә нәниләр. Балалар бакчалары тәрбиячеләренә кулланма»сы (автордашы Р.А. Борһанова; 2005) тәрбиячеләр өчен әле дә өстәл китабы ролен үти.

Фәһимә Миргали кызы төрле тип белем бирү учреждениеәрендә укучылар өчен туган тел дәреслекләре төзүдә дә катнаша. Моннан тыш, «Казан утлары» журналында 1989–1990 елларда аның «Татар теле дәресләре» дигән мәкаләләр циклы да басыла һәм даими укучысын таба.

Фәһимә Миргали кызы Хисамованың хезмәт юлы Казан дәүләт университеты белән бәйле. Ул күп еллар татар теле кафедрасында эшли, аның мөдире булып тора, татар теле морфологиясе, тел тарихы, тарихи грамматика, фонетика буенча лекцияләр укый, иске татар теле, язма истәлекләрнең текстологиясе һәм тел үзенчәлекләре фәннәре буенча гамәли дәресләр, махсус курслар алып бара. Галимәнең бу юнәлештәге эшчәнлеге төрле программалар, вуз дәреслекләре, методик кулланмалары төзү белән үрелеп бара. Ф.М. Хисамова – «Татар теле морфологиясеннән күнегүләр җыентыгы» (1973), «Хәзерге татар теле. Морфология (студентлар өчен методик әсбап) (1981), «Хәзерге татар теле фонетикасы. Студентлар өчен лекцияләр һәм методик күрсәтмәләр» (1981) авторы, күпсанлы программаларның редакторы да була.

2006 елда Фәһимә Миргали кызының татар теле морфологиясе өлкәсендәге күп еллык эзләнүләренең нәтиҗәсе буларак «Татар теле морфологиясе» дәреслеге дөнья күрде. Әлеге хезмәт турында М.З. Зәкиев болай дип яза: «Бу татар теленең морфологик системасын логик эзлеклелектә ачып бирә торган беренче дәреслек булачак». Хезмәттә морфология, аның өйрәнү объекты, морфемика, сүз ясалышы, сүз төркемнәре һәм аларның грамматик категорияләре турында фәнни яктан төгәл мәгълүмат бирелә. Дәреслектә һәр грамматик күренеш җентекле анализлана, теге яки

бу төшенчә белән бәйле бәхәсле фикерләр, карашлар төрлелеге китерелә, автор аларга үз мөнәсәбәтен җиткерә. Хезмәттә белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм морфологик анализ үрнәкләре дә бирелә. Шул рәвешле, биредә Фәһимә Миргали кызының фәнни һәм педагогик тәҗрибәсе кушылып, югары дәрәҗәдә эшләнгән хезмәт барлыкка килә. 2015 елда дәреслек яңадан бастырыла.

Тынгысыз галимә телнең үткәне турында гына түгел, киләчәге турында да уйлана. Халыкара тюркологик конференцияләрнең берсендә ул: «Билгеле инде телнең төзелешен, үзенчәлеген өйрәнү тукталып тормаячак. Моңа кадәр без күбрәк телнең тышкы ягын – структур юнәлешен өйрәндек. Менә хәзер эчтәлек ягы алга чыга: телнең нәкъ үзенең, һәр милли телнең хосусиятен чагылдыра торган һәр кушымчаның, һәр сүз кисәгенең үз мәгънәсе бар һәм аларның сөйләмдә урнашуы тәртибе һәр телдә үзенчәлекле. Хәзер телне өйрәнүдә менә шушы функциональ-тематик юнәлешкә күчү бик әһәмиятле», – дип, тел белеменең киләчәктә үсеш-үзгәреш юлларын, юнәлешләрен дә билгели.

Ф. Хисамованың бөтен хезмәт юлы, фәнни эшчәнлеге студентларга белем бирү белән тыгыз бәйләнгән. Аның һәр дәресе – үзе бер ачыш. Лектор, студентларның игътибарын җәлеп итеп, әллә нинди катлаулы материалны да кызыклы, үтемле итеп җиткерә, конкрет мисаллар белән дәлилли. Сөйләгәннәре хәтергә уелып кала. Фәһимә Миргали кызының хезмәттәшләре һәм шәкертләре килешер, ул үзенең лекцияләрендә дә логик эзлеклелеккә зур игътибар бирә, укучыларын да шуңа өйрәтә иде. Бу сыйфаты аның югарыда аталган хезмәтләрендә дә чагылыш таба.

Фәһимә апа – татар халкы, татар милләте, татар теле өчен җан атып йөргән милләтпәрвәр затларның берсе. «Азатлык» радиосына биргән бер әңгәмәсендә ул: «Татар теле беренче чиратта ул шәхеснең үзенә кирәк. Шул тел аша балаларыбыз рухи һәм җан байлыгы ала, ул шуның аша күңелен баета, туган теле аша уйлый. Татарча белеп үскән бала рухы бай була», – ди. Фәһимә апа белән Нурмөхәммәт абыйның өч баласы да, дәрвишләр бистәсенә йөреп, татар мәктәбендә белем ала.

Фәһимә Миргали кызы Хисамова җитәкчелегендә күпсанлы кандидатлык диссертацияләре яклаңды: Р.Т. Йөзмөхәммәтов (2002), Г.Ф. Гарипова (2003), Р.Ш. Хөрмәтуллина (2004), Ф.М. Мө-

хәммәтшин (2007), В.Р. Фәхретдинова (2007), Л.Р. Садыйкова (2010), М.Р. Сәйхунов (2010), Л.А. Хисамоваларның (2010) эзләнүләре татар теле һәм, гомумән, төрки тел белеменең төрле мәсьәләләрен өйрәнүгә лаеклы өлеш керттеләр.

Фәһимә Миргали кызы – тормышта да олы җанлы, киң күңелле, шәфкатьле, башкаларның эчке халәтен бик тә нечкә тоемлый торган сизгер җанлы, шул ук вакытта гаҗәеп гади кеше. Укучыларына ул һәрвакыт хөрмәт белән карый, хәлләрен сораша, тормышлары, укулары һәм эшләре белән кызыксына. Урынлы киңәшләрен биреп, шәкертләрен тирән фикер йөртергә өйрәтә.

Безгә – Фәһимә апаның шәкертләренә – аларның тыйнак фатирларында булырга туры килгәне бар. Аларның өенә килеп керүгә, ниндидер яктылык бөркелә. Фәһимә апа белән Нурмөхәммәт абый җылы һәм ягымлы каршы алалар. Стена тулы картиналар, шәмаилләр, китап киштәләре күзгә ташлана. Мәһабәт гәүдәле Нурмөхәммәт абый үзенең баритон тавышы белән сихри бер дөньяга алып кереп китә: туган ягы, туган туфрагы, әти-әниләре турында сөйли. Сизмәстән генә әдәбият дөньясына, аннары төрле тарихи, фәлсәфи, дөньяви мәсьәләләргә «чумганыңны» сизми дә каласың. Җор телле Нурмөхәммәт абый шул арада комплиментлар да әйтеп куярга өлгерә: «Кызлар, сезгә бәхет килешә-ә-ә», – ди. Бу вакытта татар хатын-кызларына хас булган тыйнаклык белән Фәһимә апа, тормыш иптәшенең сүзен бүлдермичә, ахыргача тыңлап тора, аннары, безнең соравыбыз буенча, уллары ясаган рәсемнәрне күрсәтеп, аларны язу тарихын сөйли башлый. Аның һәр сүзендә улларына карата мәхәббәт, алар белән горурлану сизелә.

Фәһимә Миргали кызы әле дә эзләнүдә. Ул әле дә телнең үткәне, хәзергесе, киләчәге өчен җан атып яши. Аның һәр сүзендә, һәр хәрәкәтендә үз эшенә чын күңелдән бирелгәнлек, яңалыкка омтылыш сизелә.

Хөрмәтле остазыбыз Фәһимә Миргалиевна! Сезне гомер бәйрәмегез – юбилеегыз белән котлыйбыз. Без, укучыларыгыз, Сезгә биргән белемнәрегез, киңәшләрегез өчен рәхмәтле. Тормыш юлыгыз үзегез теләгәнчә матур һәм көйле барсын!

*Г.Ф. Гайнуллина,*
*В.Р. Гафарова.*
*2016*

## ТАУ КЫЗЫ

Казан шәһәрен еш кына диңгезгә охшатып була: бер карасаң, ярсулы-тынгысыз, икенче вакытта тыныч, биниһая булуы өстенә, ул әле бик күп елга-инеш суларын – кеше язмышларын да үзенә җыя. Әлеге инеш-сулар диңгезгә төрле яклардан килеп кушылалар: менә Буа үзәннәренең чая һәм искиткеч тырыш холыклы елгалары, менә тыңгысыз, тиктормас Казан арты инешләре; челтерәп кенә аккан тавышлы Зәй, Мөслим сулары... Таулы яклардан да агып килә инеш-язмышлар. Кавказ таулары кебек мәгърур, күз карашы җитмәслек биек булмасалар да, Татарстанның көнчыгышында үзләренә генә хас холыклы тыныч-горур таулар бар. Шул биеклекләрнең, җилдә талгын гына чайкалып утырган кылганнарның сәламнәрен Казан диңгезенә Ютазы инешләре дә алып килә. Сүзебез Ютазының Кәрәкәшле авылында туып үскән һәм Казанга килеп төпләнгән Тау кызы турында барыр...

Игътибар иткәнегез бармы икән: Татарстанның таулы як кешеләре горур, ләкин тыныч холыклы, тормышта һәрвакыт ниндидер биеклеккә омтылып яшәүчән була. Казан дәүләт университетының татар теле кафедрасы профессоры Хисамова Фәһимә Миргалиевнаны чын мәгънәсендә Тау кызы дип атый алабыз. Таулар аны кечкенәдән сөеп үстергән, тынычлык, горурлык, салмаклык биргән, дөньяга таулар фәлсәфәсеннән чыгып карарга өйрәткән. Бала чагы сугыш елларына туры килсә дә, авырлыклар, ачлык-ялангачлык аша үтсә дә, Тау кызы киләчәккә өмет белән караган. Бүгенге болгавыр заманда, татар халкының мөстәкыйльлеккә булган өметләре какшаган бер вакытта да ул дөреслекнең җиңеп чыгарына ышана, латин графикасын гамәлгә кую өчен, фәнни эзләнүләр алып бара, китаплар чыгара... «Әй Фәһимә апа, булырмы икән соң ул?» дигән шикләнүләребезне кабул итми. «Булачак, һичшиксез, латин графикасы кулланышка керәчәк. Аның кирәклеген аңлата белергә генә кирәк», – ди ул. Чыннан да, Фәһимә Миргали кызының 2004 елда рус һәм татар телләрендә чыккан «Татар теле: латин әлифбасына кайтуның фәнни нигезләре» хезмәтен укып чыкканнан сон, латин графикасының кирәклегенә шик калмый. Аңлата белү – Фәһимә Миргалиевнаның иң төп сыйфатларының берсе. Аның искиткеч логик эзлеклелек белән сөйләвенә, фәнни нигезләүләрнең, дәлил-

ләрнең һәрберсенең үз урынында, үз вакытында тиешле тәртип белән бирелүенә таң калабыз, «Әй, кайчан без дә шулай сөйләргә өйрәнербез?» дип, остазыбызның һәр сүзен, җөмлә төзү, текст кору тәртибен күңелгә салып барабыз. Фәһимә Миргали кызы трибунадан чыгыш ясаганда тыңлаучылар арасында аның сөйләү логикасына, техникасына, тавышына көнләшмәгән кеше юктыр. Әлеге осталыкка өйрәнүнең серләрен сорагач, укытучыбыз тыйнак кына елмаеп куя да: «Тел тарихын белергә кирәк, – дип җавап кайтара. – Хәзерге татар теленең нечкәлекләрен белү бары аның тарихын аңлау аркылы гына мөмкин. Тел тарихын белмәгән галим хәзерге тел турында дөрес фикер йөртә алмый». Әйе, Фәһимә Миргали кызы – татар теле тарихы өлкәсендә күренекле галимнәребезнең берсе. «Хәзерге татар әдәби телендә сыйфат фигыль» дип аталган кандидатлык диссертациясен (1971) язганда ук, ул тел тарихын үзләштерергә кирәк икәнлеген тоеп, сиземләп ала, шуңа күрә алдагы елларда ике юнәлештә фәнни эзләнүләр алып бара: аның беренчесе хәзерге татар әдәби теленең грамматик структурасы белән бәйле булса, икенче юнәлеш – татар теленең тарихи грамматикасы. 1995 елда якланган һәм «Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности XVI – перв. пол. XIX в.» дип исемләнгән докторлык диссертациясе – төрле архивлардан гасырлар аша ут-янгыннардан сакланып калган тарихи документларны эзләп-табып, озак еллар буе җентекле өйрәнүнең нәтиҗәсе. Мондый хезмәтләр буш урында барлыкка килә алмый, чөнки реаль, фактик тарихи документ белән эш итү галимнән зур тәҗрибә һәм белем таләп итә, якланган фикер фаразый шәкелдә, гипотеза рәвешендә була алмый, һәрбер җөмлә ныклы дәлилләү көтә... Бу яссылыктан караганда, Фәһимә Миргали кызының ышандырып, эзлекле итеп сөйләү сәләте фәнни хезмәтләренең күп еллар дәвамында чарланган бер кыры икәнен тоярга була. Фәһимә Миргали кызының икенче төп сыйфаты – кешелеклелек. Ул – студентларның иң яраткан укытучысы, дисәм, ялгышмамын. Юк, кемдер уйлаганча, «икеле»ләр куймаган өчен генә түгел. Кайчакта Фәһимә Миргалиевна куйган «өчле» билгесе студентка кайберәүләр куйган «икеле»дән үтемлерәк тәэсир итә. «Әй, кызым, – дип эндәшә ул студентка. – Нишләп укымадың? Вакытың җитмәдеме? Әллә укыр урының, я китабың булмадымы?» Студент кызара, башын ия,

башка укытучылар алдында әйтә торган «Укыдым, укыдым мин, оныттым гына» дигән сүзләрне әйтергә теле әйләнми, чөнки аның укымаганлыгын Фәһимә апасы фаш итте инде: «Кызым, моны белмәсәң, менә бусын беләсеңдер, яле, сөйлә әле» – дип, программа буенча «куды». «Боларны белмәсәң, син бит ана телен рәнҗетәсең. Алга таба ничек укырсың, әниеңә нәрсә дип җавап бирерсең, кызым?» Шәһәргә укырга килгән авыл баласына, Аллага шөкер, авызыннан үз ризыгын өзеп җибәргән әнисе бик кадерле. Шуңа күрә Фәһимә апасының сүзләре дә Йагъкуб пәйгамбәрнең Йосыфка бармак янавы кебек тәэсир итә: студент кыз күңеленнән «Алла теләсә, имтиханнар беткәнче, дискотекага башка бармыйм, тырышам – укыйм», – дип ант итә, Фәһимә Миргалиевна янына икенче тапкыр килгәндә инде шактый әзерлекле килеш күренә...

Кайчагында безгә дә – Фәһимә Миргалиевна укыган лекцияләр буенча гамәли дәресләр алып баручы яшьрәк укытучыларга да – кызарырга туры килә. Җавап бирә алмый утырган студенттан безгә таба борылып, Фәһимә Миргалиевна тыныч кына сорап куя: «Бу кыз дәрес калдырмадымы соң?» Юк шул, калдырмады, дәрескә йөрү катгый куелгач, арттагы парталарда утырып, бер-ике тапкыр «SMS»калар белән тотылды тотылуын... Димәк, без – гамәли дәрес укытучылары – җитәрлек аңлатмаганбыз, нишләптер, студентны кызыксындыра белмәгәнбез, материалны төссез итеп биргәнбез. Юк, Фәһимә Миргалиевна боларны әйтми, тик менә шул тыныч тон белән сорап куюыннан әллә кайда эчтә нәрсәдер калтырый башлый, студент елларыннан иң дәһшәтле имтихан хәтердә яңара, шуңа күрә соралган материалны тизрәк йөгереп барып студент урынына сөйләп бирәсе килә башлый...

Менә имтихан тәмамланды... Кафедра бүлмәсенә төшкәч, Фәһимә Миргалиевнаның тормыштагы иң төп сыйфаты калкып чыга: кафедрада ул – Әни. Авырган вакытка туры килсә, бер карауда кәеф юклыгын чамалап ала да: «Әллә авырыйсың инде? Нинди дарулар эчәсең? Менә бу бик әйбәт дару, шуны эч әле», – дип, хәлне белешми калмый. Еш кына үзе дә бездән кием-салым турында киңәшләр сорый. Хәер, юкка: Фәһимә Миргалиевна үзе искиткеч нечкә зәвыклы ханым – алган киеменең һәрберсе үзенә үлчәп теккәндәй, килешле, яңа модалы, яхшы материалдан булыр. Иннекнең килешле төсен сайларга да, сумканың итеккә туры кил-

гәнен тотарга да, шарф яки яулыкны матур итеп бәйләргә дә әле без Әниебездән өйрәнәбез...

Татар теле кафедрасы укытучыларының күбесе хатын-кызлар. Аллага шөкер, һәрберебез диярлек Ана булу бәхетенә ирештек, һәрберебезгә балаларыбыз бик тә, бик тә кадерле. Шулай да чын мәгънәсендә «Балаларым!» дип яшәүче Фәһимә Миргалиевнадыр. Аның балаларын, оныкларын искә алмаган көне юк. Кафедрабызда улы Айдар ясаган картиналар эленеп тора, өстәлдә оныклары бүләк иткән фотолар. Килгән кунакларга «Боларны минем улым ясады!» дип әйтми калмый Фәһимә Миргалиевна. Күзләрендә горурлану, өзелеп ярату булыр...

Тантаналы кичәләрдә Фәһимә Миргалиевнаны тормыш иптәше – олы галим, танылган әдәбият белгече, филология фәннәре докторы Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Хисамов белән күрәбез. Озын буйлы, мәһабәт гәүдәле, гаять чибәр ир-ат белән янәшә шундый ук чибәр, искиткеч сөйкемле, мөлаем Фәһимә апабыз атлый. Күпләр аларның залдагы иң матур пар икәнен искәрәләр, бераз көнләшеп тә карыйлардыр әле. Шулай да бер үзенчәлек бар: Нурмөхәммәт абый янында Фәһимә апабыз һәрвакыттагыча матур, чибәр, ә менә Фәһимә апа янында Нурмөхәммәт абый тагы да яктырып, нурланып, сөйкемлеләнеп киткән кебек тоела...

...Казаннан еракта-еракта, Ютазы якларында таулар бар. Алар әле үзләренең итәкләреннән юа-эрем җыйган, иң биек үткелләргә үрмәләгән кызчыкны хәтерлиләрдер. Хәзер инде ул кызчык гыйлем дөньясында үзе таулар биеклегенә күтәрелде. «Тауга карап тау булып булмый», – дип әйтергә ярата татар халкы. Шулай да Фәһимә Миргалиевна ирешкән дәрәҗәләргә күтәрелү – күпләребезнең хыялы. Остазыбыз хатын-кыз буларак та, галим буларак та безнең өчен үрнәк булып тора.

Фәһимә Миргалиевна! Без Сезне олы бәйрәмегез белән котлыйбыз! Безнең йөрәкләрдән чыккан иң җылы хисләр Сезнең тормышыгызга ямь өстәсен, югарыга – тагы да зуррак биеклекләргә – өндәсен, иң самими һәм иң ихлас сүзләребез тынгысыз көннәрдә таяныч булсын иде. Без сезне бик яратабыз! Исәнлек-саулык һәм җан тынычлыгы насыйп булсын Сезгә!

*Татар теле кафедрасы укытучылары исеменнән*
*Халисә Ширмән, 2006*

# ЦЕННЫЙ ВКЛАД В ИЗУЧЕНИЕ ИСТОРИИ ТЮРКСКИХ ЯЗЫКОВ

(Рецензия на книгу: Хисамова Ф.М.
Татарский язык в восточной дипломатии России. –
Казань: Изд-во «Мастер-Лайн», 1999. – 401 с.)

История письменно-литературной традиции тюрко-татарского народа, как и история развития его государственности, уходит в глубокую древность. Первая письменная фиксация уже литературно обработанного древнетюркского языка состоялась в VI–VII веках, т.е. во времена Великого тюркского каганата.

Функционирование татарского языка в качестве государственного, уже не в общетюркском, а в региональном значении, также совпадает с этапами государственного развития татарского народа. Это – Булгарское государство, Золотая Орда и Казанское ханство. Данной социально-политической и культурно-исторической ситуацией было обусловлено появление официально-делового стиля татарского языка, который в течение ряда последующих веков выступал как язык межгосударственной дипломатии на Востоке.

После распада Золотой Орды и падения поволжских татарских ханств татарский язык в течение трех столетий служил Российской империи в качестве языка дипломатии в ее отношениях с Востоком. В архивных фондах Москвы, Санкт-Петербурга, Оренбурга, Махачкалы и других городов сохранились образцы дипломатических актов, административной переписки на татарском языке. Грамотами на этом языке снабжались русские посольства в таких странах, как Индия, Китай, Иран, Турция, Крым, среднеазиатские ханства и др.

Этот исторический феномен в функционировании татарского языка подробно и квалифицированно освещен в рецензируемой монографии профессора Ф.М. Хисамовой.

Значимость разработки ею проблем теории и истории литературных языков становится все более очевидной в свете тенденций современной лингвистики понять роль языка (и науки о языке) в различные эпохи цивилизации или более узко – понять взаимосвязь языка с историей и культурой того или иного этноса. От ра-

бот по истории литературного языка мы ждем ответа и на вопрос о типе такого языка, что способствовало бы пониманию типологии литературных языков, их сложения и функционирования. Наконец, введение в научный оборот новых письменных источников уже само по себе является важной научной задачей.

Все это мы имеем в рецензируемой монографии Ф.М. Хисамовой, где находим и концепцию литературного языка (в частности, типологический подход), и функциональное рассмотрение одной из ее разновидностей – языка деловой письменности – по отдельным синхронным срезам и на длительном историческом отрезке времени, и обширный свод памятников как объектов культурно-исторического и лингвотекстологического анализа. Несомненным достоинством работы является глобальный охват памятников деловой письменности – от истоков их зарождения и на протяжении трех веков, когда роль этой разновидности письменного татарского языка была особо значимой для развития литературного языка в целом.

Хотелось бы отметить, что работа Ф.М. Хисамовой органично вписывается в традиционно сильную и развитую область татарского языкознания – историю татарского языка. Представляется, что среди языков с длительной письменной традицией именно татарский язык являет собою наиболее исследованную и теоретически продвинутую область проблем, входящих в современное понимание истории литературного языка (в отличие от исторической грамматики и общей истории языка).

Прежде всего автор стояла перед сложной проблемой раскрытия истоков деловой письменности и разграничения собственно предыстории конкретного языка и письменных традиций, уходящих в древность и Средневековье. Известно, что XIII–XIV века были для тюркского мира эпохой сложения региональных языков, одним из которых был письменный язык Золотой Орды и ее культурных центров. В региональных языках, с одной стороны, отразились в той или иной степени старые письменные традиции (чаще всего древнеуйгурской и караханидской литератур), с другой – некое наддиалектное койне, о чем говорит и сама нормированность региональных языков, и общий комплекс их определенных структурных черт, которые больше усматривались в художественной литературе и во многом объяснялись особенностями средневековой литературы

с ее приверженностью к канонам, традициям, общим сюжетам и т.д. Реконструирование этих пластов (койне Золотой Орды и Казанского ханства) на основе письменных памятников XVI–XVIII веков позволило автору не сводить все к караханидской традиции, а увидеть более сложный процесс, характерный вообще для памятников делового письма в периоды определенных исторических сдвигов: на первоначальном этапе – относительная «пустота» письменного языка, близость его к общенародному языку, как правило, в маргинальных областях, где начинают зарождаться свои культурные и административные центры. В дальнейшем происходит стилистическое усложнение, стремление литературными стилитическими приемами превратить этот тип языка в одну из функциональных разновидностей литературного письменного языка в целом.

В книге Ф.М. Хисамовой весьма корректно поставлен вопрос о инодиалектных письменных традициях, которые четко локализованы и рассмотрены в свете историко-культурных условий эпохи. Обосновывается важная мысль о способности к адаптации делового языка на ареал и тип коммуникации.

Вывод автора о роли деловой письменности как ведущего стиля (особенно в ранний период XVI–XVII вв.) в развитии татарского литературного языка представляется важным для типологических выводов, конкретизации исторического процесса сложения татарского литературного языка, хотя можно предположить значимость других функциональных сфер, в частности религиозной литературы, начавшийся лингвистический и историко-культурный анализ которой уже вносит некоторые коррективы в соотношение ведущих факторов указанного процесса[1].

Подходы к исследованию объекта в книге определены и реализованы очень четко. Помимо вертикали – языковой и историко-культурной преемственности в развитии деловой письменности – прослеживается и соотношение по горизонтали, т.е. по синхронным срезам в той достаточно сложной системе состояния литературного языка каждого рассматриваемого среза. Автор опирается на уже имеющиеся в татарском языкознании исследования

---

[1] См.: *Зайнуллин Дж.Г.* Татарская богословская литература XVII – начала XIX века (на татарском языке). Казань, 1998.

в этой области. Вся функциональная парадигма татарского языка предстает в таком виде: диалекты, общенародный разговорный язык (общетатарское койне), устный литературный язык – обработанный вариант общетатарского койне, употреблявшийся в административной и правовой сферах, язык религиозных ритуалов; язык фольклора (прежде всего эпических произведений); письменно-литературный язык (классическая поэзия, художественная проза, исторические повествования, деловая письменность). Стратификация функциональных разновидностей языка представляет собой отдельную исследовательскую проблему. Однако стремление автора соотнести язык деловой письменности с языком художественной литературы и исторических источников выгодно отличает ее монографию от близких по тематике работ, с которыми нам пришлось ознакомиться в последние годы.

Этот аспект проблемы очень важен в свете отмечаемой исследователями смешанности старописьменного татарского языка. С нашей точки зрения, данный термин не очень корректен, поскольку в нем не учитываются характер нормы, степень ее широты для определенных историко-культурных и лингво-этнических условий, а также не разграничивается индивидуальное в памятнике от типологического (как социально-культурное явление). Поэтому нам понятна сдержанность автора в оценке этого явления в исследуемом ею пласте старотатарского литературного языка. Интересно, что в период XVI–XVII вв. дает для письменных памятников делового стиля достаточно умеренное вкрапление огузских черт, поскольку и для других ареалов этот период отмечен нарастающим влиянием норм обыденно разговорной речи на нормы письменного языка. Усиление огузского элемента в деловой письменности последующих эпох в монографии подвергается очень скрупулезному анализу, определяемому и хронологическими рамками, и типом документов. Думается, можно согласиться с общей идеей автора о том, что огузское влияние (вплоть до «южно-турецкого влияния» в конце XIX в.) в деловой письменности было связано с адаптацией этой разновидности письменного языка к ареалам и типом коммуникации. Однако, как кажется, реализация этой адаптации, ее внутриязыковая мотивация уходят своими корнями в глубокую древность периода огузо-кыпчакской этноисторической

общности. Так что, может быть, следует различать своего рода «регенерирование» прошлого языков и непосредственное влияние. Работа Ф.М. Хисамовой дает очень много интересного для понимания проблемы огузо-кыпчакской общности, которая в тюркологии выдвинута уже давно. И хотя это лишь часть ответа на указанную проблему, которая в целом еще ждет своего решения, идеи и наблюдения автора по ней, несомненно, повышают научную значимость работы в целом.

Следует отметить исследовательскую добросовестность и глубокий анализ, проделанные автором на обширном круге документов, прежде всего в процессе их выявления и обработки. Привлекает внимание тщательная фиксация географических особенностей документов, выделение стилеобразующих черт (особенно в сфере грамматики), анализ документов как единиц и типов текста с их определенной композицией, формульными элементами, клише и т.д.

Если суммировать наиболее важные составляющие монографии Ф.М. Хисамовой с точки зрения специалиста, занимающегося близкими вопросами, но на материале другого тюркского языка, с длительной письменной традицией, то можно сделать следующие выводы.

Весь комплекс дошедших до нас памятников деловой письменности на старотатарском языке исследован глобально. Это позволило уяснить, что уже в XVI в. существовала сформировавшаяся функциональная разновидность делового письма, которая в силу исторических причин стала приобретать статус языка международного общения. Эта роль складывалась как рефлекс традиций, заложенных еще в период Золотой Орды и Казанского ханства, и как следствие посреднической роли, связующего звена, которые выполняла образованная и деловая прослойка татарского общества уже в эпоху вхождения в состав России. Стилистическая ясность, «простота» делового письма XVI–XVIII вв., как нам представляется, были следствием этнической и языковой консолидации, наступившей после исторических потрясений, когда в становлении письменной разновидности татарского языка больше участвуют резервы его общеразговорного жанра, а более «низкие» жанры в меньшей степени реализуют в себе потенции собственно литературных процессов.

Исследование Ф.М. Хисамовой показывало, что татарское деловое письмо естественно развивалось в системе других разновидностей литературного языка, но широта коммуникативного назначения делала его нечто большим, чем это подразумевается в термине «деловая письменность». В последующие эпохи роль коммуникативно связующего звена делового письма возрастает, усиливается его способность к адаптации и язык деловой письменности получает вариативность, условно говоря – юго-западного и восточно-тюркского (чагатайского) характера. Вариативность тем самым получает ареальный характер, «смешанность», при кажущейся стихийности она все же имеет тенденцию к нормированности. В указанной ареальной адаптации языка деловой письменности очень важную роль играла арабская графика. Она в известной степени нивелировала фонетические особенности, которые наиболее сильно различали языки, образно выражаясь, того исторического котла, чем являлся в раннем Средневековье ареал Средней Азии и Поволжья.

Тематический круг деловых документов (дипломатические акты, жалованные грамоты, охранительные письма и т.д.) также был фактором, предопределявшим нормализацию языка деловой письменности. Наконец, морфология, синтаксис в памятниках делового письма обнаруживали системное сходство, которое продолжало грамматическую синонимию, выявляло функциональное сходство форм и т.д., что, может быть, можно рассматривать и как «смешанность», и как типологическое качество литературного языка в определенный исторический период его развития. В целом можно присоединиться к выводу автора о том, что проделанная ею работа подводит к следующему важному этапу – функциональному описанию старотатарского языка.

В целом следует отметить, что научная значимость работы Ф.М. Хисамовой не ограничивается лишь проблемами истории татарского литературного языка. Она актуальна и будет весьма полезна для исследования аналогичных проблем на материале других тюркских языков с длительной письменной традицией.

*Э.А. Грунина,*

*профессор кафедры тюркологии Института Азии и Африки МГУ.*

*2006*

## ТАТАРНЫҢ КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМӘСЕ

Казан дәүләт университеты татар филологиясе һәм тарихы факультетының хөрмәтле профессоры, филология фәннәре докторы Фәһимә Миргали кызы Хисамовага шушы көннәрдә 70 яшь тулды. Кадерле коллегабызны олугъ юбилее белән котлап, укучы игътибарына аның тормыш юлын һәм фәнни эшчәнлеген яктырткан сәхифәләрне тәкъдим итәбез. Фәһимә Хисамова Татарстан Республикасы Ютазы районының Кәрәкәшле авылында туган. Туган авылында урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университеты тарих һәм филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. 1960–1967 елларда Чүпрәле һәм Азнакай районы мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли.

1967 елда күренекле тел галиме профессор Д.Г. Тумашева сәләтле укытучыны күреп ала һәм татар теле кафедрасында аспирантура үтәргә чакыра. Аспирантураны тәмамлаганнан соң, яшь галимә татар теле кафедрасына ассистент итеп билгеләнә. 1971 елда «Хәзерге татар әдәби телендә сыйфат фигыльләр» дип аталган темага кандидатлык диссертациясе, ә 1995 елда «Иске татар рәсми эш кәгазьләре стиленең формалашуы һәм кулланылыш үзенчәлекләре (XVI йөз – XIX йөзнең беренче яртысы)» дигән темага докторлык диссертациясе яклый.

1970 елдан башлап, Фәһимә Хисамованың тормышы Казан дәүләт университетының татар теле кафедрасы белән бәйле. Башта ассистент, аннан өлкән укытучы, доцент, 1998 елдан профессор вазифаларын башкара. 1999 елдан алып, бүгенге көнгә кадәр Фәһимә Миргали кызы – татар теле кафедрасы мөдире.

Ф.М. Хисамованың фәнни эшчәнлеге ике юнәлештә – 1) татар әдәби теле тарихы һәм 2) хәзерге татар әдәби теленең грамматик төзелеше (морфология) өлкәсендә бара. Төп өч монографиясе *(XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре. Казан: КДУ нәшр., 1981. 161 б.; Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности XVI–XVII вв. Казань: Изд-во КГУ, 1990. 152 с; Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – начало XIX в.). Казань: Изд-во «Мастер-Лайн», 1999. 407 с.)* татар язма әдәби телендә рәсми эш кәгазьләре стиленең барлыкка килүен, үсү һәм кулланылыш үзенчәлекләрен ачыкла-

уга багышланган. Әлеге хезмәтләрдә XVI–XIX гасырларда язылган рәсми документлар теленә, төрле аспекттан чыгып, җентекле анализ бирелә, шул чорның иҗтимагый һәм тел ситуациясе яктыртыла. Ф.М. Хисамованың төрле җыентыкларда һәм газета-журнал битләрендә басылган күпсанлы мәкаләләрендә дә әдәби тел тарихына караган мәсьәләләр урын ала.

Хәзерге татар теленең грамматик төзелешен өйрәнү аспирантура елларында ук башлана. Галимәнең татар телендә сыйфат фигыль кулланылышын ачыклауга багышланган хезмәте татар һәм рус телләрендә чыккан Академик грамматикаларның бер өлеше буларак дөнья күрә (1992 һәм 2002 елларда). «Татар теле: латин графикасына кайтуның фәнни нигезләре» (2004) дип аталган хезмәтендә хәзерге орфографиянең җитешсезлекләре күрсәтелә һәм латин графикасын кулланышка кертүнең зарурлыгы фәнни рәвештә аңлатыла. Татар теле кафедрасында утыз елдан артык эшләү дәверендә Ф.М. Хисамова татар теле фонетикасы һәм морфологиясе буенча программалар, методик кулланмалар, уку-укыту әсбаплары әзерли, вуз дәреслеге буларак тәкъдим ителә торган «Хәзерге татар әдәби теле. Морфология» (2006) китабын яза.

Күпкырлы фәнни эшчәнлеге һәм ирешкән дәрәҗәләренә карамастан, Фәһимә Миргали кызы, иң беренче чиратта, искиткеч саф күңелле Шәхес булып кала. Фәнни казанышлары турында сөйләгәндә, ул һәрвакыт үзенең остазы – күренекле тел галиме, профессор Д.Г. Тумашеваны искә ала, аның якты истәлеге алдында баш ия. Фәһимә Миргали кызы – уңган, тырыш хатын-кыз, учак терелтүче дә. Филология фәннәре докторы Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Хисамов белән алар өч бала тәрбияләп үстергәннәр, өч уллары да бүгенге көндә югары белемле, тормышта үз урыннарын тапкан җитди белгечләр.

Хөрмәтле Фәһимә Миргали кызы! Без Сезне данлы юбилеегыз белән котлыйбыз! Тормышыгызда шатлыклы көннәр күбрәк булсын, белемле шәкертләр куандырсын, киләчәккә өметләр баглап яшәгез! Сезгә уңышлар, ныклы сәламәтлек, иминлек телибез!

*И.А. Гыйләҗев,*
*тарих фәннәре докторы, профессор,*
*Татар филологиясе һәм тарихы факультеты деканы.*
*2006*

## ФӘҺИМӘ – ФӘҺЕМ ИЯСЕ...

Фәһимә дигәч тә... татар халкының танылган әдибе Ә. Еникинең сүзләре искә төшә. Ул үзенең бер хикәясендә болай дип язган: «...Гаҗәп, кайчакта кешенең исеме үзенә, ничектер, бик туры килеп, килешеп тора».

1936–1937 елларда безнең халык арасында Эльза, Луиза, Клара һәм башка шуның кебек яңгыравыклы исемнәр ишетелә башлаган вакытта, Бөгелмә укытучылар семинариясен тәмамлаган укытучы Мәрхәбә апа кызына Фәһимә дип исем куша. Ул аның, һичшиксез, фәһемле, ягъни үткен, зирәк акыллы кеше булып үсәчәгенә өметләнә. Һәм аның өмете, чыннан да, аклана.

Сугыштан соң ач-ялангач елларда да, аннан соң да Фәһимә Нигъмәтуллина Ютазы районы Кәрәкәшле мәктәбенең тырыш, намуслы укучысы булып таныла. Ул үзе бу хакта болай ди: «Мәктәптә укыганда математиканы, әдәбиятны, телне бик ярата идем. Яраткан укытучым, республикада танылган, атказанган укытучы – математик Рәүф Ваззах улы Ибраһимов иде».

1960 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, Фәһимә Хисамова Чүпрәле һәм Азнакай районы мәктәпләрендә җиде ел укытучы булып эшли. Бу вакытта ул, үзе белән бергә укыган Нурмөхәммәт Хисамовка иргә чыгып, өч бала анасы булырга да өлгерә. Шулай итеп, сөйкемле-чибәр кыз хәзер инде сөекле, уңган хатын һәм газиз әнкәй булып тормыш итә башлый. Дөнья түгәрәкләнә.

Инде тыныч кына, ипле генә, үз балаларына да, мәктәп балаларына да акыл-белем биреп яшәп ятасы гына да бит... юк.

Гаилә Казанга кайта. Ирле-хатынлы икесе дә аспирантурада укый башлыйлар, яңадан имтиханнар, яңадан китапханәләрдә утыру...

Фәһимә Хисамова аспирантураны танылган тел белгече, академик Диләрә Гариф кызы Тумашева җитәкчелегендә уза. Фәһимә Миргали кызы үзе бу хакта болай ди: «Диләрә апага рәхмәт, ышанды, өч баласы бар дип, куркып калмады, таләпчән булды. Мин аңа бик тә рәхмәтле, хөрмәтем чиксез зур».

Фәһимә Миргали кызы Хисамова күпсанлы студентларның яраткан укытучысына әверелә. Татар теленең фонетика-

сы һәм морфологиясе буенча лекцияләр укый, гамәли дәресләр алып бара, курс, диплом эшләрен җитәкли, методик кулланмалар, фәнни мәкаләләр яза, докладлар укый, аспирантлар хәзерли, бетмәс-төкәнмәс җәмәгать эшләрендә катнаша. «...Үземне бик бәхетле санаем. Татарлар яшәгән кайсы гына төбәккә барып чыксам да, үземнең шәкертләрем белән очрашам. Баштарак аларны энеләрем, сеңелләрем итеп ярата идем, аннары үз балаларым кебек күреп, хәзер инде оныкларым кебек яратам», – ди үзе бу турыда.

Оныклар дигәннән, бу һич тә сүз җае, сүз ибе булсын өчен генә түгел. Өч малай да исән-сау үсеп җитеп, үз гаиләләрен булдырып, алты онык белән Фәһимә ханымны алты тапкыр әби ясарга да өлгерделәр. Иң олысы – Зөһрә тел гыйлеменнән кандидатлык диссертациясен төгәлләде. Зөһрәнең сеңлесе Ләйлә, шулай ук, татар-инглиз теле белгечлеге буенча университетны тәмамларга җыена. Иң кече оныклары Надир (Айдар улы) татар мәктәбенең беренче сыйныфында гел «5»кә генә укый.

Әйе, Фәһимә һәм Нурмөхәммәт Хисамовларның өч улы да эшчән, булдыклы, тырыш булып үстеләр. Әле дә хәтеремдә, безне, институт хезмәткәрләрен, шул исәптән ул вакытта институтның фәнни хезмәткәре Айваз Хисамовны да колхозга эшкә җибәргәннәр иде. Ул зур куллы, таза, эшчән егет, һәрвакытта да бүрәнәнең калын башына барып ябыша. Тыр-пыр килеп сөйләшергә яратучы кызларга акыл да бирә: «Сез минем әнием кебек була белегез. Ул бервакытта да әтигә каршы сүз әйтми, шул ук вакытта үзенчә дә эшли. Сез менә шулай була белегез», – ди.

Фәһимә ханымның игезәк уллары Айдар һәм Нияз – танылган рәссамнар. Алар Казан сынлы сәнгать училищесын һәм Ленинградтагы Репин исемендәге Сәнгать академиясен тәмамлаганнан соң, Харис Якупов җитәкчелегендә ике ел аспирантурада укыдылар. Соңыннан язмыш җилләре Ниязны Алманиягә китерә. Ниязның Казанга бер кайтуында Милли мәдәни үзәктә «Игезәк Хисамовлар» дигән зур һәм шактый бай күргәзмә оештырылды. Икесенең дә портрет һәм пейзаж осталыгын чагылдырган колоритлы әсәрләре куелган иде. Ниязның «Исәнме, туган җир!» картинасы күңелләрне үзенең мәһабәт колачы һәм лирик кайнарлыгы белән җәлеп итте. Айдарның «Академик Д. Тумашева», бабасы

һәм әтисе портретлары, «Яңгырдан соң» пейзажы аеруча истә калырлык булды.

Хисамовлар өенә кунак булып килсәгез, анда сезне Айдар иҗат иткән «Әни» портреты каршы алачак. Рәссам үзенең әнисен прототип итеп алып, илаһилык һәм сабырлык үрнәге булган Ана образын тудырган.

Шулай итеп, кайчандыр чибәр-көләч кыз, аннан сөекле хатын һәм гүзәл ана булган Фәһимә хәзер тормышын белдекле, кадерле әбекәй – дәү әни буларак дәвам итә.

Гаиләдә әби була алу – зур бәхет ул!

Әмма фәндә әби булырга ярамый. Бу өлкәдә һәм күңел белән, һәм акыл белән һәрвакытта да фәкать яшь-җитез, өлгер-тырыш булу гына таләп ителә. Фәһимә Миргали кызы нәкъ менә шундый тынгысыз галимә буларак танылa. 1970 еллардан башлап, ул үзе өчен яңа тема – татар теленең тарихын өйрәнү юнәлешен сайлый. Үзе бу хакта болай ди: «Профессор Хатип ага Госман, академик Миркасыйм Госмановлар юнәлтүе роль уйнады. Әһәмиятле кульязма документлар – Е. Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышына кагылышлы материаллар табылган вакыт. Мин шуларны тикшерә башладым. Алга таба фәнни эзләнүләр XVIII йөзгә караган бу татарча язмаларның очраклы күренеш кенә түгел, ә иске татар теленең Рус дәүләтендә, бигрәк тә аның Көнчыгыш дәүләтләр белән мөнәсәбәтендә, дипломатия теле булуын, икенче дәүләт теле дәрәҗәсендә ике-өч гасыр дәвамында чарлануын, кулланышта булуын күрсәтте». Әлеге теманы җентекләп өйрәнү өчен Фәһимә Хисамовага Казан, Мәскәү, Ленинград, Оренбург, Махачкала кебек шәһәрләрнең архивларында эшләргә, гарәп графикасында язылган кульязма документларны табарга, фотокопияләр алырга, фәнни классификация ясарга туры килә. Нәтиҗәдә, күпсанлы мәкаләләр һәм «XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре» дип аталган монография дөнья күрә.

Фәһимә Миргали кызы иске татар телендә язылган һәм XVI–XVIII йөзләргә караган күптөрле документларның телен өйрәнеп, күрсәтелгән чордагы эш кәгазьләре стиленең табигатен һәм вазифасын тулы тасвирлап чыкты. «Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности XVI–XVII вв.»

дип аталган монография шуның нәтиҗәсе. Әлеге хезмәтләрне Ф.М. Хисамова 1995 елның мартында докторлык диссертациясе буларак яклады.

Инде татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую буенча эшләр башлангач, Фәһимә Хисамовага эш-шөгыль күбәя. Ул 2–3 нче рус класслары өчен татар теле дәреслекләре язуда, күренекле методист Р. Борһанова белән берлектә балалар бакчалары өчен татар теленнән кулланма төзүдә катнаша. Латин графикасына күчү буенча эш башлангач, Фәһимә Хисамова «Латин графикасына кайтуның фәнни нигезләре» дигән бик әһәмиятле фәнни-популяр хезмәт бастырып чыгарды (2004).

Фәһимә ханым һаман да яшьләрчә якты итеп елмая, хезмәттәшләре белән дә, дуслары белән дә һәрчакта да итагатьле-сөйкемле, эчкерсез-мөлаем.

Без дә аңа чын күңелебездән исәнлек-саулык, гаилә җылысы, яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез.

*И.Б. Бәширова,*
*филология фәннәре докторы, профессор.*
*2006*

## ТЕЛЕБЕЗНЕҢ ФИДАКЯР ГАЛИМӘСЕ

Хөрмәтле коллегам Фәһимә ханым үзенең олы юбилеенә һәм шәхси тормышында, һәм фәнни иҗат юлында зур уңышлар белән килә.

Ул – татар тел белеме өлкәсендә әйдәп баручы галимнәрнең берсе, күпсанлы фәнни мәкаләләр, 6 монография авторы. Аның хезмәтләрендә төрле-төрле катлаулы мәсьәләләр күтәрелгән. Татар теленең грамматикасы, фигыль сүз төркеме турында, ягъни күп көч куюны, тирән анализлый белүне сорый торган мәсьәләләрне тикшереп, берсеннән-берсе әһәмиятле китаплар чыгарды.

Фәһимә ханым халкыбызның абруен күтәрә, аның тарихын объектив яктырта торган хезмәтләр язды, Пугачев хәрәкәтендә җитәкчеләр буларак актив катнашкан татар каһарманнарын чагылдырган язма документларның телен өйрәнде. Россия дәүләтенең

Кавказ һәм Якын Көнчыгыш, Урта Азия, Көнчыгыш Азия илләре белән дипломатик мөнәсәбәтләрне татар телендә алып баруын татар халкына җиткерде, архивлардан табып күп кенә хатлар, ярлыклар һәм башка кыйммәтле документларны тикшерде. Безнең туган телебезнең инде ничә йөз ел буена дипломатия теле, дәүләт теле, Урта Идел һәм Урал төбәкләрендә төрле милләттәге халыклар өчен аралашу теле булуын дәлилле раслады, татар телен, тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертте.

Фәһимә ханым хәзерге телебез өлкәсендә дә аеруча максатчан һәм нәтиҗәле эшләп килә. Аның фонетикага, язу тарихына багышланган хезмәтләре галимнәр өчен файдалы чыганак, ә студентлар өчен гаять кирәкле кулланма ролен үти.

Татар теле морфологиясенә багышланган саллы китабы – аның иҗат юлының күркәм таҗы; башка хезмәтләре кебек үк, татар тел белеменә генә түгел, гомумтюркологиягә дә зур һәм әһәмиятле өлеш булып тора. Фәһимә ханым татар тел белеме фәнен оештыручы буларак та зур эш башкара, күпсанлы аспирантларны фән эшенә өйрәтә, югары белгечләр әзерли.

Аның студентлар белән эшли, аларга мәгълүмат, белем бирә белүе турында аеруча басым ясап күрсәтәсе килә. Ул аларга зур остаз, дус, киңәшче, аларны тормыш юлына аяк бастыручы дип әйтергә кирәк. Миңа аның белән Уфада, Мәскәүдә, Төмәндә булырга туры килде. Фәһимә ханымга укучыларының шул кадәр хөрмәт, тирән ихтирам күрсәтүләренә сокланып йөрдем.

Шәхес буларак та Фәһимә ханым турында берничә сүз әйтми мөмкин түгел. Ул – Нурмөхәммәт Шаһвәли улының сөекле тормыш иптәше, баһадирлар кебек өч малайның кадерле әниләре, филология фәннәре докторы Венера Нәфикъ кызының һәм күренекле сәнгать белгече Динә Диас кызының ягымлы кайнанасы, аның инде аспирантурада укый торган оныгы да бар, ягъни ул – мөлаем генә әби кеше дә.

Чыннан да шулай, берне булдырган кеше барысын да булдыра. Балаларының, күпсанлы оныкларының язмышларын, гаилә хәлләрен кайгыртуга ул гаять күп көч түгә.

Кыскасы, данлы юбилее алдыннан Фәһимә ханым турында бары мактау сүзләре генә әйтәсе килә, матур, изге теләкләр генә телим. Халкыбызның күренекле кызы, татар теле фәненең танып-

ган вәкиле була алу – бу зур казаныш. Киләчәктә тагын бик күп юбилейлар кабатлансын, иҗат чишмәләре саекмасын, һаман шулай тулы булсын.

*Д.Б. Рамазанова,*
*филология фәннәре докторы.*
*2006*

## О МОЕЙ СВЕКРОВИ

А годы летят, наши годы, как птицы, летят. Действительно, как все быстротечно...

Неужели уже 80 лет моей милой и славной свекрови – Хисамовой Фагиме Миргалиевне?

Прошло более тридцати лет, когда я впервые вошла в дом моего мужа Айваза. Меня он представил своему отцу Хисамову Нурмухаммету Шагвалиевичу и своей матери. Она понравилась мне с первого взгляда: женщина приятной наружности и с мягким голосом.

Со своей свекровью, которую я стала называть Әни (мама), мы сразу подружились, нашли общий язык быстро, более того мы вели беседы на самые сокровенные темы.

Боюсь, я не смогу описать полный портрет этой удивительной женщины, поэтому ограничусь лишь некоторыми штрихами из ее жизни, которые запечатлелись в моей памяти.

1982 год. В этот период наша большая семья в количестве семи человек (родилась уже старшая дочь Зухра) проживала в маленькой квартире поселка Дербышки. Заниматься научно-исследовательской деятельностью в тесных условиях было сложно, поэтому Әни часто уезжала в читальный зал библиотеки КГУ, чтобы полностью быть поглощенной наукой.

А иногда мне доводилось наблюдать, как она работает за письменным столом в домашних условиях: сосредоточенно, не отвлекаясь ни на разговоры, ни на посторонние предметы. Это дано не каждому.

Свидетельством беззаветного служения науке, татарскому языку являются многочисленные труды Фагимы Миргалиевны в области фонетики, морфологии и истории татарского языка.

Моя докторская диссертация была посвящена сопоставительному анализу глагольной системы разноструктурных языков – английского и татарского. И, безусловно, неоценимую помощь как консультанта татарского языка мне оказала Әни. Ее глубокие познания временной системы, модальности татарского глагола впечатляют.

Я считаю, что Фагима Миргалиевна – это эпоха в татарской, тюркской лингвистике. Более того, она очень простой и глубоко порядочный человек.

*В.Н. Хисамова,*
*доктор филологических наук, профессор.*
*2016*

## ТРУДЫ ПО ТАТАРИСТИКЕ И ТЮРКОЛОГИИ В ТВОРЧЕСКОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ ОДНОГО ОТДЕЛЬНО ВЗЯТОГО УДМУРТОВЕДА

(В связи с 80-летием Ф.М. Хисамовой)

**1.** Занимаясь научным исследованием удмуртского языка в самых различных аспектах, я постоянно – хотя бы (!) вполглаза – вглядываюсь на исследования в области весьма продвинутого татарского языкознания: они мне исключительно важны как своими конечными результатами (ведь удмуртский язык испытал на себе довольно сильное влияние тюркских языков, и в первую очередь – в хронологическом порядке – булгарского и татарского), так и идеями или подходами к анализу фактического материала (ибо мой родной язык имеет те же самые типологические – агглютинативные – параметры и относится к тому же самому Волго-Камскому языковому союзу, что и татарский, и чувашский).

Первая татароведческая работа, которую я, еще будучи аспирантом Института языкознания в Москве, с великой радостью (!) и, естественно, с огромной пользой для себя (вернее, для своей кандидатской диссертации «Кукморский диалект удмуртского языка») прочитал – не без определенного труда, разумеется, – это была книга Л. Заляя (Залялетдинова) «Материалы по исто-

рической фонетике татарского языка»[1]. В ходе работы над своей рукописной монографией мною выборочно были использованы, как сейчас замечаю по ее тексту, соответствующие разделы и других работ этого языковеда[2], а также публикации иных татарских, башкирского, русских и зарубежных тюркологов, таких как: Э.М. Ахунзянов[3], У.Ш. Байчура[4], Р.С. Газизов[5], Ф.Г. Исхаков[6], А.И. Хангильдин[7], А.А. Юлдашев[8], Н.А. Баскаков[9], В.А. Богороицкий[10], В. Котвич[11], В.В. Радлов[12], Г.Й. Рамстедт[13]; М. Рясянен[14],

---

[1] *Җәләй Л.* Татар теленеп тарихи фонетикасы буенча материаллар. Казан, 1954. 108 б.

[2] *Җәләй Л.* Татар диалектологиясе: югары уку йортлары һәм педагогия училищелары студентлары өчен дәреслек. Казан 1947. 137 б.; *Заляй Л.З.* К вопросу о происхождении татар Поволжья (по материалам языка) // Происхождение казанских татар. Казань, 1948. С. 85–89.

[3] *Ахунзяное Э.М.* Русские заимствования в татарском языке. Казань: Изд-во КГУ, 1968. 367 с.

[4] *Байчура У.Ш.* Звуковой строй татарского языка. Экспериментально-фонетический очерк. Ч. I. Казань: Изд-во КГУ, 1959. 182 с.; *Байчура У.Ш.* Звуковой строй татарского языка в связи с некоторыми другими тюркскими и финно-угорскими языками. Ч. II. Казань: Изд-во КГУ, 1961. 392 с.

[5] *Газизов Р.С.* Опыт сопоставительного освещения грамматических особенностей русского и татарского языков. Казань, 1952. 256 с.

[6] *Исхаков Ф.Г.* Об отдельных фонемах татарского языка // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. Ч. I: Фонетика. М., 1955. С. 217–248; *Исхакое Ф.Г.* Законы словесного ударения в татарском языке // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. Ч. I: Фонетика. М, 1955. С. 329–332.

[7] *Хангильдин В.Н.* Татар теле грамматикасы (Морфология һәм синтаксис). Казан: Таткнигоиздат, 1959. 642 б.

[8] *Юлдашев А.А.* Аналитические формы глагола в тюркских языках. – М., 1965. 275 с.

[9] *Баскаков Н.А.* Тюркские языки. М., 1960. 240 с.

[10] *Богородицкий В.А.* Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. Казань, 1953. 220 с.

[11] *Котвич В.* Исследования по алтайским языкам. М., 1962. 371 с.

[12] *Radlqff W.* Vergleichende Grammatik Erster Theil. Phonetik der nordlichen Türksprachen. Leipzig, 1883. XL, 318 s.

[13] *Рамстедт Г.Й.* Введение в алтайское языкознание. Морфология. М., 1957. 254 с.

[14] *Рясянен М.* Материалы по исторической фонетике тюркских языков. М., 1955. 222 с.

Н.Н. Поппе[1] и др. Положения и мысли вышеупомянутых и ряда не названных здесь авторов были использованы при попытке объяснения нерешенных проблем современной фонетики удмуртского диалектного и литературного языка и ее истории, напр.:

1) субституции удмуртскими диалектными широкими гласными татарских узких: а) кукм. *е* < тат. и, напр.: кукм. ***e**goṷ* ~ ***e**gol* ‘напильник’ < тат. ***и**гәү*, кукм. ***e**l’* ‘край’ < тат. ***и**л* ‘страна, государство’, кукм. ***e**s: **e**set koškoz* ‘с ума сойдешь’ (*koškoz* ‘уйдет’) < тат. ***и**с* китү ‘прийти в изумление, поразиться’ и др.[2]; б) кукм. *ȯ* < тат. *ү*, напр. кукм. *k**ȯ**rso* ‘сосед’ < тат. *к**ү**рше*, кукм. *č’**ȯ**p* ‘сор’, мусор < тат. *ч**ү**п*, кукм. *č’**ȯ**kiś* ‘молот < тат. *ч**ү**кеч* и др.[3];

2) замещения узким огубленным гласным кукм. *ů* татарских полуузких огубленных редуцированных *о* и *ө*, напр.: в) кукм. *g**ů**mor* ‘период жизни живого существа от рождения (появления) до смерти (исчезновения), век’ < тат. *г**о**мер*, кукм. ***ů**č’өranө* ‘попасться навстречу’ < тат. ***о**чрау*; кукм. ***čůr*** ‘период, время’ < тат. *ч**о**р*; б) ***dů**rөs* ‘верно, правдиво; истина’ < тат. *д**ө**рес*, *k**ů**t’ө* ‘стадо’ < тат. *к**ө**тү* и др.[4] В обоих приведенных случаях (1–2) предположительно имеем дело с сохранением в ранних заимствованиях более ранних гласных татарского языка: 1) широких **е* и **ö* – до их сужения в *и* (= *i*) и *ү* (= *ü*), 2) узких **и* и **ü* – до их редукции в *о* (= *ŏ*) и *ө* (= *ö̆*); в поздних же заимствованиях татарские узкие гласные *и* и *ү* обычно субституировались в рассматриваемом удмуртском диалекте аналогичными узкими гласными соотв. *i* (= *и*) и *ů* (= ӱ), напр.: тат. ***и**яру* > кукм. ***i**jarөnө* ‘пристать, привязаться, следовать’, тат. ***и**зге* > кукм. ***i**zgө* ‘святой’ и др.; тат. *ач б**ү**ре* ‘голодный волк’ > *aś b**ů**rө* ‘голодный, ненасытный’ и др.[5];

3) возникновения фонемы *а* в учинском и лельвижском кустах кукморского говора не только по внутренним законам развития

---

[1] *Poppe N.N.* Vergleichende Grammatik der altaischen Sprachen. T. 1. Vergleichende Lautlehre. – Wiesbaden, 1960.

[2] *Кельмаков В.К.* Кукморский диалект удмуртского языка: дис. ... канд. филол. наук / АН СССР. Ин-т языкознания. М., 1969. С. 72.

[3] Там же. С. 81.

[4] Там же. С. 84–85.

[5] Там же. С. 81–82.

вокализма диалекта, но и под воздействием соседних татарских говоров[1];

4) сохранения заднеязычного носового сонанта *ŋ* под консервирующим влиянием татарского языка[2];

5) утрату смычного элемента удмуртскими аффрикатами в определенных позициях как влияние татарской фонетики[3];

6) возникновение деканья, т.е. произношения анлаутного *й-* как *d’* (= *д*-) или *ǯ’* (= *ӟ*-), в чем усматривается также воздействие татарской фонемной синтагматики на удмуртскую диалектную[4] и пр.

С апелляцией на особенности морфологии татарского языка были объяснены также и некоторых специфичные явления в морфологии рассматриваемого удмуртского диалекта.

**2.** В последующие десятилетия неизмеримо возрос в моей личной библиотеке круг тех татароведческих и тюркологических исследований в области лингвистики, которыми я пользовался/пользуюсь при написании своих статей, научных докладов, монографических исследований и составлении учебно-методических пособий для студентов вуза. Многие из этих книг были выписаны в свое время по почте (такую услугу некогда предоставляла клиентам «Книга-почтой», а теперь – Интернет) или приобретены в различных городах и научных центрах, будучи в них проездом или в командировках. Среди множества других – имеющий фундаментальный характер и очень любимый мною энциклопедический справочник «Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков», который предоставляет в распоряжение ученых почти что исчерпывающие сведения как по синхронному состоянию, так и истории развития отдельных категорий и элементов различных уровней системы тюркских языков: фонетики[5], морфологии[6], син-

---

[1] *Кельмаков В.К.* Кукморский диалект удмуртского языка: дис. ... канд. филол. наук. С. 203–204.

[2] Там же. С. 252–253.

[3] Там же. С. 243.

[4] Там же. С. 216.

[5] Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: Фонетика / АН СССР. Ин-т языкознания. М.: Наука, 1984. 484 с.

[6] Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: Морфология / АН СССР. Ин-т языкознания. М.: Наука, 1988. 560 с.

таксиса[1], лексики[2]; а также по региональной реконструкции[3] и картине мира пратюркского этноса, реконструируемого по языковым материалам[4].

**3.** Деловые контакты непосредственно с татарскими лингвистами из Казани сложились у меня позднее, в последние полтора-два десятилетия работы в университете.

*Они* появились на моем горизонте как-то приятно неожиданно; только не помню точно, когда это произошло. Если это случилось на очередном, юбилейном, симпозиуме «Диалекты и история пермских языков во взаимодействии с другими языками», то это было в Ижевске в 2002 году (а может быть, и раньше). ***Они*** – это три татарских языковеда: Фәһимә-апа (Хисамова Фагима Миргалиевна) – почтенная бике, серьезная, рассудительная, немногословная; Гаффарова Фирая Фаязовна – тихая, спокойная, скромная и крайне дотошно-скрупулезная; Тагирова Фяридя Инсановна – разговорчивая, веселая, умная с исключительным чувством юмора и обязательная «до неприличия», как с особой теплотой говорят иногда в таких случаях. Именно она, мне кажется, и является неформальным лидером этой «святой троицы», как любовно называю я эту группу, с которой всегда приятно (было) мне встречаться, где бы она, эта встреча, ни состоялась: в Ижевске ли, Чебоксарах или в другом городе по случаю какой-либо конференции.

Правда, отдельно с Фәһимә-апа я имел встречу еще и в г. Турку (Финляндия), куда были приглашены в качестве участников научного совещания не только ученые из Саранска и Йошкар-Олы, но и представители лингвистических сообществ из Чебоксар,

---

[1] *Гаджиева Н.З., Серебренников Б.А.* Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: Синтаксис / АН СССР. Ин-т языкознания. М.: Наука, 1986. 284 с.

[2] Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: Лексика / РАН. Ин-т языкознания. М.: Наука, 2006.

[3] Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: Региональные рекострукции / РАН. Ин-т языкознания. М.: Наука, 2002. 768 с.

[4] Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: Пратюркский язык-основа. Картина мира пратюркского этноса по данным языка / РАН. Ин-т языкознания. М.: Наука, 2006. 908 с.

Ижевска и Казани. Оргкомитет симпозиума, посвященного – как было первоначально задумано – волжско-финским (марийским и мордовским) языкам, который был организован под эгидой кафедры общего и финно-угорского языкознания Туркуского университета под руководством профессора Сиркки Сааринен, решил расширить диапазон охвата языков данным симпозиумом, включив «в сферу своего влияния» и такие языки Поволжья, как татарский, чувашский и удмуртский, хотя последний можно назвать поволжским, лишь имея весьма солидную долю фантазии. И Фагима Миргалиевна (вместе с А.П. Хузангаем из Чебоксар и автором данной статьи из Ижевска) была дополнительно введена в Оргкомитет симпозиума в качестве его постоянного члена от татарских языковедов, в каковой должности она находится и в настоящее время. И с того времени очередными центрами проведения симпозиума стали не только Саранск, Йошкар-Ола и Турку (как было раньше), но и Ижевск, Чебоксары, Казань[1].

**4.** Солидная часть моей личной библиотеки по татарской филологии – это книги, подаренные и присланные мне моими татарскими коллегами из Казани (Ф.И. Тагировой (в первую очередь), Ф.М. Хисамовой и др.) и также из Уфы (А.Х. Шайхуловым, И.С. Насиповым, П.А. Мукимовой и др.) по той тематике, в пределах которой я занимался и занимаюсь уже длительное время или намереваюсь работать в ближайшем будущем. Дело в том, что каждый раз, приступая к изучению какой-либо новой проблемы в области удмуртского языкознания, я обкладываю себя книжными изданиями на аналогичную тему по другим – родственным и неродственным – языкам: мне, как старому и старомодному исследователю, куда привычнее работать с бумажными книгами, нежели виртуально-интернетными копиями с них. Так, к примеру, мой

---

[1] Кстати, на последнем заседании Оргкомитета симпозиума «Языковые контакты в Поволжье», состоявшегося в Ижевске в мае 2016 года, в состав «языков Поволжья» были включены еще 4 языка: *калмыцкий* (истинно поволжский язык), *коми-(зырянский)* и *коми-пермяцкий* (они генетически не отделимы от удмуртского) и *башкирский* (имеющий весьма интимные связи с татарским), в соответствии с этим и симпозиум получил новое наименование – «Языковые контакты в Поволжско-Приуральском регионе».

пробудившийся в последние годы интерес к ранним памятникам удмуртской письменности и истории удмуртского литературного языка спровоцировал «свежее» появление в моей библиотеке около двух десятков монографий и учебников по истории русского литературного языка, ранних и современных изданий по истории литературного формата ряда родственных (коми[1], марийского[2] и др.) и неродственных тюркских (чувашского[3], башкирского[4], якутского[5] и др.) языков. Я, как ученый, несказанно рад тому, что благодаря молитвам (и не только, разумеется!) моих казанских коллег имею возможность пользоваться, не отходя «от кассы», фундаментальными исследованиями, которые посвящены истории татарского литературного языка, – книгами И.Б. Башировой[6] и коллективной монографией «История татарского литературного языка (XIII – первая четверть XX в.)»[7]. Самое последнее приобретение по татарской филологии в этой области – это монография

---

[1] *Лудыкова В.М.* Коми гижӧд кыв история (История коми литературного языка). Сыктывкар: Изд-во Сыктывкарского ун-та, 2007. 160 с.; *Лудыкова В.М.* Литературный коми язык: история и современное состояние (социолингвистический аспект): монография. Сыктывкар: Изд-во Сыктывкарского ун-та, 2014. 144 с.

[2] *Иванов И.Г.* История марийского литературного языка. Йошкар-Ола: Мар. кн. изд-во, 1975. 256 с.; Иванов И.Г. Марий литератур йылме историй / Мар. гос. ун-т. Йошкар-Ола, 2003. 299 с.

[3] *Горский С.П.* Очерки истории чувашского литературного языка дооктябрьского периода. Чебоксары: Чув. гос. изд-во, 1959. 272 с.

[4] Очерки истории башкирского литературного языка. М.: Наука, 1989. 256 с.

[5] *Слепцов П.А.* Якутский литературный язык. Истоки, становление норм. Новосибирск: Наука, 1986. 262 с.; *Слепцов П.А.* Якутский литературный язык: Формирование и развитие общенациональных норм. Новосибирск: Наука, Сиб. отд-ние, 1990. 277 с.

[6] *Бәширова И.Б.* XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле: исем категорияләре һәм фигыль наклонениеләрендә әдәби норма, норма вариантлылыгы һәм функциональ-стилистик варантлылык. Казан: КДТУ, 1999. 576 б.; *Бәширова И.Б.* XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле: Жанр-стильләре, аерым грамматик категорияләрендә норма һәм варантлылык. Казан, 2008. 340 б.

[7] История татарского литературного языка (XIII – первая четверть XX в.). Казань: Фикер, 2003. 656 с.

Фагимы Миргалиевны Хисамовой «Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – начало XIX в.)»[1], полученная мною от автора с ее автографом (!) в дни проведения конференции «Татарское языкознание в контексте Евразийской гуманитарной науки» (г. Казань, 1–4 ноября 2016 г.), куда я приехал с группой филологов из Института удмуртской филологии, финно-угроведения и журналистики УдГУ. «В монографии подробно исследован язык документов в различных аспектах, автор довольно много внимания уделяет описанию отдельных этапов функционирования деловой письменности, а также характеристике социально-исторической и культурно-языковой ситуации периода ее функционирования», – написали составители биобиблиографического справочника «Казанская лингвистическая школа»[2] о ней. Это, разумеется, так, однако для меня эта книга исключительно важна не столько своими конечными выводами и результатами (материалы-то разные: письменные памятники делового стиля татарского языка XVI–XIX вв. ни по времени возникновения, ни по своим жанрам отнюдь не сопоставимы с удмуртскими, даже с самыми ранними), сколько *приемами, способами, подходами* – одним словом, *методикой – лингвистического анализа* конкретных документов официально-деловой письменности, которой (методикой) я мог бы пользоваться при изучении ранних памятников удмуртской письменности.

**5.** В самое последнее время «спевшееся трио» как будто бы распалось (возможно, лишь временно?). На двух последних симпозиумах, проведенных в последние годы в Ижевске: на XV Международном симпозиуме «Диалекты и история пермских языков во взаимодействии с другими языками» (28–29.10.2014) «трио» отсутствовало в полном составе; в работе же X Международного симпозиума «Языковые контакты народов Поволжья...» (17–19.05.2016) участвовала лишь Ф.И. Тагирова с группой других татарских лингвистов, Ф.М. Хисамовой и Ф.Ф. Гаффаровой среди участников не оказалось. Я, как один из организаторов научного

---

[1] *Хисамова Ф.М.* Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – начало XIX вв.). Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 405 с.

[2] Казанская лингвистическая школа. Казань, 2008. С. 308.

совещания по языковым контактам, несколько раз звонил в Казань к Фәһимә-апа, она собиралась ехать, однако в самый последний момент все же отказалась от поездки – не решилась (ведь у каждого свои причины...), и тем приятнее мне было через несколько месяцев встретиться с ней в Казани, да еще и познакомиться с ее супругом, профессором Нурмухамедом-ага.

Как я нынче узнал, с осени этого года Фагима Миргалиевна уже не работает в университете, где она долгое время занимала должность заведующей кафедрой татарского языка – она на пенсии. Тем не менее мне кажется (и я хочу этого), что она еще долго будет находиться в дружном строю многочисленных татарских лингвистов: ведь на пенсию уходят преподаватели учебных заведений или работники научных учреждений, но в Науке пенсия для ее служителей не предусмотрена! Фәһимә-апа может ничего и не писать (уже заслужила этой чести!), но пусть продолжает чувствовать себя, вместе со своим спутником жизни, частицей огромного содружества творческих людей; считать себя членом нашего реально-виртуального квартета!

Здоровья, счастья и благополучия Вам, незабвенная Фәһимә-апа, в Вашем, возможно, уже «трехкратном рождении на этот свет»!

*В.К. Кельмаков,*
*доктор филологических наук, профессор (Ижевск).*
*2016*

## ЯЗЫК ВОСТОЧНОЙ ДИПЛОМАТИИ

Чтобы познать свое прошлое, нельзя обойтись без труда языковедов. Профессор Казанского федерального университета Фагима Миргалеевна Хисамова именно такой ученый. Она изучает самые древние пласты татарского языка, на основе тщательных и кропотливых исследований пытается понять и донести до нас то, чем жили лучшие татарские умы прошлых веков: на каком языке они писали и общались, каким образом им удалось вписаться в те реалии, которые сложились после потери татарами своей государственности.

В 1955 году она пришла студенткой в Казанский университет и с тех пор ее судьба неразрывными нитями связана с этим вузом. Студент, аспирант, ассистент, доцент, профессор, заведующая кафедрой татарского языка – вот основные вехи ее биографии в стенах родной альма-матер. Всего несколько строк, а за ними сотни исследований, десятки монографий и учебных пособий, открытий, находок – и все на вес золота, потому что добыто в результате неимоверно тяжелой работы с первоисточниками и рукописями. Благодаря Ф.М. Хисамовой с «карты» татарского языкознания исчезло белое пятно, охватывавшее целых три века: XVI, XVII, XVIII! Это огромное достижение, ставящее ее в один ряд с выдающимися российскими и зарубежными тюркологами.

И самое главное, Фагима Миргалеевна не прекращает активной, научной деятельности, опровергая своей работой расхожую поговорку о том, что первую половину жизни человек работает на свое имя, а вторую – имя работает на человека. Колоссальный научный багаж, богатый педагогический опыт, умение понять и проанализировать и, самое главное, донести до адресата огромный объем знаний – вот те причины, которые не дают ей почивать на лаврах.

И мы, ее ученики, рады тому, что результаты ее работы находят воплощение в виде книг. И вот у меня в руках ее новый труд «Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – нач. XIX в.)», вышедший в конце прошлого года в Татарском книжном издательстве. В этом солидном, 400-страничном томе говорится об истоках, специфике бытования и этапах функционирования старотатарского языка как делового языка восточной дипломатии России в XVI – нач. XIX в.

Как говорит сама Ф.М. Хисамова, к изучению этой темы в свое время ее подтолкнули татарские историки Миркасым Усманов и Салям Алишев. При изучении истории Золотой Орды и Казанского ханства они обнаружили, что существует множество деловых писем, написанных на старотатарском языке. Эти бумаги представляли большой интерес не только для историков, но и для филологов. Таким образом она и занялась этой темой. На основе многих разрозненных документов ей удалось проследить путь развития старотатарского литературного языка, сделав акцент на

изучении официально-делового стиля. Например, тот же профессор Усманов писал, что после падения Казанского ханства нормальное развитие татарского литературного языка прекратило свое поступательное развитие. Но вместе с тем официальными властями был востребован татарский деловой язык, который фактически стал вторым функциональным государственным языком в России. Он был принят русским государством для дипломатического общения со странами Востока.

В новой книге автор дает ответы на многие вопросы, долгое время находившиеся в «подвешенном» состоянии или трактовавшиеся в искаженном виде. Например, она четко указывает на то, что в XVI–XVIII вв. татарское официально-деловое письмо практически не имело конкурентов и было широко распространено среди большинства тюркских народов России того времени. В силу типологической близости языка деловой письменности к живому народно-разговорному языку, как по лексическому составу, так и по грамматическим формам была максимально приближена к татарскому языку. Поэтому любые попытки скрыть старотатарский язык под термином «среднеазиатский», нивелировать его роль являются несостоятельными.

Что касается общенародного татарского языка, то автор считает, что он зародился в Волжской Булгарии, а окончательно сформировался в период Казанского ханства. А в структурном плане в нем преобладали черты языка казанских татар (средний диалект).

Ф.М. Хисамова, опираясь на мнение предшественников, подтверждает важное положение о том, что в эпоху феодализма границы литературного языка и языка народности часто не совпадали. Например, сформировавшаяся на базе официальных традиций Золотой Орды и Казанского ханства старотатарская деловая письменность XVI–XVIII вв. выходила далеко за рамки расселения татарской народности в этот период. Она использовалась в качестве языка русской дипломатии не только при сношениях с тюркскими народами, но и при отправке грамот и писем в такие страны, как Индия, Китай, Иран.

Но все-таки главная цель книги – это изучение старотатарской деловой письменности, ее языка. Ведь именно в этой области

тюркология испытывала недостаток серьезных, обобщающих исследований. Исследование Фагимы Миргалеевны на долгие годы закрыло эту проблему. Если и появятся новые труды, то только с обнаружением новых письменных источников, поскольку весь предыдущий нарративный багаж разобран автором, что называется «по косточкам».

Книга состоит из трех больших глав, каждая посвящена определенному хронологическому отрезку. Говоря о XVI–XVII вв., автор книги исследует крымские дипломатические акты, различные грамоты и письма делового характера. XVIII век представлен языком манифестов Петра I, дипломатическими актами, отражающими русско-среднеазиатские, русско-иранские отношения, по второй половине XVIII – нач. XIX в. приведены дипломатические грамоты и документы, касающиеся организации восточной торговли, документы, возникшие в связи с крестьянскими выступлениями, путевые записки-рапорты дипломатов.

Автор монографии самым подробнейшим образом изучает язык этих документов, выявляет особенности и закономерности, свойственные татарскому языку того времени. Все это помогает понять принципы формирования современного татарского языка, дает ответы на многие вопросы, которые до сих пор считались риторическими.

Монография Ф.М. Хисамовой «Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – нач. XIX в.)» вышла достаточно большим для нашего времени тиражом в 2000 экземпляров и будет доступна всем тем, кто интересуется историей не только татарского, но и других тюркских языков, для тех, кто хочет понять, как формировалась восточная политика Российского государства и какую роль в этом сыграли татары. Одним словом, книга ждет своего вдумчивого, мыслящего читателя, а ее выход, мы надеемся, станет событием всероссийского масштаба.

*А. Ахунов,*
*Татарский мир (г. Москва),*
*2013. №4 (6351)*

## ГАЛИМНӘРСЕЗ ТЕЛ УЛ – ҮКСЕЗ, ЯТИМ БАЛА КЕБЕК...

*Тел дә мул җимеш бирә торган агачларны, бакчаларда күкрәп чәчәк атучы гөлләрне хәтерләтә сыман, һәрдаим су сибеп, ашлап, тәрбияләп тормасаң, барысы да кибә, корый, шиңә. Җимешләре дә булмый. Ә инде берсеннән-берсе матур яңгырашы, гүзәллеге, моңы-аһәңе белән тибрәлеп, чыңлап торса, алар күкрәп үскән зур гөлбакчаны хәтерләтер иде. Кемнәр тәрбияли, кемнәр су сибә соң ул гөлләргә, җимеш агачларына? Галимнәр, тел белгечләре икән, һәр милләтнең үз теле, тарихы булган кебек, һәммәсенең дә үз гаилә башлыгы, килеп чыгышын, ялгысын өйрәнүче белгече, галиме бар икән. Без бүген укучыларыбызны әнә шундый галимнәр даирәсенең бер күренекле вәкиле – филология фәннәре докторы, КФУ профессоры Фәһимә Хисамова белән якыннанрак таныштырырга уйладык. Төгәлрәк әйткәндә, бездә татар теле һәм әдәбияты тарихын өйрәнүче галимнәр бик күп түгел. Бигрәк тә бу тынгысыз һәм четерекле хезмәткә бөтен гомерен багышлаган Хисамовлар гаиләсе турында да бик аз беләдер шикелле хәзерге яшьләр. Борынгы заманнардан, гасырлар түреннән Кол Галиләрне, атаклы «Йосыф кыйссасы»н халкыбызга кайтаруда баһадирлар көче куйган, үзе дә искиткеч матур фәлсәфи-лирик шигырьләр, поэмалар иҗат иткән шагыйрь, Йосыф белән Зөләйхаларны яңадан сәхнәгә менгергән драматург, борынгы әдәби мирасыбызны, аның тарихын өйрәнеп, бөтен төрки дөньяга таныткан күренекле галим, профессор Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Хисамов хезмәтләрен дә бүгенгәчә күреп-бәяләп бетерә алмыйбыз кебек әле. Ә бит аларның берсе дә мәңгелеккә килмәгән. Мәшһүр галимнәребез дә олыгаеп, картаеп сиздермичә генә бакыйлыкка күчеп бара...*

*Телләр дә картая икән. Һәр заманның үз теле бар. Яшь буын өлкән буыннар, ата-бабалар телен бөтен гүзәллеге белән аңласын, тулысынча кабул итә алсын өчен нишләргә соң? Татарстанның «берсе – кояш чыгышыннан, берсе – баешларыннан» булган Хисамовларны бу сорау кайчан кызыксындыра башлады икән? Соравыбызны Фәһимә апага юллыйбыз.*

– Чыннан да, икебез ике яктан шул без. Мин Ютазы районының Кәрәкәшле авылында туып-үстем. Ә Нурмөхәммәт – Чүпрәле

егете, Мүнчәли авылыннан. Казан университеты очраштырды инде безне.

*– ...КДПИның элеккеге ректорлары Мирфатыйх ага Зәкиев белән Җәмил ага Нигъмәтовлар да Ютазыдан түгелме соң әле?..*

– Әйе, райондашлар гына түгел, хәтта авылдашлар да әле без. Дөрес, Җәмил Газизович безнең авыл белән бер колхозга кергән Урал бистәсеннән. Ә Мирфатыйх ага Кәрәкәшленеке. Гомумән, безнең авылдан 7 фән докторы, профессор үсеп чыккан. Сәгадәт Ибраһимовны, Әнвәр Шәриповны (Чаллыда), Мөкатдис Газизовны (КХТИ), Кәүсәр Яхинны (психиатрия табибы) да беләсездер бәлки. Укытучыларыбыз да бик көчле иде безнең. Математикадан Рәүф абый Ибраһимов (Спас районыннан), татар теленнән Сәлимә апа Шәрәфиева укытты. Үз фәннәренә карата мәхәббәт тәрбияли алды алар яшьләрдә. Шуңа күрә безнең, урта мәктәпне тәмамлагач, КДУга юл алуыбыз да көтелмәгән, очраклы гамәл булмады. Ул чакларда Мирфатыйх абыйларның галим булып танылып килүе дә этәргеч ясагандыр инде билгеле. Без КДУга чибәр классташым Зөмәрә Сафиуллина белән килдек. Тик ул, ничектер, конкурстан үтә алмады. Мин кердем.

*– Ничәнче еллар иде бу?*

– 1955–1960 елларда укыдык. Шунысы кызык, хәзер бит педагогик белгечлеккә, бигрәк тә татар бүлегенә кызлар күп килә. Үзегез дә беләсездер, хәтта кайбер төркемнәрдә 1–2 генә ир-егет очрый. Ә без укыганда 25 кешелек төркемнең сигезе генә кызлар иде. Фәнне шулкадәр кызыксынып, яратып өйрәнәләр иде. Шуңа күрә, барысы да диярлек, күренекле шәхесләр булып чыктылар. Төркемдәшләремнән Рәшит Зәкиев (журналист, «Чаян» журналы мөхәррире), Илгизәр Хәбибуллин, Мөнир Абдуллин (шулай ук журналистлар) исемнәрен сез дә беләсездер, Шәйхи Садретдинов, Нурмөхәммәт Хисамов, Флера Сафиуллина (ул безнең лидерыбыз да иде хәтта, бик яхшы укыды) башта ук фәнгә кереп киттеләр. Вузда да укытучыларыбыздан бик уңдык. Хатип ага Госман, Якуб Агишев, Диләрә апа Тумашева, Гаяз Ишмөхәммәтов (гарәп телен укытты), Мирза ага Мәхмүтовларның (шулай ук гарәп теле) искиткеч эчтәлекле дәресләре, лекцияләре хәзергәчә хәтердә саклана. Нурмөхәммәт белән шул елларда ук ныклап дуслашып киттек, кавыштык. Олы улыбыз Айваз да университетта укыган чакта туды.

1960 елда исә юллама белән Чүпрәлегә җибәрделәр. Нурмөхәммәт район газетасында эшли башлады. Ә мин, татар теле укытучысы урыны буш булмау сәбәпле, рус теле укыттым. Бер елдан инде Мүнчәлигә күчтек. Анда игезәк улларыбыз Айдар белән Нияз тудылар. Аннан соң инде Нурмөхәммәт аспирантурага керде. Миңа 3 бала белән туган авылга кайтырга туры килде. 3 ел буе Азнакайда кичке эшче яшьләр мәктәбендә укыттым. 1967 елда бугай, Нурмөхәммәткә фатир бирделәр. Шулай итеп без дә балалар белән Казанга күчеп килдек. Диләрә Гариф кызы бик тә игелекле, киң күңелле кеше иде. Мине дә (3 балалы килеш!) үз кафедрасына аспирантурага кабул итте.

*– Ялгышмасам, Диләрә апа морфология, тел тарихы буенча көчле белгеч иде бит...*

– Әйе, Мәскәү дәүләт университетының көнчыгыш телләре факультетын тәмамлап, аспирантура бетереп кайткан иде ул безгә. Аннан соң, минем диплом эше җитәкчем дә Хатип ага Госман иде бит, «Һади Такташ әсәрләрендә фигыльләр (троплар) кулланышы» темасына яздым мин. Ул үзе дә поэзияне бик ярата иде. Үзенең дә шигырьләр язганын беләсездер. Аның лекцияләрен бөтен факультет йотлыгып, мөкиббән китеп тыңлый иде.

*– Әйе, борынгы һәм урта гасырлар әдәбияты тарихы буенча гаять эчтәлекле, кызыклы лекцияләрен безгә дә тыңларга насыйп булды аның...*

– Аспирантурага керергә ниятләвемне дә Хатип ага хуплап каршы алды. «Гадәттә, әдәбиятны белмәгәннәр телгә барып ябыша, ә Фәһимә телгә әдәбиятны белеп килә», – диде ул кафедра утырышында. Шуннан мин рухланып, мәшһүр галимнәребезнең йөзенә кызыллык китермәскә тырышып укыдым, өйрәндем, эшләдем, фигыльләр диңгезенә кереп чумдым. Әлбәттә, Нурмөхәммәт белән икебезгә дә бик авыр иде. Фән кешеләренә бервакытта да җиңел булмаган анысы. Уйлап карагыз, өч бала белән аспирант стипендиясенә ничек яшәргә кирәк?! Ләкин бөек остазларыбызның ышанычын, өметен аклар өчен, аларның йөзенә кызыллык китермәс өчен, фәндә үз фикереңне, үз сүзеңне әйтер өчен барысына да түзәргә өйрәндек. Шуңа да, бәлки, аспирантураны тәмамлаганчы ук минем кандидатлык диссертациясе язылып беткән иде.

*– Тел тарихы, тарихи грамматика белән кызыксынуыгыз да шулай башландымы?*

– Безнең татар теле тарихы ике юнәлештә өйрәнелә. Беренчесе – тел кайчан барлыкка килгән, әдәби тел ничек формалашкан һ.б. Ә тарихи грамматика юнәлеше исә халыкның килеп чыгышы белән бәйле. Мәскәү тюркологлары бу уңайдан 6 томлык капиталь энциклопедик хезмәтләр бастырып чыгарды. Мәшһүр милләттәшебез Әдһәм Рәхим улы Тенишев җитәкчелегендәге галимнәр төркеме каршына бу басмада һәрбер халыкның тарихи грамматикасын язу бурычы куелган иде. Татар галимнәреннән моңа беренче булып Латыйф ага Җәләй алынды. Ул безне дә укытканлыгын әйтеп китү кирәктер, Аннан Рифкать Әхмәтҗанов дәвам иттерде. Минем хезмәтнең темасы да шуңа бәйле иде. Ул чакларда фән үрләренә кыю күтәрелеп килүче тагын бер күренекле галимебез – Миркасыйм Госманов та миңа гаять мөһим киңәшләрен бирде. Үзәк дәүләт архивларында бик күп тарихи документлар саклана. Алар барысы да иске татар телендә, гарәп имлясында язылган, шуларны казып, актарып өйрәнәсе иде, дигән тәкъдим ясады. Үҗәтлегемне, тырышлыгымны, гарәпчә язуны белүемне сизгәндер инде галим. Әле бит ул архивларга үтеп керүе үзе бер әҗәл. Зур тырышлыклар белән Борынгы актлар үзәк дәүләт архивына (ЦГАДА – Центральный государственный архив древних актов) юл салдык. Аннан инде җиде йозак артына яшерелгән Россиянең тышкы сәясәт архивына (АВПР – Архив внешней политики России) да үтеп кердек. Бәхеткә, монысының директоры Уфадан килгән, татарларны да, башкортларны да яхшы белгән рус кешесе булып чыкты. Ул заманнарда, хәзерге кебек, аудио-видео, компьютер, ксерокс кебек электрон әсбаплар юк иде. Документлар шулкадәр күп, барысын да кулдан күчереп язасы. Ярый инде архив хуҗасы хәлгә керде. Эш сәгате бетү, тәнәфесләр белән вакланмады, рәхмәт төшкере. Шул эзләнүләр, тикшеренүләр нәтиҗәсендә «Иске татар эш кәгазе язмаларының тел үзенчәлеге», «Татарский язык в восточной дипломатии России» дигән саллы гына монографик хезмәтләрем пәйда булды. Алар инде кандидатлык диссертациясен (1971 елда якладым) докторлыкка үстерергә дә этәргеч бирде. Янәдән Мәскәү, Ленинград, Уфа, Махачкала архивлары юлын тапtarga туры килде. Фәнгә фанатларча бирелгәнлек булмаса, мондый

кыенлыкларга беркем дә бармас иде әлбәттә. Өчәр айлык стажировкаларга киткәндә, өч бала белән калган Нурмөхәммәт ничек түзгәндер, мескенем! Мең-мең рәхмәтләр укыйм аңа.

*– Җитмәсә, әле икегез дә эштә бит, студентларга дәрес тә бирәсе булгандыр, фән белән дә шөгыльләнәсе?!.*

– Әлбәттә! Диләрә ападан соң КДУда морфология укыттым. Мәшһүр остазым мәктәбен югалтырга һич ярамый иде. Структур морфология (заман, килеш төрләре һ.б.), функциональ грамматика (милли-семантик кыр, диләр, һәрбер кушымчаның үз фикер төсмере бар), фонетика (Хәлим Сәлимов Алабугага күчеп киткәч, миңа бу тармакны да укытырга туры килде), әдәби тел тарихы (анысын Вахит ага Хаков укыта иде) – күрәсезме, нинди юнәлешләрдә эшләргә туры килде.

Газиз туган телебез сагында нинди көчле, кодрәтле галимнәр торса һәм дә алар аның сафлыгы, пакьлеге турында туктаусыз кайгыртса, ул халык күңеленнән мәңге җуелмас, аның гомере да гасырлар, дәверләр белән генә чикләнмәс иде...

Җир шарында ел саен күпме телнең юкка чыгып баруы, «сезнең татар теленең дә гомере санаулы» дигән кара мәкерле сүзләр ишетелгәләп кую йөрәккә курку хисләре дә сала кайвакыт. Безгә дә янамыймы соң бу афәт? Балаларымның, оныкларымның оныклары да аңламас микәнни инде мине киләчәктә? Нишләргә алайса? Кайсы телгә ябышырга? Кайсысы мәңгелек? Һәр заманның үз холкы, әхлагы, үз теле, үз гадәте (о времена, о нравы...) дигәндәй, телнең өйрәнүчесе вә өйрәтүчесе, саклаучысы вә яклаучысы, кыскасы, заманга яраклаштырып баручысы булганда – ул яшәячәк кебек!..

*– Димәк, бакыйлыкка күчеп барган тел белгечләре, галимнәребезнең дә үз шәкертләре, яшь тарафдарлары, дәвамчы-фикердәшләре калырга тиеш. Шулай булса гына, фән яши, галимнең исеме яши, тел яши, дигән сүз. Ә яшәү инде – туктаусыз хәрәкәт, үзгәреш, бәхәс, көрәш буладыр ул (үсешнең төп шарты, диалектика законы!). Фәһимә апа, сезнең дә нинди мәшһүр галимнәрдән гыйлем вә фатиха алып, фән юлыннан киткәнегезне белдек. Үзегезнең шәкертләрегез дә байтактыр инде?*

– Әйе, диалектика, бәхәсләр турында сез бик урынлы искә алдыгыз. Чыннан да, безнең тел галимнәре арасында да фикер каршылыклары, бәхәс, ыгы-зыгы элек-электән булган һәм хәзер

дә бар, шәкертләре арасында да яшәп килә ул. Әмма төп максатка хилафлык китермәскә тиештер алар. Барыбызның да төп бурычыбыз билгеле бит: телне саклауга, үстерүгә булышлык итү! Фәндә шәхси мәнфәгатьләреңне, үз максатларыңны бераз читкәрәк куярга туры килә. Һәм галимнең мирасын шәкертләре санына карап кына бәяләргә дә ярамый. Аның төп мирасы – фәнни хезмәтләре, тикшеренүләре ич. Галим шәхесе тулысынча хезмәтләрендә генә ачыладыр минемчә һәм, әлбәттә, шәкерте укытучысын уздырмаса – ул начар укытучы (яки начар шәкерт!) булган, дигән әйтемне дә онытмыйк.

Мин үзем, мәсәлән, докторлык диссертациясен 58 яшемдә генә якладым. Оппонентларым арасында Мирфатыйх ага Зәкиев, Мәскәү дәүләт университеты тюркология профессоры Эльвира Александровна Грунина, Ленинград галиме, көнчыгыш телләре белгече Сергей Николаевич Иванов (Нурмөхәммәт белән Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ын рус теленә тәрҗемә итүдә баш күтәрми эшләгән шәхес) кебек мөхтәрәм затлар булуы үзе генә дә күп нәрсә турында сөйлидер. Алар барысы да «Татарский язык в восточной дипломатии России» дигән монографиямне зур, саллы хезмәт буларак бәяләделәр. Чыннан да, китап тел, тарих белән кызыксынучы киң катлам укучыларга да, хәтта бүгенге яшьләргә дә шулкадәр ошар дип уйламаган идем. Аны хәтта быелтыр Татарстан китап нәшрияты икенче тапкыр бастырып чыгарды. Шул уңайдан халык шагыйре Роберт Миңнуллин телевидение аша үзе алып бара торган «Китап» тапшыруына чакырды. Бу тирән эчтәлекле, популяр тапшыруны Татарстанның беренче президенты, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә карамый калмаган күрәсең. Күпмедер вакыттан соң ТР Президенты аппаратыннан махсус депеша белән безнең өйгә аның Рәхмәт хатын китереп тапшырдылар.

Ә шәкертләргә килгәндә, шәхсән үземнең җитәкчелектә 12 кеше кандидатлык диссертациясе яклады. Алар арасында Рамил Йөзмөхәммәтов, Мансур Сәйхунов, Гөлназ Гарипова, Ләйсән Садыйкова, Вилүзә Гафарова кебек фәнни даирәгә кыю килеп кергән яшь белгечләр, тел галимнәре бар. Грамматика, тел тарихы буенча үзем соңгы елларда университетта махсус курс алып бардым. Ләкин телебезне саклау, үстерү, камилләштерү эшенә яңа буын яшьләрен дә җәлеп итәргә кирәк. Чөнки замана, яшәеш үзгәргән

саен телебезнең кулланылышы да үзгәреш кичерә бит. Мәгънә ясалышын тәэмин итүче кушымчалар, яңа сүзләр һәм сүзтезмәләр, яңа фигыльләр дә пәйда була. Заманага карап, вакытлы матбугат, радио һәм телевидение теле дә үзгәрә, яраклаша. Мондый чакта шушы катлаулы процессны җентекләп өйрәнеп, һәрдаим күзәтеп торучы галимнәр, белгечләр булуы зарур.

*– Дөньяның, илебезнең төрле өлкәләрендә, төрле төбәкләрендә туып-үскән язучыларның, әдәбият һәм сәнгать әһелләренең дә теле үзенчәлекле, үзгәрәк була шул...*

– Әлбәттә! Вузларга яңа гына кереп, укырга килгән яшьләрне генә карагыз: үзара ничек аралашалар, чүкердәшәләр бит. Борынгы шагыйрьләребезнең теле дә бер-берсеннән аерылып торган. Тукайлар чоры, бүгенге чор әдипләребезне дә чагыштырып карагыз: һәрберсе үзенчә матур, һәр былбыл үзенчә сайраган кебек. Бу процесс татар әдәби теле формалашуга да зур йогынты ясый әлбәттә. Тел белгечләренә биредә эш муеннан дип әйтәсе килә. Мин үзем яшь студентларны беренче көннән үк шушы эшкә тартырга тырышам. Алар үз төбәкләрендә, яки башкалабызда чыгып килгән татар матбугатының телен өйрәнәләр. Кимчелекләре, хаталары турында рефератлар язалар. Шуннан без аларны бергәләшеп тикшерәбез, фикер уртаклашабыз. Беркемгә дә сер түгел: элеккедән үк кабул ителгән орфографик нормалар сакланып бетми ич, кагыйдәләр искерә, заман таләпләренә җавап биреп бетерми. Мәсәлән, кириллица имлясына күчкәндә эшләнгән кагыйдә буенча, русчадан кергән барлык сүзләргә дә калын кушымчалар гына ялганырга тиеш янәсе (Бубыйлар, табиблар...), яки сыйфат фигыльләр кулланылышы мәсәлән. Ә бит татар телендә 6 рәсми сыйфат фигыль бар. Кайбер басмалар барысын да «-учы, -үче»гә кайтарып калдыра. Нәтиҗәдә телнең тәме дә, мәгънәсе дә бозыла. Бу урында аларны «-ган» яки «-а торган» һ.б. кушымчалар белән дә алыштырып буладыр ич.

*– Грамматика кагыйдәләре көн таләпләренә җавап биреп бетерми, дисез инде алайса?..*

– Орфография кагыйдәләре, һичшиксез, искерде. Аларны яңадан эшлисе бар дип әйтәсем килә. Бу турыда республикабыз җитәкчелеге, хөкүмәт даирәләрендә дә сүз бара, кагыйдәләрне яңадан эшләү бурычы куела. Моның өчен хәтта ТР Министрлар Кабинеты каршында Мирфатыйх ага Зәкиев җитәкчелегендәге ор-

фография комиссиясе дә төзелде. Шундагы бер бүлек өчен мин дә җаваплы саналам. Ләкин эш һаман бер урында тора әле, акча җитми, диләр...

*– Фәһимә апа, безнең заман язучыларыннан иң матур теллесе дип кемне саныйсыз?*

– Иң матур телле әсәрләр Гомәр ага Бәшировныкыдыр, миңа калса, һәр өтер, һәр сүз, һәр кушымча үз урынында кебек аларда. Шулай ук Роберт Миңнуллинның да теле искиткеч матур. Рабит Батулланың теле дә яшьләргә өлге булырлык.

*– Сез күптән түгел генә Мордовия башкаласында узган халыкара симпозиумда булып кайттыгыз. Ниндиерәк җыен иде ул? Шуннан алган тәэсирләрегез белән дә уртаклашмассызмы?*

– Идел буе төбәкләрендә яшәүче фин-угыр телле халыкларның халыкара симпозиумы Саранскида үтте.

Аның беренчесе 2001 елда Финляндиянең Турку университетында уздырылган иде. Аннан соңгы җыеннар Чабаксарда (ике тапкыр), Ижевскида, Казанда, Йошкар-Олада һәм, ниһаять, Саранскида үткәрелде. Финнәр фин-угыр телләр төркеменә кергән кардәш халыклар турында зур кайгыртучанлык күрсәтә. Венгрларны да (мадьяр), удмурт, чуваш, мари, мордва халкын да ташламыйлар. Үз галимнәрен, профессорларын еш кына шул төбәкләрнең вузларына укытырга да, киңәшмә-җыеннарга да, тәҗрибә уртаклашырга да җибәрәләр һәм, киресенчә, Финляндиягә дә еш чакырып торалар, фәнне, әдәбиятны, мәдәниятне, телне үстерүдә һәрдаим ярдәм күрсәтәләр. Татар-башкортларга ничек берләшү мөмкинлеген күрсәтеп торган бер өлге кебек бу. Аларның бердәмлегенә сокланып кайтасың. Шуңадыр да бәлки, соңгы елларда кузгалган «милли компонент» гаугасы аларга бөтенләй кагылмаган кебек. Чөнки безнең бу күрше төбәкләрдә милли телдә укыта торган бер генә уку йорты да, вуз да, бер генә матбугат органы да ябылмаган. Галимнәр, укытучылар да күп акча алып эшли, ябабыз, кыскартабыз дип куркытып торучы да юк.

*– Төрки халыклар белән фин-угыр телле милләтләрне бергә бәйләрлек бәйләнешләр бармы?*

– Симпозиумда төрле фикерләр ишетелә әлбәттә. Мәсәлән, чувашларны борынгы болгарларның дәвамчысы дип санаучы галимнәр дә бар. Бу, минемчә, телебездәге кайбер охшашлыклар булудан

киләдер. Әйтик, бездәге йомшак «җ» авазы аларда «ч» булып яңгырый. Ә менә мишәрләр теле күбрәк кыпчак, угызга тартымрак һ.б. Шулай булгач, безгә алардан бергәлеккә өйрәнергә кирәктер, татар милләтен бүлгәләргә тырышу файдага түгел. Телнең кадерен белергә өйрәтик без яшьләрне. Мисал өчен, безнең университетта булачак журналистларга татар теле нибары 70 сәгать укытыла. Ә тел белгечләре бу курсны 400–500 сәгать укый бит. Рус журналистларын рус теле укытмыйча гына әзерләү мөмкинме соң мәсәлән?

*– Ни өчен бездә туган телгә мөнәсәбәт үзгәрде икән, Фәһимә апа? Ни өчен ике зур вуз авыр хәлдә калды, ике зур факультет юкка чыкты бит?..*

– Мондый сорауны без вуз җитәкчеләренә, галимнәребезгә дә юллаган идек. Бәхеткә, күңелне бераз тынычландыра торган хәбәр ишеттерделәр. Янәсе, татар тарихы һәм филологиясен укыту институты ачу фикере бар икән. Алда ни буласын бер Ходай белә. Тел яшәсә – милләт яшәр!

*– Тирән эчтәлекле әңгәмәгез өчен рәхмәт, Фәһимә апа!*

*Әңгәмәдәш Хөсәен Вәлиәхмәтов.*
*«Мәгърифәт» газетасы, 2 август,*
*2013 ел (№ 31, 32)*

## КАЗАНЬ МОЖЕТ СТАТЬ ЦЕНТРОМ ТЮРКОЛОГИИ

*Профессор Казанского университета Фагима Хисамова изучает самые древние пласты татарского языка, на основе тщательных и кропотливых исследований пытается понять и донести до нас то, чем жили лучшие татарские умы прошлых веков: на каком языке они писали и общались, каким образом им удалось вписаться в те реалии, которые сложились после потери татарами своей государственности.*

*– Фагима Миргалиевна, каждый человек сам выбирает свой путь. Вы избрали путь науки, стали известным ученым, профессором, создали свою школу. Но все же интересно знать: почему Вы ступили именно на эту стезю?*

– Моя малая родина – деревня Каракашлы Ютазинского района. Это юго-восток Татарстана, почти на границе с Башкортоста-

ном. Далеко от научных центров? Да. Но именно в этой глухой деревне существовала простая сельская школа, которая дала науке такие имена, как академик Мирфатых Закиев, известный ученый-фольклорист Ильбарис Надиров, бывший ректор Казанского ветеринарного института Нариман Хазипов, доцент университета Сагадат Ибрагимов.

Я никогда не думала, что поступлю в Казанский университет, а тем более, что стану ученым. Все это произошло стихийно. В науку меня привела большая любовь к родному языку, родной литературе. Не обошлось без влияния моего мужа – литературоведа Нурмухаммета Хисамова, а тогда простого аспиранта. Но самую большую роль, наверное, сыграла моя встреча с Дилярой Гарифовной Тумашевой, которая и убедила меня поступать в аспирантуру. Она же стала моим научным руководителем.

*– Летом этого года Диляра Гарифовна ушла из жизни. Мы потеряли тюрколога с мировым именем...*

– Да, Диляра Гарифовна была большим, великим ученым, Главная ее заслуга в том, что она создала научную школу по изучению грамматики татарского языка. Правда, татарское языкознание имеет давнюю историю. В этом направлении работали Гибад Алпаров, Вали Хангильдин, другие ученые. Но роль Диляры Гарифовны особенная. Приехав из Московского университета, она подняла нашу языковедческую науку на новый уровень, придала ей своеобразный столичный лоск. До сих пор существует множество спорных вопросов относительно татарской грамматики и фонетики. Есть ученые, которые пытаются экспериментировать, предлагают свои варианты решений. Но все же самый надежный вариант принадлежит Диляре Гарифовне и ее ученикам. Для меня это бесспорно.

*– Как развивается современная языковедческая наука?*

– Уже не такими темпами, как раньше. Я занимаюсь проблемами истории татарского языка, работаю по направлению исторической грамматики. В этой области есть хорошие специалисты в Москве, Санкт-Петербурге, среднеазиатских республиках. Довольно продвинутая языковедческая наука сегодня в Чувашии. Раньше при Институте языкознания в Москве работал отдел тюркологии и монголистики, который координировал работу всех языковедов-тюркологов в стране. Но там уже не осталось тех

крупных ученых с мировыми именами, и, к сожалению, на сегодня такого крупного тюркологического центра в России нет.

*– А сможет ли Казань подхватить падающее знамя и стать центром тюркологии? И что нужно сделать для этого?*

– Я считаю, что вполне может. У нас много научных кадров, хороших специалистов. Есть молодые, перспективные ученые. Прибавьте к этому традиции казанского востоковедения, казанской тюркологической школы. Благополучное состояние нашей республики, татарстанской науки, множество вузов, научных институтов – все это вкупе может стать надежной основой для становления центра тюркологии в Казани.

Мне кажется, что прежде всего необходимо усилить научно-исследовательский центр. Этим центром может стать Институт языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова. Там работает немало крупных ученых, которые прекрасно справились бы с этой задачей.

Недавно к нам приезжал профессор Геттингенского университета Эберхард Винклер. Он занимается финно-угроведением, но хочет создать у себя в университете тюркологический центр. Винклер был в Москве и говорит, что тюркологии там сейчас нет. Так что пока он поддерживает отношения с нашим Казанским университетом. Но вузы, как Вы знаете, занимаются обучением студентов, а наука должна развиваться в научно-исследовательских институтах.

*– Вы занимаетесь исследованиями в области исторической грамматики татарского языка. Почему именно эта тема?*

– В свое время меня подтолкнули к ней наши ученые-историки Миркасым Усманов и Салям Алишев. При изучении истории Золотой Орды и Казанского ханства они обнаружили, что существует множество деловых писем, написанных на старотатарском языке. Эти бумаги представляли большой интерес не только для историков, но и для филологов. Таким образом я и занялась этой темой. На основе многих разрозненных документов мне удалось проследить путь развития старотатарского литературного языка, сделав акцент на изучении официально-делового стиля. Тот же профессор Усманов писал, что после падения Казанского ханства нормальное развитие татарского литературного языка прекратило свой поступательный ход. Но вместе с тем официальными властями был востребован татарский деловой язык, который фактически

стал вторым функциональным государственным языком в России. Он был принят русским государством для дипломатического общения со странами Востока. Что там говорить – даже в Индию с татарскими грамотами ездили!

*– Получается, татарский язык понимали на всем Востоке?*

– Именно так. Там, где не понимали, приглашали на работу татарских писарей и переводчиков. Раньше существовал общетюркский литературный язык, который был понятен и на Кавказе, и в Поволжье, и в Средней Азии. Примерно после XIII–XIV веков начинают появляться региональные варианты, которые несли в себе элемент местного разговорного языка. Начало регионального литературного татарского языка – это булгарский период, но особенно язык периода Казанского ханства.

*– В последнее время ученые много спорят о том, на каком языке разговаривали наши предки в период Волжской Булгарин. Если судить по надписям, сохранившимся на надмогильных камнях, этот язык заметно отличался от современного татарского.*

– Во-первых, никто не знает, каким был булгарский язык. Судят только по эпитафиям, поскольку письменные памятники не сохранились. Был ли он похож на казанско-татарский язык или на чувашский, точно никто сказать не может. Издавна идут такие споры. Но в том, что чувашский язык – тюркский, у меня нет никаких сомнений. В то же время сами чуваши полагают, что их язык – это смесь тюркского и угро-финского языков. А что касается эпитафий, то да, там много общего с чувашским языком, и никуда от этого не денешься. Хотя некоторые наши ученые, например, Мирфатых Закиев, придерживаются противоположной точки зрения. А что до отличий, то здесь все понятно. В период Казанского ханства произошла сильная кипчакизация местного языка. Например, известный венгерский языковед Андраш Рона-Таш утверждает, что казанские татары по крови булгары, но они были ассимилированы кипчаками. Отсюда идут те различия, о которых мы говорили.

*– Давайте пофантазируем. Скажем, современный татарин каким-то чудом оказался в Казанском ханстве. Смог бы он понять язык своих соплеменников?*

– Да, несомненно. Почитайте поэта Мухаммедъяра и поэзию XIX – начала XX века. В первом случае вам все будет ясно, а во

втором – вы ничего не поймете. Произошла сильная арабизация и османизация татарского литературного языка. Это случилось в результате тех тесных связей, которые существовали у татар со странами Востока. Шакирды возвращались из арабских и турецких медресе и в последующем непроизвольно оказывали влияние на литературный язык.

*– Как Вы оцениваете период суверенитета Татарстана? В последнее время о нем все чаще говорят как о времени упущенных возможностей – имеется в виду ситуация с татарским языком.*

– Я бы не стала так говорить. Все познается в сравнении. Были открыты татарские школы, гимназии. Вспомним так называемые застойные годы. В Казани оставалась одна-единственная татарская школа. Мы не знали, куда вести студентов на практику. Конечно, можно было сделать больше. И все же я остаюсь оптимистом. Возьмите факультет татарской филологии. Кто там учился раньше? В основном выходцы из деревни. А сейчас у нас обучаются городские ребята из Казани, Челнов, Елабуги. К нам идет хорошо подготовленная молодежь, которая приучена к умственному труду и знает, чего она хочет. О чем это говорит? О том, что интерес к родному языку возрос многократно.

*– А латиница? Почему этот вопрос так и не был решен?*

– На то есть множество причин. Но я уверена в том, что рано или поздно мы вернемся к этому вопросу. Только не знаю, раньше или позже русских. Я как языковед убеждена в том, что латиница лучше всего соответствует природе нашего языка. Кириллица рассчитана на особенности русского языка, а наша грамматическая система и русская прямо противоположны друг другу. Какой самый совершенный в мире алфавит? Турецкий и еще финский. Оба – на базе латинской графики.

*– Фагима Миргалиевна, спасибо Вам за интересную беседу. И я надеюсь, что этот разговор станет для читателей не только пищей для размышления, но и, возможно, подтолкнет кого-то заняться наукой.*

Беседовал<br>Азат Ахунов.<br>2006

## Фәһимә Хисамова:
## НУРМӨХӘММӘТ ҮСЕНДЕРЕП ТОРА: СИН ҺАМАН МАТУР, ДИ...

*Казан дәүләт университеты профессоры, татар теле кафедрасы мөдире Фәһимә Миргали кызы Хисамова белән еш очрашып торабыз. Төрле фәнни чараларда да, әдәби кичәләрдә дә... Сөйкемле, мөлаем Фәһимә апа янәшәсендә һәрвакыт диярлек озын буйлы, мәһабәт гәүдәле ир-ат булыр. Ул аның тормыш иптәше – танылган әдәбият белгече, филология фәннәре докторы, язучы һәм шагыйрь Нурмөхәммәт Хисамов. Бәхетле озын гомер юлында имәндәй 3 егет үстергән гаилә һәркемгә үрнәк. Татар әдәби теле һәм хәзерге татар әдәби теленең грамматик төзелешен фәнни калыпка салган мөгаллимә белән бу юлы хатын-кыз бәхете, бәхетле гаилә серләре турында сөйләшергә булдык әле.*

*– Хәзер хатын-кызларның күбесе ир-атларның ролен үзләренә алды, бизнеста да, гаиләдә дә хәтта ки. Сезнең гаиләдә ничек ул? Милли традицияләр сакланамы? Аларны саклап калу кирәкме?*

– Һичшиксез, кирәк. Башкача була да алмый. Нурмөхәммәт – мишәр, нык холыклы. Хәер, мишәрләрнең уңай ягы да бар – гаиләне саклау, балалар үстерү ягыннан бик ышанычлы алар. Без һәрвакыт аның белән исәпләшәбез. Хәтта балалар да, үзләренә бишенче дистә китүгә карамастан, һәрвакыт «әти ничек анда, ул ничек дип әйтер икән...» дип кенә торалар. Дөрес, бу балаларга ирек бирмәү булып тоелырга да мөмкин. Минемчә, гаиләдә ирләр үз урынында булырга тиеш. Аның фикере бездә гомер буе өстен булды. Бервакыт Надир оныгыбыз авырып китте. Шалтыратам: «Улым, терелдеңме инде, хәлең ничек?» – дим. «Бүген мәктәпкә бармадым әле, тик бабайга әйтмә, яме», – ди. Бабасының «усал җиле» хәтта балага ук барып җиткән...

*– Без студент чакта ук Нурмөхәммәт абыйның кырыс холкын сизә идек, Фәһимә апа белән ничек икән, ул гына җайлаша ала торгандыр, дигән фикер дә бар иде әле.*

– Җайлашу кирәк. Һәркем үз законын алга куеп, шуны үткәрергә тырышса, ул гаилә бозыла, минемчә. Үземнең кул астында

эшләгән яшь ханымнарга да шундый киңәшләр биргәлим. «Ничек инде, ул миңа шулай дип әйткәч, мин ничек дәшми калыйм?» – диләр. Минәйтәм, син алай эшләмә, көтеп тор, ул әзрәк тынычлангач әйтерсең. Соңыннан хәтта уңай нәтиҗәләрен дә күргәнем бар. Димәк, киңәшем урынлы булган.

*– Ә сезгә бу сабырлык кайдан килә?*

– Белмим инде, холкым шундый йомшак микән соң... Мин үземнең күңелем белән гармониядә яшәргә яратам. Күңелем шулай куша. Димәк, бу очракта сабыр итәргә, эчке күңелеңне тыңларга кирәк, дим. Яшьрәк вакытта әзрәк каршы әйтүләр дә булгандыр инде, хәзер юк... ирнең җаена төшә белергә кирәк. Һәм ул соңыннан яхшы булып кайта, минемчә.

*– Фәһимә апа, гаиләдә җайга төшеп була, ә фәндә ничегрәк? Фәндә андый нәрсә кабул ителми бит. Ике галим кеше бер фәнни казанга ничек сыя?*

– Юк, фәндә җайлашу була да алмый, ярамый да. Тик безнең Нурмөхәммәт белән фикерләребез уртак. Студент чагымда мин күп нәрсәләр турында төптән уйламый торган, ваемсыз бер кыз идем. Ә Нурмөхәммәт мәктәптән килгәндә үк җитешкән, өлгергән, үзенең милләтен, халкын ярата торган, шуның өчен көрәшкә әзер булган кеше иде. Хәзер дә шундый ул... 11 нче сыйныфта укыганда ук Илья Эренбургка хат язган булган. Ни өчен менә бездә милли мәсьәләдә тигезсезлек дип, мисаллар китергән. Җавап хаты да алган, ул әле дә саклана. Гомер буе аның йогынтысы миңа бик көчле булды. Минем ниндидер дәрәҗәдә өлгереп җитүемдә Нурмөхәммәтнең роле бик зур.

*– Берегез – Ютазыда, икенчегез – Чүпрәледә... ничек очраштыгыз да, ничек кавыштыгыз?*

– Бер группада укыдык. Мәхәббәт бер күрүдән генә булмады әлбәттә. Икенче курстан соң Диләрә Гарифовна Тумашева, Нурмөхәммәт, мин, 5 нче курста укый торган бер Башкортстан кызы һәм Шәүкәт Сәйфетдинов атлы егет экспедициягә бардык. Менә шунда гына бер-беребезне «күрдек»... Ә аңа кадәр кая ул! Аңа якын бара торган түгел, ул бик интеллигент кыяфәтле, без инде читтән генә карап, Хисамов дип кенә йөртә идек үзен. Ул да миңа алай сөеп карамый иде. Бик күп сөйләргә ярата иде, милләт, тел проблемалары турында аеруча. Мин тыңлый идем, андый кешегә

тыңлый белүче дә кирәк бит. Тыңлап, кабул итеп, бәлки шул ягым ошап киткәндер инде, белмим. Экспедициядән кайткач дуслашып киттек, 4 нче курста өйләнештек.

*– Хатын-кыз, беренче чиратта, ана бит әле ул. Сезнең күренекле татар галиме дигән мактаулы атыгыз бар, шуның өстенә 3 бала анасы да. Әле өчесе дә ир бала бит...*

– Ир бала икәнен белмәдем шул мин аларның. Беренчесен студент вакытта таптым. Айваз 9 ай сабыйлар йортында үсте, барып имезеп кенә кайта идем. Ә башкача мөмкин түгел, чөнки тулай торакта торабыз, бүлмәдә студентлар, баланы алып кайтырга ярамый. Икенчесен алып кайту болайрак булды. Нурмөхәммәтнең аспирантурага җыенган вакыты. Табыйк микән, юк микән дип ут йотып йөргән көндә, ирем «ярый, бер кыз алып кайтырбыз инде» ди. Кыз түгел, ә игезәк малайлар туды. Мин берара каенанамнар белән Мунчәлидә яшәдем. Анда бала үстерү өчен бернинди шартлар юк, 3 айдан укытырга да чыктым. Игезәк бала тапсам да, ул вакытта шундый закон бар иде. Аннары бик авыр булгач, үз ягыма кайттым. Анда туганнар бар, ярдәм итәрләр дидем. Нурмөхәммәт ул вакытта аспирантурада укый. Тормышка яраклашырга тырышып, 6 ел аерым яшәдек. Аерым торгач, гаиләгез таркалды инде, дип әйтүчеләр дә булды. Фаразлары дөрескә чыкмады. Фатир булгач, балалар белән Казанга күчендек. «Жизнь пройти – не поле перейти» дигән урыс мәкале бар бит әле, бөтенесе дә баштан кичте.

*– Укытучыларның мәшәкатьләре бик күп, шулай да хатын-кыз булып калу өчен үзеңне ничегрәк тотарга кирәк?*

– Кеше үзен яратырга тиеш. Олыгайгач та хәтта. Чөнки кеше никадәр матур булса да яше арткан саен үзгәрә, ә үзен-үзе карамый башласа бик ямьсезләнә, тирә-якка начар тәэсир итә. Шуңа күрә, никадәр генә авыр булса да, хатын-кыз – хытын-кыз булып калырга тиеш. 60 та да, 70 тә дә. Кибетләргә дә, салоннарга да йөрергә тиеш. Бу яктан мин бераз тырышам. Ничек килеп чыгадыр, белмим. Аннары Нурмөхәммәт тә гел үсендереп тора: син шундый сөйкемле, син әле һаман матур, ди. Син генә миңа шулай әйтәсең, дип көләм инде.

*– Ир-егетләрегезне тәмле ризыклар белән сыйлыйсыздыр. Нәрсәләрне аеруча ратып пешерәсез?*

– Бәлеш. Кыстыбыйны да бик яраталар. Хикмәте – аның камырын аерым пешерүдә. Ул калынрак чүпрәк кебек була. Ә кайберәүләр чи камырга бәрәңге төйи дә, кыздырып ала, алай һич тәмле булмый. Бәрәңгесенә вак кына суган, ак май һәм сөт саласың. Камыры өзеп-өзеп ашый торган булырга тиеш. Тары ярмасыннан тәбикмәк пешерергә дә хыялланам. Без яшь чакта тары ярмасын юып-киптереп, аннары ике мәртәбә иттарткычтан чыгарып һәм әз генә бодай онына аш ясап, тары оныннан коймак камыры әзерлиләр иде. Шуны табада пешерсәң, искиткеч тәмле була инде ул. Хәзер кытай ашын яратып пешерәм. Мәскәүдә өйрәнеп кайттым.

*– Ризык пешергәндә нинди җырлар көйлисез?*

– Яшь вакытта өйдә гел пластинкалар әйләндерә идем, ничек җыр тыңламыйча яшәргә мөмкин дип аптырый идем әле. Менә шул вакытта сеңеп калган җырларны көйлим, элеккеге халык җырлары, «Агыйделнең параходы»...

*– Нурмөхәммәт абый Сезгә нәрсәләр бүләк итәргә ярата?*

– Бүләкләр бик күп инде. Мин олы яшьтә булсам да үземә һаман киемнәр алырга яратам. Кибетләрдә йөргәндә кайчакта кызык кына килеп чыга. Нурмөхәммәт: «Ярый, матур, килешә, бу сиңа 8 март бүләге булыр», – дип куя. Аның зәвыгы бик яхшы. 1983 ел иде микән, мин үземә бик матур, ак якалы күн пальто алдым. Башыма да алырга кирәк, тик акча юк, балаларның бәләкәй чаклары. Нурмөхәммәт андый чакта акча белән исәпләшеп тормый, бик матур ак кеш тиресе белән бизәлгән каракүл бүрек алып бирде. Бик килешә иде. Хәзер дә үземне шулай күз алдына китерәм... Иң беренче истә калган бүләге...

*– Өегездә гел тере чәчәкләр буладыр инде... һәрбер хатын-кыз чәчәкләр ярата бит.*

– Яратам да, бүләк тә итәләр. Һичшиксез, роза чәчәге, шиңми торган хризантемалар... Бакчада эре-эре ромашкалар үстерәм. Победилово янындагы бакчабызга авыл өе китереп салдык, мунча төзедек, Нурмөхәммәт үзе кое казыды. Кыяр, помидор, җиләк үстерү минем өстә булса, Нурмөхәммәт агачларны карый. Ул моңа бик оста, кечкенә вакытында ук алмагачлар ялгый торган булган. Безнең бер алмагачта 3 төрле алма үсә. Кызыл карлыганны, аның желесын бик яратабыз.

*– Тәүлекнең кайсы вакытын яратасыз?*

– Кичкә таба авышкан вакытын. Сәгать 11 ләрдә эчем пошып ала минем, эшем булмаса бигрәк тә. Ә менә кичкә таба кәефем күтәрелә...

*– Иртә торгач, иң беренче сүзегез?*

– Соңарып булса да акыл керде инде. Яшь чакта теләкләр тели белмәгәнмен, хәзер уянуга ук балаларыма, ил-көнгә изге теләкләремне кабатлый башлыйм...

*Әңгәмәдәш Гөлүсә Закирова.*
*«Мәгърифәт» газетасы,*
*8 март, 2008 ел*

# ТЕЛНЕ КАЛӘМ САКЛЫЙ

## ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ТАРИХИ ГРАММАТИКАСЫ

### Кереш

**1. Тел тарихы һәм аны өйрәнүнең төп юнәлешләре.** Лингвистикада хәзерге телләрнең төзелешен һәрьяклап өйрәнү белән бергә (хәзерге әдәби тел) тел тарихын өйрәнү дә әһәмиятле фәнни юнәлешләрнең берсен тәшкил итә. Тел тарихын өйрәнүнең хәзерге фәндә ачык билгеләнгән ике юнәлеше бар: **тарихи грамматика** һәм **әдәби тел тарихы**. Бу ике тармак өйрәнүнең максаты, ысуллары һәм өйрәнү өчен нигез булган төп чыганаклар буенча да бер-берсеннән шактый нык аерылып тора.

Тарихи грамматика татар **гомумхалык теленең** тарихын төзелеше буенча, ягъни **структур яктан** өйрәнә. Икенче төрле әйтсәк, тарихи грамматикада гомумхалык теленең фонетик, лексик һәм грамматик төзелеше тарихи яссылыкта өйрәнелә.

Мәгълүм булганча, татар теле үзенең тамырлары белән бик ерак чорларга, борынгы төрки нигез телгә барып тоташа, һәм телебезнең тарихи грамматикасын өйрәнү дә гомуми рәвештә төрки телләрнең чагыштырмалы-тарихи грамматикасын өйрәнү кысаларында алып барыла, һәм күпмедер дәрәҗәдә аның состав өлешен тәшкил итә.

Тел белеменең «Әдәби тел тарихы» тармагы исә борынгыдан килгән һәртөрле язма ядкәрләргә нигезләнеп, теге яки бу телдә, яисә телләр төркемендә әдәби телләр формалашу тарихын, әдәби телнең чорларга бүленешен һәртөрле язма истәлекләр нигезендә аның кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнә. Тел тарихы бу очракта

тарихи-иҗтимагый вазгыятькә бәйле рәвештә, ягъни **функциональ** юнәлештә тикшерелә.

Максаты, юнәлешләре төрле булуга карамастан, тарихи грамматика һәм әдәби тел тарихы шул ук вакытта бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тора. Гасырлар дәвамында тудырылган күпсанлы һәм кыйммәтле төрки-татар язма ядкәрләрне өйрәнү, мәсәлән, билгеле булганча, әдәби мирас һәм әдәби тел тарихы юнәлешендә алып барыла. Шул ук вакытта төрле чорларга караган язма истәлекләр телендә теркәлеп калган борынгылык күренешләре төрки телләрнең тарихи грамматикасын өйрәнү өчен дә кыйммәтле чыганак хезмәтен үти.

Татар филологиясе бүлекләрендә укытыла торган «Иске татар әдәби теле» курсы да татар теле тарихын өйрәнүнең бер состав өлешен, элгәресен тәшкил итә.

**2. Татар теленең тарихи грамматикасы, аның состав өлешләре, өйрәнү өчен төп чыганаклар.** Алда әйтелгәнчә, тарихи грамматика гомумхалык теленең тарихи үсеш-үзгәрешен өйрәнә торган фән тармагы. Ул тарихи фонетика, тарихи морфология, тарихи синтаксис, тарихи лексикология бүлекләрен берләштерә, һәм телнең фонетик һәм грамматик төзелешендә, лексик составында күп гасырлар дәвамында барлыкка килгән үзгәрешләрне өйрәнә.

Мәгълүм булганча, тел төзелешенең төрле тармакларында тарихи үзгәрешләр бердәй дәрәҗәдә булмый. Аның иң хәрәкәтчән өлеше – лексикасы, лексик составы. Татар теле мисалында алсак, узган гасыр дәвамында иҗтимагый вазгыятькә бәйле рәвештә телнең лексик составында барган үзгәрешләр генә дә моның ачык мисалы булып тора.

Телнең авазлар составы һәм грамматик төзелеше чагыштырмача тотрыклы булып санала, алар тарихи үзгәрешләргә авыррак бирелә, әмма аларда да төрле дәрәҗәдәге тарихи үзгәрешләр барлыкка килә. Идел буендагы төрки телләрдә, ягъни татар, башкорт, чуваш телләрендә, сузык авазларның системалы үзгәреше, **сузыклар күчеше**, мәсәлән, гомумән, төрки телләрнең чагыштырмалы тарихи фонетикасын өйрәнүдә үзәк мәсьәләләрнең берсен тәшкил итә.

Тарихи грамматиканы өйрәнү өчен төп чыганаклар:

1) хәзерге татар әдәби теле, диалектлар һәм сөйләшләр;

2) кардәш төрки телләр;

3) борынгы язма истәлекләр;

4) тарихи рәвештә бер төбәктә яшәгән кардәш булмаган халыкларның телләре;

5) ономастика материаллары, археологик чыганаклар һ.б.

1. Аерым телнең тарихи грамматикасын өйрәнү иң беренче чиратта хәзерге әдәби телгә һәм аның диалектларына нигезләнә. Төрле тел берәмлекләренең тарихи үзгәрешләре гадәттә аның борынгы нигез телдәге төрдәше – архетипка мөнәсәбәттә ачыклана.

Тарихи грамматиканы өйрәнү өчен шулай ук телебезнең диалектлары һәм күпсанлы сөйләшләре гаять кыйммәтле чыганак вазифасын үти. Диалект һәм сөйләшләрдә, билгеле булганча, борынгылык күренешләре күбрәк һәм тотрыклырак саклана.

2. Аерым төрки телләр тарихын өйрәнгәндә башка кардәш төрки телләр материаллары да киң кулланыла. Төрки телләр үзләренең төзелеше буенча бер-берсенә бик якын торалар. Тел тарихын башлап өйрәнгән галимнәрдән В.В. Радлов, мәсәлән, кардәш төрки телләрне хәтта диалектлар дәрәҗәсенә куеп «сөйләшләр» («тюркские наречия») дип атый. Тарихи үзгәрешләр дә төрле телләрдә төрлечә дәрәҗәдә чагылыш таба.

3. Телдәге борынгылык күренешләре, һичшиксез, төрле гасырларга караган күпсанлы төрки язма истәлекләрдә теркәлеп калган, һәм алар тел тарихын өйрәнүдә шулай ук әһәмиятле чыганак хезмәтен үти. Әмма шуны истә тотарга кирәк, борынгы язма истәлекләрдә чагылыш тапкан әдәби тел ул, кагыйдә буларак, билгеле бер төбәктә яшәгән халыкның сөйләмә теле белән тулысынча тәңгәл килми. Борынгыга киткән саен, язма әдәби тел һәм гомумхалык сөйләмә теле бер-берсеннән шактый нык аерыла. VI–VII йөзләрдән башлап кулланылып килгән төрки язма әдәби телләрдә тарихи күчемлелек һәм борынгы язма традицияләр нык саклана. Төрле географик төбәкләрдә аерым төрки халыклар формалашканга кадәр тудырылган бу язма әдәбият, язма истәлекләр гомумтөрки мирас булып санала.

4. Турыдан-туры үзара кардәш дип саналмаган телләрнең тарихи рәвештә бер-берсенә тәэсире, башлыча, бу халыкларның күп гасырлар дәвамында бер ареалда яшәүләре белән бәйле. Идел буенда яшәгән төрки халыклар (татар, башкорт, чувашлар)

меңнәрчә еллар буена угро-фин төркеменә кергән мари, удмурт, мордва халыклары белән, шулай ук бераз соңрак руслар белән янәшә һәм тыгыз аралашып яшәгәннәр, һәм бу телләр арасындагы тарихи бәйләнеш, аларның бер-берсенә тәэсире хәзерге фәндә расланган күренеш булып санала. Күп кенә галимнәр, мәсәлән, татар, башкорт, чуаш телләрендәге сузыклар үзгәрешен (сузыклар күчешен) дә угро-фин телләре тәэсире белән бәйләп карау ягында торалар.

5. Тел тарихын өйрәнүдә ономастика материаллары, ягъни авыл, шәһәр һәм һәртөрле урын-җир атамалары, микротопонимнар, шулай ук археологик казылмаларда табылган язу элементлары да кызыклы гына тел материалын бирә.

**3. Тел тарихын өйрәнү ысуллары.** Тел тарихын өйрәнүдә кулланыла торган ысуллар:

а) тарихи-чагыштырмалы ысул;

б) ареаль ысул (лингвистик география);

в) типологик ысул.

Болар арасында беренчел дәрәҗәдә әһәмияткә ия булган төп ысул (метод) булып чагыштырмалы-тарихи ысул санала.

**Тарихи-чагыштырмалы ысул (компаративистика)** тел белемендә XIX йөз башларында ачыла һәм, башлап, Һинд-Европа семьялыгына кергән телләрнең тарихын өйрәнүдә кулланыла. Төрки компаративистиканың башлануы исә XIX йөзнең II яртысына карый, һәм ул күренекле тюрколог галимнәр О. Бётлинг, В.В. Радлов, В. Томсен һ.б. исемнәре белән бәйле. Алга таба исә төрки телләрне тарихи-чагыштырмалы ысул белән өйрәнүгә П.М. Мелиоранский, В.А. Богородицкий, Г. Рамстедт, М. Рясянен, А.Җ. Эмре, А.М. Щербак һ.б. галимнәр зур өлеш кертә.

Хәзерге фәндә телләр тарихын өйрәнүдә бу ысулны куллануның төп нигезләмәсе һәм алымнары шактый ачык билгеләнгән[1].

---

[1] Карагыз: Общее языкознание (Методы лингвистических исследований). М.: Наука, 1973. С. 34–101; Сравнительное изучение языков разных семей (Теория лингвистической реконструкции). М.: Наука, 1988. С. 90–105; 181–189; *Щербак А.М.* Сравнительная фонетика тюркских языков. Л.: Наука, Ленингр. отд-ние, 1970. С. 9–24; Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Фонетика. М.: Наука, 1984. С. 3–15.

*Тарихи-чагыштырмалы ысул дип кардәш телләрнең тарихын үзара чагыштырып өйрәнгәндә кулланыла торган фәнни-тикшерену ысуллары җыелмасын – системасын атыйлар.*

Бу ысулны куллану бер телдән үсеп чыккан кардәш телләрнең, борынгы нигез телдән башлап, тарихи үткәнен күзаллауны һәм аларның үсеш-үзгәреш закончалыкларын ачыклауны күз алдында тота.

Тарихи-чагыштырмалы ысул нәрсәләргә нигезләнә?

1. Борынгы нигез тел булу, аның таркалуы һәм аннан төрле кардәш телләр аерылып чыгуга нигезләнә.

Төрки телләр тарихында борынгы нигез телнең хронологик яктан ике халәте аерып карала: а) **борынгы төрки нигез тел** (пратюркский язык), ул төрки телләрнең язу белән теркәлгән үткәненә, ягъни безнең эраның VI–VII йөзләренә, Орхон-Енисей язмалары чорына нисбәтләнә; ә) **иң борынгы төрки нигез тел** (прототюркский язык) язу барлыкка килгәнгә кадәрге, ягъни тагын да борынгырак чорларны үз эченә ала.

2. Тарихи-чагыштырмалы ысул үзара кардәш булган телләрдә тарихи үзгәрешләрнең төрлечә дәрәҗәдә булуына нигезләнә.

Билгеле булганча, төрки телләр классификациясендә борынгылыкны күбрәк саклаган һәм шулай ук тарихи үзгәрешкә ныграк дучар булган «яңа» телләр аерып карала.

3. Тарихи-чагыштырмалы ысул тел төзелешенең төрле ярусларында тарихи үзгәрешләрнең бердәй булмавына һәм шулай ук тел төзелеше тулаем һәм берьюлы үзгәрмәвенә нигезләнә. Бу исә телнең, коммуникатив чара буларак, үзенең бөтенлеген саклау закончалыгы белән аңлатыла. Һәр аерым телнең үз эчендә дә төрле дәрәҗәдәге үзгәрешләр булырга мөмкин. Гадәттә тарихи үзгәреш кичергән берәмлекләр һәм бик борынгы күренешләр телдә берлектә яши. Максат – борынгылык күренешләрен билгеләү һәм тарихи үзгәрешләрне төрки нигез телгә мөнәсәбәттә ачыклау.

4. Бу ысул шулай ук аерым төркемгә караган телләрдәге структур үзенчәлекләр башка телләр өчен дә уртак булуы мөмкинлегенә нигезләнә (типология).

5. Тарихи-чагыштырмалы ысул телләрнең кардәшлеген билгеләүдә һәм кардәш телләрне чагыштырып өйрәнгәндә иң беренче

чиратта **даими аваз тәңгәллекләренә** нигезләнә. Чагыштырыла торган берничә телдә сүзнең төрле позицияләрендә даими рәвештә бер аваз икенче аваз белән алышынса, бу күренеш ул телләрнең генетик яктан кардәш булулары турында сөйли. Тарихи аваз тәңгәллекләренең даими һәм закончалыклы булуы – бер сүздә барлыкка килгән аваз үзгәрешенең сүзнең шул ук позициясендә (сүз башы, сүз ахыры һ.б.) телдәге барлык сүзләрдә дә чагылыш табуы дигән сүз. Әгәр дә нинди дә булса аерым сүздә ул закончалык бозыла икән, ул сүз алынма, яки аның үзенчәлекле яңгырашы башка сәбәпләргә бәйле булырга мөмкин.

**Кыпчак** һәм **угыз** төркеменә кергән төрки телләр өчен, мәсәлән, сүз башында *т – д, к– г* даими аваз тәңгәллеге хас.

| **татар теле** (кыпчак төркеме): | **төрек теле** (угыз төркеме): |
|---|---|
| күз | göz (гёз) |
| күр- | gör (гёр) |
| күзлек | gözliik (гёзлүк) |
| теш | diş (диш) |
| тар | dar (дар) |
| төз | düz (дүз) |

Татар телендәге һәм аның аерым сөйләшләрендәге т – д, к – г чиратлашуын да (*тары – дары, кәрәз – гәрәз, дулкын – тулкын*) тикшеренүчеләр угыз телләре үзенчәлегенең татар телендә чагылышы дип билгелиләр.

Гадәти төрки телләр (шул исәптән татар теле) һәм чуваш теле өчен, мәсәлән, шундый ук закончалыклы фонетик күренеш – *р – з, л – ш* тәңгәллеге хас:

| | **татар теле:** | **чуваш теле:** |
|---|---|---|
| *р – з* | йөз | čер |
| | кондыз | хӑнтӑр |
| | кыз | хер |
| | тугыз | тӑхӑр һ.б. |
| *л – ш* | кыш | хӗл |
| | биш | пилӗк |
| | ишек | алӑк |
| | алтмыш | утмӑл һ.б. |

Телләр кардәшлеген нигезләүдә аваз тәңгәллекләренә өстенлек бирү нәрсә белән аңлатыла соң? Телдәге тарихи үзгәрешләр, билгеле, тел төзелешенең төрле берәмлекләрендә (тамыр, кушымча, сүзформа) чагылыш таба. Әмма кардәш телләрдә бу үзгәрешләр күпчелек очракта шул ук аваз тәңгәллекләренә, яки авазларның төрлечә дәрәҗәдәге ассимилятив үзгәрешләренә кайтып кала. Мәсәлән, хәзерге татар телендәге *тугыз* саны (лексемасы) башка төрки телләрдә асылда фонетик яктан гына төрлечә яңгыраш ала: *toguz* (рун), *toğuz* (казах), *doğğuz* (азәрб.), *tăxăr* (чуваш), *tuğyz* (татар) һ.б.

Тарихи-чагыштырмалы ысулның хәзерге телдә кулланыла торган төп алымнарыннан берсе – **реконструкция** алымы. Ул бер уртак нигез телдән үсеп чыккан телләрнең иң борынгы чыганагын, ягъни **нигез телнең** төп структур элементларын ачыклауны максат итеп куя. Билгеле булганча, тарихи рәвештә язу белән теркәлмәгән бик борынгы нигез телне җанлы хәлендә реконструкцияләү мөмкин түгел. Бу очракта кардәш телләрне үзара чагыштыру юлы белән борынгы телнең аерым структур үзенчәлекләрен, мәсәлән, сузык һәм тартык авазларның санын, составын; грамматик үзенчәлекләрдән исә сүз төркемнәрен, аерым грамматик категорияләрне, мәсәлән, исемдә килеш, фигыльдә заман формаларын һ.б. ачыклау күздә тотыла.

Хәзерге фәндә нигез тел ул борынгыда ук якын кардәш телләр җыелмасы булган дигән караш өстенлек итә. Төрки телләргә карата да галимнәр шул ук фикердә торалар. Ягъни иң борынгы нигез тел, прототөрки тел үзе дә аерым бер үзгәрмәс бербөтен күренеш түгел, ә төрле диалекталь төркемнәр җыелмасыннан торган дигән карашка өстенлек бирелә. Шуңа бәйле рәвештә хәзерге төрки телләрдәге кайбер аермалыклар, мәсәлән, сүз башында *б – м* тәңгәллеге (*бән – мĕн – мин*) шулай ук *ә – и* күчеше дә борынгы диалекталь үзенчәлекләрнең саклануы булырга мөмкин икәнлеге дә инкяр ителми.

Борынгы формаларны чагыштыру юлы белән ачыклау өчен тышкы һәм **эчке реконструкция** алымы кулланыла.

**Тышкы реконструкция** алымында үзара якын һәм чагыштырмача ерак кардәшлектә торган тел күренешләрен чагыштыру билгеле бер эзлеклелектә алып барыла. Әйтик, аерым татар теле

тарихын өйрәнүгә мөнәсәбәтле рәвештә телләрне чагыштыру түбәндәге тәртиптә алып барылырга тиеш булыр иде:

1. Әдәби тел, диалектлар, сөйләшләр;

2. Бер төбәктә яшәгән якын кардәш телләр (татар, башкорт, чуваш телләре);

3. Бер этник төркемгә кергән, ягъни кыпчак төркеме телләре;

4. Гомумтөрки телләр;

5. Алтай семьялыгына кергән телләр (монгол, тунгус-маньчжур телләре һ.б.).

**Эчке реконструкция** һәр телнең үз эчендә чагылыш тапкан тарихи үзгәрешләрне ачыклауга нигезләнә. Алдарак искәртелгәнчә, һәр аерым телдә борынгы тел күренешләре һәм тарихи үзгәреш кичергән яңа күренешләр берлектә яши. Мәсәлән, татар телендә бер тамырга караган *азак (азагы)* һәм *айак* сүзләре кулланыла. Бу сүзләрнең кайсы борынгырак дигән сорау туа. Бу очракта шул ук тарихи аваз тәңгәллекләренә *(з – й)* мөрәҗәгать итәбез:

*Ийгелек – изгелек,*

*Айак – азак,* димәк *й-з* тәңгәллегендә *з* һичшиксез борынгырак. Бу очракта тышкы реконструкциягә мөрәҗәгать итәргә дә мөмкин:

*Қойо – қузуғ*

*Бийек – бәзүк* һ.б.

Шулай ук, мәсәлән, татар әдәби телендә һәм диалектларда *энә* сүзе ике вариантта *инә – энә* рәвешендә кулланыла. Бу очракта *и* авазының борынгырак булуы Идел буендагы төрки телләрдәге сузыклар күчеше белән аңлатыла *(и > ĕ)*.

Реконструкция ысулы белән табылган тел берәмлекләре тарихи-чагыштырмалы ысул белән эзләнүләрдә башлангыч санау ноктасы буларак карала һәм алар тел тарихы буенча хезмәтләрдә теге яки бу тел берәмлегенең иң борынгы үрнәге, ягъни **архетибы** буларак билгеләнә. Гадәттә архетип *(йолдызчык) белән күрсәтелә (мәсәлән, төрки телләрдәге ачык әйтелешле **а* авазы).

Аерым телләрнең тарихын (тарихи грамматикасын) һәм кардәш телләрнең чагыштырмалы-тарихи грамматикасын өйрәнгәндә шулай ук **ареаль ысул** да кулланыла.

**Ареаль ысул**ны икенче төрле лингвистик география ысулы дип тә атыйлар, кардәш телләрнең төрле этник төркемнәре (төрки

телләрдәге кыпчак төркеме, угыз төркеме, карлук төркеме), шулай ук бер үк телнең төрле диалектлары һәм сөйләшләре арасында тарихи-территориаль бәйләнешләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән уртак тел күренешләрен (изоглоссаларны) ачыклауны күздә тота. Асылда кыпчак төркеменә кергән татар телендә, мәсәлән, угыз телләренә хас үзенчәлекләрнең дә саклануы бу кабилә телләренең тарихи рәвештә тыгыз бәйләнештә булулары турында сөйли.

Тел тарихын өйрәнүдә ареаль ысул шулай ук тарихи рәвештә бер төбәктә (ареалда) яшәгән, үзара турыдан-туры кардәш булмаган яки ерак кардәшлектә булган телләрнең үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән тел күренешләрен ачыклаганда да кулланыла. Тел тарихы өчен бу җәһәттән татар теленең угро-фин төркеменә кергән мари, мордва, удмурт һ.б. телләр белән үзара бәйләнешен өйрәнү гаять мөһим. Галимнәр, мәсәлән, татар һәм башкорт телләрендә *а* авазының иренләшүен һәм чуваш телендә *а* > *у* күчешен, шулай ук чуваш һәм хакас телләрендә сүз башы тартыкларының саңгыраулашуын (саңгырау анлаут) угро-фин телләре тәэсире дип карыйлар.

**Типологик ысул** исә үзара кардәш булмаган телләрнең тарихи үсеш-үзгәрешендә дә аерым уртаклыклар булуга нигезләнә. Дөнья телләрендә типологик уртаклыклар яки аерымлыклар тел төзелешенең төрле өлкәләрендә (фонетика, грамматика һ.б.) чагылыш табарга мөмкин. Фонетикада, мәсәлән, телнең фонологик төзелешендә бу күренеш сузык һәм тартыклар пропорциясендә дә күренә. Әйтик, татар телендә 12 тартык, 28 сузык аваз булса, рус телендә 6 сузык, 37 тартык аваз санала, һәм бу очракта инде без рус һәм татар телләрендәге типологик аерымлыклар турында сүз алып барырга тиеш булабыз. Төрле телләр өчен хас типологик уртаклыклардан исә галимнәр ике сузык уртасында саңгырау тартыкларның көчсезләнүе, ягъни яңгыраулашуын, сүз ахырында *н* сонор тартыгының төшеп калуын, тотрыксыз булуын (мәсәлән, татар телендә: *белән – белә; илән – илә),* шулай ук сүз башы позициясе – анлаутта авазлар өстәлү күренешен *(әйбәт – һәйбәт, йокы – уйку)* һ.б. күрсәтәләр. Типологик закончалыклардан А.М. Щербак, мәсәлән, сүз эчендә геминатлар (кушык тартыклар) куллану интервокаль позициядә тартыклар яңгыраулашу күренеше булган телләр өчен генә хас булуын билгели. Шул рәвешле, алда саналган

фәнни ысуллар: тарихи-чагыштырмалы ысул, ареаль ысул, типологик ысул телләр тарихын өйрәнгәндә берлектә кулланыла, алар бер-берсен тулыландыралар.

**4. Татар һәм төрки тел белемендә тел тарихын өйрәнүнең торышы.**

1. Татар теленең тарихын, аның тарихи грамматикасын өйрәнүгә багышланган махсус хезмәтләр чагыштырмача соң, узган гасырның урталарында гына мәйданга чыга башлый. Бу уңайдан, иң беренчеләрдән, күренекле диалектолог һәм тел тарихчысы Латыйф ага Җәләй хезмәтләрен искә алырга кирәк. Галимнең 1954 елда чыккан «Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар»[1] дигән хезмәтендә татар телендәге сузык һәм тартык авазлар өлкәсендәге тарихи үзгәрешләр шактый эзлекле яктыртыла, һәм андагы күп кенә фикерләр бүгенге тел тарихы фәне өчен дә әһәмиятен югалтмаган. Иң кыйммәтлесе шунда, галим телдәге тарихи үзгәрешләрне аңлатканда, башка төрки телләргә һәм татар теленең диалект һәм сөйләшләренә дә мөрәҗәгать итә. Л. Җәләйнең икенче капиталь хезмәте телебезнең грамматик төзелешен (морфологиясен) тарихи юнәлештә өйрәнүгә багышланган. Бу хезмәт профессор Л. Җәләйнең университет студентларына тел тарихы буенча укыган лекцияләренең кульязмалары нигезендә төзелгән, һәм ул махсус китап рәвешендә 2000 елда басылып чыкты[2].

Татар теленең тарихи грамматикасын өйрәнүгә нигез салган икенче бер әһәмиятле хезмәт – ул В.А. Богородицкийның «Введение в татарское языкознание» дигән хезмәте[3].

В.А. Богородицкий – Казан лингвистика мәктәбенең күренекле вәкиле, СССР Фәннәр Академиясенең мөхбир әгъзасы, Казан дәүләт университеты профессоры, русист галим. Аның татар телен өйрәнүгә багышланган әлеге хезмәте узган гасырның 30 нчы

---

[1] *Җәләй Л.* Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. Казан: Таткнигоиздат, 1954.

[2] *Җәләй Л.* Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар). Казан: Фикер, 2000 (Китапны төзү һәм матбугатка хәзерләү эшен Ф.С. Фәсиев башкарган. Кульязмаларны хәзерләүдә шулай ук фәннәр докторы Ф.Ю. Юсупов һәм Ә. Латыйпов катнашкан).

[3] *Богородицкий В.А.* Введение в татарское языкознание. Казань: Татгосиздат, 1953.

елларында ук дөнья күрә. Әмма хәзерге фәнни җәмәгатьчелеккә аның күбрәк икенче, 1953 елда кирилл әлифбасында басылган нөсхәсе билгеле. Бу басманың редакторы – зур тюрколог галим Н.К. Дмитриев. Редактор үзенең кереш мәкаләсендә В.А. Богородицкий хезмәтенә югары бәя бирә, ул аны төрки телләрне өйрәнүдә башлап тарихи-чагыштырмалы ысулны уңышлы кулланган галим буларак билгели. Тарихи грамматиканы өйрәнү җәһәтеннән бу хезмәттә «Фонетика» бүлеге аеруча әһәмиятле. Татар теленең вокализмын (сузыкларны) һәм консонантизмын (тартыклар системасын) чагыштырмалы ысул белән тикшерүгә багышланган бу бүлектә авазлар башта сыйфатлары, ягъни ясалыш һәм әйтелеш үзенчәлекләре буенча рус теле авазлары белән чагыштырыла, һәм һәр ике телдәге авазларның типологик юнәлештә уртак һәм үзенчәлекле яклары ачыклана. Галим, мәсәлән, рус һәм татар телендә бары тик ике сузык аваз *у* һәм *и* авазларының гына төп билгеләр буенча охшаш булуларын, шулай ук татар телендә *а* сузыгының, иренләшү төсмереннән тыш, арттарак ясалуын (...имеет более глубокую артикуляцию), *о (ө)* авазларының бик кыска әйтелешен һәм күтәрелеш буенча рус телендәге *д* авазыннан таррак булуын һ.б. билгели. Шунысы әһәмиятле, галим бу нәтиҗәләрен экспериментал фонетика ысуллары белән дә дәлилли. В.А. Богородицкий хезмәтенең икенче өлеше исә турыдан-туры татар теле авазларын тарихи яссылыкта өйрәнүгә багышланган. Бу юнәлештә татар теле авазлары төрки телләр – төрек, алтай, казах телләре һәм шулай ук чуваш, монгол телләре белән чагыштырыла. Шуны да искәртеп үтәргә кирәк, В.А. Богородицкийның бу хезмәте татар теленең тарихи грамматикасы буенча беренче гаять җитди хезмәт булу белән бергә, ул гомумән төрки телләрнең чагыштырмалы-тарихи грамматикасын өйрәнүгә дә зур өлеш кертә, анда, мәсәлән, төрки телләрнең тартыклар һәм сузыклар системасын чагыштырып өйрәнү, Идел буендагы сузыклар күчеше, төрки телләрдәге монгол телләре белән фонетик уртаклыклар һ.б. мәсьәләләр гаять җитди фәнни югарылыкта анализлана[1].

---

[1] В.А. Богородицкий хезмәтендә татар авазлары тарихына караган мөһим фикерләр алдагы бүлекләрдә тәфсиллерәк шәрехләнә.

Татар теле белемендә 50 нче елларда шулай ук тарихи фонетика мәсьәләләренә багышланган махсус тикшеренүләрдән телче галим Л.И. Яфаров хезмәтләрен билгеләп үтәргә кирәк[1]. Узган гасырның 70 нче елларыннан башлап университетта татар теленең тарихи грамматикасы гомуми тел тарихы фәненнән аерылып, «Татар теленең тарихи грамматикасы» һәм «Татар әдәби теле тарихы» буларак укытыла башлады. Шул уңайдан һәр ике фән буенча уку-укыту программалары, укыту-методик әсбаплар төзелә башлады. Мәсәлән, 1975 елда А.Х. Нуриеваның «Татар теле тарихыннан материаллар» дигән дәреслек-кулланмасы һәм күнегүләр җыентыгы басылып чыкты[2].

Тел тарихын өйрәнү гомумән шул телнең хуҗасы булган халык тарихын өйрәнү өчен дә әһәмиятле алшарт булып тора. Татар халкы, аның этногенезы «болгар» мәсьәләсенә бәйле рәвештә күренекле галим, тел тарихчысы Р.Г. Әхмәтьяновның татар һәм чуваш телләрен чагыштырып өйрәнүгә багышланган монографик хезмәтләре чыгу тарихи грамматиканы өйрәнүгә җитди этәргеч булды[3]. Бу уңайдан шулай ук галимнең әле соңгы елларда чыккан этимологик сүзлеген һәм татар терминологиясе тарихына багышланган хезмәтен дә искә алырга кирәк[4].

2. Төрки телләрнең тарихын, шул исәптән тарихи-чагыштырмалы грамматикасын өйрәнү, алдагы бүлекләрдә әйтелгәнчә, XIX йөз урталарыннан ук башлана. Бу өлкәдәге беренче җитди тикшеренүләр чит ил тюркологлары О. Бётлинг, В. Томсен, В.В. Радлов исемнәре белән бәйле. Соңгырак чорда исә төрки телләрне тарихи-чагыштырмалы ысул белән өйрәнүгә В. Грёнбек, В. Банг, Х. Педерсен, Ф.Е. Корш, К. Фой, П.М. Мелиоранский,

---

[1] *Яфаров Л.И.* Некоторые тенденции в фонетике татарского языка: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1955.

[2] *Нуриева А.Х.* Татар теле тарихыннан материаллар. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1975.

[3] *Ахметьянов Р.Г.* Сравнительное исследование татарского и чувашского языков. М.: Наука, 1978.

[4] *Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге. Дүрт томда. Т. 1 (А–Й). Бирск. 2005. Әхмәтьянов Р.Г. Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.

Г. Рамстедт, Ю. Немет, М. Рясянен, К.Г. Менгес һ.б. галимнәр җитди өлеш кертәләр.

Россия тюркология фәнендә төрки телләр тарихын тарихи чагыштырмалы ысул белән өйрәнү эшен күренекле тюрколог галим Н.К. Дмитриев башлап җибәрә. Аның турыдан-туры җитәкчелегендә узган гасырның илленче елларында СССР Фәннәр академиясенең Тел белеме институты төрки телләр бүлеге галимнәре тарафыннан төрки телләрне чагыштырмалы ысул белән өйрәнүгә багышланган 4 томлык капиталь хезмәт эшләнә, һәм ул 1955–1962 еллар арасында «Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков» дигән гомуми исем белән бастырып чыгарыла: «Фонетика» (1955 ел), «Морфология» (1956 ел), «Синтаксис (1961 ел), «Лексика» (1962 ел).

Бу хезмәттә төрки телләрне хәзерге халәтендә төзелеше буенча, ягъни авазлар составы, грамматик формалары, җөмлә төзелеше, сүзлек составы буенча үзара чагыштыру шактый зур урын алып тора. Шул ук вакытта анда тарихи якка да аерым сылтамалар (экскурслар) ясала, тарихи үзгәрешләрне анализлау тәҗрибәләре китерелә. Авторлар арасында Э.В. Севортян, Н.К. Дмитриев, Ф.Г. Исхаков, А.Н. Баскаков, А.А. Юлдашев һ.б. кебек зур тюрколог галимнәрнең булуы да бу күмәк хезмәтнең фәнни-методик дәрәҗәсе югары булуы турында сөйли.

Россия тюркология фәнендә төрки телләрне тарихи-чагыштырмалы ысул белән өйрәнү өлкәсендә хезмәт куйган һәм бай фәнни мирас калдырган башка бер галим, ул, һичшиксез, А.М. Щербак. 1970 елда А.Н. Щербакның төрки телләрнең тарихи-чагыштырмалы фонетикасы буенча күләмле хезмәте басылып чыга[1]. Дөнья тюркология фәне казанышларына таянып һәм аларны фәнни-тәнкыйди юнәлештә тәфсилле анализлап язылган бу хезмәт, бер үк вакытта бөтен төрки телләр һәм аларның диалектлары материалларына нигезләнгән булуы белән дә гаять зур фәнни-методик әһәмияткә ия.

Төрки телләр тарихын эзлекле өйрәнүне дәвам итеп, галим 1977–1987 елларда тарихи-чагыштырмалы морфология буенча

---

[1] *Щербак А.М.* Сравнительная фонетика тюркских языков. Л.: Наука, Ленингр. отд-ние, 1970.

очерклар рәвешендә өч томлык хезмәтен бастыра. 1993 елда басылган яңа хезмәте исә, галимнең төрки телләр тарихын өйрәнү буенча гомум теоретик мәсьәләләрне эченә алган йомгаклау хезмәте булып тора[1].

Төрки телләр тарихын, аның тарихи грамматикасын өйрәнүнең яңа этабы Мәскәү тюркологларының күренекле галим Әдһәм Рәхим улы Тенишев җитәкчелегендә төрки телләрнең чагыштырмалы тарихи грамматикасы буенча күптомлы һәм гаять зур фәнни кыйммәткә ия булган күмәк хезмәт язылуы белән характерлана. 1984–2006 елларда бастырып чыгарылган алты томлык бу хезмәт алга таба аерым төрки телләрнең тарихи грамматикасын өйрәнү өчен дә ышанычлы фәнни-теоретик нигез булып тора[2].

Әлеге хезмәтнең беренче дүрт томы төрки телләрнең төзелеше буенча төрле тармакларын (фонетика, морфология, синтаксис, лексикология) тарихи-чагыштырмалы ысул белән өйрәнүгә һәм шулар нигезендә иң соңгы чордагы[3], борынгы нигез телнең төп структур үзенчәлекләрен ачыклауга, ягъни борынгы төрки нигез телне реконструкцияләүгә багышланган. Аларда шулай ук тагын да борынгырак чорларга, иң борынгы нигез тел үзенчәлекләрен ачыклауга да аерым экскурслар ясала[4].

Региональ реконструкцияләргә багышланган бишенче том[5] төрки телләрнең төрле этник төркемнәре һәм аларның борынгы

---

[1] *Щербак А.М.* Очерки по сравнительной морфологии тюркских языков. (Имя), Л.: Наука, Ленингр. отд-ние, 1977; Щербак А.М. Очерки по сравнительной морфологии тюркских языков. (Глагол), Л.: Наука, Ленингр. отд-ние, 1981; Щербак А.М. Очерки по сравнительной морфологии тюркских языков (Наречие, служебные части речи, изобразительные слова). Л.: Наука, Ленингр. отд-ние, 1987.

[2] *Щербак А.М.* Введение в сравнительно-историческое изучение тюркских языков.

[3] «Соңгы чордагы төрки нигез тел» дигән төшенчә бу хезмәтләрдә «тюркский праязык периода распада» дип бирелә.

[4] Сравнительная грамматика тюркских языков. Фонетика. М.: Наука, 1984; Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Морфология. М.: Наука, 1988; Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Синтаксис. М.: Наука, 1986; Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика. М., 1999; М., 2001.

[5] Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Региональные реконструкции. М.: Наука, 2002.

нигез телләрен, ягъни борынгы угыз, борынгы кыпчак, борынгы карлук-уйгыр һ.б. нигез телләрне реконструкцияләү тәҗрибәсен үз эченә ала. Алтынчы, йомгаклау томында[1] исә алдагы томнардагы мәгълүматлар гомумиләштерелә, яңа фәнни казанышлар нигезендә аерым төгәллекләр кертелә. Бу томның икенче бүлеге тел материаллары нигезендә борынгы төркиләрнең дөнья картинасын өйрәнүгә багышланган. Бу бүлек бер үк вакытта төрки халыкларның бай лексик мирасын тарихи юнәлештә өйрәнү ягыннан да гаять әһәмиятле.

*2015*

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ДӘРӘҖӘ КАТЕГОРИЯСЕ

### (Аспектуальлек)

**Гомуми төшенчә.** Эшнең үтәлү дәрәҗәсен белдерү – төрки телләр өчен үзенчәлекле лексик-грамматик категория. Ул эш-хәлнең үтәлешен төрле яклап – башлану, тәмамлану, дәвамлылык, кинәтлек, кабатлану, юнәлгәнлек һ.б. яклардан характерлый һәм төрле аналитик (ярдәмче фигыльләр) яки синтетик чаралар (кушымчалар) белән белдерелә: *әйтте* ~ ***әйткәләде,*** *күрде* ~ ***күргәләде,*** *көлде* ~ ***көлемсерәде,*** *килде* ~ ***килеп җитте,*** *укыды* ~ ***укып чыкты,*** *җырлады* ~ ***җырлап җибәрде,*** *басты* ~ ***басып торды*** һ.б.

Дәрәҗә категориясе астында берләштерелгән төрле тел чаралары мәгънәләре буенча күпмедер дәрәҗәдә славян телләре өчен хас, аерым алганда, рус телендәге *вид* (төр) категориясе белән уртаклык күрсәтә, әмма төрки телләрдәге дәрәҗә эшнең дәвамлы булуы яки тәмамлануы буенча бер-берсенә капма-каршы куелган бинар *вид* категориясеннән шактый нык аерыла. Телләр типологиясендә төрки телләрдәге дәрәҗә күбрәк эш-хәлнең үтәлү рәвешен, үтәлү характерын белдерә торган аспектуальлек чарасы буларак билгеләнә. «Эшнең үтәлү ысулын белдерү аспектуаль

---

[1] Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык – основа. Картина мира. М.: Наука, 2006.

мәгънәгә карый, чөнки аспектуальлек эшнең үтәлү характерын һәм вакыт эчендә бүленешен белдерә»[1].

Дәрәҗә категориясе татар телендә ике төрле юл белән белдерелә: а) фигыль нигезенә ялганып килгән махсус кушымчалар белән (синтетик юл): *кил-**гәлә**, бар-**гала**, көл-**емсерә**, яз-**ыштыргала*** һ.б.; ә) хәл фигыль формалары янында килгән ярдәмче фигыльләр белән (аналитик юл): *бар**ып җитте**, кайт**ып китте**, яз**ып утыра**, яшә**п ята**, аш**ый калды**, сөйл**и тора**, бар**а тор*** һ.б.

**Эшнең үтәлү дәрәҗәсен кушымчалар ярдәмендә белдерү.** Эшнең үтәлү дәрәҗәсен синтетик юл белән белдерү татар телендә әллә ни киң таралган күренеш түгел. *-гала/-гәлә, -ыштыр/-ештер, -ынкыра/-енкерә, -ымсыра/-емсерә, -ыштыргала/-ештергәлә* тибындагы катлаулы төзелешле кушымчалар аерым фигыль нигезләренә генә ялганып киләләр, аларда башка форма ясагыч кушымчаларга хас универсальлек юк. Мәгънәләренә килгәндә, мәсәлән, *-гала/-гәлә* кушымчасы күбрәк эшнең кабатлануын белдерә: *баргала, килгәлә, әйткәлә, әйләнгәлә* һ.б.

*Кичә-кичә кырыс гасырны, Кил, **килгәлә** миңа хатыңда, Юлдаш булып һәрбер адымда* (Х. Туфан). *Иртән болытлар **күренгәләп,** карлар **очкалап торды...*** (Ф. Хөсни). *Һәр тарафка тәмле исләр **чәчкәли** бу чәчкәләр* (Г. Тукай)

Д.Г. Тумашева *-гала/-гәлә* кушымчасының аерым очракларда процессның тулы булмавын белдерүен һәм яңа сүз ясау мөмкинлеген дә билгели. Мәсәлән: *кубу ~ купкалау. Мичнең акшары **купкалаган*** (сөйл. т.); *өзү ~ өзгәләнү. **Өзгәләнә** күңел* һ.б.;

*-ыштыр/-ештер, -штыр/-штер* кушымчасы эшнең тоташтан түгел, ара-тирә эшләнүен яки кабатлануын белдерә: *яз ~ языштыр, кара ~ караштыр* һ.б.

*Утырабыз. **Сораштырып чыктык** Бергә йөргән шәрикташләрне* (Р. Фәйзуллин).

Әмма сөйләмдә ул, күбрәк *-гала/-гәлә* кушымчасы белән бергә килеп, кабатлану мәгънәсе катыш ара-тирә башкарылган эшне белдерә: *уйна ~ уйнаштыргала, эшлә ~ эшләштергәлә, сөйлә ~ сөйләштергәлә* һ.б.

---

[1] Татар грамматикасы: 3 томда. II т. М.; Казан. 2002. Б. 223.

*-ынкыра/-енкерә, -нкыра/-нкерә* кушымчасы аерым фигыльләр белән генә килә, эшнең өлешчә үтәлүен белдерә: *җитми ~ җитенкерәми, тартына ~ тартынкырый.*

*-ымсыра/-емсерә* кушымчасы шулай ук эшнең өлешчә үтәлүен, кимлеген белдерә: *көлә ~ көлемсери, елый ~ еламсырый, йоклый ~ йокымсырый.*

**Эшнең үтәлү дәрәҗәсен аналитик юл белән белдерү.** Дәрәҗә белдерә торган аналитик төзелмәләр хәл фигыльләр нигезендә ясала, һәм ярдәмче рольдә бу очракта мөстәкыйль мәгънәле фигыльләр килә. Бу төзелмәләрнең ике структур тибы бар:

1) *-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыль һәм ярдәмче фигыль *(ба****рып җитте,*** *кайт****ып китте,*** *бас****ып тора)*****;**

2) *-а/-ә (-ый/-и)* кушымчаны хәл фигыль һәм ярдәмче фигыль *(бар****а тора,*** *сөйл****и бирә,*** *кил****ә башлады).***

Ярдәмче рольдә түбәндәге фигыльләр килә: *башла, җибәр, куй, кит, сал, төр, утыр, ят, йөр, бар, кил, яз, кал, кара, бак, төш, ат, ал, бир, җит, җиткер, бет, бетер, чык, чыгар.*

Бу ярдәмче фигыльләр, төп лексик мәгънәне белдергән хәл фигыль формаларыннан соң килеп, эш-хәлне аспектуаль яктан төрлечә төсмерләндерәләр, ягъни аңа башлану, дәвамлылык, кинәтлек, тәмамлану кебек төсмерләр өстиләр. Бу формалар телебез өчен табигый һәм сөйләмдә еш очрый торган күренеш. Алар һәр җөмләдә диярлек кулланыла, кабатланып та киләләр. Мәсәлән:

*Кара болыт, зәңгәр итәген өстерәп, бирегә таба* ***килә башлады.*** *Монда әле бер тамчы да төшкәне юк. Табигать үз өстенә килгән дәһшәттән курыккан кебек* ***сагаеп калды:*** *яңа гына күңелле* ***шаулап утырган*** *агачлар, яфрак та кагарга базмыйча, юаш кына* ***басып торалар,*** *тик усак кына әллә нигә бер* ***калтыранып куя.*** *Кошлар әллә кая китеп югалды* (И. Гази).

Дәрәҗә белдерә торган мондый аналитик төзелмәләрнең фигыльнең алдагы бүлекләрдә өйрәнелгән һәртөрле аналитик формаларыннан (хикәя фигыль заманнары, *бул* белән ясалган тасвирлама формалар, модаль мәгънә белдерә торган аналитик фигыльләр һ.б.) аермалы ягы шунда: биредә төп фигыльне төсмерләндерүче ярдәмче фигыльләр, гадәттә, нигез составында

каралалар. Дәрәҗә формалары грамматик хезмәтләрдә аналитик нигезле фигыльләр дип йөртелә. Аналитик нигезле фигыль үзе дә сөйләмдә күптөрле аналитик һәм тасвирлама формаларда килә ала. Шул рәвешле, үзендә төрле аспектуаль, модаль һәм заман төсмерләрен берләштергән үтә катлаулы фигыль формалары да ясала. Мәсәлән: *килеп җиткән иде, барып кайтмакчы булган иде, әйтеп куя торган иде* һ.б.

Дәрәҗә формалары белдергән аспектуаль мәгънәләр үз эчләрендә берничә төргә аерып карала:

а) эшнең үтәлү рәвешен (ысулын) һәм вакыт эчендә бүленешен белдергән формалар;

ә) эшнең субъект-объектка карата юнәлешен (ориентациясен) белдергән формалар;

б) модаль мәгънә белдерә торган аналитик нигезле фигыльләр.

***1. Эшнең вакытка мөнәсәбәтле үтәлү характерын белдерә торган фигыльләр***. Бу типтагы дәрәҗә формалары кулланылыш ешлыгы буенча да, күптөрле төсмерләрне белдерүләре буенча да телдә аерым урын алып торалар. Эшнең үтәлү дәрәҗәсен татар телендә башлап һәм гаять әтрафлы итеп өйрәнгән галим Ф.Ә. Ганиев, мәсәлән, аларны төркемли һәм түбәндәге дәрәҗә формаларын аерып күрсәтә: башлану, дәвамлылык, кинәтлек, кабатлану, өлешчә үтәлү, нәтиҗә һәм тәмамлану дәрәҗәләре [Ганиев, 1963].

1) Эш-хәлнең башлануы күбрәк *-а/-ә (-ый/-и)* кушымчалы хәл фигыль һәм *башла* ярдәмче фигыле белән белдерелә: *ала башлады, укый башлады, көлә башлады, сөйли башлады* һ.б.

*Ярты сәгатькә генә туктап торган яңгыр төштән соң кабат* ***ява башлады*** (Ф. Гыйльметдинов). *Игеннәр күзгә күренеп калка, буынга утыра, баш чыгара. Чөгендер, бәрәңге басуларының кара җире* ***күренми башлый*** (А. Гыйләҗев).

2) Эшнең көтелмәгәндә, кинәт башлануы исә *-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыль һәм *җибәр, сал, кит, ал* ярдәмче фигыльләре белән белдерелә: *кычкырып җибәрде, куркып китте, әйтеп салды, күреп алды* һ.б.

*Марат* ***сискәнеп китте*** (Ф. Латыйфи). *Төшкә таба күк йөзе ачылып, көн бөтенләй* ***аязып китте,*** *кояш язча* ***көлеп***

***җибәрде*** (Ф. Хөсни). *Бөркәүләр астыннан елау, сыктау авазлары ишетелүен Морат бәк шунда гына* ***абайлап алды*** (Ф. Латыйфи). *Әнә берсе, кулларын чалбар кесәсенә тыгып, башын бераз артка ташлады да* ***җырлап җибәрде*** (М. Мәһдиев).

3) Дәвамлы эш-хәлләрне белдерү өчен, телдә күптөрле аналитик төзелмәләр кулланыла:

а) *ят, тор, утыр, кал, йөр, бар* ярдәмче фигыльләре, *-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыль белән килеп, эшнең дәвамлы булуын, билгеле бер халәттә тукталып калуын белдерәләр: *яшәп ята, басып тора, үсеп утыра, кайтмый калды, эшләп йөри* һ.б.

*Без, шул тирә-як малайлары, Галләм абзыйның кайтканын дүрт күз белән* ***көтеп торабыз...*** (Ф. Хөсни). *Әлегә эреп бетмәгән уйдык-уйдык бозларга, йөгерек гөрләвекләргә таң качып* ***карап тордым*** (Г. Сабитов). *Йолдызлар сүнделәр, ай* ***агарып калды*** (Г. Әпсәләмов). *Күпер башында малайлар, көрәкләр күтәреп, гөрләвек* ***агызып йөриләр.*** *Хәлим дә шунда йөгерде. Их, аның да көрәге булса!* (И. Гази). *Безнең авыл да, менә шушы Ямаширмә шикелле, язгы кояш нурларында* ***балкып ятадыр*** (Г. Бәширов). *Буран бөтенләй* ***тынып калган*** (Г. Сабитов);

ә) *бар, йөр, кал, бир, тор* ярдәмче фигыльләре, *-а/-ә (-ый/-и)* кушымчалы хәл фигыльләр белән килеп, эшнең билгеле бер ноктадан башланып дәвам итүен белдерә: *кими бара, ашый калды, бара тора, сөйли бирә* һ.б.

*Максуд җитәр,* ***бара торгач*** *юл кыскарыр, Әллә кайда яткан хиссият кузгалыр...* (Г. Тукай). *Правление алдындагы күрсәткеч тактага Фазылҗанов узганда да, барганда да* ***күз сала йөри*** (Ф. Хөсни). *Өйалды ишеген ачуга, йөземә кояш җиле бөркелде. Шактый вакыт күзләремне* ***ача алмый тордым*** (Г. Сабитов) .*Иртәгә... мин сине Кукмарага кадәр* ***озата барам*** (Р. Сибат). *Әти, бүтәннәр белән* ***сөйләшә биреп,*** *минем я башымнан сыйпап куя, я иңбашыма тиеп ала* (Г. Бәширов);

б) *бар, кил, тор* ярдәмче фигыльләре, *-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыль белән килеп тә, дәвамлы эш-хәлләрне белдерә ала: *узып бара, үсеп килә, үсеп бара* һ.б.

*Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам, Әкрен-әкрен югарыга* ***үрләп барам*** (Г. Тукай). *Балалар* ***үсеп киләләр*** *инде* (сөйл. т.). *Менә тагын* ***узып китеп барам,*** *Уңда кала сезгә борылыш...* (И. Гый-

ләҗев). *Үзе **сөйләп тора,** кулы **эшләп тора,** чулпылары чылтырап ала* (Ф. Садриев).

4) б е р  г е н ә  т а п к ы р  яки  т и з  а р а д а  башкарылган эшләрне белдерү өчен, күбрәк *куй, ал, кит, ташла, уз* фигыльләре белән ясалган төзелмәләр кулланыла: *карап алды, әйтеп куйды, күренеп китте, сөйләп ташлады* һ.б.

*Сирай бабайның күңеле нәрсәдер сизенеп, каты **әрнеп куйды*** (Г. Сабитов). *Бераз киткәч, үр түбәсенә менеп җиткәч, ул, артына әйләнеп, Урманбаш авылына тагын бер **карап алды*** (Ф. Хөсни). *Кәүсәләре ап-ак булып та, ябалдашлары кап-кара каеннар кемгәдер рәнҗегән сыман **шаулашып алдылар*** (Г. Әпсәләмов). *Әкрен генә иртәнге салкын җил **исеп куйды*** (И. Гази). *Һәм шулчак әллә нинди хатирәләр, яшен ташыдай, зиһенне **яктыртып узды**.* (Ф. Латыйфи). *Әңгәмә **куерып китте*** (Г. Сабитов).

5) Эш-хәлнең, процессның  т ә м а м л а н у ы ,  а х ы р г а ч а  ү т ә л ү е  күбрәк *җит, җиткер, бет, бетер, чык* ярдәмче фигыльләре белән белдерелә: *кайтып җитте, китереп җиткерде, арып бетте, язып бетерде, укып чыкты* һ.б.

*Көтә-көтә **зарыгып беттем*** (Һ. Такташ). *Зариф станциягә **килеп җитте,** йөгереп платформага чыкты һәм як-ягына карарга өлгерә алмады, кара киемле бер рус хатыны: «Балам!» – дип кычкырып, Зарифка ташланды* (Ә. Еники). *Аннары бакча тирәли нихәтле агач **утыртып чыгарга** кирәк. Барысы да быел яз эшләнәчәк эшләр* (И. Гази). *Ул тәмәкесен **тартып бетерде** дә тагын үзенең эшенә тотынды* (М. Гафури). *Тиз **барып җиткән** егет, эшкә тотынган баргач ук* (Г. Тукай).

6) Эшнең  ө л е ш ч ә  ү т ә л ү е н  белдергәндә, аналитик фигыль, гадәттә, *-а/-ә* кушымчалы хәл фигыль һәм *төш* ярдәмче фигыле белән килә: *арый төште, матурлана төште, салкыная төште* һ.б.

*Төн **салкыная төште*** (И. Гази). *Менә күкрәген **киерә төшеп** барган паровозның кечкенә җиз торбасыннан кинәт ап-ак пар ишелеп йөзеп китә* (Ә. Еники). *Ачар кузгалып киткәч, Заһидә, янә бераз **бара төшеп,** юл буена чирәмгә утырды* (Ә. Еники).

*Төш* ярдәмче фигыле, *-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыль белән килгәндә исә эш-хәлнең  а х ы р г а ч а  ү т ә л ү е н  дә белдерә; бу очракта ул күбрәк хис-тойгыны, психологик халәтне тасвирлый: *коелып төште, сыгылып төште* һ.б.

*Туган телебез бетә, халкыбыз, тарихыбыз юкка чыга дип, күптән генәме башыбыз тәмам* ***сыгылып төшкән*** *көннәребез бар иде* (Г. Сабитов).

7) Эш-хәлнең үтәлү алдында тукталып калуы *яз (язды)* ярдәмче фигыле белән белдерелә: *егыла язды, әйтә язды, көлә язды* һ.б.

*Нәсимәнең әнисе Гыйльменур, Мәскәүдән килеп төшеп, малайга күз ташлау белән* ***егылып китә язды*** (Ф. Садриев). – *Кала уртасында* ***туңып үлә яздыгыз бит!*** *– диде ул. Беләсезме, күпме вакыт сез суыкта басып* ***торасыз*** (Ә. Еники).

***2. Эшнең субъект-объектка карата юнәлешен белдерә торган аналитик фигыльләр.*** Алар, башлыча, хәрәкәт фигыльләре катнашында ясала: *чыгып китте, килеп керде, йөзеп йөри, кайтып бара* һ.б.

Бу аналитик төзелмәләр күпмедер дәрәҗәдә рус телендәге приставкалар белән ясалган хәрәкәт фигыльләренә якын тора: *очып чыкты – вылетел, очып керде – влетел, чыгып китте – вышел, кайтып китте – ушёл* һ.б. Аналитик фигыльләрнең эшнең субъектка-объектка карата юнәлешен (ориентациясен) белдерүе соңгы вакытта Д.Г. Тумашева тарафыннан җентекләп тикшерелде. Галимә хәрәкәт фигыльләре белән ясалган төзелмәләрнең түбәндәге төрләрен аерып тикшерә[1]:

1) төп фигыль хәрәкәтнең ысулын белдерә, ярдәмче рольдә юнәлешкә ишарә итә торган фигыльләр килә: *очып китте, йөгереп килә* һ.б.;

2) аналитик төзелмәдә һәр икесе юнәлешне белдерә торган фигыльләр килә: *кайтып килә, килеп керде, чыгып китте* һ.б.;

3) төп фигыль – төрле мәгънәдә, икенче фигыль юнәлеш мәгънәсендәге хәрәкәт фигыле була: *күрешеп узу, эшләп кайту, җыелып чыгу, ишетеп кайту* һ.б.

*Ала каргалар да өер-өер түбән төшеп,* ***очып үтәләр*** (Р. Фәйзуллин). *Шәһәр өстендә ялт-йолт килеп уйнаган яшен ...өй түбәләре өстеннән кыйгачлап* ***йөгереп үтте*** (Г. Әпсәләмов). *Тимерчеләр цехына* ***барып керделәр.*** *Цех металл тавышы белән тулган* (Г. Әпсәләмов). *Алар... караңгы бакчалар аркылы Казанка*

---

[1] Татар грамматикасы: 3 томда. II т. М.; Казан. 2002. Б. 224–231.

*буена* ***төшеп киттеләр*** (И. Гази). *Көтә-көтә туңып беттем, ахры түзә алмагач, бер иптәш кызыма кереп* ***җылынып чыктым*** (Ә. Еники). *Ә ул онытмый иде. Һәйкәлләрне дә, исәннәрне дә... Мәскәү-Петербург музей-театрларын да* ***айкап кайта иде*** (Р. Юсупова).

Хәрәкәт фигыльләре белән ясалган мондый аналитик төзелешле фигыльләр эш-хәлнең үтәүчесенә (субъектка) яки объектны белдергән затка, предметка карата төрле юнәлешләрне белдерәләр:

а) аналитик фигыль эшнең объект яки субъекттан читкә юнәлүен белдерә: *чыгып китте, кайтып китте, китеп барды* һ.б.

*Якыннан гына – иң беренче юлдан, кычкырта-кычкырта, ике яшел вагон таккан товар поезды* ***үтеп китте*** (Ә. Рәшит). *Ана беренче тетрәнүдән айнымас борын ук, Зариф тимер юл буйлап йөгерә-йөгерә* ***китеп барды*** (Ә. Еники). *Барам, туктыйм, колак салып торам, тагын* ***кузгалып китәм...*** (Ә. Еники);

ә) эш-хәлнең сөйләүчегә (субъектка) таба юнәлүен белдерә: *килеп керде, йөреп килде, көтеп алды, алып кайтты* һ.б.

*Буран эчләреннән* ***килеп керде.*** *Йөзе карлы, карлы киеме* (Р. Фәйзуллин). *Тыштагы сүрән яктылык калын пәрдәләре аша да бүлмәгә* ***үтеп керде*** (Ф. Латыйфи). *Сугышкан кадәр сугышасы калмады. Менә күп тә үтмәс, әйләнеп чыккан кояш шикелле, яңадан* ***кайтып килербез*** (Ә. Еники). *Урам ташларына каты басып, Касыйм* ***кайтып килә***. (И. Гази);

б) төрле юнәлештәге хәрәкәтне, үтеп йөрүне белдерә: *йөзеп йөри, узып бара* һ.б.

*Яз көннәрендә бакча эче ап-ак чәчәк: умарта кортлары чәчәктән чәчәккә тыз-быз* ***очып йөри*** (И. Гази). *Тагын башыннан сәер уй* ***йөгереп узды*** (Ф. Латыйфи).

***3. Модаль мәгънә белдерә торган аналитик фигыльләр.*** Мондый фигыльләр, башлыча, *ал, бул, күр* ярдәмче фигыльләре белән ясала. Алдагы бүлекләрдә без *-а ал* һәм *-ып бул* формаларының мөмкинлекне (мөмкин түгеллекне) белдерүен билгеләгән идек: *бара алам ~ бара алмыйм, сөйли алам ~ сөйли алмыйм, укып була ~ укып булмый* һ.б.

*Көчләремне мин кара көннәргә* ***саклый алмадым,*** *Көннәремнең һичберен дә чөнки ак* ***ди алмадым*** (Г. Тукай). *Тәзкирә бүген*

*председатель әйткәнне язып утыру белән* ***чикләнеп кала алмады*** (Ф. Хөсни). *Кулга шундый мал эләккәндә, аны абыйга* ***күрсәтмичә калып буламы соң?*** (Ф. Хөсни). *Хәзергә бүтәнен* ***булдырып булмый*** (сөйл. т.).

*Күр* ярдәмче фигыле белән ясалган аналитик фигыль ү т е н ү, к и с ә т ү, к и ң ә ш кебек модаль мәгънәләрне белдерә һәм, башлыча, боерык фигыль формасында кулланыла: *килә күр, әйтә күрегез, авырый күрмә, бара күрмә* һ.б. *Соңга* ***кала күрмәгез*** (сөйл. т.).

*Ал, бир* ярдәмче фигыльләре эш-хәлнең кем файдасына башкарылуын белдерә: *язып алдым, күчереп алдым* – эш сөйләүче файдасына эшләнә; *язып бирдем, кайтарып бирдем, сөйләп бирдем* – эш-хәл башка берәүгә юнәлтелә.

*Һич көтмәгәндә килеп кергән бер карт безгә бу авылның бөтен фаҗигасен* ***сөйләп бирде*** (Г. Сабитов). *Тешләренең гәүһәреннән* ***кабызып алдым*** *менә Мин бу шигъре – әйтсәңез лә, энҗедән ким кай төше?* (Г. Тукай).

*Кара* ярдәмче фигыле, *-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыль белән килеп, с ы н а п к а р а у модаль мәгънәсен белдерә: *барып карыйк, әйтеп карыйк, сынап карыйк, карап карыйк* һ.б.

*И кардәшләр, кул тотышып, алга барыйк, Башка милләтләрнең хәлен* ***карап карыйк*** (Г. Тукай).

Аерым очракларда аналитик төзелешле фигыльләр тулысынча сүз ясалышына карарга мөмкин. Мәсәлән, Д.Г. Тумашева *ал* нигезеннән хәрәкәт фигыльләре белән ясалган *алып бару, алып китү, алып килү, алып чыгу, алып кайту, алып керү* фигыльләренең аспектуаль мәгънә яки юнәлеш мәгънәсен белдерә торган башка аналитик фигыльләрдән аерылып торуын, аларның бербөтен лексик мәгънә белдерүен күрсәтә. Ф.Ә. Ганиев исә шундый ук фигыльләрдә беренче компонент (*алып*) префиксоидка әйләнгән дип билгели: *апкайту, апкилү, апчыгу* һ.б.[1] .

*2015*

---

[1] Татар грамматикасы: 3 томда. II т. М.; Казан. 2002. Б. 231–232.

## ОСТАЗЫМ ДИЛӘРӘ АПА ТУМАШЕВА

Гүзәллеге шагыйрьләргә иҗат илһамы биргән, сурәте рәссамнарның киндерләренә төшкән күркәм бер хатын-кыз – татар теле фәненә зур өлеш керткән Диләрә Гариф кызы Тумашева турында галимнәр, язучылар, журналистларның җылы, нәзакәтле язылган хезмәтләрен әледән-әле укып торабыз.

Аның тормыш юлының иң зур өлеше Казан дәүләт университетына бәйләнгән. Чирек гасыр дәвамында ул анда татар теле кафедрасын җитәкләде, шулардан ун елын әле ул тарих-филология факультетының деканы да булды. Ул филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе иясе, Төркия тел җәмгыятенең (Түрк дил курумының) шәрәфле әгъзасы. Аңа хезмәтләре өчен заманында хөкүмәтнең иң югары бүләге – Ленин ордены бирелде. 1992 елдан ул башта Россия президенты каршында оештырылган, соңыннан Россия Федерациясе хөкүмәте каршындагы Рус теле советы әгъзасы булып тора.

Диләрә Гариф кызы – минем остазым. Моннан утыз биш ел элек ул, өстенә зур җаваплылык алып, миңа – өч балалы авыл укытучысына үз җитәкчелегендә аспирантурага керү фатихасын биргән иде. Шул рәвешле ул мине зур фән өлкәсенә алып керде. Утыз биш ел буена фәндә, университетта, гаиләдә аралашу барды һәм мин аның казанышларына, өзлексез фәнни эзләнүләренә сокланып һәм гаҗәпләнеп туя алмыйм. Аның академик фәндәге гаять әһәмиятле хезмәтләре бөтен дөньяга танылды, алар турында, мәсәлән, атаклы тюркологлар – алман профессоры Г. Дерфернең, мажар галиме Л. Лигетинең Диләрә Тумашева хезмәтләренә югары бәя биргән мәкаләләре нәшер ителде.

Себер татарлары диалектларын өйрәнү – Диләрә ханымның фәнни эзләнүләренең төп юнәлеше. Әлеге өйрәнү, тикшеренүләрнең һәм шул өлкәдә дөньяга килгән капиталь хезмәтләрнең үз тарихы бар.

Ул Мәскәү университетының Шәрекъне өйрәнү бүлегендә төрки телләр кафедрасында белем ала. Аның укытучылары

Шәрекъне өйрәнүнең күренекле галимнәре була. СССР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы – күренекле тюрколог Н.К. Дмитриев, аның Төмәннән икәнен белгәч, шул төбәктәге татарлар сөйләме буенча диплом эше язарга тәкъдим итә. Шул рәвешле Диләрә Тумашева Себер татарлары шивәләрен өйрәнүгә керешә.

Диләрә Тумашеваның фәнни тикшеренү нәтиҗәләре кандидатлык диссертациясендә, ә 1969 елда исә «Татар теленә һәм башка төрки телләргә мөнәсәбәттә Себер татарлары диалектлары» дигән зур хезмәтендә – докторлык диссертациясендә яктыртыла.

Себер татарлары телен өйрәнү өчен ул җәйләрен, үзе белән берничә студентны алып, Себер авылларына чыгып китә. Унбиш ел дәвамында шул юл белән Себердәге йөзләрчә авылларда яшәгән татарларның тел үзенчәлекләре җентекләп өйрәнелә. Яшь галимә һәм аның шәкертләренә ат яки трактор арбаларында юл гизәргә, каекларда күлләр һәм елгалар буйлап, хәтта сазлыкларда утырган авылларга җәяүләп тә барырга туры килә. Ерактагырак, сазлыклар арасындагы авылларда үзара аралашу кыенга килгәнгә күрә, тел үзенчәлекләре ныграк сакланып калган. «Без шуңа аеруча игътибар бирә идек, – дип искә ала Диләрә ханым. – Сазлык арасындагы Лайтамак авылына вертолет яллап илттерүләренә ирештек. Шуннан соң бу авылга даими вертолет маршруты ачылган».

Иртеш, Тубыл, Обь елгалары буендагы татар авылларында экспедициядә йөрүләрен университетның татар теле бүлеген тәмамлаучыларның байтагы хәтерли булыр. Алар арасында безнең хөрмәтле хезмәттәшебез, күренекле татар язучысы Мөхәммәт Мәһдиев тә була. Диләрә ханым аны үз җитәкчелегендәге студентларның бер төркеме белән Обь елгасы буендагы авылларны йөреп, өйрәнеп кайтырга җибәрүен искә ала. Әлеге төркем татар авылларына тап булмый. Мөхәммәт Мәһдиев бер-бер артлы телеграмма җибәрә: «Татар авыллары юк, кайтырта рөхсәт итегез!» Диләрә Тумашевадан җавап оча: «Маршрут буенча барырга, эзләнүләрне дәвам итәргә!» Ниһаять, экспедиция төркеме Обь елгасының ярына утырган искиткеч гүзәл табигатьле Оры (Умар) авылына барып чыга. Чыннан да, бу авылга юлыгу фән өчен зур табыш була. Соңрак Диләрә Тумашева әлеге авыл шивәсен аерым – «Оры сөйләме» дип билгели.

Себер экспедициясендә катнашу Нурмөхәммәт белән безгә дә насыйп булды. 1957 елның җәендә Диләрә апа безне дә Тубыл, Байкал һәм Вагай районнарына экспедициягә алып чыкты. Татар авылларында концертлар да куйдык. Нурмөхәммәт Муса Җәлил турында доклад сөйли һәм җырлый иде. Шунда дуслаштык та, соңрак без икәү гаилә корып җибәрдек.

В.В. Радловтан соң Себердәге татарларны өйрәнү өчен нибары бер генә экспедиция оештырыла. 1940 елгы бу эзләнүдә Казаннан фольклорчы галим Х. Ярми, Омск шәһәреннән С. Әмиров, язучы Н. Исәнбәт катнаша. Тикшеренүне өр-яңадан башлаган яшь галимә Диләрәгә зур җирләргә таралган меңнәрчә төрле әйтелешләрнең, сүзләр, грамматик калыпларның баштарак диңгез сыман күренүе бер дә гаҗәп түгел. Әмма максатчан, эзлекле, дөрес ысул сайлау һәм, иң әһәмиятлесе, фәнгә җаны-тәне белән бирелгәнлек аңа гыйльми җилкән куя. Нәтиҗә буларак, галимә Себер татарлары телендә өч диалект: Тубыл – Иртеш, Бараба, Том диалектлары һәм күпсанлы сөйләшләр булуын ачыклый. Болар арасында ике сөйләш яңабаштан ачыла.

Диалектларны төрки телләр һәм борынгы язма истәлекләр белән чагыштырып өйрәнү Себер татарлары шивәләрендә, чагыштырмача яңа кыпчак теле элементлары белән бергә, төрки телләрнең күп кенә борынгы гәүдәләнешләре дә саклануын ачыкларга мөмкинлек бирә. Шул рәвешле Себер татарлары теленең төрки телләр арасындагы урыны да ачык билгеләнә.

Шул телне бөтен нечкәлекләренәчә өйрәнгән һәм аңа үзенең зур иҗат көчен багышлаган Д. Тумашева, Төмән шәһәрендә туып үссә дә, чыгышы белән Себердән түгел. Аның ата-бабаларының төп нигезе Казан якларыннан. Әнисе Әминә Пермь төбәгеннән, ул Төмән шәһәрендә татар теле укытучысы булып эшләгән. Тик ана җылысыннан Диләрә бик иртә – 12 яшендә мәхрүм кала. Бу хакта ул:

– Минем бөтен рухиятемнең нигезен әнием салып калдырды, – ди.

Зыялы, затлы нәселдән чыккан Әминә, гомеренең кыска буласын белеп торган хәлдә, үз кызына мөмкин кадәр күбрәк белем биреп калырга омтыла. Шул катлаулы авыр чорда, 30 нчы елларның икенче яртысында, ул аны җитәкләп музыка мәктәбенә йөртә.

Аңа татар китаплары эзләп кайтара, татар көйләренә өйрәтергә тырыша. Соңыннан, мәктәптә дә, югары уку йортында да бары тик русча белем алган Диләрә, Казанга килеп, университетның татар теле бүлеге студентларына татарча лекцияләр укый башлагач, бу тәрбия бик ярап куя.

Әнисенең вафатыннан соң кечкенә Диләрәне әтисе Гариф тәрбияли. Ул озак еллар буена Төмәндә һөнәр училищесының директоры булып эшли. Зыялы, җор телле Гариф абзый Себергә экспедициягә барган студентларның күбесенә таныш. Авылларга чыгып киткәнче, алар әле Төмәндә – Гариф абзый өендә берничә көн буена кунак булып торалар.

Диләрә Гариф кызы хезмәтләренең икенче юнәлеше – татар әдәби теленең морфологиясен өйрәнү. 1964 елда аның «Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе» дигән күләмле хезмәте дөнья күрә. Ә 1978 елда ул СССР Югары белем министрлыгы тарафыннан расланган яңа дәреслек чыгара. Фундаменталь хезмәтләр буларак, аларның әһәмияте әле дә югалмый.

Диләрә Тумашева фундаменталь фәнгә нигезләнгән үз мәктәбен булдырган галим. Аның шәкертләре дә шул саллы фәнни нигезгә таянып эш итә, һәм, әйтергә кирәк, алар үз казанышлары белән барыннан да элек шушы академик фәнни мәктәпкә, үзләренең остазына бурычлы.

Академик Диләрә Гариф кызы Тумашева зур һәм тирән эчтәлекле, югары дәрәҗәдәге фәнни абруе булган галим. Ул күпләрне көнләштерерлек иҗат дәрте, иҗат көче белән кызыклы һәм бәрәкәтле фәнни тикшеренү эшләре алып бара.

*1996*

## АНА ТЕЛЕ ҺӘМ МИЛЛИ МАТБУГАТ

Хәзерге көндә татар телендә чыга торган төрле газета-журнал битләрендә, радио-телевидение сөйләмендә, Интернет язмаларында һ.б.да шактый еш очрый торган тел кимчелекләре, һәртөрле хаталар турында күренекле галимнәребез матбугатта, чаң суккандай, бик урынлы чыгышлар ясый. Үз чиратымда, миңа да төрле басмаларда бу хакта язып чыгарга, редакция хезмәткәрләре, язучылар

алдында әлеге хаталарны искәртеп, чыгышлар ясарга туры килгәне булды. Кызганычка, бүгенге көндә дә шул ук кимчелекләрнең төрле газета-журнал, радио-телевидение телендә һәм аеруча Интернеттагы һәртөрле язмаларда шактый мулдан саклануын әйтергә туры килә. Дөрес, нәкъ менә соңгы бер-ике ел эчендә (2013–2014) рәсми статуска ия кайбер республика, шәһәр басмаларында бу мәсьәләдә шактый алга китеш сизелә, әмма соңгырак елларда чыга башлаган хосусый газеталарда һәм аеруча халкыбызга бик якын торган, бай һәм халыкчан телле булуга өмет уяткан район газеталарында әлеге хаталар, тупасрак әйтсәк, «тулып ята».

Шуны да танырга туры килә, бүгенге әдәби телебезнең хәлхәләте, аны яклау һәм саклау мәсьәләләре өчен, телне һәртөрле өлкәләрдә кулланучылар белән бергә (журналистлар, язучылар һ.б.), тел галимнәре дә җаваплы. Моны истә тотып, без әлеге хаталарның асылын аңлату, аларның килеп чыгу сәбәпләрен ачыклау кирәк, дип саныйбыз.

Теге яки бу күренешне тирәнтенрәк, ягъни фәнни юнәлештә өйрәнү, билгеле булганча, күпчелек очракта фактик материал туплау һәм аларны төркемләүдән башлана. Әйтергә кирәк, соңгы 4–5 ел эчендә әлеге проблема буенча республикабызда чыга торган басмалардан (күбрәк газеталардан) тупланган тел материалы типик хаталарны күпмедер дәрәҗәдә барларга һәм шулай ук төркемләргә мөмкинлек бирде. Шуны да өстәп әйтик, соңгы 2–3 ел эчендә әлеге проблема буенча университетның татар филологиясе бүлеге студентлары да махсус курс кысаларында бу эшкә җәлеп ителде һәм республика газеталары, шулай ук кайбер район газеталары теленә шактый җентекле анализ ясады.

Күп кенә газеталарда урын алган һәм күңелгә шактый тия торган кимчелекләрнең берсе тел белеменең «Фонетика» дип аталган бүлегенә, ягъни авазлар һәм хәрефләр һәм аларның язылыш үзенчәлекләренә карый. Эш шунда ки, татар теленә һәм, гомумән, төрки телләргә, сингармонизм закончалыгы хас. Телебездә аның ике төре бар: а) рәт гармониясе һәм ә) иренләшү гармониясе:

а) рәт гармониясе – бер сүз кысаларында (кушымчаларны да кертеп) яки арткы рәт, ягъни калын сузыклар гына, яки алгы рәт, ягъни нечкә сузыклар гына кулланыла ала. Сузыкларның калын яки нечкә әйтелүе исә авыз куышлыгында телнең горизонталь

юнәлештә хәрәкәтенә, ягъни рәтенә бәйле: *алма-лар-ны, тәрәзә-ләр-не* һ.б.

ә) иренләшү гармониясе – сүзнең беренче, икенче иҗекләрендә иренләшкән *о, ө* сузыклары булса, алардан соң килгән тар сузыклар *ы, е* иренләшеп әйтелә: *бороңгыо, йөзөгеө* һ.б.

Көндәлек матбугат битләрендә телебезнең табигатен бозуга китерә торган хаталар һәм җитешсезлекләр исә күбрәк беренче очракка, ягъни һәртөрле алынма сүзләргә кушымчалар ялгаганда рәт гармониясенең, ягъни сингармонизмның бозылуына карый. Мәсәлән, газеталарда, еш кына, *премияга, фестивальда, сиреньнар, армиядагы* кебек язылышлар белән очрашырга туры килә. Әгәр игътибар итсәгез, бу үзенчәлекләрне исә без гадәти сөйләмебездә һәрчак саклыйбыз. Мәсәлән, *Киевкә бардык, табибкә күрендем, расписаниене күчереп алдым, армиягә киткән* дип сөйлибез; иренләшү гармониясе исә сөйләмдә *болотлыо көн, көндезгеө аш* кебек сүзтезмәләрдә реальләшә.

Билгеле булганча, әдәби телдә сүзләрнең язылыш кагыйдәләре нормалашкан, алар галимнәр тарафыннан төзелә һәм дәүләт тарафыннан раслана. Бүгенге көндә исә без язуыбыз кирилл әлифбасына күчкән чорда, ягъни 1939 елда кабул ителгән орфографик, ягъни язылыш кагыйдәләре белән эш итәбез. Беренче иҗектән соңгы иҗектә иренләшкән *о, ө* сузыкларының язуда күрсәтелмәве дә (*болынлык, болытлы, сөлге, көзге* һ.б.) шул кагыйдәләргә бәйле, һәм бу үзенчәлек шул чорда әлифбаны төзүче галимнәрнең әлеге мәсьәләгә беркадәр хосусый якын килүе, ягъни язылышта көнбатыш диалект, ягъни мишәр сөйләше үзенчәлекләренә якыная төшү белән аңлатыла, дигән караш та бар.

Шуны да искәртеп үтик: минемчә, иренләшкән сузыкларның язылышта тулы күрсәтелмәве хәзергә кадәр әле татарча әдәби сөйләмгә ул кадәр зыян сала алмаган. Татар кешесе һәрхәлдә хәзерге көндә дә *бо-лыт-лы көн, то-лы-мы о-зын* дип иренсезләтеп сөйләшми, ягъни иренләшү гармониясе, орфография камил булмаса да, әйтелештә саклана, дияр идем мин.

Ә менә алынма сүзләр язылышында рәт гармониясенең тупас бозылуы, ягъни *Киевка бардык, табибка күрендем, шул стильда сөйләү, Кемерда ял иттем* дип язу ул орфографиягә хилафлык кына түгел, ә телнең табигатен тупас бозуга китерә. Шуны да бил-

геләп үтик, газета-журналларыбыз теленә махсус игътибар юнәлтү элегрәк, 2008–2009 елларда ук башланган иде. Әйтергә кирәк, ул еллардагы хаталар белән чагыштырганда, хәзерге матбугат теленә журналистларыбызның таләпчәнлеге беркадәр артуы сизелә, әмма күп кенә кимчелекләр, хаталар, кызганычка, әле дә сакланып килә.

Беренчедән, рәт гармониясенә мөнәсәбәттә язылышта закон саналган мөһим орфографик кагыйдә бозыла. Искә төшереп үтик, әлеге орфографик кагыйдә түбәндәгечә билгеләнгән: «Тамыры һәм нигезе белән нечкә булган, һәм *-ль* гә, шулай ук *-ия, -ие* гә тәмамланган сүзләргә нечкә кушымчалар ялгана; мәсәлән: *тәрәзәгә, мебельгә, рольдә, нефтьтән, типографиядә, Бельгиянең, Швециядән, учреждениегә...*»

Бу уңайдан шуны да билгеләп үтү урынлы булыр: кирилл әлифбасына көчле чорында шәхес культының иң дәһшәтле, куркыныч еллары булуга карамастан, безнең хөрмәтле олуг галимнәребез телебезнең табигый яңгырашын саклау өчен мөмкин булганның барысын да эшләргә тырышкан. Сингармонизмны саклауга юнәлтелгән әлеге кагыйдә нәкъ шул турыда сөйли.

Шул ук вакытта хәзерге газета-журналларыбыз теленә игътибар иткәндә, нәкъ менә шушы мөһим кагыйдәләрнең бик еш бозылуын икърар итәргә туры килә. Мәсәлән, «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан», «Татарстан яшьләре» кебек республика басмаларында, шулай ук «Татарстан-Яңа Гасыр» телевидениесе тапшыруларында һ.б. еш кабатлана торган шундый хата һәм кимчелекләргә игътибар итик: *лицензиядан (мәхрүм ителде), госпитальда, стратегияга (нигезләнә), академияда, спектакльдагы, Малайзияның, премияга, фестивальда* һ.б. («Ватаным Татарстан»); *Ангела Меркельның, консерваторияда, пенсиясын, батареяда (эшли торган), февральдан (бирле), женшеньда, ассамблеясында, (шул) стильда, артгалереяны* һ.б. («Шәһри Казан»).

Университеттагы махсус курс кысаларында студентлар игътибар юнәлткән кайбер район газеталарында әлеге типтагы хаталарның тәмам нормага әверелүе тагын да кызганычрак, билгеле. Мисаллар: *гимназияга, информацияларны, фотографиялар, Севастопольны* һ.б. («Туган як» газетасы); («Хезмәт» газетасы) һ.б.

Сингармонизм законына мөнәсәбәттә, алынма сүзләргә кушымчалар ялганганда, югарыда күрсәтелгән орфографик кагый-

дәләрдән тыш та, үзеннән-үзе нечкә кушымчалар соралып торган сүзләргә калын кушымчалар ялгарга омтылу шулай ук телебез табигатенә хилафлык буларак кабул ителергә тиеш. Хәлбуки без еш кына: *финнар, теш табиблары, Киевта, Галиевлар* һ.б. («Шәһри Казан»); *һиндлардагы (икмәк), Шәймиевка, жюрида, шәфәкълар* (бу соңгы мисалда исә калынлык билгесе сузыкны түгел, ә тартыкны калынайта – *k!*) һ.б. («Ватаным Татарстан») дип язабыз.

Әйтергә кирәк, инде халык телендә бик табигый, матур яңгырый торган мондый сүзләрнең хәзерге күпчелек басмаларда, шулай ук радио-телевидение сөйләшендә бу рәвешле калын кушымча белән бирелүе телне бик тупаслый, аның гасырлардан килгән табигый яңгырашын боза. Безнең фикеребезчә, борынгыдан кулланылып килгән *табиб, мохит, шаһит, нашир, талиб* кебек сүзләр, шулай ук яңгырашы белән нечкә булган *эфир, грипп, жюри, һинд, фин, Хельсинки (Һелсинки), Киев* кебек сүзләр, һичшиксез, түбәндәгечә нечкә кушымчалар алырга хаклы: *эфиргә (чыга торган тапшыру), табибә ~ теш табибе ~ теш табибләре, (шәһәр) мохите, шаһитләр, нашире ~ наширләр, талибләр, финнәр, Хельсинкидә, жюридә, гриппкә(каршы), һиндләр, Киевкә* һ.б. (Шуны да ассызыклап китик: телебездә кулланыла торган һәртөрле алынма сүзләргә бары тик калын кушымчалар гына ялганырга тиеш дигән орфографик кагыйдә юк бит!)

Газета-журнал сәхифәләрендә еш очрый торган кимчелекләрнең кайберләре телебезнең грамматик төзелешенә, ягъни тел белеменең «Морфология» һәм «Синтаксис» дип аталган өлкәсенә карый. Актив ике теллелек шартларында тыгыз янәшәлектә кулланыла торган татар һәм урыс телләре грамматик яктан да (грамматик типология) бер-берсеннән шактый нык аерыла. Әйтик, фигыль заманнарының күп төрле булуы, җөмләдә сүз тәртибе һ.б. буенча төрки телләр инглиз теленә якынрак торалар.

Төрки телләр семьялыгына кергән татар телендә, мәсәлән, хикәя фигыльнең рәсми рәвештә әдәби телдә кулланыла торган заман формалары гына да унга якын: *бара, барды, барган, барыр, барачак, барачак иде, бара иде, бара торган иде* һ.б.

Без алга таба сүз алып барачак икенче бер фигыль формасы – сыйфат фигыльләр исә үзенчәлекле рәвештә алты формада килә: *сөйләүче (агай), сөйли торган (сүз), сөйләгән (сүз), сөйләячәк (сүз),*

ягъни *-учы/-үче, -ган/-гән, -ыр/-ер (-ар/-әр), -асы/-әсе, -ачак/-әчәк (-ячак/-ячәк), -а торган/-ә торган* кушымчаларын алып ясала. Ә рус телендә исә сыйфат фигыль формасы, ягъни «причастиенең асылда *-ущий/-ющий* кушымчалы бер генә формасы бар һәм ул хәзерге һәм үткән заманнарда: *пишущий, писавший,* шулай ук төшем юнәлешендә (страдательный залог) килә ала: *написанный* кулланыла[1].

Әлеге уңайдан сыйфат фигыльнең татар телендәге бай һәм үзенчәлекле мөмкинлеге еш кына матбугат телендә урынлыга да, урынсызга да бердәнбер *-учы* кушымчалы сыйфат фигыль белән алыштырылуы кебек иләмсез күренешне тагын бер кат шәрехләп үтәргә кирәк. Мисалга килгәндә, алда искә алынган республика һәм кайбер район газеталарында, шулай ук радио-телевидение сөйләшендә очрый торган мисалларга игътибар итик: *чын татарча чыгучы газета, тикшерүне таләп итүче ике сорау, битне каплап йөрүне тыючы закон, чәйнәлүче ризыклар, Сочида узучы Олимпиада, укып булмаучы ун китап, бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелүче Казаныбыз, тәмәке тартуны тыючы закон, аягында нык басып торучы уку йорты, үсеп утыручы үләннән ясалган сыннар, кан йөрүче тамырлар; куелучы спектакль, үсеп утыручы чыршылар, 6 тема буенча үтүче секция, кием-салым сатучы базар, күңелне дәвалаучы сәнгать, кайнап утыручы аш, өйрәтүче семинарлар, шәхси хуҗалыклардан җыелучы сөтләр, узып баручы атна, яңгыр сулары китүче коелар* һ.б.

Китерелгән әлеге сүзтезмәләрдә *-учы* кушымчалы сыйфат фигыльнең урынсыз кулланылышы беркемдә дә бәхәс тудырмый дип уйлыйм. Биредә сыйфат фигыльләр кулланылышындагы мөһим кагыйдә бозыла: *-учы* кушымчалы сыйфат фигыль, кагыйдә буларак, шәхесне ачыклаганда гына кулланыла: *оста биюче кыз, яхшы укучы студент, мәктәптән кайтучы балалар* һ.б. Сирәк кенә җансыз предметларга карата кулланылышы, бары тик сурәтләү чарасы рәвешендә, җанландыруларда очрый:

Мәсәлән, Г. Тукайда:

*...Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем*
*Була минем юл күрсәткүче йолдызым...*
(«Китап» шигыреннән.)

[1] Русская грамматика. Т. 1. М.: Наука, 1980. С. 665–666.

-*учы* формасы юклыкта, ягъни -*маучы* рәвешендә бөтенләй кулланылмый иде, әмма безнең журналистлар аны шактый иләмсез итеп юклыкта да куллана башлады. Мәсәлән: *тотынырга сәлам бөртеге да калмаучы* (ни өчен калмаган түгел?) *бу баланың...; яшьләрне кайгыртмаучы бу главалар...* (ни өчен кайгыртмый торган түгел) («Ватаным Татарстан») һ.б.

Югарыда китерелгән мисалларда исә *-ган,* яисә *-а торган* кушымчалы сыйфат фигыльләр, һичшиксез, табигыйрәк яңгырар иде: *татарча чыга торган газета; яшьләрне кайгыртмый торган главалар; тикшерүне таләп итә торган ике сорау; битне каплап йөрүне тыя торган закон; чәйнәлә торган ризыклар; Сочида узган (уза торган) Олимпиада; укып булмый торган ун китап; бөтендөнья мирасы исемлегенә теркәлгән Казаныбыз; аягында нык басып торган уку йорты; үсеп утырган үләннән ясалган сыннар; кан йөри торган тамырлар; куелган спектакль; үсеп утырган чыршылар; кием-салым сата торган базар; кайнап утырган аш; шәхси хуҗалыклардан җыелган сөтләр; узып барган атна; яңгыр сулары китә торган коелар* һ.б.

Сүз уңаеннан шуны да билгеләп китик, *-ган* һәм *-а торган* кушымчалы сыйфат фигыльләр – төрки телләрнең кыпчак төркеме өчен хас булган бик борынгы фигыль формалары, алар хәзерге телебездә дә бик мул кулланыла һәм һәрчак диярлек бик табигый яңгырый. Мәсәлән, халык җырларында да бит –

*... Аккан суга карап торам,*
*Төшәм тирән уйларга...*

яки

*Исә җилләр, исә җилләр,*
*Искән җилләр файдасыз... –*

дип җырлаганнар, һәрхәлдә, хәзергечә *агучы су, исүче җил, чәчәк атучы агачлар* димәгәннәр.

Әйтергә кирәк, матур әдәбиятта дә Гомәр Бәширов, Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов кебек классик язучыларыбыз телендә -*учы* формасының урынсыз кулланылышын ялгыш та очратырга мөмкин түгел. Моннан 7–8 еллар элеккеге газета-журналларыбыз телендә дә бу хәл мөмкин түгел иде! Фикерем дәлилсез булмасын өчен, кайсыдыр газетадан (хәтерләвемчә, Мамадыш районы га-

зетасы кебек) теленең төзеклегенә, матурлыгына сокланып язып алган бер кечкенә өзекне китерәм: *«... Поезд сәгатьләр буе әле куе урманнар, әле сабыр гына агып яткан елгалар, җәйрәп күренгән күлләр янәшәсеннән... чуарланып беткән иңкүлекләр аркылы үтә...»* (Зәки Хәнәфиев). (Игътибар итегез, хәзергечә «агып ятучы елгалар», «күренүче күлләр» түгел!)

Морфология өлкәсенә караган тагын бер кагыйдәне искәртеп китү кирәк дип саныйм. Эш шунда, еш кына кайбер фигыль нигезләренә *-ачак/-әчәк (-ячак/-ячәк)* кушымчалары ялганганда, мәсәлән: *йөриячәк, төзиячәк, сөйлиячәк* тибындагы хаталар күзгә ташлана. Бу очракта шуны истә тоту мөһим: татар телендә хикәя фигыльнең заманнары күп төрле, һәм аларны ясый торган кушымчалар һәрвакыт фигыльнең нигезенә ялгана, һәрхәлдә ялганырга тиеш. Ә фигыль нигезе татар телендә, тышкы яктан II зат берлектәге боерык фигыльгә охшаш була: *Бар! Бар-а, бар-ды, бар-ган, барыр, бар-ачак* һ.б. Искәрмә бары тик сузык авазга тәмамланган фигыль нигезләреннән хәзерге заман хикәя фигыль ясалышына гына карый: *кара ~ кара-й ~ кар-ый: сөйлә ~ сөйлә-й ~ сөй-ли...* (әлеге очракта исә кушымчалар ялганганда, нигез кыскару – нигез тартылу күренеше барлыкка килә).

Алдарак күрсәтелгән очрак, ягъни киләчәк заман формалары ясалганда исә гомуми кагыйдә, ягъни *-ачак/-әчәк, -ячак/-ячәк* кушымчаларын, һичшиксез, нигезгә ялгау сорала: *сөйлә-ячәк, төзе-ячәк, йөре-ячәк, аша-ячак, укы-ячак, ныгы-ячак* һ.б. Ләкин һич тә инде *йөри-ячәк, төзи-ячәк* түгел! Синтаксис һәм шулай ук өлешчә лексика өлкәсенә караган хаталарга килгәндә исә җөмләдә татар телендә сүзләр бәйләнеше закончалыкларын исәпкә алмау, сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне сүзгә-сүз тәрҗемә итү, ягъни синтаксик һәм шулай ук лексик калькалар куллану аерым очракларда хәтта мәзәк дәрәҗәсенә җитә.

Мәсәлән, рус телендәге творительный падеж ярдәмендә ясалган сүзләр бәйләнеше күп кенә очракларда чыннан да татарча белән бәйлеге белән бирелә: *балта белән яра* – «рубит топором», *карандаш белән язган* – «написано карандашом» һ.б. Әмма һәр очракта әлеге бәйләнешне «белән» бәйлеге белән бирү – тупас хата, ягъни турыдан-туры – калька буларак кабул ителә: *ремонт белән соңга калу* «опоздать с ремонтом» – *ремонтка соңга калу;*

*Әмәт станциясендә манзара белән соклану* «любоваться видом» – *манзарага соклану, троплар белән файдалану* «пользоваться тропами...» – *троплардан файдалану, хаталар белән язу* «писать с ошибками» – *хаталы язу* һ.б.

Шундый ук иләмсез калькаларга рус телендәге сүзләр бәйләнешен механик рәвештә «өстендә», «астында», «артында», «чыгып», «караган» һ.б. сүзләр белән тәрҗемә итәргә омтылу, ягъни русча уйлап, татарча язу очраклары да керә. Мәсәлән: *контроль астында тоту* «держать под контролем» – *контрольдә тоту; көй астында йоклап китү* «заснуть под музыку» – *көйгә йоклап китү, икенче төркемгә караган инвалид; Сез, билгеле тавыш бирүне дәүләт артында калдыру өчен чаралар күрдегез* («Ватаным Татарстан») «за государством» *дәүләт карамагында* һ.б. Мондый калькаларны, әйтергә кирәк, аеруча «Татарстан яшьләре» газетасы хуп күрә, мәсәлән: *үземнән чыгып әйтәм* «исходя из себя» – *үз тәҗрибәм буенча әйтәм; сыйныфтагы укучылар һәрберсе үз диненнән чыгып шушы юнәлешләрнең берсен сайларга тиеш* «исходя из (яки: по) своей религии» – *үз дине буенча* (үз диненнән чыккач, ни була инде ул?) һ.б.; *бәяләрне стандартлардан чыгып билгеләрләр* – «исходя из стандартов» – *стандартлар буенча* яки *стандартларга нигезләнеп,* ләкин «чыгып» түгел! *Сез үзегездән чыгып фикер йөртмәгез* «исходя из себя (по себе)» – *үзегез буенча* һ.б. Бу типтагы хаталарны төзәтү өчен, минемчә, үзеңә: «Ә татарча бу ничек булыр иде?» – дип сорау кую да җитәр иде.

Урынсыз калькалар рус теленнән *врач-терапевт, журналист-депутат* тибындагы парлы сүзләрне тәрҗемә иткәндә дә кулланыла. Мәсәлән, газета-журналларыбызда мондый сүзләр, кагыйдә буларак: *табиб-терапевт, лицей-интернат, рәссам-пейзажчы, галим-археолог, музей-тыюлык, сугышчы-интернационалист* һ.б. рәвешендә бирелә. Бер республика газетасында хәтта *эт-космонавт* дигән әкәмәт гыйбарә дә урын алган иде. Бу очракта шуны гына истә тоту мөһим: әлеге тезмәләрдә, кайсы сүз кайсын ачыклый? Татар телендә, кагыйдә буларак, ачыклаучы сүз алдан килә, ә рус телендә бу бәйләнеш ирекләрәк. Шуңа күрә андый сүзләр татарча, һичшиксез, *терапевт-табиб, депутат-журналист, космонавт-эт, интернат-лицей, пейзажчы-рәссам, археолог-галим* рәвешендә бирелергә тиеш.

Язмамны башлаганда ук әйтелгәнчә, төрле газета-журналлардан китерелгән кимчелекләр, турыдан-туры хаталы язмалар инде элеккерәк елларда, ягъни 2009–2010 елларда ук теркәлә башлаган иде. Ул вакытлар белән чагыштырганда, аерым газеталарның теле шактый төзекләнә төште. Хаталы язмалар да кимүгә таба бара. Әмма шулай да сингармонизмны исәпкә алмау, урынсыз калькалар куллану дәвам итә әле. Тынычлану дигәннән дә менә әле «Шәһри Казан» газетасының 15 сентябрь санына кушымта итеп бирелгән «Атна вакыйгалары» сәхифәсен укыгач, образлы итеп әйтсәк, яңадан «чәчләр үрә торды». Телгә бу дәрәҗәдәге игътибарсызлык, ихтирамсызлыкның әле алдагы еллардагы газеталарда дә очраганы булмагандыр. Әлеге «Вакыйга»лардан берничә мисал: сәхифәдәге беренче җөмлә үк *«мәктәптән чыгарылучыларның белем дәрәҗәсе түбән»* дип башлана. Ничек?! Мәктәптән куылганнарныңмы? Без бит *«мәктәпне тәмамлаучылар»* дип сөйли идек. Аңлашыла, бу очракта ул «выпускники» сүзеннән калька икән! Шул ук биттә алга таба укыйбыз: *Буа һәм Мамадышның 2 санлы (?) лицее; Казанның 102 санлы гимназиясе, Әлмәтнең 56 санлы мәктәбе* һ.б. Нәрсә бу 102 яки 56 мәктәпме? Мондый очракта без *2 нче лицее* яки *102 нче гимназиясе* дип яза идек кебек.

Шул «Вакыйга»ларның 5 нче битендә исә тагын да «оригинальрәк» *Ата-Ватан паркы* сүзтезмәсе китерелгән. Ничек? Рус телендә дә, татар телендә дә, минемчә, бу уңайдан мондый тезмәнең аналогы буларак *«Родина-Матъ»* һәм *«Ватан-Ана»* тезмәләре кабул ителгән иде! Нәрсә бу? Ватанның җенесенә ишарәләүме? Аңлашыла төшсен өчен аңлатып үтик инде. Бу сүзтезмәләрдә «Родина» һәм «Ватан» сүзләре «мать», «ана» сүзләрен ачыклый. Нинди ана? *Ватан-ана!* Нинди ата? *Ватан-ата!* Белүебезчә, һәр кешенең бик кадерле «туган анасы» һәм шундый ук кадерле «Ватан анасы» бар! Әгәр без «татар телендә ачыклый торган сүз алдан килә» дигән кагыйдәне истә тотсак, мондый «әкәмәтләр» килеп тә чыкмас иде.

Әмма мин шулай да бүгенге газета-журналларыбызның теле хаталардан арына, камилләшә бара, дигән фикеремнән кире кайтмыйм. Тик бу, башлыча, республика газеталарына карый. Хосусый басмаларда һәм аеруча без игътибар иткән район газеталарында әле алар, кызганычка, шактый мулдан саклана.

*2014*

## ГАЛИМӘНЕҢ БИБЛИОГРАФИЯСЕ

### а) китаплар, монографияләр

Причастие в современном татарском литературном языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1971. – 27 с.

XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре (Е.И. Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышына кагылышлы материаллар буенча). – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1981. – 161 б.

Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности XVI–XVII вв. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1990. – 152 с.

Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности (XVII – начало XIX вв.): дис. … д-ра филол. наук. Рукопись. Казань, 1994. – 418 с.

Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности (XVII – начало XIX вв.): автореф. дис. ... д-ра. филол. наук. – Казань, 1995. – 57 с.

Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – начало XIX вв.). – Казань: Мастер-Лайн, 1999. – 407 с.

Татар теле: латин әлифбасына кайтуның фәнни нигезләре. – Казан: Школа. – 71 б.

### ә) коллектив монографияләрдәге бүлекләр

Причастие // Татарская грамматика. Морфология. Т. 2. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. – С. 199–223.

Сыйфат фигыль // Татар грамматикасы. Морфология. Т. 2. – М.: Инсан; Казан: Фикер, 2002. – Б. 255–298.

История татарского литературного языка (XIII – первая четверть XX вв.) // Письменно-литературный язык XV – начала XVII вв. Язык деловых бумаг. – Казань: Фикер, 2003. – С. 407–418.

История татарского литературного языка (XIII – первая четверть XX вв.) // Письменно-литературный язык XVII – первой четверти XX в. – Казань: Фикер, 2003. – С. 419–497.

Воззвания и переписка вожаков Пугачевского движения в Поволжье и Приуралье [сост.: М.А. Усманов, Ф.М. Хисамова и др.]. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. – 463 с.

### б) фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләр

Татар телендә -ган формасының кулланылышында кайбер үзенчәлекләр // Татар тел белеме мәсьәләләре. 3 китап. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1969. – Б. 197–209.

Татар телендә -асы кушымчалы сыйфат фигыль // Сборник аспирантских работ. Гуманитарные науки. Кн. 2. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1971.

Временные значения причастной формы на -ган в татарском языке // Сборник аспирантских работ. Гуманитарные науки. Филология. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1971. – С. 97–106.

К вопросу об изучении причастно-именных форм татарского глагола // Татар тел белеме мәсьәләләре. 4 нче китап. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1972. – Б. 120–133.

Некоторые морфологические особенности татароязычных документов Пугачевского восстания // Проблемы историографии и источниковедения крестьянской войны 1773–1775 гг. – Казань, 1974.

Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» поэмасында фигыль формалары // Исследования по татарскому языку. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977. – Б. 128–139.

Об особенностях развития старотатарской деловой письменности // Советская тюркология. – 1977. – № 3. – С. 51–67. (в соавторстве с М.А. Усмановым, Д.Г. Тумашевой).

Отражение диалектных черт в материалах старотатарской деловой письменности (тезисы доклада) // Совещание по общим вопросам диалектологии и истории. – М., 1977.

Пугачев восстаниесе документларында фигыль // Очерки по морфологии татарского глагола. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1978. – С. 116–129.

Русско-татарские словари XVIII–XIX вв. как источник по исторической диалектологии татарского языка // Совещание по общим вопросам диалектологии и истории языка. – М., 1979 (тезисы доклада).

Ахметьянов Р.Г. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков. М.: Наука, 1978 (рец. на книгу) // Советская тюркология. – 1979. – № 5. – С. 80–82.

Традиции языка средневековых тюркских памятников в татарской деловой письменности XVII–XVIII вв. // III Всесоюзная тюркологическая конференция – Ташкент-80. Языкознание. – Ташкент: Фан, 1980.

Старотатарская деловая письменность и диалектология // Тезисы докладов Тюркологической конференции. Проблемы диалектологии и лингвогеографии тюркских языков. – Уфа, 1982.

Языковые особенности «Трактата о бракосочетании» // Структура и история татарского языка. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1982. – С. 79–90.

Особенности залоговой семантики в причастиях // Татарский язык: лексическая и грамматическая семантика. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1984. – С. 71–76.

Материалы по татарской диалектологии: образцы текстов (рец. на книгу) // Советская тюркология. – 1984. – № 5. – С. 82–84.

Ольмесов Н.Х. Сопоставительная грамматика кумыкского и русского языков (рец. на книгу) // Советская тюркология. – 1984. – № 2. – С. 90–91. (в соавторстве с Ф.Ю. Юсуповым).

Телебез төзек һәм матур булсын // Социалистик Татарстан. – 1985. – октябрь.

Старотатарская деловая письменность и историческая диалектология // Проблемы диалектологии и лингвогеографии тюркских языков. – Уфа, 1986. (в соавторстве).

Юсупов Ф.Ю. Неличные формы глагола в диалектах татарского языка (рец. на книгу) // Советская тюркология. – 1986. – № 3. – С. 85–89.

Хәзинәдә ниләр бар? // Казан утлары. – 1987. – № 6. – Б. 145–150.

Татароязычные грамоты XVII–XVIII вв. // Истоки татарского литературного языка. – Казань, 1988. – С. 57–72.

Татароязычные юридические документы XVIII в. // Истоки татарского литературного языка. – Казань, 1988. – С. 20–27. (в соавторстве с И.А. Гилязовым).

Старотатарская деловая писменность и ареалы ее распространения // Тюркология-88. – Фрунзе: Илим, 1988 (тезисы доклада).

Тукай телен киләчәк буыннарга җиткерик // Социалистик Татарстан. – 1989. – апрель.

Любовь к родному слову // Вечерняя Казань. – 1989. – сентябрь.

Тумашева Д.Г. Татарский глагол: опыт функционально-семантического исследования грамматических категорий (рец. на книгу) // Советская тюркология. – 1989. – № 2. – С. 110–111. (в соавторстве с Д.М. Насиловым).

Язык деловой письменности и его место в функциональной парадигме татарского языка XVII–XVIII вв. // Старотатарский литературный язык: исследования и тексты. – Казань, 1991. – С. 60–80.

Язык татароязычных дипломатических актов, отражающих русско-иранские отношения // Некоторые итоги и задачи изучения татарского литературного языка. – Казань, 1992. – С. 67–85.

О специфике грамматической природы причастий в татарском языке // Модели национальных языков. – Казань: Фән, 1996. – С. 144–147.

Академик, укытучы, остаз // Мәдәни җомга – 1996. – 18 окт. – Б. 12.

Сүзем – остаз турында [академик, профессор Диләрә Тумашева турында] // Мирас. – 1996. – № 12. – Б. 77–84.

Нугай бәге Иштирәкнең хаты // Мирас. – 1997. – № 1. – Б. 137–141.

Тукай шигъриятендә әдәби тел яңарышы // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – С. 254–258.

Профессор Н.Ф. Катанов и изучение истории тюркских языков // Катановские чтения, 1998. – С. 91–94.

Авылдаш, остаз, академик // Академик Мирфатыйх Зәкиев. 70-еллыгына. – М.: Инсан, 1998. – Б. 164–171.

Төрки-татар тарихының яңа сәхифәләре // Академик Мирфатыйх Зәкиев. 70 еллыгына. – Казань: Инсан, 1998 (Х.Ш. Мәхмүтов, Н.Ш. Хисамов, Ф.И. Урманче белән берлектә). – Б. 367–375.

Кардәшләрнең ачык күңеле // Заман (Татарстан). – 1998.

Татар теленә тәрҗемә итүнең кайбер грамматик үзенчәлекләре // Мәгариф. – 1998. – № 5. – Б. 24–26.

Rusyanin Doğu siyasetinde Tatatarca Diplomatik Yazişmalar // XIII Türk tarih kongresi. Bildiri özetleri. Ankara, 1999.

Традицияләрне ишәйтеп ... // Татар теле, әдәбияты, тарихы, үткәне һәм бүгенгесе. – Казан, 2000.

История татарского языка как государственного // Народы России и Татарстана: возрождение и развитие. – Альметьевск, 2000 (тезисы). – С. 22–26.

История татарского языка как государственного // Татарское возрождение. Эпоха и личность. – Казань: Фән, 2000. – С. 340–344.

Иске татар әдәби телендә угызчалык // Dördüncü uluslar arasi türk dil kurultaye. Ankara, 2000.

Роль типологических исследований по истории литературных языков для изучения функционирования старотатарской деловой письменности // Татар теле, әдәбияты, тарихы – үткәне һәм бүгенгесе. – Казан, 2000.

О причинах исторических изменений гласных в татарском языке // Бодуэновские чтения: Бодуэн де Куртенэ и современная лингвистика: Междунар. науч. конф. (Казань, 11–13 дек. 2001 г.): Труды и материалы: в 2 т. / под общ. ред. К.Р. Галиуллина, Г.А. Николаева. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2001. – Т. 1. – С. 117–118.

Остаз [Академик Диләрә Тумашевага – 75 яшь] // Ватаным Татарстан. – 2001. – 20 июль.

Илчеләр татарча сөйләшкән // Татарстан. – 2001. – № 1. – Б. 44–46.

О влиянии финно-угорского субстрата в исторических изменениях системы вокализма татарского языка // Симпозиум «Языковые контакты Поволжья». – Турку (Финляндия), 2001. (тезисы доклада).

Татароязычные документы в русско-иранских отношениях (конец XVII – начало XVIII в.) // Россия и Иран. Иранистика в Татарстане. – М., 2001. – С. 201–205.

Путевые записки – рапорт Абдулнасыйра Субханкулова о поездке в Бухару (начало XIX в.) // Фәнни язмалар – 2001. – Казань: Школа, 2002. – С. 324–330.

Путь к новым открытиям (Диляра Тумашева) // Казань. – 2001. – № 12.

Яңа ачышлар юлы (Диляра Тумашева) // Казан. – 2001. – № 12. – Б. 52–54.

Истоки и этапы развития татарского литературного языка // Единство татарской нации. – Казань: Фән, 2002. – С. 105–111.

Об исторических изменениях вокализма татарского языка // Ученые заметки Казанского государственного университета. Т. 143. – Казань, 2002. – Б. 78–82.

О роли финно-угорского субстрата в исторических изменениях звукового состава татарского языка // Языковые контакты Поволжья. – Турку (Финляндия). – 2002. – С. 205–209.

Төньяк кардәшләрдә кунакта // Мәдәни җомга. – 2002. – 8 март. – Б. 9.

Иске татар рәсми дипломатия язмаларында борынгы уйгыр әдәби теле традицияләре // Казан дәүләт университеты татар филологиясе һәм тарихы факультеты укытучыларының фәнни язмалары (2002). – Казан: РПФ «Гарт», 2002. – Б. 78–82.

Формирование и функционирование официально-делового стиля в древне- и среднетюркских языках // Взаимодействие Урало-алтайских языков. Язык и культура (материалы международной конференции). – Чебоксары, 2003.

Татарский язык в восточной дипломатии России // Востоковедение. Вып. 1. – Казань, 2003. – С. 15–21.

Татар әдәби теленең тарихи үсеше // Татарский народ после 1552 г.: Потери и приобретения. – Казань, 2003. – С. 227–234.

Әдәби телебезнең кыйммәтле ядкәре // Казан утлары. – 2003. – № 8. – Б. 180–183.

Иҗади эзләнүләр юлыннан // Фәнни Татарстан. – 2003. – № 3–4. – Б. 152–156. (Ф.Ф. Гаффарова белән берлектә).

Татарский язык в восточной дипломатии России // ТУРКОЛОГИЯ. ТУРКІСТАН. – 2003. – № 1. – С. 103–110.

Иске татар язмаларында борынгы уйгыр әдәби теле элементларының чагылышы // Фәнни язмалар. – Казан: Школа, 2003. – Б. 291–296.

Актуальные задачи исследования состава слова в татарском языке в связи с составлением структурно-функционально компьютерной модели татарских морфем // Международный симпозиум «Типология аргументной структуры и синтаксических отношений». – Казань, 2004. – С. 342–344 (тезисы доклада).

Латин хәрефләренә нигезләнгән яңа әлифба // Проблемы развития татарской нации. – Казань: Фән, 2004. – Б. 47–53.

Татар һәм башкорт телләренең лексик байлыгын өйрәнгәндә // Фәнни Татарстан. – 2004. – № 4. – Б. 93–96 (соавтор).

Вакытлы матбугатта тел культурасы мәсьәләләре // Фәнни язмалар – 2004. – Казан: Школа, 2005. – Б. 314–328.

Татарский язык в Восточной дипломатии России // Научный Татарстан. – 2005. – № 1/2. – С. 97–103.

Altin Orda Dönemi tatar edebi dili Kaynaklar ve tarihi gelişme // The golden Hordesits successors. Second international conference. 2005. Istanbul. – С. 43–44.

Диляра Тумашева [О профессоре кафедры татарского языка КГУ, докторе филологических наук] // Наше женское счастье. – 2005. – № 1 (Янв.). – С.1–3.

Көндәлек матбугатта тел культурасы // Мәдәни җомга. – 2005. – 18, 25 март; 1 апр. (№ 11–13). – Б. 17.

Вакытлы матбугатта тел культурасы мәсьләләре // Фәнни язмалар. – 2004. – 2005. – Б. 314–328.

Исторические судьбы татарского языка // Казанский университет. – 2005. – № 8 (Авг.). – С. 6–7.

Күпкырлы галим [КГУ профессоры, тарихчы галим, академик М. Госманов турында] // Источники и исследования по истории татарского народа: Материалы к учебным курсам в честь юбилея акад. – 2006. – Б. 20–26.

Татар телендә килеш категориясен өйрәнүгә карата // Сохранение и развитие родных языков в условиях многонационального государства: проблемы и перспективы (Международная научно-практическая конференция. 23–24 июня 2006 г.). – Казань, 2006. – Б. 176–180.

Старотатарская деловая письменность XVII–XVIII вв. Истоки и специфика функционирования // Ученые записки КГУ. Т. 148, серия гуманитарных наук, кн. 2. – Казань, 2006. – С. 164–170.

Почему по-русски Кул Гали? // Звезда Поволжья. – 2006. – 3–9 августа.

Бар рухы белән фәнгә хезмәттә (Профессор А. Шәйхулловның фәнни эшчәнлеге хакында) // Мәдәни җомга. – 2006. – 25 авг. – Б. 13.

Һәрбер шивә тарих сөйли [Күренекле тел галиме, диалектолог Дария Рамазанова турында] // Мәдәни җомга. – 2008. – 12 сент. – Б. 14.

История щелевых согласных ч и җ в татарском языке // Тюркологические исследования. – 2012. – № 3. – Б. 103–109.

Мәгълүмат чараларының теле // Мәгърифәт. – 2012. – 9 ноябрь (№ 45). – Б. 3.

Туган тел һәм милләт язмышы // TATARICA. – 2013. – № 1. – Б. 28–34.

Ана теле һәм милли матбугат // Мәдәни җомга. – 2014. – 3 окт. – Б. 14.

**в) дәреслекләр, методик әсбаплар, фәнни-методик мәкаләләр**

Татар теле морфологиясеннән күнегүләр җыентыгы. – Казан: КДУның офсет лаб., 1973. – 53 б.

Татар теле фонетикасына өйрәтүдә алгоритмнардан файдалану // Вопросы обучения татарскому языку. – Казань, 1975. (К.Л. Биктагиров белән берлектә).

4 нче класста татар теле дәресләре (укытучылар өчен методик кулланма). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. (соавтор).

Хәзерге татар әдәби теле. Морфология. (Студентлар өчен методик кулланма.). – Казан: КДУның офсет лаб., 1981.

Хәзерге татар теле. Морфология (студентлар өчен методик әсбап). – Казан: КДУның офсет лаб., 1981.

Хәзерге татар теле фонетикасы. Студентлар өчен лекцияләр һәм методик күрсәтмәләр. – Казан: КДУның офсет лаб., 1981.

Татар теле дәресләре // Казан утлары. – 1989. – № 7.

Татар теле дәресләре // Казан утлары. – 1989. – № 8.

Татар теле дәресләре // Казан утлары. – 1989. – № 9.

Татар теле дәресләре // Казан утлары. – 1989. – № 10.

Татар теле дөресләре // Казан утлары. – 1989. – № 11.

Татар теле дәресләре // Казан утлары. – 1989. – № 12.

Татар теле дәресләре // Казан утлары. – 1990. – № 1.

Татар теле дәресләре // Казан утлары. – 1990. – № 2.

Татар теле дәресләре // Казан утлары. – 1990. – № 3.

Татар теле дәресләре // Казан утлары. – 1990. – № 4.

Татар теле дәресләре // Казан утлары. – 1990. – № 5.

Туган тел китабы. 3 нче класс өчен дәреслек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991 (соавтор).

Татар теле. 3 нче сыйныф. Рус мәктәпләрендә укучы татар балалары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 1994 (соавтор).

Татар теле. 3 нче сыйныф. – Казан: Мәгариф, 1998 (соавтор).

Туган тел. 3 нче сыйныф. Рус мәктәпләре өчен. – Казан: Мәгариф, 1999 (соавтор).

Татар теле. 3 нче сыйныф. Рус мәктәпләре өчен. – Казан: Мәгариф, 2003 (соавтор).

Татар теле өйрәнә нәниләр. Балалар бакчалары тәрбиячеләренә кулланма. – Казан: Мәгариф, 1994. (Р.А. Борһанова белән берлектә).

Татар теле өйрәнә нәниләр. Балалар бакчасы тәрбиячеләренә кулланма.Тулыландырылган икенче басма. – Казан: Мәгариф, 2005.

Морфология һәм тел культурасы // Мәгариф. – 1997. – № 1. – Б. 17–18.

Татар теле морфологиясе: югары уку йорты студентлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2006. – 335 б.

Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе: уку-укыту кулланмасы. – Казан: Казан университеты, 2010. – 126 б. (Г.Р. Галиуллина, М.Х. Әнвәрова, А.Ә. Гафурова белән берлектә)

Татар теле морфологиясе: югары уку йорты студентлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2015. – 334 б.

Татар теленең тарихи грамматикасы (программа).

Төрки тел белеменә кереш (программа).

Язма истәлекләренең текстологиясе һәм тел үзенчәлекләре (мәктәп программасы).

**г) аның турында**

Тел хасияте кылдан нечкә [КДУ профессоры, филология фәннәре докторы Фәһимә Хисамова белән әңгәмә] // Ватаным Татарстан. – 2006. – 1 дек.

Ир-баш, хатын муенмы? [икесе дә филология фәннәре докторы, профессорлар Фәһимә һәм Нурмөхәммәт Хисамовлар белән әңгәмә] / Әңгәмәдәш Р. Рәхмәтуллина // Шәһри Казан. – 2009. – 6 февр.

Казань может стать центром тюркологии / беседовал А. Ахунов // Татарстан. – 2006. – № 12. – С.52–53.

Мин дөньяга ике тапкыр тудым [Казан дәүләт ун-ты профессоры, филология фәннәре докторы, Татарстанның атказанган укытучысы белән әңгәмә] / әңгәмәдәш Ф. Җамалетдинова // Сөембикә. – 2006. – № 12. – Б. 34–35.

Язмышыма әверелде туган телгә мәхәббәтем [КДУ профессоры, тел галиме, филология фәннәре докторы белән әңгәмә] / әңгәмәдәш А. Ахунов // Татарстан. – 2006. – № 12. – Б. 52–53.

Галимнәрсез тел ул – үксез, ятим бала кебек... [КФУ профессоры, филология фәннәре докторы Ф. Хисамова тур.] // Мәгърифәт. – 2013. – 2 август (№ 31); 9 август (№ 32). – Б. 5.

## ШИГЪРИ КОТЛАУЛАР

*Роберт Миңнуллин*

***Бар белгәне – Кол Гали***

*Филология фәннәре докторы,*
*профессор Нурмөхәммәт Хисамовка*

Нурмөхәммәт Хисамовның
Бар белгәне – Кол Гали.
Үзе дә, Кол Гали кебек,
Шәп гамәлләр кылгалый.

Кайчагында кандидатлык,
Докторлык яклаштыра.
Кайчакта шагыйрьләрне дә
Гәзиттә макташтыра.

Моннан соң да язачак ул,
Чәчәчәк ул, урачак.
Минем хакта да бер язса,
Ул классик булачак!

Ул юбилей уздыргалый –
Ун елга бер булса да.
Ә үзе аю егарлык...
Алтмыш яше тулса да.

Ул шәп кенә шигырьләр дә,
Җырлар да языштыра.
Ә үзе аракы эчми...
Шулай да салыштыра.

Башкалар ныклап эчкәндә
Чак кына кабыштыра.
Юбилей дип, капкаларга
Сәбәпләр табыштыра.

Иҗтимагый үзәккә дә
Ул кайчак йөрештерә.
Мине яклап, кем беләндер
Сүзгә дә керештерә.

Нурмөхәммәт Хисамовка
Барсын да биргән Ходай.
Ул бүген безнең арада
Иң чибәр татар бугай.

Татар менә шундый, диеп,
Шаккатырып дөньяны,
Экспонат итеп кенә
Йөртер идем мин аны.

Ул – шәп галим,
Ул – шәп шагыйрь,
Ул – шәп кеше, кыскасы!
Мең яшәсен Нурмөхәммәт
Һәм дә «Йосыф кыйссасы!»

*1997*

*Газинур Морат*

## ***Педант***

*Н.Х.*

Баш вәзирдәй вәкарь белән сөйләр,
Вәкарьләнеп сөйләр чак кына.
Чин теледәй безгә читтер дә ул,
Чин теледәй безгә якын да.

Һәрбер сүзе кысаланган булыр,
Ә кысасы булыр... алтыннан.
Латин теле кебек олпат та ул,
Латин теле кебек салкын да.

Алтын кысалы шул сүзе белән
Кертмәк булыр безне ул игә.
Ана теле кебек газиз дә ул,
Ана теле кебек гади дә...

*Нурмөхәммәт Хисамов*

### ***Мин эзләдем әллә кайлардан...***

Мин эзләдем әллә кайлардан,
Йолдызлардан аны, айлардан,
Романтик хыял, җырлардан,
Ерак-ерак килер еллардан.
Ә йөргәнбез үзебез янәшә,
Бәхәсләшә, укый, көрәшә,
Бергә тездән сазлар кичкәнбез,
Чирәм җирләр суын эчкәнбез,
Сагынганбыз туган якларны,
Гөрләп бергә укыр чакларны.
Җиргә кайтты хыял йолдыздан,
Мин дустымны таптым шул кызда.
Якын иттек ерак елларны,
Уртак иттек барыр юлларны.

*1962*

### ***Саубуллашу***

*Аспирантурага китү сәбәпле һәм аннары*
*Казанда фатир көтеп, байтак еллар гаилә*
*белән аерым торырга туры килде.*
*Әлеге шигырьдә шул хәлләр чагыла.*

Юллар мине тагын Одиссейдәй
Алып китә синнән еракка.
Сау бул, сау бул, минем Пенелопам,
Күзләреңне, зинһар, чылатма.
Юлларымны, беләм, җиңел булмас,
Кая илтер мине дулкыннар?
Кайтмасамчы сиңа Пер-Гюнт сыман
Көймәләрем йоткач упкыннар.

*1982*

*Буа районы Ташкичү урта мәктәбе укытучысы,*
*Татар филологиясе һәм тарихы факультетының*
*элекке студенты Гөлнур Айзатуллова*

***Хөрмәтле мөгаллимәбез, остазыбыз***
***Фәһимә апага җан йөрәктән чыккан энҗеләр***

Борынгыда халкым
Ничек язган?
Гасырларда ничек
Үзгәргән?
Халкым тарихыннан
Кайтавазлар
Кайта безгә нинди сүзләрдән?

Нинди хәзинәләр табылмыйча,
Ачылмыйча калган бу көндә?
Мөхәммәдъяр, Тукай,
Дәрдемәндләр
Ничек яши бүген бу телдә?...

Кол Галиләр нинди энҗеләрдән
Муенсалап тезгән шигырьләр?
Татар теле
Ничек үзгәргән лә,
Уза барган саен гомерләр?...

Ачасыз күп серен
Телләр дигән
Сихри мәгарәнең, дөньяның.
Тел байлыгы –
Йолдызлы күк сыман,
Тулган ае бугай Сез аның!

*1996*

*Гомәр Саттар-Мулилле*

***Фәһимәгә***
*(Туган көнең илә)*

И Фәһимә, туган көнең җитте бүген,
Җитмеш яшькә, нәкъ җитмешкә җиттең бүген,
Еллар буйлап яшьлегеңә киттең бүген,
Тәүге ярны табып сурып үптең бүген.
Тагын ныграк җитдиләнеп киттең бүген.

Чакырмыйча, мәҗлесләр дә иттең бүген.
Матурланып һәм яшәреп киттең бүген,
Бүген аштың күкләр аша гарешләргә,
Якыннарның авызы тиде бәлешләргә.

Туган көннәр бер-бер артлы килә тора,
Гомер дигән нәрсә шулай үтә тора,
Дөнья үзе мәшәкатьтән, эштән тора,
Яраган ота, ярамаган оттыра.

Җитмеш яшьтә бер мизгелдә елмаерга
Күпме бирә адәми зат көчен менә,
Алтыннарга бәрабәрен бу мизгелнең
Яшьлек үткән, җитмеш җиткән үзе белә.
Җитсә җитсен, җитсен әйдә җитмеше дә,
Җиткән җитмеш җитсен генә хәйре беләң.

*2006*

*Чаллы шәһәренең*
*татар теле мөгаллимнәре*

***Хөрмәтле Фәһимә Миргалиевна!!!***

Кара көздә тәүге кабат
Чаллыга атладыгыз.
Килдегез дә кунак булып,
Тик кенә ятмадыгыз.

Морфологиядән безгә
Яңалык өләштегез.
Шәкертләрегезне күреп,
Дусларча сөйләштегез.

Әллә язмыш, әллә мәктәп
Картайткан күбебезне.
Тик шулай да Сезнең хакта
Әйтеп булмый ул сүзне.

Сез һаман да күркәм әле,
Һаман шулай шатлыкта.
Яшьләр белән эшләгәнгә,
Кача, ахры, картлык та.

Рәхмәт сезгә, бу көннәрдә
Булдык без шәкерт чакта.
Ел да шулай вакыт табып
Килегез безнең якка.
Без көтәрбез кунакка.
*2001*

ЭЧТӘЛЕК

Хәтер сагында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3

**Нурмөхәммәт Хисамов турында замандашлары**

*Ф. Галимуллин.* Бөек элгәрләр илчесе . . . . . . . . . . . . . . . . 11
*И. Таһиров.* Нурмөхәммәт Хисамов . . . . . . . . . . . . . . . . 17
*Г. Ахунов.* Галимнең ачышлары . . . . . . . . . . . . . . . . 20
*Х. Мәхмүтов.* Олы юл башында . . . . . . . . . . . . . . . . 26
*Х. Якупов.* О Нурмухаммете Хисамове . . . . . . . . . . . . . . 33
*Р. Харис.* Төрки йосыфнамәнең чишмә башы . . . . . . . . . . 34
*К.А. Валиев.* Нурмухаммету Хисамову 70 лет . . . . . . . . . . 40
*Р. Вәлиев.* Очар өчен ике канат кирәк . . . . . . . . . . . . . 41
*Д.М. Исхаков.* Төгәл фикерләүче һәм төз йөрүче . . . . . . . . . 43
*Г. Гыйльманов.* Җан ихтыяҗы . . . . . . . . . . . . . . . . 45
*А.М. Ахунов.* Ученый, наставник, человек . . . . . . . . . . . . 55
*А.Х. Садекова.* Яркий талант и щедрость души . . . . . . . . . 59
Гасырга лаек юл нинди? (*Әңгәмәдәш В. Гарифуллин)* . . . . . . 61
*А.М. Шаронов.* Поцелованный ангелом . . . . . . . . . . . . 69
*В.И. Рогачев*. Посол добра и дружбы . . . . . . . . . . . . . 72
*З. Мансуров.* Олуглар дәрәҗәсен рухташлары күтәрә . . . . . 77

**Бер канаты – фән, икенчесе – шигърият**

Татар әдәбиятының ун гасыры . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Кол Гали һәм аның «Кыйссаи Йосыф» дастаны . . . . . . . . 101
Мөбарәк тәсбихнең бер буыны . . . . . . . . . . . . . . . 122
Нинди гамьнәр шагыйрь күңелендә? . . . . . . . . . . . . . 130
Республикамның кайнар көннәре . . . . . . . . . . . . . . 142

**Галимнең библиографиясе** . . . . . . . . . . . . . . . 148

**Фәһимә Хисамова турында замандашлары**

*Г.Ф. Гайнуллина, В.Р. Гафарова.* Галим, Остаз, Шәхес . . . . . 167
*Х. Ширмән*. Тау кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
*Э.А. Грунина*. Ценный вклад в изучение истории тюркских языков . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
*И.А. Гыйләҗев*. Татарның күренекле Галимәсе . . . . . . . . . 182
*И.Б. Бәширова*. Фәһимә – фәһем иясе... . . . . . . . . . . . . . 186
*Д.Б. Рамазанова*. Телебезнең фидакяр галимәсе . . . . . . . . 187
*В.Н. Хисамова.* О моей свекрови . . . . . . . . . . . . . . . . . 189
*В.К. Кельмаков.* Труды по татаристике и тюркологии в творческой деятельности одного отдельно взятого удмуртоведа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
*А.М. Ахунов.* Язык восточной дипломатии . . . . . . . . . . . 198
Галимнәрсез тел ул – үксез, ятим бала кебек... (*Әңгәмәдәш Х. Вәлиәхмәтов*) . . . . . . . . . . . . . . . . 202
Казань может стать центром тюркологии (*Беседовал А. Ахунов*) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 210
Фәһимә Хисамова: Нурмөхәммәт үсендереп тора: Син һаман матур, ди… (*Әңгәмәдәш Г. Закирова*) . . . . . . . . 215

**Телне каләм саклый**

Татар теленең тарихи грамматикасы . . . . . . . . . . . . . . . 220
Татар телендә дәрәҗә категориясе . . . . . . . . . . . . . . . . 234
Остазым Диләрә апа Тумашева . . . . . . . . . . . . . . . . . . 243
Ана теле һәм милли матбугат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 246

**Галимәнең библиографиясе** . . . . . . . . . . . . . . . . . . 256

**Шигъри котлаулар** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 264

**СЛУЖЕНИЕ НАУКЕ**

***К 80-летию Нурмухаммета и Фагимы Хисамовых***

Компьютерная вёрстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.А. Булатова*

Подписано в печать 14.03.2017.
Формат 60×84 $^{1}/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman.
Печать офсетная. Усл. печ. л. 15,8. Уч.-изд. л. 14,9
Тираж 200 экз. Заказ 14.3/17

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20



Н. Хисамовның әнисе Һаҗәр.
Нияз Хисамов сурәте



Әтисе Шаһвәли.
Уллары Айдар Хисамов эше



Фәһимә ханымның әтисе Миргали.
Сталинград сугышында 43 яшендә һәлак була



Әнисе Мәрхәбә.
Уллары Нияз ясаган сурәт



Н. Хисамовның әтисе Шаһвәлигә 22 яшь. Тифлис. 1907



Нурмөхәммәт Хисамовка 17 яшь. 1954



Фәһимә ханымның каенәтисе белән төшкән беренче сурәте. 1958



Себердә Диләрә Тумашева җитәкчелегендәге экспедиция. 1956



Себер татарлары сөйләмен язып алу. 1956



«Яшь сталинчы» газетасы редакциясе каршында Шәрәф Мөдәррис җитәкчелегендә оештырылган әдәби иҗат түгәрәге утырышы



Беренче шигырь китабы басылып чыккач. 1967



Уллары Айваз тугач. 1958



Яшь гаилә уллары Айваз белән. Чүпрәле, 1961.



Фәһимә Хисамова олы улы Айваз белән. Азнакай, 1965



Нурмөхәммәт Хисамов өч улы белән. Азнакай, 1963



Игезәкләр Айдар белән Нияз



Хисамовлар гаиләсе. Сул якта – Н. Хисамовның сеңлесе Мөшфика һәм аның кызы



Игезәк уллары белән Азнакайда



Бертуган апасының улы – республикабызның элекке прокуроры Сәйфихан Нәфиев



Ике кодагый уртак оныклары белән. Берсенең улы, икенчесенең кызы да бергә. Казан



Моркваш ял йортында шигърият турында сөйләшү



Нурмөхәммәт Хисамов бүлмәдәше – мордва кешесе Николай белән Кырымда ял иткәндә. 1965



Финляндиядәге татар галиме профессор Гомәр Таһир белән. 1966



Кол Галинең 800 еллыгына багышланган фәнни конференция. ТӘһТИ, 1983



Яшь азәрбайҗан галиме Вилаят Кулиев белән. Ул соңрак Алиев хөкүмәтендә тышкы эшләр министры була. Хәзер Европа илләренең берсендә илче. 1984 елгы фото



Нурмөхәммәт Хисамов Дәрвишләр бистәсе Мәдәният сараенда әдәби кичә алып бара. Язып утыра Хәсән Туфан. Президиумда утырганнар: Габдрахман Минский, Шәүкәт Галиев, Рәдиф Гаташ



Нурмөхәммәт Хисамов сеңлесе Мөшфика
һәм җәмәгате Фәһимә ханым белән



Дербышка урманында




Әрмән әдәбияты классигы Амаяк Сирас белән әңгәмә. Кисловодск, 1968



Бакый Урманче, Айрат Арсланов, Хәйдәр Бигичев, Сәлам Алишев,
Нил Юзиев, Азат Әхмәдуллин, Марат Илһамов, Нурмөхәммәт Хисамов,
Шәрифҗан Асылгәрәев һәм Алим Шәймәрдәнов фольклорчы галим
Илбарис Надировның юбилей кичәсендә



Мамадышта әдәби атналык. Беренче рәттә (сулдан уңга): Нәби Дәүли, Сибгат Хәким, Мирсәй Әмир; икенче рәттә: район мәдәният бүлеге мөдире, Галимҗан Латыйп, Нури Арслан, Нурмөхәммәт Хисамов, Атилла Расих



Университет тәмамлауның 20 еллыгы. Сабакташлар очрашуы. 1980



Фәһимә ханым килене Венера белән Төмән өлкәсендә экспедициядә



Төньяк Кавказда ял иткәндә



Яшь умартачы әтисе Шаһвәли белән бал ала



«Васильево» шифаханәсендә

Ялтада экскурсиядә





Профессор Хатип Госман студентларга «Йосыф кыйссасы» турында сөйли



Нурмөхәммәт Хисамов беренче оныгы Зөһрә белән ике Арслан арасында.
Сул кырыйда Айрат Арсланов, уң кырыйда Нури Арслан



Олы уллары Айваз, киленнәре Венера



Киленнәре Венера һәм беренче оныклары Зөһрә белән



Зөһрәне иркәләгәндә



Айваз белән Венера һәм аларның кызлары Зөһрә, Ләйлә



Игезәк уллары Нияз белән Айдар Ватан сагында



Фәһимә Миргалиевна студентлар белән



Н. Хисамовның 50 яше. Җәмәгате Фәһимә, килене Венера һәм оныгы Зөһрә белән дуслары арасында



Академик Камил Вәлиев һәм Венера Думаева-Вәлиева
ТӘһСИ директоры белән



Бөек артистларыбыз Фәридә Кудашева һәм Әзһәр Шакиров белән



Үзләренең дачаларында



Нурмөхәммәт Хисамов ике апасы белән туган авылы Мунчәлидә.
Сул якта Зәйнәпбану апасы, уң якта Хәлидә апасы Нәфиева



Фәһимә ханым – кафедра мөдире



Директор үзенең
эш кабинетында



Галимнең 70 яшенә багышланган юбилей кичәсендә
уллары Айдар һәм Нияз белән




Уллары Айдар Хисамов ясаган портретлар



Н. Хисамовка 55 яшь. Улы Нияз эшләгән сурәт. Ленинград. 1982



Улы Айдар ясаган портрет

 

Елмаюдан көннәр яктыра



Әдипләр очрашкач. Сулдан уңга: Нурмөхәммәт Хисамов, Тәлгат Галиуллин, Фоат Галимуллин, Мостай Кәрим



Хуҗиәхмәт Мәхмүтовның 70 яшьлеге. Сулдан: ТФА президенты Мансур Хәсәнев, Венера Мәхмүтова, юбиляр, директор, табынчы Нурмөхәммәт Хисамов һәм профессор Фәһимә Хисамова. 2003



ТӘһСинең халык иҗаты бүлегендә Яңа ел каршылау. 2001



Бөек галим Роберт Нигъмәтуллин белән



Институтның административ идарә коллективы. 2002



Гыйльми
утырыштан
соң



Казан галимнәре Төрек дөньясы тикшеренүләре вакыфы рәисе
Туран Язган янында. Истанбул, 2000



Казандагы төрек консулы Исмаил Хаккы Муса белән. 2005



Татар халкының милли алгарышына багышланган түгәрәк өстәл. Уңнан икенче: профессор Вадим Чурбанов (Мәскәү). 2005



Ренат Харис тантанасы. Беренче рәттә: юбиляр һәм Лилия ханым, Мостай Кәрим, Әгъзам Гобәйдуллин; икенче рәттә: Илдус Тарханов, Нурмөхәммәт Хисамов, Фәһимә Хисамова, Сәйфихан Нәфиев, Фоат Галимуллин




Шагыйрь Равил Бухараев белән. Кол Гали әсәрен Лондонда инглиз телендә чыгаруны оештырган шәхес



Җәйге җылыда



Халык шагыйре Роберт Миңнуллин белән



Төрек консуллыгында кабул кичәсе. Сулдан: Зөфәр Рәмиев,
Хатыйп Миңнегулов, Истанбулдан килгән төрек профессоры
Осман бәй Серткая һәм Нурмөхәммәт Хисамов. 2005



Измирдә халыкара төрки конференциядә. 2000



Халык дипломатиясе миссиясе белән Өфедә. Сулдан уңга:
Фоат Галимуллин, Роберт Миңнуллин, Әмир Юлдашбаев (Башкортстан делегациясе әгъзасы), Индус Таһиров (Татарстан делегациясе җитәкчесе), Җәмил Нигъмәтов, Нурмөхәммәт Хисамов. 2004



Нурмөхәммәт Хисамов дусты һәм хөрмәт иткән шагыйре Разил Вәлиев белән



Президент М.Ш. Шәймиев белән күрешү. 22 апрель, 2003



Фәрит Мөхәммәтшин «Дуслык» ордены тапшыргач. 2009



Нурмөхәммәт Хисамов ТӘһСИ директоры Ким Миңнуллин белән



Юбилейга әзерләнгәндә. Нурмөхәммәт Хисамов Институт галимнәре Ильмир Ямалтдинов, Бәхтияр Миңнуллин, Эльвира Сафина, Олег Хисамов, Рөстәм Галиуллин һәм директор Ким Миңнуллин белән